ISSN 0206—4189


# Казан утлары

8.2002



# YAZUÇILARNIÑ XIV QORILTAYI









*М. Богодвид фотолары*

# Казан утлары
# Qazan utları

2002

8

(958)

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ МИЛЛИ КИТАПХАНӘСЕ
НАЦИОНАЛЬНАЯ БИБЛИОТЕКА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:

***Татарстан хөкүмәте, Татарстан Язучылар берлеге, редакциянең хезмәт коллективы***

*БАШ МӨХӘРРИРЕ*

**Равил Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Харрас Әюпов**
**Зилә Вәлиева**
**Фоат Галимуллин**
**Тәлгат Галиуллин**
**Миркасыйм Госманов**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Флүс Латыйфи**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Салих Маннапов**
**Мирза Мәхмүтов**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатип Миңнегулов**
**Гәрәй Рәхим**
**Факил Сафин**
**Ренат Харис**
**Зиннур Хөснияр**
**Розалина Шаһиева**

---

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Наис Гамбәр, Рәдиф Гаташ, Марат Закир, Камил Кәримов, Марс Шабаев.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Гөлзадә Бәйрәмова, Лилия Гатауллина, Флера Сабирова, Тәслимә Сибгатуллина, Альбина Сибгатуллина, Тәгъзимә Шиһабиева.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Асия Рәхимова** (баш бухгалтер), **Эльвира Камалова.**

---

✉ 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
☎ Баш мөхәррир — 92-38-60.
Баш мөхәррир урынбасары — 92-36-49.
Җаваплы сәркәтип һәм компьютер үзәге — 43-56-12.
Бүлекләр: шигърият, фән, сәнгать — 92-38-61,
чәчмә әсәрләр, хатлар, әдәби тәнкыйть — 92-39-63,
гамәли хезмәткәрләр — 92-39-65.
Исәп-хисап бүлеге — 43-56-12.

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

## *Бу санда*


**ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫНЫҢ XIV КОРЫЛТАЕ**

Президент Минтимер ШӘЙМИЕВ. Әдип каләме хаклыкка хезмәт итсен ..... 5
Фоат ГАЛИМУЛЛИН. Нәтиҗәләр һәм бурычлар ..... 10
«Казан утлары» яктырак балкыр! *(1999-2002 елларга хисап)* ..... 121
Вахит ИМАМОВ. Күңелне борчыган уйлар ..... 124
Разим ВӘЛИУЛЛИН. Нефть төбәгендә әдәби мохит ..... 127
Мансур ВӘЛИ. Тәнкыйтьне җанландыру—уртак бурыч ..... 129
Рафис КОРБАН. Балалар китабына мөнәсәбәт ..... 131

**ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Роберт ӘХМӘТҖАН. Дастаннар җире. *Шигырьләр* ..... 17
Рауль МИРХӘЙДӘРОВ. Һәрнәрсәгә—акчалата. *Роман* ..... 22
Флера ТАРХАНОВА. Исемебездә—сер, көч бар... *Шигырьләр* ..... 74
Рөстәм АКЪЕГЕТ. Язмыш Атлантидасы. *Шигырьләр* ..... 78
Нәҗибә САФИНА. Җырны—җырга, серне—сергә... *Шигырьләр* ..... 91

**ПУБЛИЦИСТИКА**

Индус ТАҺИРОВ. Татарлар—мәңгелек халык ..... 95
Флюра ЗЫЯТДИНОВА. Россия федерализмының яңа мәсьәләләре ..... 105
Фирдәүс ГАРИПОВА. Сан алудагы сырт санау ..... 112

**МИЛЛӘТТӘШЛӘРЕБЕЗ ЧИТ ИЛЛӘРДӘ**

Илбарис НАДИРОВ. Төркиядәге ике милләттәшем ..... 134

**ТАРИХ**

Фатих УРМАНЧЕ. Мең ярым ел элек ..... 143
Корьән татар телендә ..... 153

**ӘДӘБИ МИРАС**

Зәет МӘҖИТОВ. Рәнҗемәгез. *Шигырьләр* ..... 160

**ЮМОР-САТИРА**

Әнәс ХӘСӘНОВ. Шаян хикәяләр ..... 165
Морад ДУСАЙ. Алай түгел, болай ул ..... 173

**ХӘТЕР**

Җәлилче Рәхим Саттар *(Шагыйрьнең тууына 90 ел)* ..... 176
Тәлгат НӘҖМИЕВ. Үзи авылының Газизҗаны ..... 182
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан ..... 189

## В НАШЕМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

«XIV съезд писателей Татарстана»: выступления Президента М. ШАЙМИЕВА, Ф. ГАЛИМУЛЛИНА, В. ИМАМОВА, Р. ВАЛИУЛЛИНА, М. ВАЛИЕВА, Р. КУРБАН.
«Проза и поэзия»: Р. МИР-ХАЙДАРОВ. Роман «За все—наличными» *(продолжение)*, рассказ Равиля ВАЛИЕВА «Пять патронов»; стихи Роб. АХМЕТЗЯНОВА, Ф. ТАРХАНОВОЙ, Р. АКЪЕГЕТ, Н. САФИНОЙ.
«Публицистика»: статьи И. ТАГИРОВА «Татары—вечный народ», Ф. ЗИЯТДИНОВОЙ «Новые вопросы Российского федерализма», Ф. ГАРИПОВОЙ «Насущные проблемы в переписи населения»
«Татары за рубежом»: статья И. НАДИРОВА «Соплеменники в Турции».
«История»: статья Ф. УРМАНЧЕ «Полторы тысячи лет тому назад».
Коран на татарском языке.
«Литературное наследие»: З. МАЗИТОВ. Стихи разных лет.
«Юмор-сатира»: рассказы А. ХАСАНОВА, пародии СУЛЕЙМАНА, М. ДУСАЙ
Забавные истории из жизни писателей.
«Память»: «Джалиловец Рахим Саттар», И. САТТАР. «Завещание» и стихи Р. САТТАРА; статья Т. НАЗМИЕВА посвящена к 60-летию Г. Кашапова.
В номере отмечается 70- летие Р. Сверигина.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: День Республики в Казани; композиция карты «Тартария» (1630) Г. Меркатора и триптиха «Татарстан» (1977) Б. Урманче.

## IN OUR ISSUE:

*The magazin edits monthly*

"XIV congress of Tatarstan writers": the speeches of President M. SHAIMIEV, F. GALIMULLIN, V. IMAMOV, R. VALIULLIN, M. VALIEV, R. KURBAN.
"Prose and poetry": R. MIRKHAIDAROV'S novel «Cash for anything» *(continuation)*, Ravil VALIEV'S story "Five cartridges"; the verses of Rob. AKHMETZIANOV, F. TARKHANOVA, R. AK'EGET, N. SAFINA.
"Journalism": I. TAGIROV'S article "Tatars are eternal people", F. ZIATDINOVA'S article "New quastions of Russian federalism", F. GARIPOVA'S article. "Problems of Population census".
"Tatars abroad": I. NADIROV'S article "Compatriots at the Turkey".
"History": F. URMANCHE'S article "One thouand and half years ago".
Koran in Tatar language.
"Literary legacy": Z. MAZITOV'S verses of different years.
"Humor and satira": A. KHASANOV'S stories, SULEIMANOV'S parodies. M. DUSAI'S stories from writer life.
"Memory": "Rakhim Sattar from Jalil", I. SATTAR "The will", R. SATTAR'S verses, T. NAZMIEV'S article devoted to 60th anniversary of G. Kashapov.
"Jubilees": 70th anniversary of R. Sverigin
The diary of social and cultural life.

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 19-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянен компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 23.07.2002 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70X108 1/16.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Тиражы 9134. Заказ Б—418
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2002 ел.

*Татарстан язучыларының XIV корылтае*



## Президент Минтимер Шәймиев

# ӘДИП КАЛӘМЕ ХАКЛЫККА ХЕЗМӘТ ИТСЕН

Бүген сез иҗат оешмагыз тарихында XIY корылтайга җыелдыгыз. Соңгы 3 елдагы иҗат, иҗтимагый-сәяси эшчәнлегегезгә йомгак ясыйсыз, киләчәккә планнар, яңа офыклар билгелисез. Татарстан Республикасы Хөкүмәте, Дәүләт Советы һәм шәхсән үз исемемнән сезне корылтай эше башлану белән чын күңелдән котлыйм һәм файдалы фикер алышулар нигезендә аны матур нәтиҗәләр белән йомгакларсыз, дип ышанып калам.

Язучыларның зур җыелышы Татарстан өчен гаять әһәмиятле вакыйга. Безнең республикабыз халкы, гомумән, татар халкы, әдәбиятны ярата, хәзерге заманда да әдәби әсәрләрдән, шигырь-хикәяләрдән үзенә тәм, илһам һәм, әлбәттә, мәгълүмат таба. Күп гасырлар буена әдәбият үзенә күрә мәктәп, тәрбия һәм җан азыгы булып хезмәт итте, алдынгы идеяләрне алга сөреп, тормышның катлаулы сорауларына җаваплар бирә килде. Хәзерге телевизор, кино, күңел ачу, тамаша заллары урынына да хезмәт итте.

Хәзер без яңа чорда яшибез. Заманалар үзгәрде, яшәү шартлары һәм иҗат итү мөмкинлекләре дә башка. Татарстан язучыларының соңгы съездыннан соң без яңа, XXI гасырга аяк бастык. Русиядә һәм Татарстанда да сәяси һәм рухи тормыш бер урында гына тормады. Техника һәм информатизация заманында да без үзебезнең калэм иясләре, акыл ияләре, Татарстан һәм татар әдәбияты белән горурланырга хаклыбыз.

Язучылар корылтаенда катнашу, гомумән, иҗат интеллигенциясе белән очрашу безнең өчен җаваплы һәм үтә дә әһәмиятле эш. Чөнки сезнең әсәрләрегез, уй-фикерләрегез, иҗади халәтегез җәмгыятьнең барометры, дияр идем.

Дәүләт Советына минем быелгы Юлламада без республикада бара торган барлык үзгәртеп коруларның асылын халыкка ачыктан-ачык әйтеп бирдек, дип саныйм, шуңа күрә кабатлап тормыйм.

Безнең өчен хәзерге чорда милли сәясәтебезнең төп принципларын эзлекле төстә гамәлгә ашыру бик мөһим. Бу, беренчедән, Татарстанда яшәүче барлык халыкларның рухи-мәдәни байлыкларын үстерүгә һәрьяклап ярдәм итү. Икенчедән, диннәр арасындагы балансны тәэмин итү.

Мондый сәясәтнең нәтиҗәләре күзгә күренеп тора. Милләтләр арасында татулык, элекке хезмәттәшлек һәм демократик институтларны актив файдалану гына халыкларның интеллектуаль дәрәҗәсен күтәрергә мөмкинлек бирә. Мин моны ни өчен әйтәм?

Иҗат—җанлы эш, чөнки бүгенге көндә моннан 10 ел элек язганча язып булмый. Әсәрләрнең темасы, эчтәлеге генә түгел, язу рәвеше дә үзгәртеп тора. Тормышыбыз гел хәрәкәттә булган кебек, сезнең әсәрләрне дә укучылар һәрвакыт яңача кабул итә. Шулай да, татар әдәбиятына гомер-гомергә хас булган тирән әхлаклылык, сафлык, кешелеклелек үзгәрмичә кала бирә. Икенче төрле әйтсәк, сүз сәнгате буларак, әдәбиятның рухи-әхлакый, тәрбияви әһәмияте әйтеп бетергесез. Шунысы кыйммәт: безнең каләм осталарыбыз бу кыйблага һәрчак тугрылыклы булды һәм булырлар да.

Халкыбызның хис-кичерешләре иң әүвәл сезнең сизгер йөрәкләрегезгә, күңелләрегезгә кагыла. Аннан соң, кайтаваз булып, яңадан халыкка кайта. Шуңа күрә без әдәби әсәрләрне эстетик ләззәт чыганагы гына түгел, тормыш энциклопедиясе дип тә карыйбыз.

Чынбарлыкны күпкырлы, сәнгатьчә чагылдырган әсәр киләчәк буыннарга тормышның соры сурәтен түгел, ә җанлы образын калдыра. Бу исә язучыга зур бурычлар да йөкли. Аларның берсе—халыкка намуслы хезмәт итү. Без ни өчен Габдулла Тукайны бөек шагыйрь, дибез. Туры Тукай дип тә өстибез. Чөнки аның каләме һәрдаим хаклыкка хезмәт иткән, шагыйрь иҗатка изге эш итеп караган. Муса Җәлил дә «Шигъремдәге чынлык—яшәвемнең бөтен мәгънәсе», дигән. Без үз иҗатына әнә шул дәрәҗәдә тугрылыклы булган бик күп осталарыбызны атый алыр идек. Вакыт ягыннан якынрак килсәк, мин Әмирхан ага Еникине аеруча хөрмәт белән искә алам. Ул шушы ике корылтай арасында дөньядан китте, әмма үзе белән бергә затлылыгын, олпатлылыгын алып китмәде. Аның бу сыйфатлары безнең белән калды. Гариф Ахунов, Аяз Гыйләҗевләр турында да шуны әйтергә мөмкин. Алар бу сыйфатларны шул ук Тукайлардан, Исхакыйлардан, Җәлилләрдән, Галимҗан Ибраһимовлардан, Хәсән Туфаннардан, Сибгат Хәкимнәрдән мирас итеп алдылар. Бүгенге аксакалларыбыз Нурихан Фәттах, Илдар Юзеев, Шәүкәт Галиев, Гамил Афзал, Мөсәгыйт Хәбибуллин, Әхсән Баяновлар шундый ук затлы бер буын тәшкил итәләр. Алар бүгенге әдәбиятнең йөзен билгелиләр.

Биредә өлкән буыннар белән яшьләр арасында традицияләр күчеше турында да әйтергә кирәк. Иҗат кешесе, тизрәк өлгерергә, башкаларга остаз булып җитешергә тиеш. Шәхес булмаган җирдә чын талантның булуы да шикле. Бәхеткә, безнең әдәбият—чын талантлар әдәбияты. Лена Шагыйрьҗан, Ренат Харис, Равил Фәйзуллин, Роберт Әхмәтҗанов, Роберт Миңнуллин, Разил Вәлиев кебек шагыйрьләр, Нәбирә Гыйматдинова, Флүс Латыйфи, Факил Сафин, Рафаэль Сибат, Якуб Зәнкиев кебек прозаиклар, Туфан Миңнуллин, Зөлфәт Хәким, Мансур Гыйләҗев кебек драматурглар белән теләсә кайсы әдәбият горурлана алыр иде. Алар бүген әдәбиятта эстафетаны үз кулларына ала киләләр. Аларны һәр жанрда яңа талантлар куып килә. Сүз уңаеннан шуны да әйтим: мондый әдипләребез киләчәктә безнең тарафтан зуррак игътибарга лаек, дип уйлыйм.

Туфан Миңнуллинның «Эзләдем, бәгърем, сине», Зөлфәт Хәкимнең «Чапты атым Казанга», Мансур Гыйләҗевнең «Баскетболист» дигән спектакльләре миндә тирән тәэсир калдырды. Аларда тормыш та, тирән фәлсәфә дә чагылыш таба. Бу спектакльләр нигездә тормыш турында, кешеләр язмышы турында зур борчылу уята. Шагыйрь Ренат Харис либреттосына композитор Леонид Любовский язган «Кыйссаи Йосыф» балеты да безнең сәнгатебездә гаҗәеп күренекле вакыйга булды.

Күптән түгел Казанда зур уңыш белән төрки халыклар театрларының

YII халыкара «Нәүрүз» фестивале булып узды. Фестивальгә чакырылган тәнкыйтьчеләр һәм театр белгечләре татар драматургиясе үсешен уңай бәяләделәр. Алар билгеләп үткәнчә, күп кенә халыкларның милли драматургиясе кризис кичергән бер вакытта татар драматургиясе тискәре йогынтыларга бирешмәде.

Сезнең идарәнең хупларга лаеклы бер эше турында әйтәсем килә: республикада яшь талантлар да онытылмый. Алар өчен семинар уздырып, идарә яхшы эшләгән. Анда 30дан артык йөгерек каләмле егет-кыз катнашкан. Инде аларны карап-тәрбияләп үстерергә кирәк. Шул ук вакытта алар артыннан килүче яшь үсентеләрне абайлап тору да зарур. Сүз дә юк, язучыны үстерүнең иң ышанычлы юлы—аларның әсәрләрен дөньяга чыгару. Әле шушы көннәрдә миңа Татарстан Язучылар берлегенең ике корылтай арасындагы эшчәнлеген гәүдәләндергән хисап китабын карарга туры килде. Аннан күренгәнчә, 3 елда 380гә якын китап чыккан. Шуның 212се дәүләт нәшриятларында. Язучыларыбызның яхшы китапларын бастырып чыгару өчен—һәм шунысын да әйтим—аларның башка ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен Татарстан Хөкүмәте шактый зур эш башкара. Татар хикәяләре антологиясе, Миргазиян Юныс, Рәфкать Кәрами, Лилия Газизова һәм башкаларның китаплары уйга гына түгел, күңелгә дә азык бирә.

Әмма шул ук вакытта сай фикерле әсәрләр дә байтак. Яхшы әсәрләрне укучыга җиткерүдә дә эшлисе эшләр бик күп. Без еш кына рухи хәзинәләребезне күрсәтеп бирә алмыйбыз. Моның өчен радиода, бигрәк тә телевидениедә соңгы вакытта туган зур мөмкинлекләр тулысынча файдаланылмый. Тәнкыйть тә ныклап җанланып китми әле.

Ел саен була торган Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләгене бирү кампаниясен генә алыйк. Каләмдәшләрегезнең әсәрләрен бүләккә тәкъдим итәсез, ә ни өчен моны эшләвегезне матбугат чараларында ныклап аңлатмыйсыз. Югыйсә, бу—әдәбиятны пропагандалау өчен никадәр җайлы форсат бит. Сез бүләкләрне кемгә бирү мәсьәләсенә караган бәхәсләрне еш кына сәхнә артында куертасыз. Акыллы, тәпле фикерләрегез белән халык алдында чыгарга кирәк ләбаса.

Халык шагыйре, халык язучысы дигән мактаулы исемнәр кыл иләктән үткәреп бирелә. Ә инде язучы бу бүләккә лаек булган икән, аңа иҗат мөмкинлекләре тагын да яхшыртылырга тиеш. Без күптән түгел бу хакта киңәш тоттык, мин, бу мәсьәлә уңышлы чишелер, дип уйлыйм.

Тагын бер мөһим мәсьәлә турында әйтергә кирәк. Ул да булса—мирасыбызны саклау проблемасы. Бездә вафат булган язучыларның әсәрләрен туплау үзагымына куелган. Бу эшне Язучылар берлеге, Г. Ибраһимов исемендәге институт һәм Дәүләт баш архив идарәсе килешеп, бергәләп алып барырга тиешләр. Татарстан Милли музее системасында әдәбият музее төзү турында да уйланырга кирәк. Без Г. Исхакый, Г. Тукай, Х. Туфан, П. Хузангай, М. Мәһдиев һәм башка әдипләр музейларын ачтык. Ш. Камал, М. Җәлил, Е. Боратынский, М. Горький музейлары да эшләп килә. Язучылар берлеге бу өлкәне дә күз уңыннан ычкындырмаска, алар эшендә актив катнашырга тиеш.

Әдәби журналларыбыз да әдәби тормыш сулышын ныграк тоеп, шул ук вакытта талымлырак эш итәргә тиешләр. Бу яктан «Казан утлары» үрнәк булып тора. Аның чыга башлавына 80 ел тулды. Ул—әдәбияттa гына түгел, сәнгатьнең башка төрләрендә дә энциклопедия булырлык басма. 2006 елның февраль саны меңенче сан булачак. Халкыбызның рухи байлыгын, иҗтимагый-сәяси, эстетик фикерен үстереп, фән-мәдәният тарихын барлап-теркәп, журнал сигез дистә ел буена зур эш алып бара. «Татарстан», «Казан», «Идел», «Сөембикә», «Ялкын», «Сабыйга», «Салават күпере» кебек журналлар да әйбәт әдәби әсәрләргә еш мөрәҗәгать итәләр. «Мәйдан» журналының аякка басып китүендә Чаллы шәһәр хакимиятенең башлыгы хуплауга лаек.

Мондый басмаларның халкыбыз өчен кирәклеге бәхәссез.

Журналлар—оператив басмалар. Алар үткәннең рухи һәм фәнни байлыгын, бүгенге иҗат җимешләрен атнасы, ае белән халыкка җиткерү мөмкинлегенә ия. Шулай да аерым басмаларның портфельләрендә сайлап басу өчен кулъязмалар кытлыгы сизелә. Бер сәбәпсез-нисез, күптән билгеле калын-калын романнарны бастырып утыру нинди ихтыяҗ белән аңлатыла? Моны дәүләт акчасын кирәксезгә сарыф итү дип кенә бәяләп була. Язучылар берлеге идарәсе дә биредә үз сүзен әйтергә тиештер.

Безгә әдипләрнең иҗтимагый активлыгын күтәрү турында да ныклап уйланасы бар әле. Сезнең ике корылтай арасында мин чын мәгънәсендә илче булып эшләүче олпат әдипләр—Чыңгыз Айтматов һәм Олҗас Сөләйманов белән очраштым. Бу олы шәхесләр белән аңгәмә кору үзе генә дә никадәр күңел азыгы бирә. Иҗади активлык аларга иҗтимагый активлыкка юл ачкан, ә бу исә талантның колачын киңәйткән. Ул язучыларның үзләреннән алда әсәрләре бара, катлаулы миссияләрен үтәүгә юл ача.

Без үзебезгә үрнәк, эталон итеп кемнәрне куярга тиешбез? Г. Тукай да үзен коеп куйган шагыйрь итеп кенә түгел, ә иҗтимагый эшлекле дип тә исәпләгән. Бу аңа үз чорының бөтен катлаулы күренешләрен колачлау мөмкинлеге биргән. Галимҗан Ибраһимовның киң колачлы әдип һәм җәмәгать эшлеклесе булганын искә төшерик. Бездә хәзер дә ил, халык, тарих, бүгенге, бигрәк тә киләчәк мәсьәләләрен шәхси борчу итеп караган шәхесләр-язучылар бар. Ләкин аларның күбрәк, җитдирәк, җаваплырак булуын күрәсе килә. Мин бүгенге корылтай әнә шундый югары таләпләр югарылыгында узар, әдәби иҗатның һәм иҗтимагый эшчәнлекнең актуаль юнәлешләрен билгеләр, дип ышанам.

Күптән түгел без Конституциябезгә төзәтмәләр керттек. Төп Законыбызда Татарстанның нигезләрен саклап калдык. Бу җиңел булмады. Аны яклау өчен безгә бүген һәм киләчәктә тагын да күбрәк көрәшергә туры киләчәк. Шикләнмәгез, без яңа шартларда Татарстан мәнфәгатьләрен яклап, үз юлыбыздан барачакбыз. Федераль үзәк белән дә бу яңа шартларда уртак тел табу өчен күпкырлы эшләр башкарыла.

Сез яңартылган Конституциягә бик мөһим өстәмә кертелгәнен беләсез. Ул—Татарстанның һәм татар халкының үзбилгеләнү хокукы турында. Бу яңалык иҗат, мәдәният, сәнгать, мәгариф өлкәсенә зур тәэсир ясаячак. Чит төбәкләрдә яшәүче татарларның ихтыяҗлары да Конституциябездә чагылыш тапты. Чыннан да, Татарстан дип аталабыз икән, димәк, безгә рәсми рәвештә татар халкының бөтенлеген, үсешен тәэмин итү, татар халкына таяну табигый хәл.

Татар мәдәнияте, татар әдәбияты бервакытта да бер төбәк, бер республика чикләрендә генә яшәмәде. Талантлы язучылар, җырчылар, артистлар, рәссамнар һәрвакыт төрле төбәкләрдән Казанга килеп, республикабызга хезмәт итте. Республиканың иҗат әһелләре дә читтә яшәүче халкыбызга мәдәни хезмәт күрсәтте. Хәзер бу агымны көчәйтү бик зарур. Әмма татар халкына таянмасак, аның рухи ихтыяҗларын күз алдында тотмасак, Татарстанның үз йөзе сакланмас иде.

Татар халкы яшәгән барлык төбәкләр—сезнең иҗат лабораториясе. Милләтебезне бербөтен итеп карау яңа мөмкинлекләр ача, бер үк вакытта яңа бурычлар куя. Русиянең башка төбәкләре белән хезмәттәшлекне киңәйтүне таләп итә. Татарстанның Мәгариф, Мәдәният министрлыклары, мәгълүмат чаралары хәзер эшчәнлек географиясен киңәйтәләр.

Башкалабызның 1000 еллыгына, быел август ахырында булачак III Бөтендөнья татар конгрессына әзерлек, октябрьдә үтәчәк халык санын алу татар милләтен барлауны, аның хәлен белүне, бердәмлеген саклауны таләп итә. Хәзерге вакытта без бу юнәлештә эзлекле, зур

күләмле җитди эшләр башкарабыз. Әлеге мөһим эштән сез дә читтә калмассыз, дип ышанам.

Яңа гасырда галимнәр, язучылар алдында зур бурычлар тора. Тарихны тулыландыру, татар халкы язмышын дөрес чагылдыруда әле эшлисе эшләр бик күп. Яшь буынның милли үзаңын формалаштыру, заманча идеяләрне, кешелек кыйммәтләрен, алдынгы илләр тәҗрибәсен үзләштерү—барыбызның да уртак эше.

Большой вклад в нравственное воспитание населения вносят русскоязычные писатели. Творческая мастерская по русской литературе объединяет около 40 литераторов. Сегодня активно работают литераторы Владимир Корчагин, Ахат Мушинский, Геннадий Паушкин, Нонна Орешина, Евгений Сухов, Сергей Малышев, Ольга Левадная и многие другие.

Одним их главных направлений в работе мастерской является работа с молодежью, начинающими литераторами. Особенно хочется отметить творческое объединение «Белая ворона», созданное поэтессой, членом Союза писателей Татарстана Наилей Ахуновой. Это сравнительно небольшая группа людей, но работают они ярко, увлеченно, с энтузиазмом.

Новому правлению хочется пожелать, чтобы оно приложило все возможные усилия для пропаганды творчества наших литераторов далеко за пределами Татарстана, чтобы нашу литературу знали и могли оценить во многих странах. Это касается и татарской литературы и произведений, созданных на русском языке.

Язучылар берлеге—барлык иҗат берлекләре эшчәнлегендә, халкыбызның рухи тормышында үзәктә торучы иҗат оешмасы. Аның эшчәнлеге гаять күпкырлы. Ул һәр язучының тормыш-көнкүреше турында кайгыртудан алып татар халкын һәм аның әдәбиятын дөнья күләменә күтәрүгә кадәр киң колачлы эш итә. Өлгергән мәсьәләләрне тиешле әзерлек белән рәсми органнар алдында кую да аның җитәкчелегеннән зур активлык, җитлеккәнлек һәм интеллект сорый. Берлекнең хәзерге рәисе Фоат Галимуллин бу күпкырлы сыйфатларга ия дип саныйм. Зыялыларның да зыялысы булган язучылар, башка мәсьәләләрдәге кебек, бүгенге катлаулы чорда төп кыйбланы билгеләүдә, идарәне һәм аның җитәкчесен сайлауда да ялгышмаслар дип уйлыйм. Сезгә саулык-сәламәтлек, шәхси бәхет һәм иҗади уңышлар телим.



**Фоат Галимуллин,**

*Татарстан Язучылар берлеге рәисе*

# НӘТИҖӘЛӘР ҺӘМ БУРЫЧЛАР

## ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕНЕҢ XIII–XIV КОРЫЛТАЙЛАР АРАСЫНДАГЫ (1999–2002) ЭШЧӘНЛЕГЕ ТУРЫНДА ХИСАП ДОКЛАДЫ

Хөрмәтле Президентыбыз Минтимер Шәрипович!
Хөрмәтле каләмдәшләр!
Хөрмәтле кунаклар, әдәбият сөючеләр!

Вакыт агышының тизлегенә хәйран калырсың. 1999 елның 23 июлендә тәмамланган XIII корылтай әле кичә генә булган кебек! Баксаң, ике ел да ун ай вакыт узган икән. Без инде бүген, Сезнең каршыга басып, шушы 34 ай вакыт эчендә эшләгәннәребезгә хисап бирәбез.

Һәммәбезгә билгеле, без йомгак ясый торган еллар (1999—2002) гади генә чор булмады. Һәм сәяси, һәм икътисади, һәм рухи өлкәләрдә без көтелмәгән сынаулар аша үтәргә, үзебезнең яшәүгә булган хокукыбызны адым саен көрәшеп яулап алырга тиеш булдык. Татарстан дәүләте яшәешенең хокукый нигезләре үзгәрү дә безне өстәмә кыенлыклар каршына китереп чыгарды. Ләкин шулай да халкыбызның затлылыгы, элек-электән килгән асыл әхлагының нигездә тотрыклы булуы, Республикабыз җитәкчелегенең акылы, аның Татарстанда, тулаем Россия Федерациясендә һәм дөньякүләм олы абруе безгә күп кенә мәсьәләләрне уңай хәл итәргә, шушы шартларда да билгеле бер тигезлекне саклап калу, алай гына да түгел, байтак күрсәткечләр буенча үсешкә ирешергә мөмкинлек бирде. Авыл хуҗалыгында, сәнәгатьтә шактый алга китеш тәэмин ителде. Газлаштыру, юллар салу, Казанда метро төзү, Чулман аша күпер булдыру, моңа кадәр күрелмәгән күләмдә уңыш үстерү, КамАЗны аякка бастыру—саный китсәң, халкыбызның фидакарьлегенә исең китәрлек. Казан Кремле диварлары эчендә Кол Шәриф мәчете төзелү генә дә җитәкчелегебезгә һәм халкыбызга гасырлар дәвамында дан китерерлек һәйкәл буларак кабул ителде. Тузган торакларны бетерү сәясәте халыкта зур яклау тапты.

Шул ук вакытта җәмгыятебездә ачык күренеп торган тискәре күренешләр барлыкка килде. Халык тиз арада ике якка аерылды: артык байлар һәм хәерчеләр. Әхлакый кыйммәтләр полярлашты: бер яктан дини гореф-гадәтләрне торгызу өчен уңай шартлар тудырылды; икенче яктан исереклек, фәхишәлек, наркоманлык кебек яман чирләр алгы планга чыкты. Яшәешне намуслы хезмәт белән тәэмин итү омтылышларының бәясе төште. Мондый шартларда тормышта чын әдәбият һәм сәнгатьнең кадере китүгә аптырарга кирәкме икән? Театрларның репертуарларына коры көлдерүләргә исәпләнгән арзанлы комедияләр кереп тулды. Җыр сәнгате үзенең гасырлар буена үстерелеп киленгән асыл үзенчәлекләрен тизлек белән югалта башлады, эстраданы талантсыз башкаручылар һәм аларның арзанлы җырлары басып алды, тамашачыларның һәм укучыларның затлы зәвыкларын

бозу өчен жирлек барлыкка килде. Бүген язучы һәм икътисади, һәм әхлакый кризис шартларында калды. Мондый хәлдә иҗат итү, бигрәк тә унышлы иҗат итү, сүз сәнгатенең көченә ихлас ышанган хәлдә генә булырга мөмкин.

Шунысы куанычлы: иҗат берлеге әһелләре каләмнәрен читкә куймадылар. Киресенчә, бик күбе иҗат активлыгын тагын да арттыра төште. Халык мондый болганчык шартларда туры, ачык сүзне язучылардан көтә. Безнең карашка, сез, хөрмәтле каләм осталары, бу өметне билгеле бер дәрәҗәдә аклый алдыгыз.

Шигърият өлкәсендә Гамил Афзал, Иллар Юзеев, Шәүкәт Галиев, Ренат Харис, Әхсән Баянов, Роберт Миңнуллин, Фәнис Яруллин, Равил Фәйзуллин, Зөлфәт, Мөдәррис Әгъләмов, Лена Шагыйрьҗан, Зиннур Мансуров, Гәрәй Рәхим, Газинур Морат, Разил Вәлиев, Рәдиф Гаташ, Сергей Малышев, Лилия Газизова, Роберт Әхмәтҗанов, Айдар Хәлим, Флера Гыйззәтуллина, Эльмира Шәрифуллина, Гөлшат Зәйнашева, Роза Кожевникова, Резеда Вәлиева, Әхмәт Рәшитов һәм башкалар аеруча иҗат активлыгы күрсәттеләр. Алар иҗатында бүгенге көн проблемаларының үзәктә торуын билгеләп үтү зарур. Бу яктан Л. Шагыйрьҗанның 11 сентябрьдә Нью-Йоркта булган фаҗигаләрдән соң татар халкының дөнья күләмендәге урынын ачыклап иҗат иткән поэмасы әдәбиятыбызның җитлеккәнлеген күрсәтте. Шуны ук Р. Харис поэмаларына карата да әйтергә кирәк.

Прозада Тәүфикъ Әйди, Мөсәгыйт Хәбибуллин, Якуб Зәнкиев, Әдип Маликов, Рауль Мирхәйдәров, Зөфәр Фәтхетдинов, Әдип Маликов, Мәдинә Маликова, Ләбибә Ихсанова, Нәбирә Гыйматдинова, Сафа Сабиров, Радик Фәизов, Нонна Орешина, Владимир Корчагин, Рафаэль Сибат, Солтан Шәмси, Фоат Садриев, Факил Сафин, Галимҗан Гыйльманов, Флүс Латыйфи, Фәүзия Бәйрәмова, Зәки Зәйнуллин, Әхәт Гаффар, Аллер Тимергалин, Зиннур Хөснияр, Вахит Имамов, Миргазиян Юныс, Евгений Сухов һәм башкалар бик җимешле иҗат иттеләр. Әсәрләрнең тыгызлыгы, җыйнаклыгы күзгә ташлана. Проза шигырь кебек оператив төргә әверелә бара. Романга алмашка повесть жанры активлаша төште. Хикәянең абруе күтәрелә. Мона әдәби журналларыбызның оештыру эшчәнлеге дә этәргеч ясый.

Драматургиянең үзәгендә һаман да Т. Миңнуллин кала килә. Ризван Хәмид, Данил Салихов, Рәдиф Сәгъди, Аманулла, Зөлфәт Хәким, Мансур Гыйләҗев бүген иҗатларының чәчәк ату чорын кичерәләр. Лев Кожевников, Борис Сулимов та каләмнәрен ныгыта баралар.

Бу каләмдәшләр янына бик өметле яшь шагыйрьләр һәм прозаиклар өстәлә бара. Луиза Янсуар, Сөмбел Гаффарова, Альбина Әпсәләмова, Лиана Әмирханова, Алмаз Гыймадиев, Гөлназ Вәлиева кебек яшь каләмнәр өмет уята.

Язучы иҗатының төп һәм бердәнбер нәтиҗәсе—китап. Беренче карашка, хәзер китап бастыру өчен мөмкинлекләр шактый киңәйде. Татарстанда 40 тан артык нәшрият эшли, аларда елга 500 ләп китап чыга дигән мәгълүмат бар. Әйе, алар хәзер шактый үрчеде. Ләкин язучы карап торган нәшриятлар берничә генә. Алар: Татарстан китап нәшрияты, «Мәгариф» нәшрияты, Чаллы нәшрияты, «Раннур» нәшрияты, «Рухият» нәшрияты, «Матбугат йорты» нәшрияты. Әлбәттә, алар арасында Татарстан китап нәшрияты иң алгы планга чыга. Китап басуның бүгенге торышын иң беренче чиратта нәкъ менә шушы нәшрият билгели. Моны басылган китапларның саны һәм сыйфаты күрсәтеп тора. 1999 елда бирелә—44 исемдә, 2000 елда—52, 2001 елда—62, 2002 елда бүгенге көнгә 17 китап басылды. Җәмгысы—177 китап. «Мәгариф» нәшриятында 35 китап. Болар—тиешле таләпләргә туры китереп, редакцияләнеп һәм авторга гонорар түләп басылган китаплар.

Чаллыда бу вакыт эчендә 74 китап чыккан. Бирелә Ф. Бәйрәмова актив эшли, ул 7 китап, А. Хәлим—5, мәрхүм язучыларыбыз Нәҗип Мадъяров һәм Заһидә Гомәрова 3 әр китап чыгарганнар. Шунысы кызык: Чаллыда яна, яшь авторларны барлауга һәм бастыруга игътибар бирәләр. Аларның байтагы әле казанлыларга ачыш булып кабул ителә. Бирелә 7 яшьлек Булат Сөләймановның «Хикмәтле малай» исемле китабы чыгу һәм аның яратып кабул ителүе әдәбиятыбызда күңелне сөендерерлек бер вакыйга буларак бәяләнде.

«Раннур» нәшрияты китапларны затлы итеп чыгаруга зур игътибар бирә.

Затлылык басыласы әсәрләрне сайлап алуда һәм матур эшләнештә күренә. Биредә аеруча Резеда Вәлиеваны яраталар, аның 7 китабы, Разил Вәлиевнең—6, Г. Тукайның—5, Ф. Яхинның 3 китабы дөнья күргән. Ниһаять, «Татар әдәбияты тарихы»ның алты томы да басылып бетте. Аның соңгысын «Раннур» нәшрияты чыгарып бирде. Бу нәшрият барлыгы 42 китап чыгарырга өлгерде.

Н. Фәттахның «Язык богов и фараонов» китабы Татарстанда гына түгел, Россия күләмендә кызыксыну уятты.

Без Мәдинә Маликованың актив иҗат итә башлавына куандык. Гөлчәчәк Галиеваның «Тулгак» исемле китабы да әдәби тормышны җанландырып алды.

Ике корылтай арасында укучы үзенә Рафаэль Сибатны ачты һәм кабул итте, дисәк, урынлы булыр. Ул, байтак уңышлы әсәрләр авторы булса да, китапсыз язучы иде. Шушы арада аның 3 китабы укучыга барып ирешге, ә «Ялгызак» романы Г. Исхакый бүләгенә лаек булды. «Матбугат йорты» нәшрияты да хисап чорында 33 китап баскан. Алар арасында Суфиян Поварисовның Г. Ибраһимовка багышланган трилогиясенең, Мөбарәк Мусин тарафыннан төзелгән «Гомәр Гали» исемле китапның әдәбиятыбыз өчен аеруча кыйммәтле икәнен әйтеп китү зарур.

Әдәбият үзе турындагы фәнсез һәм тәнкыйтьнең тиешле дәрәҗәдә куелуыннан башка сәламәт яши алмый. Бу өлкәдә китаплар күп түгел, әмма алар тирәнлекләре һәм җитдилекләре белән аерылып тора. Әлеге мәсьәләдә хәзер Татарстан Фәннәр академиясенең «Фән» нәшрияты бик файдалы эш башкара. Әле янарак кына Фәрит Бәширов, Эльмира Галиеваларның хезмәтләре басылды. «Мәгариф» нәшрияты, Т. Галиуллинның егерменче гасыр татар шигъриятен инләп өйрәнгән хезмәтен укучыларга ирештереп, үзенең изге максатына тугры калуын раслады. Х. Миннегулов, Ә. Кәримуллин китаплары әдәбият турындагы күзаллавыбызны баеттылар. «Хәсән Туфан», «Сибгат Хәким», «Һади Такташ»ларга багышланган китап-альбомнар сериясе шушы вакыт аралыгында туды. Аларны төзүдә Р. Батулла зур тырышлык куйды. Әлеге зур эшнең инициаторы—хөрмәтле Президентыбыз М. Ш. Шәймиев. Ул уены-чыны белән: «Хәсән Туфанның юбилеена шушы китапны өлгертмәсәгез, кичәгә килүем икеле» дигән иде. Бу безнең алга, нәшрият алдына куелган бурыч буларак кабул ителде. Китап көненәсәгатенә өлгерде. Минтимер Шәрипович юбилей кичәсенә килде, бик кызыклы чыгыш ясады. Без Габдрахман Әпсәләмовның юбилеена да матур гына китап чыгаруга ирештек. Хәзер Г. Кутуйның 100 еллыгына шундый ук әзерлек алып барабыз.

Публицистик әсәрләргә килгәндә, Р. Юнисовның «Татарстан референдумы», В. Якупованың «100 историй о суверенитете» китаплары киң яңгыраш алган әсәрләр булды.

Мәгъсум Хуҗин тарафыннан «Татар хикәяләре антологиясе» төзелү һәм басылып чыгу шулай ук гадәти генә хәл түгел. Хәзер аның икенче кисәген әзерләү буенча эш башланырга тора. Равил Бохараев исә Лондонда инглиз телендә «Татар шигърияте антологиясе» чыгарды. Безнең шагыйрьләр, шул рәвешле, дөнья укучыларына барып ирешә башлады. Шуңа Төркиядә чыккан шигъри антологияне дә өстәргә кирәк.

Китапның укучыларга барып җитүе турында сүз чыккан икән, хөкүмәтебезнең китапханәләрне безнең китаплар белән тәэмин итү өчен шушы өч ел эчендә биш миллион сум акча бирүен рәхмәт хисләре белән билгеләп үтәсе килә. XIII корылтайда биргән вәгъдәгезне, Минтимер Шәрипович, үтәдегез, рәхмәт Сезгә!

Бу очракта «Татнефть» җитәкчеләренә дә рәхмәт әйтү урынлы булыр. Моннан берничә ел элек алар оештырган «Рухият» нәшрияты 14 затлы китап чыгарып бирде. Әлмәттә шул китапларны тәкъдим итү кичәсе зур бәйрәмгә әверелде. М. Әгъләмов иҗатын шактый тулы итеп халыкка җиткерүдә әлеге нәшрият чыгарган «Кан тамырын кистем» китабы аеруча әһәмиятле булды.

Татарстан милли китапханәсе һәм Язучылар берлеге быел да ин күп укылучы китапларны һәм аларның авторларын билгеләделәр. Алар арасында Разил Вәлиев, Фәүзия Бәйрәмова, Госман Гомәр, Зөлфәт Хәким, Хәсән Туфан, Фирая Зыятдинова, Гөлшат Зәйнашева, Айдар Хәлим, Мөҗәһит Әхмәтҗанов, Җәүдәт Дәрзаман, Рафис Корбан, Зөфәр Фәтхетдинов, Әхәт Мушинский, Харис Закиров,

Гөлназ Вәлиева, Мансур Сафин бар. Әле, шөкер, китапларыбыз укыла, әдәби сүз халыкка барып житә. Монын кадерен белергә, әлеге хәлне тотрыклы итәргә кирәк. Бу—безнен аллагы төп бурычларыбызнын берсе.

Шул рәвешле, ижат активлыгын арттыру, аны көндәлек хәлгә әвереллерү—идарә эшенен төп юнәлешләреннән берсе булды. Шушы арада без ике тапкыр әдәби ел йомгакларына багышланган гомуми жыелышларыбызны уздырдык. Алар Г. Ибраһимов башлап жибәргән еллык ижатны гомумиләштерү бурычын тормышка ашыруда бик әһәмиятле роль уйныйлар. Шуна тагын «Казан утлары» журналы идарәсенен һәр ярты ел саен кинәйтелгән утырышлары уздырылып баруын, «Идел», «Салават күпере» журналлары турындагы мәсьәләләрнен Язучылар берлеге идарәсе утырышларына куелуларын өстәсән, әдәби ижат хәрәкәтендәге тенденцияләрнен даими билгеләнеп барылуын күрми мөмкин түгел.

Бу өлкәдәге эшне күзәтеп бару—эшнен бер генә ягы. Монын белән генә чикләнү пассив теркәп барудан гайре нәрсә булмас иде. Ин мөһиме—ижади хәрәкәтне оештыру. Бездә монын сыналган, отышлы инструменты, системасы бар. Бу эшкә гомумән житәкчелек итүче рәистән тыш, анын бер урынбасары—бу очракта Ш. С. Мостафин—бары тик шушы өлкә буенча гына эшли. Анын ин нәтижәле булышчылары—остаханә житәкчеләре. Алар бездә—алтау: проза, драматургия һәм публицистика; шигърият; балалар әдәбияты; рус телендә ижат итүчеләр; тәнкыйть; тәржемә. Бу сонгы икесен булдыруны безгә үткән корылтайда сез, хөрмәтле язучылар, безнен алга бурыч итеп куйган идегез. Без моны үтәдек. Әлбәттә инде, остаханәләргә, бөек шагыйребез Г. Тукай әйтмешли, бу өлкәдә үзләре «ат уйнаткан» каләм әһелләре житәкчелек итәргә тиеш. Без бу яктан житәкчеләрне бик унышлы сайлаган булып чыктык. Солтан Шәмси, Зиннур Мансуров, Жәүдәт Дәрзаман, Мансур Вәлиев, Кыям Минлебаев, Владимир Корчагин инициативалы, кызыксынып эшләделәр. Ижат мәсьәләләренә караган төрле мәсьәләләрне табып игътибар үзәгенә куя алдылар. Кирәк икән, ике яки өч остаханәнен берләштерелгән утырышларын да уздырдылар, яшьләр ижатын, яки, мона кадәр байтак еллар каләм тибрәтеп тә, язганнарына әлләни игътибар ителмәгән кешеләрне күрә алдылар, лаеклыларын безнен сафка тәкъдим иттеләр.

Кабул итү турында сүз чыккан икән, бу эш белән махсус шөгыльләнүче Коллегия эшенә дә унай бәя бирү дөрес булыр. Равил Фәйзуллин житәкчелегендәге бу коллектив үз эшенә бик жаваплы карады. Безгә мирас булып 55 гариза һәм бу кешеләрнен документлары калган иде. Без исә шушы арала 43 кешене язучылар сафына кабул иттек. Унга якын кешегә унай жавап бирелмәде. Ләкин әле бу алар алдында ишек ябып куелган дигән сүз түгел. Алар яна китап чыгаргач, яки Коллегия күрсәткән башка житешсезлекләрен бетергәч, яналан мөрәжәгать итә алалар. Без әдәбиятка килергә теләгән һәр кешегә бик сак карарга тиешбез.

Сонгы унъеллыкларда безнен сафка нигездә Татарстаннан гына килә иделәр. Татарлар яши торган башка төбәкләр белән эшләү кайбер нәтижәләр бирде. Без Ульяновск, Пермь, Киров өлкәләреннән, Башкортстан, Удмуртия республикаларыннан, Мәскәү шәһәреннән үз арабызга яна әгъзалар кабул итә алдык. Якын араларда Казакъстаннан, шулай ук Удмуртиядән яна әгъзалар алуыбыз көтелә. Сүз унаенда әйтергә кирәк, Әгерже районы һәм Удмуртиядә яшәүче язучыларыбызны берләштереп, без Әгерждә Татарстан Язучылар берлегенен бүлекчәсен ачу турында да уйланабыз.

Яшьләр белән эшләү дигәннән, безгә бу юнәлештә Мәгариф министрлыгы, Яшьләр белән эшләү һәм спорт министрлыгы белән элемтәләр урнаштыру бик файдалы булды. Алар ярдәмендә яшь ижатчыларнын очрашуларын уздыру гадәткә кереп бара. Быел март аенда яшь каләмнәрнен республика күләмендәге семинарын уздыру аеруча отышлы булды. Беренче тәжрибәләр әйбәт, хәзер инде аларны ныгытырга, үстерергә кирәк. Монын өчен рәиснен яшьләр белән эшләү буенча махсус урынбасарын булдырырга кирәк дип саныйбыз. Заманында ул бар иде, аны күп еллар буена халык шагыйребез И. Юзеев житәкләде. Әмма безгә кадәрге житәкчелек бу штатны саклап калуга житди карамаган булып чыкты.

Элеккеге житәкчелек әдәбиятны пропагандалау бюросын да бетергән иде. XIII корылтай безгә бу оешманы торгызунын кирәклеген басым ясап әйтте. Дөресе дә шулай бит: бигрәк тә хәзер, әдәбиятны пропагандалауны даими,

эзлекле оештырудан башка иҗат оешмасының эшен күз алдына да китереп булмый. Без бу структураны торгыздык. Аңа җитәкче итеп яшь драматург Р. Сәгъдине билгеләдек. Хәзер алар әдәби консультантлар Ф. Әһлия, В. Корчагин белән берлектә эшне әйбәт кенә оештырып килләр.

Чаллы һәм Әлмәт язучылар бүлекләре дә эшне сизелерлек яхшырттылар. Алар үз районнарында әдәбиятны пропагандалау буенча бик файдалы эш алып баралар. Чаллыда «Мәйдан» журналын оештыруга ирешү аның редакторы Ф. Сафин һәм бүлек җитәкчесе В. Имамовның зур тырышлыгы нәтиҗәсендә мөмкин булды. Бу очракта Чаллы шәһәр хакимияте башлыгы Рәшит Сәетович Хәмәдиевка рәхмәт әйтергә тиешбез. Матди якны ул тәэмин итте. Журнал тиз аякка басты, үз йөзен тапты. Хәзер аны республика бюджетына кертү мөһим бурыч булып тора. Шуннан башка ул яшәп китә алмаячак. Һәрхәлдә ул—җитди журнал, кирәкле журнал! Шуңа күрә без «Мәйдан» кебек изге максатлы басмаларыбызны хөкүмәт канаты астына алырга тиешбез.

Журнал димәктән, шушы көннәрдә безнең төп басмабыз «Казан утлары» журналының оештырылуына 80 ел тулды. «Безнең юл», «Атака», «Яңалиф», «Совет әдәбияты» исемнәре астында ул данлы юл үтте. Бүген дә ул үзенең җәмгыятебездә, әдәбиятыбызда әйдәп баручы, эталон булу ролен саклап килә. Әдәби-нәфис һәм иҗтимагый-сәяси журнал шундый булырга тиештер. Ул шуңа күрә 10 меңгә якын тираж белән чыга. Халык аны укый, ярата, чөнки мәсьләгә, эчтәлегә, халкыбыз мәнфәгатен олпатлылык белән яктыртуы сәбәпле, абруе елдан-ел арта бара. Бүген, Мәскәүдә чыга торган калын журналларның тиражы 3-4 меңнән артмаган чакта, «Казан утлары» бу яктан да шактый җегәрле булып күренә. Бу—баш мөхәррир Р. Фәйзуллинның һәм журнал коллективының, авторларның зур казанышы. Журналга котлавында хөрмәтле Президентыбыз мөһим бурычларның берсе сыйфатында журнал алдына, димәк, барыбызга да, мондый бурыч куя: «заман шаукымына бирелмичә, халкыбызның күпгасырлык рухи, әхлакый кыйммәтләрен саклап калу»ны кыйбла итәргә. Бу, дөресен әйткәндә, тулаем җәмгыять алдына куелган бурыч. Әдәбият-сәнгать, фән, дин әһелләре—тулаем барыбыз да барлык эшчәнлегебезне шушы юнәлештә оештырырга, әлеге олы максатка баруны изге юл дип санарга тиешбез.

Иҗат оешмасының төгәл һәм нәтиҗәле эшләве күп яктан аның җитәкчелегенең, идарәнең эшчәнлегенә бәйле. 32 ай эшләү дәверендә 26 идарә утырышы уздырылды. Аларда 129 мәсьәлә тикшерелде. Иҗат остаханәләренең эшен нәтиҗәле итеп оештыру, берлеккә кабул итүнең Положениесен камилләштерү, Г. Тукай исемендәге клубның эшен янабаштан оештырып җибәрү, татар телендә әдәби консультация эшенең торышы, русча язучылар остаханәсенең эше, гонорарның хәзерге торышы, «Идел» журналының эчтәлеге һәм бизәлеше, торак-көнкүреш комиссиясенең эше турында, М. Җәлил бүләген яңадан торгызу буенча тәкъдим эшләү, Җ. Вәлиди, Г. Державин исемендәге бүләкләрне торгызу, язучыларга социаль ярдәм итүнең торышы һәм аны яхшырту юллары, арабыздан киткән язучыларның мирасын барлау һ. б. күп мәсьәләләр. Күренгәнчә, әдәби тормышның гаять күп төрле аспектлары каралып барылган. Иң мөһиме—идарә бу һәм башка мәсьәләләр буенча үзе кабул иткән карарларны үтәүдә оешканлык һәм бердәмлек белән эшләде дип әйтергә мөмкин.

Идарә әдәби премияләр бирүдә дә гаделлеккә нигезләнеп эш итте дияргә мөмкин. Фәнис Яруллинга—Татарстанның халык шагыйре, Хисам Камаловка—Татарстанның халык язучысы исемнәре бирелү тулаем җәмәгатьчелектә хуплап кабул ителде. Зөлфәт, Роберт Әхмәтҗанов, Якуб Зәнкиевләргә Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге бирелү белән дә шул ук хәл. Г. Исхакый, А. Алиш, Җ. Вәлиди, Ф. Хөсни, Г. Державин бүләкләрен бирү дә иң демократик шартларда хәл ителде. Шул ук вакытта әйтергә кирәк: идарә әгъзаларына теге яки бу кешене бүләкле итүне үзмаксат итеп куйган төркемнәр нык тәэсир иткән чаклар да булды. Мондый күнелсез нәрсә алга таба булмаска тиеш. Кайчакта «халык язучысы», «халык шагыйре» исеменә ironияле караш белән очрашырга туры килә. Н. Исәнбәт, Г. Бәширов, С. Хәким, Х. Туфан, Ә. Еники, Г. Ахунов, М. Мәһдиев, А. Гыйләҗев горур йөртеп, шуңа лаек булган өчен халык тарафыннан аеруча хөрмәт ителгән әлеге исем тирәсендә мондый тотнаксыз фикер йөртү—әхлаксызлык.

Әдәбиятны изге эш итеп караучылар болай әйтмәс. Болай уйлаучылар—әдәбиятка башка максатларны күздә тотып килгән кешеләр алар. Республикабыз җитәкчелегенә бу урында «халык шагыйре», «халык язучысы» исемен йөрткән әдипләрнең статусын ачыклау юнәлешен тотканнары өчен тагын бер тапкыр рәхмәт әйтәсе килә. Без бу хакта тәкъдимнәребезне Мәдәният министрлыгына җибәрдек. Сүз уңаеннан әйтергә кирәк, Мәдәният министрлыгы иҗат берлекләренә бик хәерхаһ карый, без күп эшләрне кулга-кул тотынып эшлибез. Министр И. Г. Тарханов бөтен мәсьәләләрне тирән белеп һәм оператив төстә хәл итә, безгә ярдәмен кызганмый.

Әйе, Язучылар берлеге башка иҗат оешмалары белән дә элемтәләрен ныгытты. Без 2000 елда иҗат берлекләренең берләштерелгән пленумын уздырдык. Президент аппараты җитәкчесе Ә. С. Гобәйдуллин, пленумда үзе катнашып, аның карарларының үтәлешен үз контроленә алды. Пленумнан соң Дәүләт Советы Рәисе Ф. Х. Мөхәммәтшин иҗат берлекләре җитәкчеләрен кабул итте, аларның эшчәнлеген яхшыртуның кануный нигезләрен булдыру кирәклеген ассызыклады. Безнең җитәкчелектә Дәүләт Советында «Мәдәният турында»гы законга яңа бүлек—иҗат берлекләре турындагы бүлек әзерләнде. Хәзер исә бу хакта махсус закон кирәк дигән фикергә киленде һәм ул закон проекты әзерләнә.

Әдәби тормыш тулы канлы барсын дисәк, безгә башка әдәбиятлар белән бәйләнешне дә ныгытырга кирәк. Бу җәһәттән дә байтак эш башкарылды. Истамбулда уздырылган төрки әдәбиятлары форумында, Бакуда «Китабы Дәдә-Коркыт» эпосының 1300 еллыгына багышланган халыкара конференциядә катнаштык. Халыкара «Ауразия диалогы» (Төркия) журналын оештыручыларның берсе шулай ук без булдык. Шагыйрьләр Р. Харис һәм Р. Фәйзуллин, Төньяк Кипрда уздырылган төрки шигъриятләр фестивалендә катнашып, безнең әдәбиятыбыз турында югары фикер тудырып кайттылар. Казакъстанның Җаек каласына бөек шагыйребез Г. Тукайның бюсты Татарстан тарафыннан һәдия ителде. Бу исә ике тугандаш халыкларны һәм аларның сүз сәнгатен якынайтуга ярдәм итәчәк. Чөнки без алга таба хезмәттәшлек итү өчен ныклы нигез сала алдык. Мордовиядә, Удмуртиядә, Ульяновск, Оренбург, Төмән, Пермь өлкәләрендә татар әдәбияты көннәре уздыру шулай ук мөнәсәбәтләрне якынайтуга хезмәт итте. Чувашстан язучылары белән арабыз аеруча җылы дип әйтер идем. Татарстанда П. Хузангай музее ачылу дуслыкны тагын да ныгытты. 2003 елда Чувашстанда татар әдәбияты көннәре уздырылачак. Быел көз Әстерханда зур әдәби чаралар үткәрү планлаштырыла.

Россия язучылар оешмасы белән дә хезмәттәшлек юлга салынып килә. Аралашу, бер-береңне баетышу—тормыш таләбе. Башкортстанның Бәләбәй шәһәрендә ел саен уза торган шигъри фестивальләр моның ачык чагылышы. Соңгы өч елда анда бирелә торган Ф. Кәрим исемендәге бүләккә Р. Гаташ, З. Мәҗитов, Р. Миннуллиннар лаек булды.

Берлекнең җитәкчелеге һәм идарә язучыларның рухи һәм матди мәнфәгатен кайгыртуны үзләренең әһәмиятле бурычларыннан саналы. Каләм әһелләренең торак шартларын яхшырту буенча сизелерлек эш башкарылды. Аксакаллар шурасы рәисе М. Хәбибуллин җитәкчелегендәге тормыш-көнкүреш комиссиясе торак-фатир шартларын яхшыртуга дәгъва итүче язучыларның тулы исемлеген төзеде. Исемлектә 34 кеше булып, шулардан 4 кеше генә бөтенләй фатирсыз, калганнар—торак-көнкүреш шартларын яхшыртуны сорап гариза бирүчеләр. Роза Хәлиуллина, Нияз Акмалов, Әмир Мәхмүдов 40 ар квадрат метрлы берәр бүлмәле фатир алдылар. Газинур Морат, Йолдыз Шәрәпова, Резеда Әхтәмова һәм башкаларның фатир алуында да берлек җитәкчелегенең ярдәме булды. Хәзер тагын өч язучыбыз торак шартларын яхшыртачак.

Язучылар берлеге 621 кешегә акчалата ярдәм итә алды. Бу исәпкә пенсия яшендәгеләргә һәр ай саен бирелеп бара торган 100 сум керми. Шулай ук аерым язучыларга, вафат булган язучыларның гаиләләренә дә 3 меңнән алып 5 мең сумга кадәр дистәләрчә тапкыр ярдәм күрсәтелде. Авыру һәм мохтаҗ язучыларның өйләренә барып хәлләрен белү, мөмкин булганча ярдәм күрсәтү игелекле традициягә әверелеп бара. Өлкәннәргә һәр елны 100 данә «Казан утлары», соңгы елда «Мәйдан» журналын яздыру гадәткә керде. Берлек ярдәме белән 16

язучыны әйбәтрәк хастаханәләргә урнаштыру мөмкин булды. Шифаханәләргә юллама алуга, телефон куйдыруга, мәрхүм язучыларның каберләренә таш куюга, истәлек такталары ачуга даими игътибар ителә. Әле кичә генә халык язучысы Гомәр ага Бәширов яшәгән өйгә истәлек тактасы куелды.

Бу вакыт эчендә Г. Исхакый, М. Мәһдиев, Х. Туфаннарның музей йортлары ачылды. К. Сибгатуллин музее да әйбәт кенә эшләп китте.

Бу өч ел—Язучылар берлеге бинасын карау, ныгыту еллары да булды. 1999 елның көзендә жылылык системасы тулысынча яңартылды. Сафтан чыккан су челтәре 2000 елда яңадан булдырылды. Өлешчә түбә ябылды. Эш бүлмәләре төзәтелде. Г. Тукай клубы ремонтланды. Хәзер бинага капиталь ремонт ясатуга әзерлек бара. Берлек карамагындагы «Ока», «УАЗ» машиналары Чаллы, Әлмәт бүлекләренә бирелде. Берлеккә өр-яңа ике машина сатып алынды. Компьютер, теле-радиоаппаратуралар алынды. 200 мең сумга мебель яңартылды.

Шул ук вакытта әдәби тормышны тагын да җанландыру, тулы канлы итү, анда барлык язучыларның катнашуына ирешү, ягъни аларның шәхси активлыгын булдыру мәсьәләләрендә эшлисе эшләр шактый әле. Язучылар берлеге оештыручысы булган «Казан утлары», «Идел», «Мәйдан», «Салават күпере» журналлары да көндәлек игътибар сорый. Аларның сыйфат ягыннан яхшыруы, эшләнешенең игътибарны җәлеп итәрлек булу-булмавы, тиражларын арттыру проблемасы шулай ук авторлар коллективыннан, димәк, язучылардан тора. Чаллы, Әлмәт бүлекләренә игътибарны арттырасы бар. Язучыларның матди ягын кайгырту юнәлешендә дә хәл итәсе мәсьәләләр күп. Иҗат йорты эшен җайга салып җибәрәсе, Язучылар берлеге бинасына капиталь ремонт ясыйсы бар. Боларның һәммәсе аерым-аерым алганда да гаять катлаулы бурычлар. Әмма аларны бер үк вакытта, ягъни комплекслы алып барырга кирәк. Яңа идарәне, шул рәвешле, житди эшләр көтә. Ана унышлы эш, оешканлык һәм уртак эш хакына тупланганлык телисе генә кала.

Бер докладта өч йөзгә якын язучыны берләштергән иҗат оешмасының эш юнәлешләре турында барысын да сөйләп бирүне максат итеп булмый. Кулыгызда хисап китабы, унышлы якларны да, кимчелекләрне һәм бурычларны да шуннан ачыклау мөмкинлеге бар.

Хөрмәтле каләмдәшләр, без хәлдән килгәнчә эшләргә тырыштык. Бөтен эшебез сезнең күз алдында. Инде хезмәтебезне бәяләү сезнең карамакта. Һәрхәлдә—булсын дип тырышкан көн. Кимчелекләр дә бардыр. Аларын да күрсәтерсез, эшне камилләштерү юлларын билгеләрсез дигән өметтә торабыз.

# Şiğriət
# Шигърият



## Роберт Әхмәтҗан

ДАСТАННАР ЖИРЕ

### Казанга мәдхия

Балкыта җирне мәңгелек язың,
дәртле көйләрне уйныйдыр сазың...
Ак диварларың
хәтерли барын,
мең яшьлек Казан,
мең яшәр Казан!

Иркәли җанны Идел һавасы,
ишетәм синдә әнкәм авазын.
Мәхәббәтем син,
бәхетем каласы,
мең яшьлек Казан,
мең яшәр Казан.

Сиңа, ак калам, безнең язмышта
изге йортыбыз булырга язган.
Дастаннар җире,
яугирләр иле,
мең яшьлек Казан,
мең яшәр Казан!..

---

Роберт ӘХМӘТҖАН *(1935) —шагыйрь, күпсанлы шигырь китаплары («Таң шәһәре», «Идел-йорт» «Җәяүле күбәләк» һ. б.) авторы, Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. Казанда яши*

Һәр ташың синең җанлы, хәтерле,
сиңа мәдхия Тукайлар язган...
Милләтемнең син
алтын бишеге,
Мең яшьлек Казан,
мең яшәр Казан!..

Кайталар сиңа Сөембикәләр,
Колшәрифләрең калка яңадан.
Бәйсезлек рухы яшәр мәңгегә,
яшәр мәңгегә,
мең яшә, Казан!..

## Әманәт

### I

Безне сулардан куганнар,
«бөек милләт» булганнар,
уттан алып, бозга салып,
чукындырмак булганнар.
Уттан алып, суга салып,
бары чыныктырганнар!..

Итил-суларга ятып,
бер батып та, бер калкып,
түләгәндер бу халкым
җирдә яшәүнең хакын!..

Безне бозлы Казан-суга
кылыч айкап куганнар
«Бөек урыс туганнар».
Баткан-чумган, чукынмаган,
иман—имин, туганнар.
Үлсәк—үлгән, иман—бар!
Килсә килсен Идел-йортка
күпме Явыз Иваннар,
сер бирмикче, оланнар!

Безне сулардан куганнар,
үзебезнең сулардан...
Ыруым кабер ташлары
кан-яшькә чыланган.

### II

Биш йөз ел элек батканнар
калкабыз сулардан.
Чыгабыз төптән ишелеп
азатлык суларга.
Яшәвебез-дәшмәвебез
кыйммәт соң һаман да,
маңкортлар баш түбәбездә
биегән заманда!..

Үз кадереңне белмәгәч,
кем безне кадерләр?
Бөтен суларны буйлатып,
изге дулкыннарга ятып,
Чулманнан—Хәзәргә чаклы
чайкала тәреләр,
чайкала тәреләр!

Җыйналыйк, милләт рухына
бер дога кылганнар.
Әманәт: чынкый тарихны
укысын оланнар!

## Азатлыкка кереш

Азатлыкның бер йотымын гына
татып карар өчен... үлә халык!..
Чапаланып ята ярда балык,
саңаклары белән сулыш алып,
күккә багып ята,
«хәйран калып!..»
Аяз күктә азат кояш балкый!—
... Ә ул йөзә алмас
гомер бакый!..
Су буенда ята
суга сусап...

Тик бер йотым азатлыкка сусап,
тыны беткән
балык мисле халык...
Балык—дәшә алмый,
халык—ләм-мим—
Шул балыктан әллә
үрнәк алып?!..

Җитте, вакыт!
Ятма оеп-талып,
Азатлыкмы сиңа
бер йотарлык?
Вакыт инде, татар,
Ил-байталның
дилбегәсен үзең
нык тотарлык!
Нидән өркеп калдың?
Әллә инде
кылган гамәлләрең
җир йотарлык?

Ант-шигарең җирдә ятарлыкмы,
әллә юлдан тибеп атарлыкмы?
Күрсә иде гавам: җирдә ныклы
сан
сыйфатка
ускән
татарлыкны!

Азатлыкмы сиңа бер йотарлык,
урыс бәләмеме—үт сытарлык?..
Иле белән чүкәнме
татарлык?—
нинди тарлык!..
Түгел инде җирдә бу тарлыкны
бүтән тарлык белән
һич бутарлык!..

## Гомер юлы

Гомер тирәгемнең ябалдашын
Алтмыш еллар җиле шаулатты.
Аңлатты ул күкләр төпсезлеген,
Еллар чиксезлеген аңлатты.

Шунда белдем, тиңсез гомерләр дә
Чиксезлектә—тотен,
бер тузан,
Чәчрәп очкан йолдыз кыйпылчыгы,
Чәрдәкләнгән Айдай, фаразан!..

Кыйблаларын җуйган кәрванмыни—
Болытларым йөрде каңгырып.
Әле дә булса газиз башларыма
Пыскып тора салкын яңгыры...

Кешни анда җилләр, елый болыт,
Көлә Кояш, укшый гамьсезлек.
Мәнсезлекләр тулы игелекләр,
Изгелекләр катнаш мәнсезлек!..

Гомер тирәгемнең һәр яфрагы
Вакыт узуларга бик сизгер.
Мизгелләре кайчак—тулы гасыр,
Гасырлары—тулмас бер мизгел!..

Дөньягызга килеп бәхетле мин,
Йә, Ходаем, килеп шаккаттым!—
Гасырларын сабыр кичтем кебек,
Мизгеленә—
бетте «тәккатем!..»

Дөньяларга килеп яшәүләрнең
Бер ядкаре әле ярады:
Болыннарда үскән яшьлегемне
Урлап очты Энә Карагы!..

Мизгел булса, гасыр—яшәр иде,—
Бер гасырга—мизгел сыймады...
Узып китте бер гасырлык мизгел,
Бер гасырлык!—
беркем тоймады!..

*Елганың борылган төшендә...*

С. Хәким.

**Карадым борылып елларга**
**Борылган төшендә елганың...**
**Елга да, минем кук, борылып,**
**Карыймы үтелгән юлларын?..**

**Елганың борылган төшендә**
**Кычкырып әйләнә тәкәрлек...**
**Аккан су, искән җил—мәңгелек,**
**Гомерләр—бер генә сәфәрлек!..**

**Елганың борылган төшендә**
**Карт тупыл сөйләшә җил белән.**
**Бу җиргә ябышып үскәнгә,**
**Аларның телләрен бик беләм.**

**Яшәгән еллары билгесе—**
**Карт тупыл тәнендә—мугыллар...**
**Елганың борылган төшендә**
**Уйланып торадыр ул еллар?...**

**Үзем дә шауладым гомеремдә,**
**Ил буйлап үткәндә күп юллар...**
**Үзем дә карт тупыл шикелле,—**
**Йөрәктә ишәя... мугыллар.**

**Ел саен ачыла тамырлар,—**
**Карт тупыл текә яр өстендә...**
**Минем дә**
**Яшәвем, эшем дә**
**Елганың борылган төшендә.**

**Яшим тик, туп-туры, үч итеп,**
**Үзем һәм бүтәннәр өчен дә.**
**Борылмыйм әле мин,**
**төз яшим,—**

**Елганың—**
**Язмышның борылган төшендә!..**

## Рауль Мирхәйдәров

# ҺӘРНӘРСӘГӘ—АКЧАЛАТА

РОМАН

### «Лос-Анджелес таймс» хәбәрчесе

1

«Пекин» ресторанына ул кичне Карлен Татлян очраклы гына барып чыккан иде. Анда исә йә исеме белән генә Слава дип, йә Картье дип йөртелгән бер яшь кеше туган көнен үткәреп, күпсанлы кунаклары белән мәҗлес корып утыра икән. Картье аның фамилиясе булудан бигрәк, кушаматыдыр, мөгаен. Карлен Татлян өчен бу кич бик унышлы булып чыкты бит әле. Ниһаять, аңа бәхет елмайды шикелле. Юкса ул инде Мәскәүдә ярты елга якын яши һәм әле үзенә йөкләнгән бурычны үтәү юлында бер адым да алга китә алмаган кебек тоела иде. Алга китү ди сина, дөресен генә әйткәндә, бу эшкә кайсы ягыннан тотынырга да белмичә, бөтенләй югалып калган иде ул. Иң әүвәл аны Мәскәү таң калдырды—шәһәр шундый галәмәт зур, һич аңлап бетерешле түгел, анда яшәү дә әкәмәт кыйммәт икән. Бу башкала-ташкала үзенә генә хас Мәскәү кануннарына буйсына булса кирәк, аны алдан төшенеп тә, нәрсәсендер күрәзәлек итеп тә белеп бетерә торган түгел. Биредә бер генә нәрсә дә гадәти мантыйк-логикага сыймый. Мәскәүдәге тормыш Татлян инде хәбәрче сыйфатында эшләп киткән Нью-Йорктагы яки Европа илләренең бүтән башкалаларындагы шикелле генә түгел, биредә тизлек, ыгы-зыгы һәм киеренкелек хөкем итә. Ә хәвефсезлек мәсьәләсе? Лондон, Чикаго, Париж яки Берлинның иң куркыныч районнары да Мәскәүдә тынычлык-иминлек почмагы булып күренер иде. Биредә ни көндез, ни кичен, ни төнен бер генә урында да үзеңне имин-тыныч итеп тоя алмыйсың. Сине теләсә кайсы биш йолдызлы отельдә—«Метрополь»дәме, «Савой»дамы яки «Националь»дәме—кычкыртып таларга яки үтереп китәргә мөмкиннәр. Җиргә бөтенләй ярлы булган Токионың иң кыйммәтле квартираларыннан да кыйммәтлерәк квартирлы, абруйлы теләсә кайсы районның ишек төбендә якты көн уртасында

---

Дәвамы. Башы 7 санда

чишендереп ташларга да күп сорамыйлар. Көнбатыш илләрендә һәммәсе дә ачык билгеле: тегендә бармасаң, монда йөрмәсәң—исән-сау буласың. Биредә исә сезгә беркем дә куркынычсыз берәр урын барын әйтеп бирә алмаячак—юк андый урыннар. Бервакыт Карлен Татлян, хәбәрче буларак, ничектер заложник-тотык алучылар турында бер материал җибәргән иде. Вакыйга кайда баргандыр дип уйлап карагыз әле. Кремль капкасыннан ике адымда, туп-туры Кызыл мәйданнан Васильев тарафына төшә торган урында! Россиянең ин төп мәйданында, кизү торучы милиционерлар, һәртөрле саклар, гади киемле йөзләгән махсус хезмәткәрләр кайнап торган җирдә!

Ә банк-фәләнгә барып килү? Юкса бу гамәл Европаның теләсә кайсы башкаласында гап-гади көндәлек бер эш бит инде, ә Мәскәүдә, акча салырга йә алырга барасың булса, алдан васыятьнамә язып, өеңдәгеләр белән хушлашып чыгып китсәң дә ярыйдыр: көннен көнендә йә шартлаталар, йә яндыралар банкларны, яки әченә тротил тутырып банк янына куеп киткән берәр машина күккә оча. Йәисә ишектән чыгып килүче инкассаторны ут ачып каршы алалар, йәисә касса залын талаганның шаһиты буласың. Юк, Мәскәү тормышына бик нык кунегергә кирәк әле ана.

Карленны кызыксындырган барлык атаклы казинолар, төнге клублар, уч иткәндәй, шәһәрнең төрле почмакларына таралып утырган, ә төнлә исә транспортка түләү һәрвакыт диярлек йөз бакстан-доллардан да артып китә. Штатлардан һәм Европадан аермалы буларак, һәр җиргә түләп керергә кирәк, гади генә төнге рестораннарның бәяләре дә Парижның гранд-отель рестораннарындагы бәяләренә торырлык. Шулай булгач, эш хакыңны кушып түләгәндә дә, бернинди вәкиллек акчаларың җитмәячәк, менә шуннан соң урыс башкаласының төнге тормышы белән яхшылап танышып кара әле син!

Шундый заманнар булган дип сөйлиләр, Мәскәүгә килгән чит ил кешеләренә башка планетадан төшкән кешегә карагандай карый торган булганнар һәм аны, һичшиксез, бик бай дип санаганнар. Карленның мона ышанасы да килми, чөнки хәзер ул белгән чит ил кешеләренең күпчелеге башкалада бик тыйнак кына гомер сөрәләр, юк, барыр җир булмаганлыктан яки сатып алыр әйбер юклыктан түгел—ин гади сәбәбе шул: финанс мөмкинлекләре шуның кадәр генә, кесәләре такыр. Ә инде Карлен йөри торган урыннарда чит ил кешеләрен бөтенләй очрата да алмавың бар, рәсәйлеләр бик эредән кубып уйный, оттырганда долларларын шундый җинел генә чыгарып сала, шуна күрәдерме, казинода Карленның күнеленә: «урысларның серле-серле рухын аңлап бетерерлек түгел», дигән уй килә, хәтерендә Достоевскийның «Игрок» («Уенчы») романы яңара. Үз максатына бер генә адым якыная алмаса да, Татлян бер нәрсәне ачык аңлады: бөек дәүләт булырга ачыктан-ачык хыялланган кытайлыларның борынына чиертеп, урыслар, һичшиксез, бик тиздән янадан бөек ил-дәүләт дәрәҗәсенә күтәреләчәк һәм, үз вакытында атом-төш коралы, галәмгә күтәрелүләре, тавыш тизлеген узып оча торган авиациясе һәм балеты белән таң калдырган шикелле, әле киләчәктә дә дөньяны кат-кат таң калдырачак.

Россиягә килеп эләккәч, Карлен үзен аналитик бүлеккә эшкә билгеләмәүләре өчен үкенә башлады—их, үзәккә нинди генә күзәтүләр, ачышлар, перспективалар, фаразлар тулы хәбәрләр җибәрмәс, шефлары белән уртаклашмас иде икән ул! Шул юнәлештә Мәскәүдә бер-ике ел эшләп алсаң, Россия буенча бәяләп бетергесез белгеч буласың инде аннары. Ләкин Карлен Татлян алдына бик анык максат куйдылар шул, ә андый мәсьәләләр бик сирәк кенә тиз дан китерәләр, китерсәләр әле?

Әгәр дә Мәскәүдә әнисе ягыннан туганнан туганы Ашот Казарян булмаса,—алар әле яшьтәшләр дә, бер-берсенә бик нык охшашлар да,—менә шул Ашот булмаса, Татлян Россия тормышына тагын да зур кыенлыклар белән иңләшкән булыр иде, мөгаен.

Карлен Татлян Россиягә атаклы «Лос-Анджелес таймс» газеты хәбәрчесе сыйфатында, Америка гражданы буларак килсә дә: ул Ереванда туган һәм хәтта СССР гражданынын урак-чүкечле паспортын да алырга өлгергән иде. Әмма сиксән беренче елны уналты яшьлек егет әти-әниләре белән АКШка, кояшлы Филадельфиягә китеп барды. Ул төбәкне дөньяның төрле якларында яшәүче әрмәннәр бик ярата һәм анда Татляннарның да күпсанлы бай туган-тумачалары яши иде.

Карленның яшьтәше Ашот Казарян, тумышы белән мәскәүле, унганбулдыклы эшмәкәр, хәзергечә әйтсәк, бизнесмен, «Арарат» дигән сату-алу фирмасы тота. Аның дуслары Америкадан килгән киң күнелле, уенчак егетне Мәскәү тормышына ияләштерергә керештеләр. Алар ярдәменнән башка Карлен Татлян Мәскәүне һич кенә дә өйрәнеп-анлап бетерә алмас, димәк, үзенә йөкләнгән бурычны да тиз генә үтәп чыкмас иде, ә вакыт, һәрвакыттагыча, кысынкы булды. Мөгаен, мәскәүле яңа дусларын да Карленның американ һәм халыкара журналист булуы кызыксындыра—кемгә океан артына кунакка барып кайту өчен виза алып бирә, кемгә чит ил паспорты юнәтә, гомумән, Америкадагы тормыш-көнкүреш турында файдалы киңәшләр әйтә: анда илтеп ни-нәрсәне әйбәт кенә бәягә сатарга, аннан тагын табышлырак ни-нәрсәләрне бирегә алып кайтырга була—һәммәсен дә өйрәтә иде. Шулай итеп, үзеннән-үзе һәр ике як өчен дә кулай бергәлек барлыкка килде. Ашот та, Карлен да, күпчелек дуслары да, яшьләре утызларга житеп килсә дә, ә кайберләре инде ул чикне байтактан узган булсалар да, әле өйләнмәгән буйдаклар иде. Юкса, утызлар тирәсе гаилә кору өчен иң кулай вакыт санала-саналуын, әмма, күрәсең, бу көчеш-борылыш еллары, тотрыксызлык, яшьләргә чума авыруы кебек йоккан бизнес мәшәкате өйләнү-фәләннәрне арткарак чигереп тора иде. Бу хәл Карлен Татлян өчен дә бик уңайлы—дусларының буш вакытлары житеп арткан, төннәрен кәеф-сафа коруны яраталар һәм иң мөһиме—акчалары бер букча иде.

Мәскәүдә бер өч айлап яшәгәч, Карленга яңа танышлар да табылды: алар Арбаттагы төнге «Метелица» клубында очраклы гына очрашты. Карлен анда үзе белән Ереванда бер сыйныфта укыган биш егеткә тап булды. Кайсысыныңдыр туган көнен үткәрергә мәжлес корган бу төркемдә Ереванның Саокан урамындагы билгеле композиторлар йортында яшәүче өч егет тә бар иде. Калганнарын да белә иде Татлян—егетләрнең барысы да диярлек бер кварталдан, ә житмешенче еллар ахырында Ереван ул кадәр үк зур шәһәр түгел иде әле. Бу ереванлы дуслар Мәскәүдә ярым легаль хәлдә яши, пропискалары юк, төрле жирдән фатирдыр-бүлмәдер юнәтеп, вак-төяк бизнес белән шөгыльләнә: сәүдә палаткалары, ларекләр тота, кайдандыр нәрсәләрнедер, күпләп сатып ала да шуннан табыш чыгара, кайберләре автосервиста эш майтара. Әрмәнстанда ул чорда бик көчле икътисади кризис, галәмәт эшсезлек, кыргый инфляция—үз акчалары—драм көне-сәгате белән бәясен югалта, аның Әрмәнстаннан башка бер жирдә дә кирәге юк, шуның өстенә—Карабахтагы туктый алмаган сугыш... Менә болар барысы да иң әүвәл яшьләрне жылы ояларын ташлап китәргә мәжбүр итте. Россиядә теләсә нинди бизнес-сәүдә эшенә—банкмы ул, зиннәтле чит ил маркалы машиналармы, кыйммәтле күчемсез милекме яки Карленның сыйныфташларыныкы шикелле юк кына ларек-фәләннәрме—һәрберсенә «түбә» кирәк. «Түбә» дигәне шул: сине яклап-саклап торучы, шуның хисабына синнән акча каеручы төркем инде ул. Мәскәүдәге милли жинаятьчел төркемнәр арасында әрмәннәр соңгы урында саналмый, алар чечен, дагстан яки әзербәйжан төркемнәреннән күп алдан барлыкка килгән. Грузиннар белән берлектә әрмән мафиясе ак кала-башкалада иң өлкәннәрдәндер, аның башында әле легендар Сво торган. Хәерчелек-ярлылык үз сыныгын намус белән эшләп табарга теләүчеләрне генә түгел, һәркайда күп булып үрчегән шикелле, Ереванда да үрчегән һәртөрле бандитларны да Әрмәнстаннан читкә куды. Карлен Татлянның сыйныфташ егетләре дә үзләренең вак-төяк сәүдә эшләрей

үз милләттәшләре «түбәсе»нә ышыкланып кына майтара иделәр. Шуларның кайберләре әлеге кичтә «Метелица»да элекке сыйныфташының туган көнендә сыйланып утыра иде. Аннары соныннанрак Киев вокзалы янындагы «Редиссон-Славянская» кунакханәсе ресторанында үткән бер бик бай мәҗлестә аларның кайберләре белән Карленны да таныштырдылар.

Әле ул вакытта Мәскәү тормышына бик төшенеп житмәгән американ хәбәрчесе бу гангстерларның үз «һөнәрләрен» яшермәүләренә, хәтта шуның белән горурлануларына бик гаҗәпләнгән дә иде. Тегеләр киң күңеллелек күрсәтеп, бу тынгысыз Мәскәүдә аны үз канатлары астына алырга вәгъдә дә биреп куйдылар. Ул кичтә Татлян: «Нәкъ егерменче еллардагы Чикагода кебек икән»,—дип уйлап та алган иде. Ул, әлбәттә, башкаланың җинаятьчел дөньясына шулай җинел генә килеп төртелү шатлыгын беркемгә дә сиздермәде, мондый танышлыклар аңа йөкләнгән төп бурычның аерылгысыз бер өлеше булырга тиеш иде.

Инде ярты елдан соң Татлянның Мәскәүдәге танышлары шактый ишәйгән, ул танышлар төрле катлам кешеләре иде. Болар, әлбәттә, Ашот Казарянның бик күпләр белән бәйләнештә булуы нәтиҗәсе булды—ул бит театрал, гомумән, сәнгатькә гашыйк шәхес. Карлен үзе дә, музыкаль гаиләдә үскәнлектән, гитарада менә дигән уйный, фортепьяноны да чит итми, студентлык елларында яшьләр төркемендә җырлап та йөрде. Шунлыктан ул үз газетына Мәскәүдәге мәдәни тормыш турында еш кына хәбәрләр дә җибәреп тора иде. Бер театр-концертлар сезоны дәвамында ук ул сәнгать дөньясында үз кеше булып китте, зур концерт яки абруйлы-дәрәҗәле артистлар белән очрашу кичәләрен сирәк калдыра башлады.

Гамьсез тормыш алып баручы артистлар, рәссамнар, әдәбиятчылар һәм башка зыялылар төркемен, гадәттә, богема мөхите дип атыйлар. Еш кына менә шундый төркемнәр арасында йөри торгач, Татлян бервакыт Картьены очратты һәм, әлбәттә, фырт-көяз киенгән бу егетнең җәмгыятьтә «яңа урыслар» дип йөртелә торган катламнан икәнлеген шундук абайлап алды. Хәер, ул кичтә Татлян Слава Неделинга артык игътибар да итмәде: сәнгать әһелләре тирәсендә, гадәттә, һәрвакыт һәм һәркайда, һәр илдә «алтын яшьләр» күп бөтерелә. Бу яктан караганда, зур тизлек белән янарып-үзгәреп килгән Мәскәү дә аерылып тормый иде, әлбәттә. Ләкин «Пекин» ресторанында очратканга кадәр әле исеме дә Карленга билгесез булган бу егет аның күзенә тагын бер мәртәбә чалынды. Һәм бөтенләй башка хәлләрдә. Ә монысының инде халык мыжгып торган галәмәт зур башкалада игътибардан читтә калуы гайре табигый булыр иде. Бу икенче очрашу «Трефовый туз» дип танылган билгеле казинодагы каһәрле көнне булган иде.

Татлянны ул казинога «Редиссон-Славянская» кунакханәсе ресторанында сыйныфташлары таныштырган әрмән гангстерлары чакырган иде. Татлян аларга ничектер, сүзләренә бик артык басым ясамыйча гына, журналист буларак, үзенә «яңа урысларның» урыс рулеткасы уенын күрәсе килүен сиздереп куйган иде. Алган тәэсирләре гомер онытылмаслык булып калды, болай акылдан шашкандай уйнауны, мондый котырынып уенга куелган зур суммаларны аның әле һичкайчан да күргәне булмады. Кайдадыр артистлар төркемендә күзенә чалынып калган теге егетне менә шул «Трефовый туз» казиносында икенче тапкыр очратты да инде ул. Егет уенны алып баручы крупье янәшәсендә утыра һәм, шактый зур суммалар куя-куя, гел бер-бер артлы оттыра бара иде. Шул оттырышлары белән Карленның игътибарын үзенә җәлеп итте дә ул. «Трефовый туз»га ул төндә Карлен белән килгән егетләр шактый зур суммалар отып кына утырдылар, аның үзенә дә мең доллар отыш чыкты.

Ләкин Карлен, уйнаудан бигрәк, уенны һәм уенчыларны күбрәк күзәтте—аның казинога килүенең төп максаты да шул иде бит. Картье ул төндә, иң аз дигәндә дә, бер утыз-кырык мең доллар оттырды. Сәгать төнге икеләр тирәсендә аның кәнәфие янында бик зиннәтле киенгән гаҗәеп гүзәл ике кыз пәйда булды. Картье, йөзенә бернинди ризасызлык

галәмәтләре чыгармыйча гына, өстәл яныннан кузгалды, әлеге кызлар белән, шактый каты кычкырып, төннең калган өлешен кайсы төнге клубка барып күңел ачуны дәвам итү турында фикер алыша башлады. Карлен хәтеренә салып куйды: тегеләр «Какаду» клубына барырга булдылар. Егет Карленны оттырган акчалары, аларны җиңел генә өстәлгә ташлый баруы һәм, иң мөһиме, уеннан да шулай ук җиңел генә чыгып китүе белән таң калдырды. «Бер кичтә дистәләрчә мең долларларын шулай ыргытып утыручы бу адәм нинди суммалар белән эш йөртә икән соң?»—дигән уй килде Татлянның башына. «Трефовый туз»да шулай кыланып типтерүче бу байны, кирәге чыга-нитә калса дип, фотога төшереп алмавына да үкенеп куйды ул.

Бер атнадан соң Карленга бу эшне эшләмәве өчен тагын да ныграк үкенергә туры килде. Теге кичтә казинога бергәләп барган егетләр аңа үзләрен «Трефовый туз» хуҗаларының эзләп табулары һәм, бер төргәк фоторәсемнәр күрсәтә-күрсәтә, әллә никадәр күңелсез сораулар белән тинтерәткәннәре турында сөйләделәр. Фоторәсемнәрне күрсәтәләр икән дә: «Монысы кем дә, монысы кем?»—дип төпченәләр икән. «Америка гражданы» дип, синең хакта да сөйләп бирергә туры килде, юкса алар синең үзеңнән дә сораштырырга теләгәннәр иде, диделәр.

Бу хәбәрләр турында уйланып утыра торгач, Татлян кинәт аңлап алды: ул үзенә кирәкле эзгә килеп чыккан ич! Әмма бу эшнең кайсы башыннан тотынырга икәнлеген белми иде әле ул. Шул төндә үк Карлен «Трефовый туз»га барып чыгарга ашыкты. Ләкин аны анда ишектәге күңелсез игълан гына каршы алды: казино бөлгән һәм ябылган. Менә-менә күренә башлаган эз шулай ук көтмәгәндә генә өзелде дә куйды...

Ләкин урысларның бер акыллы мәкале бар: куян аучының каршысына үзе чабып чыга, диләр. Бөлгән казино яныннан Карлен борынын салындырып кайтып, берничә көн үткәч, Ашот, үзенең дуслары белән ниндидер бер бик уңышлы эшләрен «юып» алырга дип, «Пекин» ресторанына юнәлде. Соң мизгелдә генә үзләренә Карленны да иярттеләр. Бер зал аша икенче залда, ерак та түгел зур гына бер төркем утыра иде, табыннарындагы сый-нигъмәтнең муллыгы һәм купшы чәчәкләрнең күплегенә караганда, анда ниндидер бик зур тантана бара иде булса кирәк. Шул кунаклар арасында «Трефовый туз»да типтереп, акча туздырып утырган теге бай кемсәне дә күргәч, Татлянның күзләре шар булды. Бу юлы Татлян үз эшен эшләми калмады инде: яннарында бии-бии, егетнең Слава исемле икәнлеген ишетеп калды. Аңа тагын әле Картье дип тә эндәшкәли иделәр—анысы, күрәсең, кушаматы булгандыр инде. Карлен, кирәге чыга-нитә калса дип, кунакларны да хәтерендә калдырырга тырышты. Җаен китереп, Картьены фоторәсемгә дә төшереп алды, ә кичә азагында, тоткарланган булып, тегенең машина номерын да фотога «эләктерде». Әле шуның өстенә, кунаклар арасындагы бик бизәнгән-ясанган бер туташ белән биегән арада шул туташка үзенең визиткасын да төртергә өлгерде: бу туташ тантананың «гаеплесе» булган Слава-Картье турында шактый нәрсәләр сөйли алыр, ә инде, кирәге чыкса, мөгаен, үзләрен таныштыра да алыр иде. Слава Неделин кебек үк, Карлен Татлян да ул кичне кытай ресторанынннан күтәренке күңел белән кайтып китте.

## Махсус вәкаләтле кеше

### I

«Пекин»да бәйрәм үткәргән көннең икенче иртәсендә Неделин гадәттәгедән соңрак уянды. Ванна бүлмәсенә юынырга үтешли, ул өстәлдә үзенең «Соглядатай» дип аталган фотоаппаратыннан алынган микропленканы күрде, кытай ресторанында кичә үткәргән күңелле

истәлекләре шундук очып юкка чыктылар. Иртәнге аш итеп, буйдакларча гади генә бутерброд белән зур чынаяк кофе эчеп утырганда, ул ирексездән кичәге сый-нигъмәт тулы өстәлләрне хәтереннән үткәрде, әмма бүген ул хакта фәлсәфә корып утырырга вакыты юк—тизрәк кичәге хәл-вакыйгаларга ачыклык кертергә кирәк иде. Ул кухня өстәле өстендә тиз генә шундый сүзләр сызгалап алды: «Рәсемдә өстенә соры твид пинжәк һәм чия төсендәге күлмәк кигән яшь кешенең кем икәнлеген бик ашыгыч ачыклавыгызны үтенәм. Аның минем белән бик нык кызыксынуына иманым камил. Ул төркемдәгеләрдән берсен дә элек очратканым булмады. Филипп».

Аннары Картье Кутузов проспектындагы йортның телефон номерын җыйды, трубкада көр генә карт кеше тавышын ишеткәч, исәнләште дә:

—Бабакай, әгәр вакыт булса, мин, мөгаен, бүген сезгә сугылып чыгармын,—диде, үзе җавап та көтеп тормыйча, трубканы тиз генә куярга ашыкты.

Бу сүзләрнең мәгънәсе болай иде: ярты сәгать эчендә ул отставкадагы милиция полковнигының почта тартмасына мөһим хәбәр салып китәргә тиеш.

Тол калган карт полковникның апартаментлары Неделин өчен үз хуҗасы белән конспиратив очрашу хезмәтен дә үти иде. Урыны да, Мәскәү районнарының берсендә элек угрозыск башлыгы булып эшләгән йорт хуҗасы үзе дә Картье өчен бик кулай иде. Халык күп йөри торган шау-шулы проспект, унике подъездлы йорт, парадный ишек төбенә төрле урамнардан туп-туры килеп туктау мөмкинлеге, Триумфаль арка ягына карап тора торган тәрәзәләр—Лубянкада һәммәсен дә төптән уйлап эшләгәннәр шул.

Филипп исеме Неделинның һөнәри псевдонимы—тәхәллүсе булып, ул Лубянкада да, Петровкадагы 38 нче йортта да документ кәгазьләрендә шул шифрланган исем белән йөри иде. Инде өч елдан артык ул илдәүләткә каршы икътисади диверсия-корткычлыклар, эре финанс аферalaры, таларга әзерләнүчеләр, мафия белән бәйләнгән югары дәрәҗәле дәүләт түрәләре, ришвәтче хөкүмәт хезмәткәрләре, Россия өчен бик мөһим яшерен серләрнең читкә китүе кебек бик җитди мәгълүматларны җыеп тапшыра барып, үзенең бу исем-псевдонимына тәмам ияләшеп беткән иде инде.

...Армиядә хезмәт итеп, 1988 елның декабрендә Мәскәүгә кайтып төшкәч, Неделин МГИМОга (Мәскәү дәүләт халыкара мөнәсәбәтләр институтына) укырга керергә ниятләде. Армия срогы эш стажы булып хисаплана, флоттан алып кайткан характеристикалары да менә дигән: часть комсоргы, хәрби һәм сәяси әзерлек отличнигы, разрядлы спортчы, инглиз телен су кебек эчә.

Керү имтиханнарына кадәр әле ярты ел вакыт бар иде. Слава Неделин бер газеттагы игълан буенча хосусый бер нәшрият өчен инглиз теленнән тәрҗемәләр белән шөгыльләнде. Август айларына таба аннары инде ныклап дәресләргә тотынды, икеләнерлек урын калмаска тиеш—яше дә шактый бит. Әмма... Әмма... Имтиханнарда ана нибары бер балл җитмәде... Чиктән тыш күңелсезләнеп, институтның кабул итү комиссиясеннән документларын алырга килгәч, секретарша аңа шәхси эшен кайтарып бирде дә, кинәт исенә төшереп:

—МГИМОның спецбүлегенә кереп чыгуыгызны сораган иделәр сезне,—дип, анда ничек барырга кирәклеген аңлатты.

Неделинга спецбүлекнең ни-нәрсә икәнен һәм мондый җитди институтта аның нәрсәләр белән шөгыльләнгәнен аңлатып торасы юк иде, гаҗәпкә калган булса да, коридорның иң караңгы почмагындагы әлеге әйтелгән бүлмәгә кереп чыгасы итте. Аны пенсия яшендәге, әмма һаман да әле хәрбиләрчә төз гәүдәле, озын гына бер агай каршы алды, күрәсең, яшьлек елларында шактый җитди эшләр белән шөгыльләнгән булгандыр. Неделинга утырырга тәкъдим итеп, ул берниндн кыланусызнисез кинәт кенә әйтеп куйды:

—Кызганыч, укытучыларыбыз сезне абайлап бетермәгәннәр икән. Безнен бүлек тә хата жибәргән. Шушындый студентны ычкындырырга соң... Кызганыч...

Аннары ул берничә минут нәрсәдер уйланып утырды да, шуннан соң өстәлдән алдан әзерләп куелган кәгазь кисәген алып, аны аптырашта калган Неделинга сузды. Блокноттан өзеп алынган кәгазьгә эре хәрефләр белән «Виктор Степанович» дип язылган һәм эш телефоны күрсәтелгән иде, беренче саннарына караганда, кайдадыр Мәскәүнең үзәк районнарынын берсендә булырга тиеш иде ул.

Бүлмә хужасы торып басты, очрашуны тәмамлаганга санап:

—Һичшиксез, шылтыратыгыз. Бер ябык уку йортына керү турындагы тәкъдимне дә уйлагыз. Уңыш телим.—Чыгып китәр алдыннан өстәп куйды:—Ышанам, безнен бу сөйләшү һәм сезгә ясалачак тәкъдим турында беркем белән дә киңәшмәскә тиешлегегезне аңлыйсыздыр.

Неделин эшне тиз тотарга булды. Кайта-кайтышлый ук беренче телефон будкасына керде дә, күрсәтелгән номерны жыеп, үзенең язмышын ничектер үзгәртергә тиешле әлеге Виктор Степановичка шылтыратты.

Телефон трубкасын башта секретарша алды һәм Неделин, үз исемфамилиясен әйтеп, аны Виктор Степанович белән тоташтыруларын үтенде, моны көттермәстән эшләделәр.

Сүзне озын-озакка сузып тормыйча, билгесез әңгәмәдәш туп-туры эшкә күчте:

—Без сезнең белән кайчан очраша алабыз?

—Теләсәгез, хәзер үк,—дип куанып жавап бирде Неделин.—Сез әйткән жиргә машина белән барып та житәрмен.

Бераз тынып торганнан соң, аңардан үзенең кайдан шылтыратканлыгын сорадылар. Неделин Горький урамындагы Үзәк телеграф автоматларынын берсеннән икәнен әйткәч, Виктор Степанович: «Егерме минуттан шунда булырмын»,—диде.

Слава Неделин Үзәк телеграф янына килеп туктаучы машиналарны ничек кенә тырышып күзәтеп тормасын, үзе көткән кешене барыбер абайлый алмый калды. Утыз биш-утыз жиде яшьләрдәге пөхтә киенгән кеше кинәт кенә аның каршысында пәйда булды һәм, кул биреп:

—Исәнмесез, Вячеслав Михайлович,—диде.—Мин Королев Виктор Степанович, таныш булыйк.—Алар ирләрчә каты итеп кул кысыштылар.

Королев шундук Славаны яннарына тавышсыз гына килеп туктаган, күзгә бәрелеп тормый торган соргылт «Волга»га утырырга чакырды. Ярты сәгатьтән алар инде бер бүлмәдә сөйләшеп утыра иделәр. Бу квартиранын Королевныкы түгеллеген Неделин тиз сизенеп алды, әмма Виктор Степанович үзен биредә бик иркен тота иде.

Әңгәмәнең башында ук, Неделиннын кулындагы шәхси эшләр папкасын күреп, Виктор Степанович елмаеп әйтеп куйды:

—Юкка сез документларыгызны алырга ашыккансыз, сөйләшүебез ничек тәмамлануга карамастан, без сезгә ярдәм итәргә булдык. Безгә институтнын спецбүлегеннән шылтыраттылар һәм, әгәр дә без сезнең белән сөйләшеп килешә алмасак, сезнең анда яңадан кереп чыгуыгызны үтенделәр. Әгәр дә сезне югары белем алуның без тәкъдим иткән варианты канәгатьләндермәсә, сез МГИМОда укый башлый аласыз, монысы да килешенгән. Бер балл тегендә, бер балл монда икән—аның берниндә әһәмияте юк. Безнең заман өчен сезнең биографиягез менә дигән, хөрмәткә лаек гаиләдән, әти-әниләрегез...

Мондый кереш сүздән соң Неделин тигезрәк сулыш ала башлады, тормышы чәлпәрәмә килгән кебек күренми иде инде, һәм ул көтмәгәндә генә әллә кайдан килеп чыккан бу игелекле кешене, үзен яклаучы изге затны бик игътибар белән тыңлый башлады.

—...Бүген, куәтле дәүләтебезне эчке ыгы-зыгылар, әрләш-талашлар тетрәндереп торуга карамастан, дәүләт үз курсын кискен үзгәртергә һәм реформалар юлыннан китәргә тели икән, без, тиешле органнар хезмәт-

кәрләре, тәҗрибәбездән чыгып һәм илдә барган вакыйгаларга, бүгенге вәзгыятькә анализ ясап, шуны күрәбез, җәмгыятебез гаять зур тетрәнүләр алдында тора. Хакимиятне бүлү, дәүләт милкен бүлгәләү, тотрыклы билгеләнгән милли-территориаль чикләрне аеру,—бигрәк тә дәүләт йомшап калган бервакытта,—болар чын-чынлап зур сугышка әверелеп китәрдәй җирле сугыш конфликтлары китереп чыгарыр. Шул конфликтлар һәм халыкларның бер-берләренә милли дошманлыклары нәтиҗәсендә качаклар ташкыны барлыкка килер. Хәерчелек-ярлылык, эшсезлек, әхлакый һәм сәяси ориентир-маякларның булмавы көнкүрештә азга да канәгать булып яшәргә күнеккән җәмгыятебезнең әхлаксызлыкка төшеп китүенә китерер. Барыннан да бигрәк зур тизлек белән җинаятьчелек мона кадәр күрелмәгән кискен үсеш-күтәрелеш алачак, талау-көчләүләр, террор күренешләре авыл-калаларыбызны ташкын булып күмеп китәчәк. Казна-дәүләт милкен талау-үзләштерү, коррупция-ришвәтчелек, галәмәт зур финанс һәм сәнәгать афералары, алдашу-хәйләләүләр һәрвакытта да болгавыр, гаугалы-чуалышлы заманнарның юлдашлары булган. Бу хакта безгә көн саен аналитик үзәкләребез хәбәр итеп тора, ә бит бездә, гомер-гомердән шулай килгән инде,—көчсез-йомшак кадрлар эшләп утырмый.

Ләкин без бүген күнелсез перспективалар турында сөйләшмәбез, илнең чынбарлыктагы вәзгыятенә һәм ин якын араларда булачак хәлләренә күз салырбыз, алары бит хәзер бигрәк тә күзгә бәрелеп тора.

Неделин: «Мине кайда кодаларга маташа соң әле бу?»—дип уйлап бетерергә дә өлгермәде, Королев, аның уйларын укыгандай, сүзне үзе шул якка борды.

—Без сезне байтактан бирле җентекләп күзәтеп киләбез, биографиягезне дә тәфсилләп өйрәндек, гаиләгезнең, барлык туганнарыгызның, якыннарыгызның тарихы белән таныштык—сезгә бер үк вакытта эшләргә дә, укырга да тәкъдим итәргә телибез, органнарда, махсус подразделениеләрдә.

—Хәзер үк эшме?—дип, тыелып кала алмыйча, гаҗәпләнеп әңгәмәдәшенең сүзен бүлде Неделин.

—Әйе, эш. Сезнең армиядә алган әзерлегегез бик төпле-нигезле. Сез хокук саклау органнарында хезмәт итү өчен тулысынча яраклы. Шуның өстенә—интеллект-акылыгыз, телләрне белүегез, холык-табигатегез, нинди дә булса тизләтелгән махсус курсларда укый алу мөмкинлегегез. Һәм, әлбәттә, безнең ябык уку йортларында читтән торып белем алу, төрле илләр, алардагы тормыш-көнкүреш белән танышу өчен чит ил университетларына стажировкаларга бару, чит телләрдә сөйләшү күнекмәләрен ныгыту. Болар барысы да ахыр чиктә менә дигән белемлезыялы кеше булуыгызны тәэмин итәр,—дип, сүзен саф инглиз телендә елмаеп төгәлләде Виктор Степанович.

—Кызык...—дип, үзе дә көтмәгәндә ычкындырып куйды Неделин.

—Кызык, дип сез бик дөрес тотып алдыгыз. Ләкин авыр булыр, еш кына хәвеф-хәтәрләр дә килеп чыгар, сезнең ризалыгыгызны алганчы, мин бу хакта да кисәтеп куярга тиешмен. Бүген,—дип дәвам итте Виктор Степанович,—безнең дошманнарыбыз гигант супердержава—Советлар Союзын таркату өчен моңа кадәр күрелмәгән мөмкинлек алдылар һәм, безнең уйлавыбызча, аларга ярдәм эчтән—үз илебездән булыр. Ә аларның максаты ачык: дөньяда бары тик бер генә көчле дәүләт—Америка Кушма Штатлары гына калырга тиеш, һәм ул бар дөньядан үз шартларын үтәүне таләп итәчәк, чөнки СССР шикелле аңа каршы торырлык башка көч калмаячак.

Мин сезгә илдәге сәяси һәм икътисади вәзгыятьнең торышын озаклап һәм, бәлки, күнелсезрәк итеп тә аңлатканмындыр. Әмма бу алшартларны сөйләү кирәк иде. Чөнки нәкъ менә сез—җинаятьчеләр белән бөтенләй башка төрле ысуллар кулланып көрәшергә тиешле яшьләр. Сез ул куркыныч көрәшне еш кына үзлегегездән, ялгызыгыз гына да башкарачаксыз. Сезне нинди дә булса анык куелган бурыч белән бернинди чикләү дә булмаячак, максатыгыз бер генә—Ватаныбызга зыян китерердәй көчләрнең юлларына аркылы төшү.

—Илленче еллардагы кебекме?—дип шаяртмакчы булды Неделин.

—Әйе, якынча шулайрак. Хәер... Ул заманнарда безнең арада һәртөрле убырлар, хыянәтчеләр, икейөзле мөнафикъләр, мөртәтләр һәм казна каракдары юк иде,—дип ачынып җавап бирде Королев.

—Болай булгач, Виктор Степанович, безнең юллар бер булыр. Мин чынлап та, туган илемнең язмышына илтифатсыз түгел. Әйдәгез, вакытны бушка үткәрмик, төп мәсьәләгә күчик, мин нәрсәләр эшләргә тиеш булачакмын?

—Ярар, бик әйбәт. Сезнең безгә кушылуыгызга мин шатмын. Сез ышанычлы кеше булырсыз дип өметләнәм—Королев тагын бер кат Неделинның кулын каты итеп кысты.—Алайса, хәзер сүздән эшкә күчик инде...

Виктор Степанович яңадан ашыкмый гына сөйләргә кереште:

—Җинаятьчел дөньяның, «яңа урысларның»—кыскасы, мафиянең органнарда да, хакимият оешмаларында да үз кешеләре бар. Менә шулар арасына без дә үз кешеләребезне кертеп «утыртырга» тиешбез. Юкса без оттырганнан оттыра гына барачакбыз, аларның комсызлыкларының чиге юк. Безгә аларның уй-ниятләрен белеп тору кирәк, чөнки алар илдәүләт өчен дә, халык-җәмгыять өчен дә бик куркынычлы.

Ул даирәгә үтеп керү өчен иң әүвәл үз шөгылең-бизнесың булсын, бай бул, яшь бул, үз-үзеңә ышанган оятсыз-әрсез бул, шулар мәнфәгате белән яши бел. Кыйммәтле рестораннарга, казиноларга, төнге клубларга йөр, мода күргәзмәләрен, вернисажларны, театр премьераларын калдырма. Кайда «алтын яшьләр»—син дә шунда булырга тырыш. Богема клубларында, артистлар арасында, зур суммаларга уйнаучы катраннарда күзләреңә чалын, журналист кафеларында, танылган адвокат контораларында ешрак бул—хәзер безгә кирәкле мөһим мәгълүматлар шунда сатыла һәм сатып алына. Болар безнең өчен бик тә әһәмиятле. Сез уңган-булдыклы эшмәкәр, бүгенге дөнья кешесе, типтереп яшәүче энергияле шәхес булырга тиешсез. Җинаятьчеләр белән дуслашу да гаепкә саналмый, бигрәк тә аларның законлы каракдары, «авторитетлары» белән элемтәгә керү яхшы булыр иде. Ләкин монда инде сез үз чамагызны үзегез белергә тиеш. Бу соңгылары бик сизгер, алдын-артын карап эш йөртүчеләр, үткен психологлар, аларны хәйләләргә тырышмагыз да—алар сезне «укый» алмаска тиеш.

—Минем боларга көчем җитәр дип уйлыйсызмы?—дип гаҗәпләнеп тә, борчылып та сорады Неделин.

—Тулысынча. Каушамагыз гына. Безнең яшерен агентларыбыз һәрвакыт шулай нульдән башлый инде. Ә хәзер алар арасында алып ашкан милиционерлар, капитализмның чып-чын акулалары бар. Аннары шунысы да бар бит, аларга булышкан кебек, беренче адымнарыгызда сезне дә әзерләячәкбез һәм матди ярдәм күрсәтеп торачакбыз. Шулай булгач, кадерле Вячеслав Михайлович, язмышыгыз үз кулыгызда, тәвәккәлләгез!

—Бик киеренке-кирәкле очракларда минем сезнең белән элемтәм булырмы, яки нинди дә булса даими эшләүче каналлар бармы? Алар миңа беренче вакытларда, бизнеска кереп киткәнче һәм сез куйган бурычларны үти башлаганчы кирәк булачак бит,—дип сорады Неделин.

—Әйе, әлбәттә. Без сезгә почта һәм телефон элемтәсен җайга салырбыз. Хәер, миңа калса, сезне Владивостокта хезмәт иткәндә үк күп нәрсәләргә өйрәткәннәр шикелле, мин сезнең уку программаларыгыз белән җентекләп танышып чыккан идем.

—Әйе, анда безне ныклап әзерләделәр. Ләкин мин ул һөнәрләремнең кайчан да булса кирәге чыгар әле дип уйлап та карамаган идем.

—Юк, Вячеслав Михайлович, бернәрсә дә тиктомалдан гына эшләнми,—дип, очрашканнан соң беренче мәртәбә чын күңеленнән көлеп җибәрде Королев.

Аннары ул тиз генә сәгатенә карап алды да очрашуга нокта куярга ашыкты.

## 2

Шуннан соң инде Неделинның бөтен тормышы, нәкъ Королев сөйләп биргәнчә, искиткеч зур тизлек белән алга китте. Картье—без аның бу кушаматын да онытып бетермик әле,—Тышкы сәүдә академиясенең түләүле курсларында укып чыкты, анда эләгүе дә, баксаң, бик җиңел түгел икән. Шунда дөнья кадәр кешеләр белән танышты, ә иң мөһиме, икътисад, бизнес мәсьәләләре белән ныклап торып мавыгып китте—тизрәк үзен эштә сынап карыйсы килә башлады. Үзе белән укып йөрүчеләрнең байтагының үз бизнесы бар һәм алар аны тагын да киңәйтү турында хыяллана иде—ул чорда әле беркем дә банкротлыкка чыгу турында уйлап та карамый: базар дигәнең иксез-чиксез, бернинди көндәш-фәләннәр дә юк сыман, алда бары табыш, табыш кына ымсындырып тора иде...

Картьеның бер инглиз фирмасы белән төзегән беренче килешүе гадәттән тыш табышлы гына булып калмады, заказчылары күз алдында аның үзенең дә абруен арттырды, чөнки әле ул заманнарда бик сирәк сәүдәгәр генә үзе сата торган товарның ни-нәрсә икәнен күз алдына китерә ала иде, товар югары технологияле һәм интеллектуаль эчтәлекле булганда бигрәк тә. Шул елда ук Картье әти-әниләре янәшәсеннән генә, Кутузов проспектыннан өч бүлмәле квартира сатып алды—бер парта артында утырып ун ел бергә укыган сабакташы әти-әниләре белән Израильгә китеп барган иде.

Күләме белән әле моңа кадәр күрелмәгән галәмәт зур финанс махинациясе үткәрү өчен җинаятьчел дөнья бик югары сыйфатлы берничә белгечне Россиянең Үзәк банкына урнаштырганлыгы турындагы беренче мәгълүматын Неделинның тиешле органнарга тапшырганыннан соң өч ел үтеп китте. Ул вакытта әле ул «ак якалы» җинаятьчеләрнең исем-фамилияләрен дә әйтә алмый, әлеге афераның асылын да ачыклау мөмкин түгел, бары тик аның чечен мафиясе белән бәйле икәнлеген генә белә, чөнки бөтенесе дә бик нык яшерен сер итеп саклана, Неделин да бу хакта очраклы гына белеп калган иде. Бу хәл нәкъ туксан беренче елның августында дәүләт түнтәрелеше алдыннан булган иде. Түнтәрелеш илне бик озакка чыгырыннан чыгарды, аннары айлар буе МВД (эчке эшләр министрлыгы белән КГБ (дәүләт иминлеге комитеты) хезмәткәрләренә ябырылдылар, һәр ике оешмада да кешеләрне урыннарыннан алу, эшне үзгәртеп кору дигән гамәлләр башланды, шунлыктан Неделин-Филипптан кергән мәгълүмат белән җитди шөгыльләнер мөмкинлек тә булмады. Аннары шунысы да бар, Неделин бәйләнеш тоткан кешеләр, шул исәптән, Виктор Степанович үзе дә, урыннарында көчкә-көчкә генә утырып кала алды. Кая ди анда банктагы аферистлар белән шөгыльләнеп торырлык вакыт! Бәлки, аның мәгълүматын алгач, зур суммадагы акчаларны күчергән чагында, акча саклау урыннарында сакны көчәйткәннәрдер дә шуның белән эш беткәндер.

Әмма ярты ел үткәч, бер көн эчендә Россиянең төрле төбәкләрендәге дистәләгән банклардан ялган авизо кәгазьләре белән триллионлаган сумнарны кемнәрдер каядыр күчергәннән соң, иң югарыда утыручылар да Филипп кушаматлы нindидер яшерен агентның әлеге сигнал-хәбәрен исләренә төшергәннәрдер төшерүен... Ә Виктор Степанович, хәтта Филипп белән махсус очрашып, аңа «Гадәттән тыш мөһим!» дигән тамга салынган кәгазь дә күрсәткән иде, ул әле теге чакта ук илнең банк системасында гаять зур афера әзерләнгәнлеген кичекмәстән югарыга хәбәр иткән булган икән, әмма югарыдагылар, ул вакытта көн саен төрле яктан үзләренә kanыгу-өстерүләрдән, яла ягып интектерүләрдән гарык булып, тәмам югалып-катып калган хәлдә иделәр шул... Афераны оештыручылар, бәлки, нәкъ шуңа исәп тотканнардыр да әле...

Иртән язуын тиешле почта тартмасына салгач, Неделин үзенең нindидер яңа кызыклы нәрсәгә тап булганын сизенде, соңгы елларда

аның интуициясе—эчке сиземләү тойгысы бик көчәйгән иде.

Көн төшлектән авышкач, ул Горький урамыннан әллә ни ерак булмаган Инкомбанктан чыгып килә иде, кесәсендәге пейджеры аваз салды. Неделин ашыкмый гына «мерседес»ның ишеген тавыш-тынсыз ачып руль артына кереп утырды, бары тик шуннан соң гына пейджердагы хәбәрне укыды: «Бабакай кич белән чәйгә килүегезне үтенде». Виктор Степанович аны мөһим мәгълүмат белән көтә, дигән сүз иде бу, Филиппны вак-төякләр белән мәшәкатьләп тормыйлар иде хәзер. «Әһә, димәк, нәкъ өстенә бастым»,—дип куанды ул һәм, машинасын борып, Елисеев кибете ягына китеп барды.

Кутузов проспектындагы квартирада берничә ел очраша торгач, ул квартир хуҗасы, элекке оперативник белән дуслашып өлгергән һәм аңа бервакытта да бүләк йә күчтәнәч-фәләнсез бармый иде. Карт яхшы чәй, кофе ярата, тәмлетамак—торт, печенье, конфет ишеләрдән үлеп китә иде инде.

Картье Кутузов проспектына килеп туктаганда, Виктор Степанович аны көтеп тора иде. Аның җанланып киткән йөзенә карауга, Неделин «Пекин» ресторанында очраткан теге кешенең органнарны кызыксындырганын аңлап алды. Өстәл өстендә яхшы сыйфатлы итеп төшерелгән ике фоторәсем ята иде. Королев шуларның берсен кулына алды да түземсезләнеп сорады:

—Син ничек аны эләктерә алдың соң? Алтынчы каттагы коллегаларымны бик шатландырдың син моның белән. Алар бу егетне ярты ел инде күз уныннан ычкындырмыйлар, аны бездә нәрсә кызыксындыра, нинди задание-максат белән килгәнен генә аңлый алмыйлар.

—Шулай ук бик кирәкле кошмыни? Әллә Әрмәнстан хәзер кемнәрнедер махсус кызыксындырамы икән?—дип сорады Неделин.

—Юк, Әрмәнстан кызыксындырмый,—дип җанланып җавап бирде Виктор Степанович.—Ә Карлен Татлян—бу фоторәсемдәге чибәр егетнең исем-фамилиясе шулай,—АКШ гражданы. Ул Иллинойста разведчиклар мәктәбе тәмамлаган һәм ЦРУ (Үзәк разведка идарәсе) белән студент чагыннан бирле хезмәттәшлек итә.

—Әллә мине дә ЦРУга эшкә тартырга телиме?—дип көлеп җибәрде Неделин.

—Белмибез, белмибез. Ләкин аның сине беренче генә күрүе түгел икән. Мин бит аны безнекеләр гел күзәтеп тора дип әйткән идем. Син үзеңнең «алтын таҗ» уеныңны уйнаганда да ул «Трефовый туз» казиносында булган. Менә фоторәсеме, таныйсыңмы?—Королев икенче рәсем сузды. Анда инде Карлен Татлян смокингтан, ак күбәләк-галстуктан иде, аны рулеткага акча куйган чагында төшереп алганнар.—Сорау туа: «Трефовый туз» казиносына ул кичтә Татлян махсус килгән идеме икән? Әгәр шулай булса, аңа синнән ни-нәрсә кирәк? Һәм икенчесе: ни өчен ул кичә «Пекин» ресторанына килгән дә, ни өчен сине рәсемгә төшереп алган?—Королев алтынчы каттагы коллегаларының сорауларын кабатлый иде булса кирәк.

—Әгәр дә ул «Пекин»га очраклы гына килеп кермәгән булса, димәк, минем турыда нәрсәдер белә, бәлки, минем белән очрашасы киләдер яки минем кемнәр белән йөргәнемне белергә телидер?—дип, сөйләнә-сөйләнә, фикер йөртә башлады Неделин.—Аның ЦРУ хезмәткәре булуы күп нәрсәне ачыклый... Виктор Степанович, сез алтынчы каттагыларның аны инде ярты еллап күзәткәннәрен әйттегез: нәрсә белән кызыксына икән соң ул, нинди тыелган-яшерен мәгълүматларны белергә омтыла икән?

—Бөтен табышмак та шунда шул, кадерле Вячеслав Михайлович... Хезмәт урыны «Лос-Анджелес таймс» газетасында аның. Шунда мәдәният мәсьәләләрен яктырта, Россиядәге хәзерге тормыш яналыкларын хәбәр итә, начар эшләми, диләр, башкалабыз тормышындагы бер генә әһәмиятле вакыйганы да ычкындырмый икән. Ләкин ул яшерен объектлар тирәсендә

дә йөрми, фәнни-тикшеренү институтлары, теге яки бу завод-фәләннәргә үтеп керү юлларын да эзләми, галимнәр тирәсендә дә бөтерелми. Хәрбиләр белән элемтә урнаштырганы да, хәрби объектлар белән кызыксынганы да сизелми. Югары хакимияттә утыручылар белән дә дустанә мөнәсәбәтләре юк. Сәер егет, серле шпион. Аның каравы, төрле казино-катранише уен йортларына бик теләп йөри, аларның да иң бай, иң кыйммәтлеләренә генә, уенга катнашса, бик эредән кылана, зур суммалар куеп уйный. Шулай да тыела белә, еш кына ота. Кыйммәтле рестораннарга, мода салоннарына йөрергә ярата, әмма вак-төяк кенә сатып ала, күбрәк үзенең яна дус-танышларына кинәшләр генә биреп тора. Кыскасы, зур акчалар, дөресрәге, котырган акчалар әйләнгән җирләрдә була ул.

—Акчалар белән кызыксына, дисезме?—дип кинәт талпынып куйды Картье, улниндидер бик кирәкле нәрсәне абайлаган шикелле иде.— Монысы бик тә кызык. Акчалар белән беркайчан да тиктомалдан гына кызыксынмыйлар...

### 3

...Шул иртәдә үк, тик берәр сәгать соңрак кына, Мәскәүнең икенче бер читеннән Карлен Татлян үз каналлары аша шифрланган хәбәр җибәрде.

Хәбәр мондый иде:

*«Мин сезгә бер яшь егетнең фоторәсемен һәм билгеле булган координатларын җибәрәм. Миңа аның турында җентекле мәгълуматлар кирәк. Ул бик актив тормыш алып бара. Байлыгы зур. Бер сәгать эчендә казинода кырык меңләп доллар оттырды. Бер атнадан соң кыйммәтле ресторанда зур кунаклар җыеп туган көнен үткәрде. «Мерседес—600» машинасында йөри. Еш кына абруйлы-дәрәҗәле урыннарда була. Бәлки, аның аша үзебезне кызыксындырган мәсьәләләргә дә юл табып булыр.*

*P. S. Шулай ук сезгә ике чечен егете—бертуган Цуцаевларның да фоторәсемнәрен җибәрәм—болар генерал Дудаев даирәсендәге кешеләргә бик якын торалар. Мәскәүгә килгән чакларында акчаны сибәләр генә. Рәсемнәр, минем үтенеч буенча, Кырымдагы Күктүбә казиносында төшереп алынганнар. Очраклы язып алынган сөйләшүләрдән шул аңлашылды: Цуцаевлар якын айларда ниндидер бик мөһим яшерен матди-сәяси миссия белән Лондонга барачаклар. Цуцаевлар үзләре белән алып чыккан акчаларны җентекле экспертиза-тикшерүгә алу мөмкинлеге туа. Алар һәркайда кейслары тулы валюта-долларлар белән йөриләр, шунлыктан, без эзли торган объект Россиядә, Чечнядәдер дип шикләнергә тулы нигез бар.*

*Норман».*

## Тоглар

### I

Ростовның август ае җай гына агып сентябрьгә барып керде, гаҗәп матур көннәр тора иде, төннәрен генә бераз салкынрак булса да, әле кыраулар күренми. Канада (аларны еш кына Американыкы дип бутыйлар) өрәнгеләренең яфракларына чын-чынлап сары куна башласа да, мәһабәт имәннәр беренче авыр чикләвекләрен коярга гына җыена иде әле. Ә көн уртасында һаман да җәйдәгечә җылы, хәтта эссерәк тә. Тоглар «Редиссон-Ростов» кунакханәсендә өч-дүрт көннән артык тормам, дип исәпләсә дә, инде икенче атна үтеп бара иде. Ул үзенә ишелеп төшкән иректән ләззәтләнә-хозурлана, ресторанга кереп искиткеч сыйнигъмәтләрен ашый, акчасын кызганып тормый—юмарт туздыра һәм еш кына бу очракта Юлиан Семеновның акыллы сүзләрен исенә төшерә: акча—ул сугылган, ташка басылган ирек.

«Камея» кибетендә чечен егетләрен очратканнан соң, Константин Николаевич, үзенә Аргентинлы ярдәме белән күп патронлы итальян пистолеты «беретта»ны юнәтеп алды, урамга да ярты битен каплап торырлык зиннәтле караңгы «Полис» күзлеге киеп кенә чыга торган булды. Ювелир кибетендәге очрактан соң беренче өч көндә шул ук Городецкий-Аргентинлы аша үзенә ике әзмәвер егетне яллады, алар шәһәрдә йөргәндә дә аның артыннан калмый, озата бара, кичләрен кунакханә ресторанында Наталья белән ашап-эчеп утырганда да күрше өстәлне биләп утыра иделәр. Соңрак ул шуны аңлады: чечен егетләре, мөгаен, аны шәһәрдән күптән чыгып сызгандыр яки озакка һәм ныклап «төпкә яткандыр» дип уйлаганнардыр—анысы да хак, акылында булган кеше, үзен куркыныч астына куеп, шундый тәвәккәл кыланыр идеме? Бу бит тормыш белән үлем мәсьәләсе иде. Анысы аның аек акыл белән уйлаганда шулай, әмма Фешин чынлап торып гашыйк, андый халәттә кешеләр башларын югалта, бу очракта Фешин да шундыйрак хәлдә иде.

Аргентинлы үз сүзенә турылыклы булып чыкты: бер атнадан ул Мәскәүдән Тогларга шылтыратты, иске «тамырдаш-братвалардан» кочак-кочак сәламнәр тапшырды, Тогларның исән-сау икәнлегенә ышангач, чиксез шатланганлыкларын әйтте, ул Мәскәүгә килү белән, иске гадәт буенча, бергә җыелышып, үткән вакытларны һәм иске дусларны искә ала-ала, матур бер кәеф-сафа корып утырырга теләкләре барын да белдерде. Аргентинлының Тогларга беренче көннәрендә үзенең менә дигән шәп квартирасында торып торырга тәкъдим ясавы да күңеленә бик хуш килде. Әлбәттә, Городецкий Тогларның берничә квартирасы барын да белә, аның аларда булганы да бар, шуларның берсен Фешин үзенең эш урыны итеп саный, махсус эш коралларын, картотекасын һәм архивын да шунда саклый иде. Ләкин алар икесе дә ул квартираларның теләсә кайсында Тогларны чечен егетләре көтеп тору мөмкинлеген дә аңлый иделәр. Тоглар ул квартираларына янадан аяк та басмаска тиеш иде. Тоглар Городецкийга рәхмәтләр әйтеп, әлбәттә, Кутузов проспектындагы квартирасына керәчәгенә дә ышандырды. Аны, чынлап та, Аргентинлының апартаментларын күрәсе килә, мөмкин булса, үзенең дә шул районда, шундыйрак квартира булдырасы килә, анда бит гомерлек мәһабәт йортлар—халык телендә «сталинка» дип йөртелә торган биналар тезелеп киткән. «Редиссон-Ростов» кунакханәсендә озак тормаса да, Тоглар андагы уңайлыкларга, рәхәт яшәүгә, һәр теләгеңне үтәргә әзер торуларына шулкадәр күнегеп беткән иде, шуңа күрә Мәскәүдә дә беренче айларын «Националь»да яки аның янәшәсендәге «Метрополь»дә яшәп торырга карар кылды. Әле бит шунысы да бар: «Метрополь»дәге бишенче катның тулы бер канатын аның элекке тамырдашы-корешы Дантес кушаматлы Олег Лозовской алып тора икән. Ленинград пропискасы сугылган паспорты белән башкалада Тоглар кунакханәдән кунакханәгә күчеп йөри дә ала. Аны әсирлектә тоткан чеченнәр хәзер Мәскәүдә галәмәт отельләр төзеделәр дип сөйли иделәр: «Софитель-Ирис», «Олимпик-Пента», «Президент-отель», «Редиссон-Славянская», «Палас-отель», дисеңме—җаның кайсын тели. Аннары иске, электән билгеле булган «Будапешт», «Берлин», «Савой» кунакханәләрен дә эчен-тышын танымаслык итеп үзгәртеп бетергәннәр һәм иң мөһиме—анда килеп яшәүчеләргә мөнәсәбәт тә бөтенләй башкача икән хәзер.

Натальяга Тоглар «Камея» кибетендә булган хәл турында, әлбәттә, сөйләп тормады, нигә дип әле кызны вакытыннан алда борчырга, ди? Аның бит кызны бик тә үзенә каратасы-ияләндерәсе килә иде. Хәер, алай дип әйтү генә җитмидер—Тоглар Натальяның үзенә игътибарын гына җәлеп итәргә теләми, ул тормышта һәр ир заты хыялланган чын мәхәббәткә сусаган иде. Мөгаен, үзенең киләчәге турында чын-чынлап беренче тапкыр уйлануы булгандыр әле аның, һәм ул сайлаган кыз аның калган бөтен гомерен бизәп, бәхетле итеп торырга тиеш. Тогларның кесәләре тулы миллионнар бит... Аның язмышы көтмәгәндә шундый

ике зур уңышка, ике уен тузына тап булды: вакытка һәм акчага. Әйе, вакыт, барыннан да битәр иркле Вакыт галиҗәнапләре, ә миллионнар—соңыннан... Әгәр дә Тоглар бу акчаларга бүген түгел, әйтик, бер ун еллар элек хуҗа була алган булса, ни-нәрсә генә эшли алыр иде? Ул заманнарда Парижга яки Лондонга очып кына барып кайта алыр идеме соң ул? Раштуа бәйрәмен һәм Яңа елны Сейшель утрауларында каршы ала алыр идеме? Яки Кутузов проспектыннан менә дигән квартира эләктерер идеме? Иң яхшы Европа дизайнерлары проекты буенча ремонт ясатып, аны җиһазлый алыр идеме? Яки «мазерати» автомобиленә ия булыр идеме? Үзенең атаклы бабасы рәссам Николай Иванович Фешинның картина-рәсемнәре турында тулы каталог бастырып чыгара алыр идеме? Мондый хәлләрне хәтта берәр Политбюро әгъзасы үзенең иң матур төшләрендә дә күрә алмас иде. Кая, ди, анда ниндидер партия боссы, моның ишеләрне күренекле бертуган Стругацкийлар да уйлап таба алмас иде. Вакыт! Заман! Тогларга хәзерге заман бик фарт килде, ул аны бары тик биредә—Ростовта гына аңлап алды.

Ул үзенең алдагы уй-хыялларын бары тик Наталья белән генә бәйли иде.

Хәер, Наталья үзе дә матур төш күреп яшәгән кебек яши: көн саен бик зиннәтле итеп бизәлгән бер үк өстәл, ресторан шәмнәре яктысындагы тәмле сый-ниганәтләр, юка саксон фарфорлары һәм көмеш чәнечке-кашыклар венециан пыяласыннан эшләнгән фужер-бокалларда, креманок-ларда чагылып, аерым бер күтәренке-шатлыклы рух биреп тора иде. Ә бик уйлап әзерләнгән, бер дә диярлек кабатланмас меню—ягъни аш-су, ризык? Ә оста сайлап куелган чәчәкләр һәм көн саен яңа француз шампан шәрабе? Кыз аларның кайсына өстенлек бирергә дә белми: ана «Биллекарт-Сальмон» да, «Крюг»та, «Мерсьер» дә бик ошый һәм, әлбәттә инде, әле Пушкин әсәрләрендә үк телгә алынган «Тумышы Понсарден булган тол ханым Клико» шампаны? Әллә болар барысы да әкияттә тиң түгел идеме? Натальяның шампан шәрабләрен бигрәк тә яратканын белеп алгач, Тоглар үз номерындагы суыткычны төрледән-төрле шәрабләр белән тутырды, аларның исемнәре генә дә башыңны әйләндерерлек, татлы хыялларыңны кузгатырлык иде.

Ничектер бер кичне ашап-эчеп утырганда, Тоглар Натальяга аны бер айдан Мәскәүгә кунакка чакырачагын әйтеп ычкындырды, кыз, шаяртып, үзенең андый дәрәҗәле юлларда йөрерлек юньле чемоданы да булмаганлыгына офтанган булып кыланды. Икенче көнне кичкелекне ашап-эчеп номерга күтәрелгәч, Константин Николаевич елмаеп әйтеп куйды:

—Чемоданыңны алып китәргә онытма. Синең хәзер Мәскәүгә барудан баш тартырлык сәбәбең юк инде, гүзәл леди!

Шунда гына кыз ишек янында алтын-сары йозакларын балкытып, алтынсу көпчәкләрен елкылдап торган зиннәтле зур күн чемоданны күреп алды да куанычыннан-каушавыннан чак кына артына егылып китмәде. Мондый чемоданны ул «Астория» күршесендәге итальян кибете витринасында күреп калган иде. Бу мизгелдә ул хәтта яхшы эшләнгән кыйммәтле чемодан күненнән исен дә тойган шикелле булды.

—Ачып кара әле,—дип, Константин Николаевич кызны бүләккә таба җиңелчә генә этеп җибәрде.

Кыз куанычлы түземсезлек белән тыгыз йозакларны чыртлатып ачты һәм зур чемодан эчендә тагын шундый кечкенәрәк бер чемодан күрде.

—Анысын да ач,—диде Тоглар.

Анысы эчендә юлда йөртә торган саквояж-кофр ята, ул да хатын-кызларныкы иде, Тоглар ирләр өчен эшләнгән нәкъ шундыйны үзенә «Формани» кибетеннән алган иде инде.

Наталья саквояжны тартып чыгарды да алгы бүлмәдәге зур көзге каршысыннан бер-ике әйләнде, аннары, күрәсең, йомшак күненә һәм алтынсу келтрифүтләренә соклана-соклана, «молния» йозагын ачып

җибәрде һәм сoклануыннан: «Ах!»—дип кычкырып куйды. Саквояж эчендә иң төп сюрприз-бүләк—саквояж белән чемодан төсендә үк эшләнгән кечкенәрәк нәфис хатын-кызлар сумкасы ята иде. Бу—иң атаклы һәм иң кыйммәтле француз фирмасы «Дюпон»ның дөньядагы иң бай хатын-кызлар кулында гына йөртергә эшләнгән тыйнак кына, әмма саф алтын «Д» хәрефе-логотипы сугылган сумкасы иде.

Соклануы һәм рәхмәт хисләре ташып чыккан кыз Тогларның муенына атылды, аны туктаусыз шашынып-шашынып үбә башлады.

2

Мәскәүгә Тоглар сентябрь урталарында кайтып керде. Домодедово аэропортында аны Городецкий каршы алды, салкын, юеш көн иде, бөтен дөньясын каплап алган вак яңгыр ява, көтеп тору залының шар ачык ишекләре аша үтәли җир йөри, ул юеш урман, череп барган яфрак һәм гөмбә исләрен китерә. Кояшта янып каралган Тогларның өстендә аксыл җинел костюм иде, әле җәй исләрен дә җуймаган җылы Ростовтан соң, ул шундук куырылып калды, үзен уңайсыз-шыксыз итеп тойды. Тегендә, янында Наталья булгангамы, пәлтә, плащ, көзге ботинкалар, зонтик, шарф һәм перчатка ише әйберләр аның уена да кереп карамаган иде.

Аргентинлы, Тогларның кәефсезләнгәнен сизенеп, гадәтенчә мыскыллап-шаяртыбрак әйтеп куйды:

—Шулай, туган, җәй үтеп тә китте. Мәскәү сиңа Ростов түгел. Әмма син кайгырма, хәзер һәрнәрсәне дә җинел төзәтеп була, безнең заман килде! Әгәр сине көзге-кышкы кием-салым, яки беренче мәлгә акча-фәлән ягы борчый икән, аптырама. Минем атна буе әйбәт кенә отып торган чагым, кәртнең иң шәпләре керә дә тора кулга, әле бервакытта да болай озаклап фарт килми торган иде, хәтта кайвакыт куркынып та китәм—юньлегә булырмы икән бу, дим, Теләсәң күпме сорасаң да була. Үз кешеләр бит, соңыннан хисаплашырбыз.

Городецкийның иркен ак «вольво» машинасында җылы иде, Мәскәүдәге пычрак җепшеклектән күңелдә туган беренче тәэсирләр тиз юкка чыкты, Тоглар әле уйлары белән һаман да Наталья елап басып калган Ростов аэропортында иде. Шулай да ул Городецкийның сүзләрен җавапсыз калдырмады:

—Рәхмәт, братан,—диде.—Акчалар белән тәртип минем. Беренче вакытларга житеп торыр дип уйлыйм. «Чехлар», чеченнәрне әйтүем, мине исән-сау килеш бервакытта да җибәрмәячәкләрен белеп, әйбәт түләп килделәр, алар кешене кызыксындыру кирәклеген белә иделәр. Аннары, сер итеп сиңа гына әйтәм,—ул ни өчендер зурдан шыттырырга булды,—киткәндә, мин аларның казналарын эләктереп чыктым. Җиде бәлагә—бер җавап.

—Жилле!—дип сызгырып куйды Аргентинлы.—«Чехлар»ны төп башына утыртуны теләсә кем булдыра алмый. Егет икәнсең!

—Өч ел әсирлектә утыру, мөгаен, аз суммага төшмәгәндер. Чечен казнасы—миңа китергән әхлакый зыяннары өчен дә, сине һәм братваны озак күрми торганым өчен дә әҗерләре булыр,—дип, үзенең оста төтен җибәрүенә куанып, рәхәтләнеп көлеп куйды Тоглар. Ахыр чиктә, аның баштагы чордарак зур-зур чыгымнар ясавы берәүдә дә кызыксыну яки гаҗәпләнү тудырмас, ичмасам.

Константин Николаевич Городецкийдан үзен хәзер үк «Националь» кунакханәсенә яки «Метрополь»гә илтеп куюны ничек кенә ялварып сорамасын, тегесе аяк терәп каршы килде.

—Миндә бер ике-өч көн торырсың, аңга килерсең, аннары «Метрополь»гә күчәрсең,—диде.—Анда Дантес алдында һәммәсе дә аяк

очларына басып кына йөри, сиңа, аның иске тамырдашы-корешына, хөрмәт вә ихтирам гына булачак.

Шулай итеп, алар Кутузов проспектындагы Тогларның бик тә күрәсе килгән Городецкий йортына барып керделәр. Өченче каттагы биш бүлмәле квартира икән, ишек төбендә консьержка-хезмәтче хатын тора, бусагадан атлауга саллы бронза тоткалы, бөтен иркен баскыч мәйданчыгын күзәтеп торучы телевизор күзле, үзе кызыл агач белән тышланган авыр бронза ишек—болар барысы да Тогларны таң калдырды. Алгы бүлмәгә каралтылган агач түшәлгән, берьюлы биш-алты пар киенә-чишенә алырлык киң коридор диварына кызгылт тамырлары беленеп торган яшькелт мәрмәр ябыштырылган. Биеклеге дүрт метрлар чамасы булган түшәмнән галәмәт зур йөзем тәлгәшләре рәвешендә ясалган әллә ничәшәр потлы ике бәллүр люстра асылынып тора. Һәркайда көзгеләр, рәсем-картиналар, идәнгә дә куелган, диварларга да эленгән яктырткычлар, бралар, торшерлар; бронза һәм фарфордан җиләнгән борынгы кытай вазалары; ак чия агачыннан нәфис-биек консольләрдә үсеп утыручы кәрлә «бонсай» агачлары—Тоглар үзен нииндидер зиннәтле сарайга яки голливуд йолдызлары тормышыннан берәр күренеш төшерә торган студиягә килеп кергәндәй хис итте.

Городецкий, аның таң калып карап йөрүеннән хушланыплəззәтләнеп, бүлмәдән-бүлмәгә йөртә-йөртә, үзенчә бик әһәмиятле аңлатмалар биреп бара иде. Залларның берсендә, әйтерсең, нәкъ менә Константин Николаевич өчендер инде, камин мичендә ягып җибәргәннәр, нәкъ авылдагыча чытыр-чытыр килеп утыннар яна. Тоглар тирән күн кәнәфигә рәхәтләнеп җәелеп утырды да аякларын утка таба сузып җибәрде. Әйе, Городецкий юкка гына мактанмаган икән—квартирасы мәһабәт, матур иде аның!

Аргентинлы Тоглар кәнәфиенә төрле эчемлекләр-фәләннәр куелган кечкенә көпчәкле өстәлчекне тартып китерде дә, аны ялгыз калдырып, аш бүлмәсе ягына чыгып китте, анда аның хатыны белән ике җиткән кызы табын әзерләп маташалар иде инде. Тоглар Аргентинлының хатыны Светланаңы күптән белә, әмма ничектер аларның кияүгә бирерлек булып пешеп өлгереп җиткән ике студент кызлары да бардыр дип уена да китерми иде.

Городецкийлардагы мәҗлес озакка сузылды. Аргентинлы һәм аның гаиләсе арасында иркенләп утыру Тогларның күңеленә бик хуш килде. Шау-шу, көлешү-шаяртулар мәҗлеснең башыннан алып ахырынача тынып тормады. Күңелләлек-шаянлыкта хатын-кызлар да әтиләреннән калышмый иделәр. Мәҗлес барганда, Константин Николаевич берничә мәртәбә күңеленнән генә Ростовка—Натальясы янына китеп-китеп алды, моның да сәбәпчесе Городецкийның дус-тату гаиләсе булды. Тоглар үзен дә, Натальяны да гаилә тормышында итеп чамалап карый, кайсыдыр мизгелләрдә ул Аргентинлының хатыны Светлана урынында Наташаны күз алдына китерә, аны зур һәм җайлы-уңайлы шушындый йортның кунакчыл хуҗабикәсе итеп күрә иде.

Городецкий бу көнгә билгеләнгән барлык кәрт уеннарын да башка вакытка күчергән һәм алар бөтен кичне дә өйдә, төн уртасына кадәр әңгәмә корып утырдылар.

—Минем дә кайдадыр шушы тирәдә синекенә охшаш квартира сатып аласым килә, бу районны яратам мин. Җәяү йөрергә дә яратам. Тагын бер җитди сәбәбем бар—өйләнергә, гаиләле булырга карар кылдым. Әгәр дә белсәң икән син минем ничек арыганлыгымны... Һәм, дөресен әйткәндә, мин сиңа көнләшеп тә карыйм,—дип, чын күңеленнән, әмма моңсу гына әйтеп куйды Константин Николаевич.

—Син теге Ростовтагы кызга өйләнмәкче буласыңмы?—дип ачыклады Аргентинлы, каминдагы утын кисәкләрен кыскыч белән актаргалапәйләндергәләп, аның йөзен камин уты яктыртып җибәрде.

—Нәкъ өстенә бастың, шуңа. Үз йортымда яшисем килә, кунаклар

кабул итеп, синең белән бергә Яңа елны, Пасханы, Раштуа бәйрәмнәрен каршы аласым килә. Шундый йорт күпмегә төшәр икән?

Аргентинлы бераз уйланып торды.

—Ихтимал, ярты миллион долларлар тирәсе булыр,—диде.—Әгәр син чынлап уйласаң, моны белүе җинел—бер риэлтер конторасының хуҗасы минем танышым. Мин аңа бай клиентлар табып бирәм, ә ул миңа килешенгән суммадан ике процент өлеш чыгара. Димәк, синең квартираңнан да күпмедер тамачак әле миңа,—дип елмайды Городецкий.

—Нәрсә соң ул риэлтер, син әйткәнчә, риэлтер конторасы?—Тоглар аңламаган иде.

—Гади генә, искечә итеп әйткәндә—маклер ул. Яңача, көнбатышча—күчемсез милек белән сату итүче. Хәзер һәр һөнәрнең үз тармагы бар. Һәркем үз куышын сайлый. Алар белән эшләү яхшырак та, аларда һәрвакыт сайлап алыр нәрсә була. Сатарга килешенгән квартирага алар үзләре ремонт ясый, яхшы дизайнер конторалары, мебель фирмалары белән эш йөртә. Кыскасы, байларны юк-бар мәшәкатьтән коткара.

Тоглар кабынып китте:

—Без синең ул маклерыңа хәзер үк шылтырата алабызмы?

—Ә нигә шылтыратмаска?—Аргентинлы өстәлдә яткан радиотелефонны алып, ниндидер номер җыйды.

Аны шунда ук тоташтырдылар.

—Саумы, Серега. Городецкий әле бу. Тормышларың ничек, эшләрең гөрлиме?—Аргентинлы трубкасын Тоглар да ишетелерлек итеп читкәрәк тоткан иде. Тоглар маклерның җавабын ишетте:

—Начар түгел болай. Тагын да яхшырак яшәсәң, тагын да шәбрәк буласы үзе. Риэлтерга тулы бәхет өчен һәрвакыт бай клиент кирәк бит.

—Ә минем шундый бер кешем бар. Дөрес, таләпләре зурдан. Сөйләшеп алырга теләмисеңме?

—Сорап торасың тагын...

Аргентинлы трубканы Фешинга тоттырды.

—Хәерле кич. Минем исемем Константин Николаевич. Сезнең Городецкийның өендә булганыгыз бармы?

—Бар. Ул квартира минем кулдан үтте. Мин аны элекке хуҗасына саткан идем. Безнең фирма анда ремонт ясады. Ничек соң, ошыймы сезгә?

Константин Николаевич хәйләләп маташмады:

—Бик ошый,—диде.—Миңа да шундыйрак бер квартира кирәк иде, тик шушы районда, сталинча йортларда булсын. Беләсенме, иркенлекне, һаваны, яктылыкны яратам...

—Бер генә секунд, компьютерымны кабызыйм әле. —Компьютерында үзенә кирәкле мәгълүматлар чыкканын бераз көтеп торды, ахрысы. Аннары сорады:

—Сез берьюлы түлисезме, әллә өлешләпме? Күчерепме, акчалата турыдан-турымы?

—Берьюлы да, акчалата да түли алам, әгәр, билгеле, сезнең тәкъдимегез миңа ошаса.

—Безнең вариантларыбыз бар, хәтта сез теләгән тирәдә үк, «Украина» кунакханәсе янәшәсендә. Йорт ишегалдында, эчкә кертеп салынган, Кутузов проспектыннан тавышлар ишетелеп, иртәләрен сезне борчымастыр.

—Ничә бүлмәле?—дип сорады Тоглар, ул инде тәмене кергән иде.

—Алтынчы катта бер үк баскыч мәйданчыгында ике квартира. Өч бүлмәле һәм дүрт бүлмәле.

Тоглар уйланыбрак торды да сорап куйды:

—Аларның икесен бергә тоташтырып булмыймы соң?

—Була,—дип көлемсерәде Серега.—Хәзер мөмкин булмаган нәрсә юк бит ул. Сезнең гаиләгез зурмы?

—Юк. Зур түгел. Мин рәссам. Өч бүлмәсендә зур остаханә, студия, кунаклар бүлмәсе булуын теләр идем. Галәти рәссам йорты түгел, ә хөҗрә шикеллерәк. Аңладыгызмы?

—Анладым. Шундыйрак берне ясаган идек инде без. Андый студиягә ярашлы европалы үрнәкләребез дә бар: фоторәсемнәр, гомуми күренешләр. Әмма шундый абруй-дәрәҗәле районда, сталинча йортта, махсус ремонт ясап... ул сезгә бик кыйммәткә төшәр бит.

—Кыйммәт дигәнегез күпме була инде?—дип сорады Тоглар, шатлыгын сиздермәскә тырышып.

—Сигез йөз мен доллар тирәсе. Күпмегәдер киметергә дә мөмкиндер. Сез бит берьюлы ике квартира алмакчысыз, акчалата түләргә дә әзер. Әлбәттә, безгә аванс кирәк булачак, ордерын рәтләү, дизайнерлар, проектчылар, төзүчеләр яллау өчен, дигәндәй...

—Әгәр дә квартира һәм сезнең проектыгыз ошаса, мин барысын да берьюлы түли алам, әмма нинди гарантияләр булачак?

Ләкин шунда аларның сөйләшүләрен тыңлап торган Аргентинлы сүзгә кысылды:

—Ә мин менә гарант булам. Ул бит кем белән эш иткәнен чамалый: шухыр-мухыр маташтырса—башың өзәчәкләр, менә сина бөтен консенсус. Сереганың коллегаларыннан кайсыларыдыр безнең братан Мансур белән хәрәмләшергә маташып караган иделәр, Мансур Петровкадан, төп ментовкалар янәшәсеннән квартира сатып алды. Хәзер инде теге контора да, аның хуҗасы да юк—авыр туфрагы җиңел булсын, ә исән калган компаньоннары шул этлекләре өчен әле һаман булса да штраф түлиләр. Мансур—каты мужик.

Городецкийның сүзләрен ишетеп торган маклер:

—Без намус белән эшләргә тырышабыз,—диде.

—Без иртәгә иртән үк сезнең ул квартираларыгызны карап чыга алабызмы?—Тогларның түземе төкәнгән иде инде.

—Әлбәттә. Кайда очрашабыз? Сезнең телефоныгыз?

—Городецкийга иртәнге унга килегез.

—Яхшы, килештек...—Серега телефонын куйды.

—Менә, өемнән чыкмый гына мин дә уналты баксны эшләп алдым бит әле,—дип шаяртты Аргентинлы. Аннары, исенә килеп, сорады:—Син чынлап та шундый кыйммәт хазаны ала аласыңмы?

—Синең белән янәшә яшәр өчен бернинди акча да кызганыч түгел,—дип, кулларын уа-уа, канәгатьләнеп җавап бирде Тоглар.—Бигрәк тә шундый апартаментларга, анда бит, ниһаять, минем остаханәм булачак һәм мин чынлап торып рәсем сәнгате белән шөгыльләнә алачакмын.

—Рәсем сәнгате белән? Син моны чынлап әйтәсеңме? Мин тагын синең Натальяң шундыйрак пижон салоны булдырырга телидер дип уйлаган идем.—Аргентинлы чын-чынлап гаҗәпкә калган иде.

—Бик җитди сөйлим, кадерлем, бик җитди. Хәзер миңе, Натальядан кала, әлбәттә, бары тик буяулар, пумалалар, киндерләр, мастихиннар гына кызыксындыра. Мин рәсем белән шөгыльләнеп карарга телим, ул минем канымда бар шикелле тоям. Әйдә, минем булачак йортым өчен берне күтәреп куйыйк әле, ул бит синең җиңел кулыңнан килеп чыкты.—Тоглар шактый әсәренгән иде.

—Йортың өчен эчәбез. Йорт—җитди әйбер, бигрәк тә ул шундый унайлы-иплe булганда—һәм алар ак шәраб салынган бокалларын чыңлатып алдылар.

Аннан соң да әле алар, Константин Николаевичның якын киләчәктәге уй-фикерләре хакында гәпләшә-гәпләшә, шактый озак утырды. Һаман да шулай эчпошыргыч яңгыр сибәләп торган тәрәзәгә карап, Тоглар кинәт кенә исенә килгәндәй булды:

—Менә нинди уй-хыяллар корып утырабыз—квартира, остаханә... Ә бит минем иртәгә урамга киеп чыгарлык киемем дә юк әле. Карале син ул юеш-елак яңгырга, иртәнгә дә туктавы икеле булыр... Тиз генә берәр көзге кием-салым юнәтергә кирәк, Мәскәү буйлап җәяү йөрисем килә... сагындырган...

—Монысы да җитди мәсьәлә, хәзер һәркайда киеменә карап кабул

итәләр...—диде Аргентинлы да.—Чүпрәк-чапрак белән дөнья тулган, хет эченә кереп чум, ләкин хәзер Карден белән Версаче киемнәре дә әллә ни-нәрсә саналмый икән, аларныкыннан да шәбрәкләре бар. Бу мәсьәләдә, дөресен әйткәндә, мин үзем бик аңлап та бетермим. Әмма,—дип ачылып китте ул,—минем бер яшь һәм иллә дә инде житез-өлгер компаньоным бар, кайчан да булса ул бөек уенчыга—«тәгәрәтүчегә» кадәр үсеп житәчәк әле, мин әйткән иде диярсең—талант!—Хужа тагын да жанлана төште.— Ярты сүздән, ярты ымнан аңлап ала, борынгылар әйтмешли, барган уңаеннан итек табаннарыңны кисеп ала инде. Мин аны үземә кулдаш итеп, каршы якка үземнең генә тешем үтмәслеген сизенгәндә, яки миңа каршы шулай ук кемнәрдер парлашып уйнаганда гына алам. Менә шул яшь даһиның,—жиңел кулдан гына мин кушкан кушаматы Эйнштейн аның,—менә шуның бер йомшак ягы бар: ул инде, модалы кием дигәндә, акылыннан шашардай була—кыскасы, үзең күрерсең әле. Бүген нәрсә киеп йөрергә, аны кайдан сатып алып була—боларны аңардан да әйбәт белүче юк, хәтта Слава Зайцев белән Алексей Греков та калыша. Менә мин аңа шылтырата алам, миңа яхшылык эшләүне ул намус эше итеп кабул итәчәк.

—Бик шәп! Син риэлтер белән эшне жайладың, инде хәзер имиджмейкер белән дә хәл кыл, алар хәзер шулай атала бугай. Әмма күреп торам: тормыш бик нык үзгәргән—акчаң булса, һәммәсе дә бер мизгелдә хәл ителә һәм иң югары дәрәжәдәге сыйфат белән.

—Дәрәжә, туган, акчадан тора. Ә калганнары—эшне бүлешү генә, һәркем үз эшен башкалардан яхшырак башкарырга тиеш. Уңышка ирешүнең кануны шул. Син беләсең, мин кәрт уйныйм, Ходай миңа шундый талант биргән. Башкаларның—үз талантлары. Димәк, мин Эйнштейнга шылтыратам хәзер.

—Әйдә, әйдә! Шәрә йөрмәм бит инде мин...

Яшь даһины өченче шылтыраткан жирдән генә эзләп таптылар. Үзен чираттагы зур отышлы уенга чакыру өчен борчымаганнарын белгәч, башта Эйнштейн күңелсезләнеп тә калган иде, әмма бай һәм бик хөрмәтле кешене иң югары дәрәжәдә бик шәп итеп киендерергә кирәклеген аңлаткач егеттә рәссам дәрте уянды. Аргентинлының дустын ул шундый итеп киендерәчәк ки, башкаланың иң абруйлы кыланчык пижоннары да көнләшүләреннән шартлаячаклар, дип вәгъдә бирде. Ул Тогларны алырга Городецкийларга иртәнге унберләрдә килер дип килештеләр. дуслар аңа кадәр Константин Николаевич риэлтер тәкъдим иткән квартираларны карап чыгарга өлгерер дип хәл кылдылар, чөнки квартиралар да янәшәдә генә иде бит...

## 3

Иртән Серега минуты-минутка килеп тә житте, шундый бай клиентны ычкындырудан курыккандыр, мөгаен. Бер сәгать эчендә алар «Украина» кунакханәсе тирәсендәге йортны карап та чыктылар. Урнашуы да, ишегалды да, этажы да, квартиралар үзләре дә Тогларга ошады. Алар карый башлаганда ук планлаштыручы архитектор белән дизайнер да килеп житте. Алар, күрсәтә-күрсәтә, бу очракта нәрсәләрне үзгәртеп корырга, янәча планлаштырырга, нәрсәләрне бөтенләй алып ташларга кирәклеген аңлатып сөйләделәр. Бер атнадан компьютерда эшләнгән дизайн-проектны күрсәтергә дә вәгъдә иттеләр. Константин Николаевич аеруча игътибар белән һәм дулкынланып, өч бүлмәле квартираны ул теләгәнчә студия-остаханә итү турындагы тәкъдимнәрен тыңлады. Квартираларны шулай карап чыкканнан соң, Фешин катгый итеп әйтте:

—Алам!

Тоглар әйләнеп кайтканда, яшь кәрт уены даһие аны Городецкийларда көтеп утыра иде инде. Ул сүнгән камин янында йорт хужасы

белән кофе эчә һәм нәрсәдер турында иренеп кенә бәхәсләшә—күрәсең, сүз чираттагы кәрт уенындагы алдашу-аферлар турында бара иде.

Җанланып кайтып кергән Тогларны күрүгә, Аргентинлы әңгәмәсен өзде һәм, кунак белән таныштырып та тормастан, түземсезләнеп сорады:

—Йә, ничек? Ярыймы?

—Әйе, бик тә ярый.—Тоглар канәгать елмаюын яшерә алмады.—Бер атнадан төсле итеп компьютерда эшләнгән дизайн-проектны күрсәтергә булдылар. Шуннан соң мин, ошаса, бөтенесенә тулысынча акчалата түлим. Димәк, син үзеңнең бакcларыңны эшләп алдың дип уйла.

Городецкий шатланып кулларын уып куйды:

—Бик әйбәт! Мин синең өчен дә, үзем өчен дә шатмын. Менә, таныш бул, яшь даһи киeм-салымда да иң купшы-көяз егет. Куркыныч буын үсә. Шунысын да әйтим. Эйнштейн өчен зәвыксыз киенгән кеше кеше дә түгел. Менә шундый дискриминация-тигезсезлек.

Яшь егет үзе:

—Георгий,—дип таныштырды. Ул, чынлап та, бик купшы-нәзакәтле киенгән, үзе йомшак-ягымлы тота, донжуан һәм ловелас. Хатын-кызларны бер карауда җинүчегә охшаган. Модалы һәм кыйммәтле әйберләргә кызыгуы-ымсынуы да, мөгаен, шуннандыр әле.—Ышанмагыз, Константин Николаевич, мэтр—бик хисчән кеше һәм һәрвакыттагыча арттырып та җибәрә. Кием белән киемнең дә аермасы бар, сез менә бүген үзегез дә ышанырсыз. Һәм тагын... Сезнең бәхет баскан чак хәзер: ике ай элек кенә сез, бернинди акчаларга да юньле нәрсә таба алмыйча, Парижга яки Дюссельдорфка очып барып кайткан булыр идегез—соңгы елларда немецлар да зур модникларга әйләнделәр. Хәер, калганы сезнең өчен сюрприз булсын әле. Димәк, кузгалдык?—Ул җинел генә урыныннан торды.

Ишек төбендә көмешсу төстәге купшы «порше» машинасы, хуҗасы кебек үк, өф-өф итеп чистартылган, елык-елык килеп көтеп тора иде. Мөгаен, Эйнштейн бу машинаны кәрт уенында отып алгандыр, анда да Аргентинлының булышлыгы беләндер әле.

—Сезнең Швейцария сәгате «Юлисс Нордан»ыгызга карап хөкем йөрткәндә—аннары Хуго Босс фирмасы костюмыгыз да ярыйсы гына—сез, Константин Николаевич, тормышта модадан калышмыйсыз шикелле. Мэтр яшьлек елларыгызда аның белән бергәләп гел «Березка» валюта кибетләреннән генә киенгәнсез дип сөйли, ә анда иң модалы әйберләр генә сатылмаса да, шактый сыйфатлы товарлар булган—Внешторгта зәвыклы кешеләр эшләгән бит. Мэтрның мин аралашырга туры килгән күп кенә дуслары кыйммәтле киенә, әмма алар, минем уйлавымча, «Сейко», «Саламандер», фин костюмнары «Туро» яки «Тикла» дәрәҗәсендә генә калган, боларга тагын итальян дубленкаларын, йәисә кайбер ил һәм фирмаларны өстәргә була, ләкин аларга карап кына модаларның асылы үзгәрми шул. Бу хәтта ретро—иске мода белән киенү дә түгел, бу—эклектика—эзлексезлек кенә. Яхшы ретро һәрвакыт кыйммәт тора, аны тоярга, аңа әйләнеп кайтырга кыюлык кына да җитми, үз зәвыгыңа ныклы ышаныч та кирәк...

Эйнштейн машинасын кабызды һәм, җай гына кузгалып китеп, сүзсез утырган Тогларга борылып карады.

—Гафу итегез, югары сыйфатлы кием-салым турында сүз чыкса, мин онытылып китәм, салулый башлыйм... Сезне минем менторларча өйрәтүем һәм бик үк тәртипле булмаган лекциям борчымыймы?

—Һич тә юк. Дәвам итегез, миңа кызык кына,—дип тынычландырды егетне Тоглар. Сөйләсен әйдә, тыңлап барган булып, сорауларына җавап бирмәсәң дә ярый.—Мөгаен, кием-салымга сезнең шикелле дулкынланып-тетрәнеп, үзегезнең тышкы кыяфәтегезгә шулкадәр игътибар итүчене минем әле менә кадәр күргәнем дә булмагандыр. Бәлки, заманы башка булгандыр, бәлки, без үзебез ул кадәрле үсеп җитә алмый калганбыздыр.

Әмма, аның үз сүзләрен җөпләп, игътибар белән тыңлап баруыннан

канатланып киткән яшь пижон Константин Николаевичның уйчан сүзләрен тынлап та бетермәде.

—Ихтимал, сез диагнозны дөрес куйгансыздыр: заманы да башка булган, мөмкинлекләре дә, кешеләр үзләре дә хәтта. Система нәрсәсе беләндер аерылып торган шәхесләрне яратмаган, монысы акылга да, иман-инануларга да, тышкы кыяфәткә дә кагыла. Без анык бер адрес белән анык бер эш буенча барабыз бит, шулай булгач, мин сезне бераз гына булса да андагы хәл-әхвәлләр, тәртип-кагыйдәләр белән таныштырырга тырышып карыйм әле.

Анын «яраткан атына менеп атланганы» һәм хәзер инде юл буе ләчтит сатып барачагы көн кебек ачык иде. Әмма анын болай лыгырдап баруы машинасын бик оста йөртүенә һич комачауламый, ә мода турындагы сөйләнүләре Тогларның бер колагыннан керә, икенчесеннән чыга бара иде. Бу көннәрдә ул инде күпме генә «лекцияләр» тынламады, монысына да көче житәр әле. Ә Эйнштейн китаптан укыган кебек итеп кенә сиптерә дә сиптерә...

—Урынга барып, товарның үзен күргәч, барысы да ачыкланыр. Жир шарында яшәүче халыкның туксан тугыз проценты югары мода дөньясын бары бер дистәләп, күп булса, ике атаклы модельер тәшкил итә дип исәпли. Андыйларның исемнәре һәрвакыт телдән төшми: Карден, Ив сен-Лоран, Ги ля Рош, Версаче, Лагерфельд, Труссарди, Армани, Зайцев, Кензо. Бу исемлекне әле зәвыгына карап дәвам итәргә дә була. Ләкин, дөньядагы иң яхшы заводларда иң яхшы конструкторлар һәм дизайнерлар эшләп чыгарган серияле машиналар булган шикелле, бары тик индивидуаль—аерым бер заказ белән эшләнгән берәр данә генә машиналар да була: «мазерати», «Роллс-ройс», «феррари»—бигрәк тә спорт машиналары яки кабриолетлар; яки, әйтик, хосусый самолетлар, яхталар. Менә шунын кебек, бай кешеләрнен дә кием-салымында үзенә генә хас бер стиле була, алар нигездә рекламалаудан да качалар. Сирәк, әмма шундый очраклар да бар, товар афишага-рекламага мохтаж түгел, мисалга «Ролекс» сәгатен китерергә мөмкин—фирма аны рекламалау өчен акча түгеп тормый. «Ролекс» ул Африкада да «Ролекс»!

Байлар стиле, дидек... Дөньяда ирләр өчен атаклы киемнәр стиле «Ягуар» дип йөртелә. Россиядә байлар күренә башлауга, Мәскәүдә дә шундый салон ачылды...—Эйнштейн «лекциясен» кинәт өзеп әйтте:

—Менә, килеп тә життек.—Һәм ул машинасын ниндидер мәһабәт кунакханә янындагы түләүле урынга кертеп тә куйды.

Константин Николаевич тәрәзәдән башын тыгып карагач, бик заманча бинанын фронтонындагы әллә кайдан күренеп торган исемен укыды: «Софитель-Ирис». Шунда ук хәтеренә килде, анын элекке хужалары чеченнәр бу отель турында ничектер сөйләгән иделәр, әмма кибете турында телгә алмадылар.

Әллә болар бик иртә килгән булып чыкты, әллә күп кенә байлар «Ягуар-стиль» салоны турында ишетеп-белеп бетермәгәннәр әле, кибеттә бу вакытта бер генә сатып алучы да күренми иде. Шуңа күрәдер, ахрысы, аларны кояш кебек балкып, елмаеп каршы алдылар. Шундук бернечә сатучы-консультант уратып алды да, теләсә нинди теләкләрен үтәргә әзер булып, бердәм ягымлы тавыш белән сорады:

—Нинди ярдәм күрсәтә алабыз?

Эйнштейн үзен түбәнсетми торган ниндидер оста бер жөмлә белән генә хужаларга үзенең озатып йөрүче икәнен аңлатуга, бөтен игътибар һәм елмаюлар шундук Константин Николаевичка юнәлтелде.

—Мөгаен, безгә башта нәрсәләр барын карап-күреп чыгарга кирәктер—вакыт житәрлек,—дип үз фикерен әйтте Тоглар.—Ә сатып алуга килгәндә, без байтак әйбер алырга уйлыйбыз. Минем яшь дустым сезнең салоныгыз турында бик әйбәт итеп сөйләде.

Игътибар һәм елмаюлар янә Эйнштейнга әйләнеп кайтты.

Эйнштейнның йөзенә карап та биредәге бәяләрнең анын өчен дә

буй житмәслеге сизелә иде. Залдан-залга, киштәләрдән-киштәләргә күчә-күчә сайланып йөргәндә, нәзакатьле сатучылар, иренмичә, һәр теләгән товарны күрсәтеп-сөйләп бардылар. Бер җаен туры китереп, Константин Николаевич Эйнштейнга пышылдады:

—Георгий, «Софитель-Ирис»ка сәяхәт кылдырганыгыз өчен мин сезгә бик рәхмәтле. Танышлыгыбызның истәлеге итеп, үзегезгә «Ягуар» логотибы төшерелгән берничә әйбер сайлагыз, галстуктыр, каештыр, шарфтыр ишеләрдән—алар сезгә миннән бүләк булыр.—Тоглар кинәт кенә шуны тоеп алды: бу гадәти булмаган, үз-үзен сөючән егет көннәрдән беркөнне аның тормышында бик кирәк булачак әле.

Атаклы «Дормей» пәлтәләре эленеп куелган зал Тогларны бигрәк тә шатландырды, ул пәлтәләр бит һәр метры алты мең долларлык «викуния» тукымасыннан тегелгән. Тогларга яраклы үлчәм, төгәлрәге, озынлыгы туры килгәне юк икән, аның чын күңелдән борчылуын күргәч, кибетчеләр: хафаланмагыз, хәзер үлчәмегезне алабыз да, ике атнадан соң Лондоннан нәкъ үлчәп тегелгән менә дигәне килеп тә җитәр, диделәр. Фешинны таңга калдырганы тагын шул булды—болар үлчәмне лазер нурлары белән генә төшереп ала икән. Без күреп күнеккән рентген кабинеты кебек бер бүлмәгә керәсең дә, чишенми-нитми, караңгы кабинага басасың, бер минут дигәндә, синең өч төрле рәсемеңне төшереп алалар: профиль, анфас һәм арткы яктан. Тоглар берьюлы ике пәлтәгә заказ бирергә булды: берсе—кышкысы, эчлегенә баргузин чәшкесе мехы куелган һәм зур якасы да шундый чәшкедән булырга тиеш, икенчесе «Дормей»нең гадәти демисезон пәлтәсе булыр.

Шундый кыйммәтле әйберләр сатылуын ишеткәч, салонның хуҗабикәсе үзе дә килеп чыкты. Ул: «Берьюлы «Дормей»нең ике пәлтәсенә заказ бирү—бу әле беренче очрак, моны махсус билгеләп үтәргә кирәк»,—диде. Залга шундук эчемлекләр һәм кофе кирәк-яраклары куелган ике арбачык тәгәрәтеп керттеләр, хуҗабикә хөрмәтле кунакларны үзе сыйларга тотынды.

Кибеттә Тоглар өч сәгатьләп торды, шундый күп әйбер алдылар ки, аларга хәзер көзең ни дә, кышың ни—берсе дә куркыныч түгел иде инде. Тоглар Натальясын да онытмады—аңа Шанталь Томаста тегелгән берничә бәрхет күлмәк алды. Баксаң, салон хуҗабикәсе үзе дә төрле кабул итүләрдә шундый күлмәкләр киеп, башкаларны көнләштереп йөри икән. Сөеклесе өчен Константин Николаевич Лаура Бьоджотти әйберләреннән тагын берничә көзге кием-салым да алырга онытмады. Болары стиле белән аның әле яңа гына үзенә «Ягуар»дан алган кием-салымнарына килешеп ярашып тора иде.

Эйнштейн белән Тоглар әйбәт кәеф белән кайтып киләләр иде. Фешин, егетнең кием-салымында гына түгел, машина йөртүдә дә маһирлыгы барын сизеп:

—Георгий, ә сез миңа нинди машина алырга киңәш итәр идегез?—дип сорады.—Хәзер сайланыр мөмкинлекләр шулкадәр күп, аптырап та калырга була.

Эйнштейн, бу игътибардан кәефе килеп һәм үзенең остазы Аргентинлының дустына янә нәрсә булса да файда китерәчәгенә шатланып, ваемсыз гына әйтеп куйды:

—Дөньядагы иң яхшы машиналар немецларныкы дип уйлыйм. Аларның билгеле булган теләсә кайсы модельләре: «Мерседес», «БМВ», «Ауди», «Порше»—игътибарга лаек. Әгәр дә минем житәрлек акчам булса, бары тик «порше»ның соңгы моделен генә алыр идем,—диде.

—Рәхмәт эшлекле киңәшең өчен! Ә сез, әйтик иртәгә үк шушы мәсьәлә белән шөгыльләнә алмас идегезме? «Порше» вәкиллеген эзләп табып, миңа машина сайлап куймассызмы икән? Караңгылатылган салонлы, чия төсендәгесе булу хәерле.

—Яхшы, бик рәхәтләнеп эшләрмен. Ә мин иң-иң яхшысы дигәнен сайлый аламмы?—дип сорады Эйнштейн.

Тоглар рәхәтләнеп көлеп җибәрде.

—Әлбәттә! Без яшь чакта шулай диләр иде: эчсән—эч шампан шәрабен, сөйсән—сөй хан кызларын!

## 4

Ростовтан кайтып, өч көн үткәч, Тоглар Городецкийлардан «Метрополь»гә күчеп килде. Дөрес, Дантес янәшәсенә, бишенче катка түгел, ә, гадәтенчә, икенче катка. Ул лифтларның бу мәһабәт отельдә яшәүчеләрне тавышсыз гына һәм бик тиз йөртә торганнарын да яратмый иде.

Эйнштейн бик өлгер егет булып чыкты: кунакханәгә күчкәннең икенче көнендә, «Метрополь»нең астагы түләүле тукталышына егет соңгы модель «порше»ны китереп тә куйган иде инде. Чия-перламутр төсендәге машинаның салоны яхшы эшкәртелгән кара бозау тиресеннән эшләнгән күн белән тышланган—Тогларның теләгәне дә шушындый автомобиль иде.

Мәскәүдәге көннәр искиткеч уңышлы үтә. «Ягуар-стиль» кибетен җиһазлаган-бизәгән дизайнер аның да Кутузов проспектындагы квартирасын һәм остаханәсен үзгәртеп эшләп бирергә алынды. Хәзер инде Тоглар иртәләрен шунда сугылып чыга, архитектор, прораб, дизайнер белән күрешә-сөйләшә—бөтенесен дә киңәш-уңаш белән, уйлашып эшләргә һәм, иң мөһиме, уртак бер фикергә килергә кирәк иде. Ул үз машинасында кесә телефоны белән пейджер да булдырды, әмма күбрәк хәбәрләр үзенең шул булачак апартаментыннан килә иде.

Ул көн саен Ростовка Натальясына шылтыратып тора, кайвакыт алар сәгатьләр буе сөйләшә, сөйләшкән саен килгән исәп кәгазьләрендәге суммалар чәчләрен үрә торырлык була иде. Көннән-көн Тоглар сәнгать салоннарына сугыла башлады, төрле кирәк-яраклы эш кораллары, материаллар җыярга тотынды, көнбатыштагыларның безнең базар шартларына һәм ихтыяҗларыбызга шундый тиз җайлашуларына да шакката иде ул. Станоклар, мольбертлар, пумалалар, мастихиннар, карандаш-каләмнәр, буяулар, лаклар, эмальләр—рәссам өчен кирәкле товарларның дистәләрчә төре, анда маркеры дисеңме, киндерне беркетеп-тарттырып куя торган атламалы кыстыргыч-беркеткечләр, дисеңме, багетларның ниндиен телисең—барысы да итальян, француз, немец, голланд, япон, кытайныкы, акварель һәм темпера өчен махсус кәгазьләргә кадәр шулардан иде.

Бу байлыкка исең-акылың китәрлек иде, әлбәттә, һәм ул андый минутларда әтисен исенә төшерә, аның дөньяда шундый сыйфатлы эш кораллары, шундый искиткеч буяулар барлыгын күз алдына да китерә алмыйча үлеп киткәнен хәтерләп, кызганып куя иде.

Ә менә, барыннан да бигрәк, ул яраткан Третьяковка әле һаман да ремонтта иде. Анда бит аның күренекле бабасының иҗат җимешләре дә, шул исәптән Ленинның 1918 елда эшләнгән портреты—әйтергә кирәк, революцион Россия юлбашчысының беренче рәсми портреты да саклана, диләр.

Сентябрь азагында көннәр көтмәгәндә аязып китте, томалап яуган янгырлар юкка чыкты, күк йөзе ачылып, кояш нурлары уйный башлады. Бу матур көзге көннәрдә Константин Николаевич, үзенең күптәнге хыялын тормышка ашырып, озын-озаклап Мәскәү буйлап җәяү йөри башлады. Ул башкаланы таный да, танымый да, бер үк вакытта шатлана да, борчыла да иде.

Шулай йөрүләренең берсендә ул Горький Ял паркы каршындагы Кырым валын үзе өчен янадан ачты. Соңгы вакытларда ул тирәләрне рәссамнар үз иткән икән. Чын-чынлап ачык һавадагы салон, әллә ничә чакрымнарга сузылган вернисаж!

Шундагы грузин рәссамнары рәтендә күреп алды ул әлеге картина-рәсемне—алсу-сирень төсендә, бик җентекләп-тәфсилләп махсус «пастоз»

манерасында язылган зур булмаган пейзаж-табигать күренеше иде ул. Бу рәсемнән ниндидер туганнарча якынлык бөркелгән шикелле булды, дулкынлануыннан Тогларның уч төпләре тирләп чыкты. Пейзаж, бергә-бер дигәндәй хәтта үлчәме белән дә аның күренекле бабасының үзендә булган бердәнбер картинасын кабатлый иде. Кайчандыр шул рәсем бит инде Тогларга очраклы рәвештә генә бабасы фамилиясенең серен ачкан иде.

Сатып торучы рәссамның гаҗәпләнүенә карамастан, Тоглар ана сораган бәясеннән биш тапкыр артык түләп, картинаны алып кайтып та китте. Үзен биләп алган дулкынлануын тыя алмыйча, ул Рәссамнар йорты янындагы бер утыргычка барып утырды. Кулындагы пейзажның һәр җирен кат-кат карап һәм Казандагы күптәнге бер язгы көнне исенә төшереп, бик озак онытылып утырды...

## 5

Ул вакытта әнисе исән иде әле, хатларның берсендә әнисе улының, мөмкинлеге булса, Казанга барып килүен, әбисе Елизавета Матвеевна Соколованың йортын эзләп табуын үтенгән иде. Анда, әбисе үлгәннән соң, Костяның әтисе Николай Николаевичка тапшырырга дип калдырылган бик кирәкле хатлар һәм кәгазьләр булырга тиеш икән. Һәм, гомумән, әнисе аның әтисе үскән борынгы Казан урамнарыннан бер әйләнүен сораган, әтисе бит унсигез яшьлек егет килеш шуннан сугышка китеп барган. Әтисе Николай Николаевич Мартукта яшәгән елларында гомере буе бер генә мәртәбә булса да Казанга барып килергә, Рәсәй һавасын суларга хыялланган булган икән... Хыялы тормышка ашмаган—сугыш яралары, ачлык-хәерчелек аны кырык яшендә гүргә керткән.

Җитмешенче еллар уртасы, ил бөтәя башлап, халык чагыштырмача имин яши башлаган һәм алдагы якты киләчәккә ышана төшкән еллар. Тогларның үзенең дә эшләре алай начар түгел иде. Әнисенең хатындагы хисләргә бирелеп, ул шул көнне үк билет алды да, йомшак вагонга утырып Казанга юл тотты. Сәфәр авыр булмады—кичтән тиз йөрешле поездга утырасың, ә иртән инде син Татарстанның башкаласында буласың.

Шәһәрнең борынгы өлешендә, күрсәтелгән адрес буенча, үзәктәге Чехов урамыннан егет гаҗәп матур архитектуралы, ике катлы аерым йортны эзләп тә тапты. Йорт гасыр башында салынган икән, фронтонына «1901» дип мөһер сугылган. Инде искергән-тузган булса да, ул әле үзенең икенче катындагы челтәрләп коеп ясалган тимер рәшәткәләр, көймәләп уелган биек таш түбәле капканың ябык ишегалдына керү юлын каплап торучы тимер капкалары, челтәрле-бизәкле тәрәзә йөзлекләре белән һаман да күнелгә хуш, матур күренә иде. Ерактан ук бу йорттан тынычлык, иминлек—иплелек, ныклык-тотрыклылык бөркелеп тора иде шикелле.

Тоглар, чүп-чар белән тулган ташландык ишегалдына керергә кыймыйча, йорт тирәли әйләнгәләп шактый озак йөрде. Шул мизгелләрдә кайчандыр бик төзек-матур булган бу йортта әтисе туганлыгын белеп, кан авазын җаны-тәне белән тойган кебек булды, шушыннан, кечкенә тимер капка келәсен шылтыратып ача-ача, аның әтисе мәктәпкә йөргән, рәсем сәнгате түгәрәкләренә барган, аннары җинел генә котомкасын җилкәсенә асып, чакыру пунктына-сугышка китеп барган. Бу йортта киленен дә, бары тик рәссам гына итеп күрергә хыялланган бердәнбер улының мирасчысын—оныгын да бер мәртәбә дә күкрәгенә кысып, кочаклап карамаган әбисе яшәгән. Барып чыкмаган—язмышлары шундый булган, һәркем өчен дә шәфкатьсез заман булган шул.

Әтисе ана Казан турында сирәк сөйли, әмма сөйли иде һәм Константин Николаевич бик томанлы итеп кенә бу ишегалдын да, бу урамны да исенә төшергәндәй була иде. Моннан ерак та түгел кинотеатр, сквер-бакча кисәге, ә өч трамвай тукталышыннан соң зур парк булырга

тиеш, әтисе анда сугыш башланыр алдыннан гына сыйныфташлары белән берничә рәт танцыга барып калган.

Әбисе икенче каттагы ике бүлмәне биләп торган, юкса кайчандыр, революциягә кадәрле, йортның яртысы Соколовларныкы булган, алар урамга да аерым ишектән чыккан икән.

Яңа хуҗалар пенсиядәге татарлар булып чыкты, алар Тогларны ачык йөз белән каршы алды, өйгә чакырды, чәй эчәргә утыртты һәм аның өзек-төтек буталчык хикәятен тыңлады. Әбисе үлгәннән соң ук бу квартирага кертелгән элекке хуҗалар, яңа микрорайонда яңа квартира алып, күптән күчеп киткәннәр икән инде. Алай да карт белән карчык иске хуҗаларның бу йортта илле ел яшәгән ниндидер Соколова әбинең аларга ниндидер кәгазьләр төргәге калдырып киткәнлеген, әгәр дә кайдадыр ерак Казакъстанда яшәүче улымы, берәр туганымы килеп чыкса, ул кәгазьләрне шуларга тапшыру хакында сөйләгәнлекләрен хәтергә төшерделәр.

Әмма ул кәгазьләр төргәге вакытлар үтү белән югалган. Күпме гомерләр үткән бит инде, аннары биш ел элегрәкме картларның йортына капиталь ремонт та ясалган икән. Ике ремонт бер янгынга тиң, диләрме әле?

Константин Николаевич инде китәргә җыенган иде, карчык кинәт кенә сискәнгәндәй итеп, кечкенә ябык кулларын шатланып бутый-бутый, тиз генә икенче бүлмәгә йөгереп чыгып керде. Ул аннан гади генә рамга куелган кечкенәрәк бер рәсем-картина күтәреп чыкты да, бәхетле елмаеп:

—Менә сезгә әбиегезнең истәлеге. Рәсем аныкы булган. Туган-тумачалары килеп чыкса, кәгазьләре белән бергә тапшыруны сораган иделәр...—диде.

Язмышы башкача булса, үзенең туган оясы булырга тиешле бу йорттан Константин Николаевич күңеле тулып, моңсуланып чыкты. Ул, әледән-әле артына борылып карый-карый, шәһәр үзәгенә таба төшеп китте, әтисе йортына беркайчан да сукмак салмаячагын белә иде инде ул. Капка төбендә, мөлаем татар карты белән аның карчыгы, аны гомерлеккә озаткандай, бик озак басып карап калды, Тогларга алар хушлашып кул болгый шикелле тоелды.

Рәсем кечкенә, утызга кырык сантиметр үлчәмле генә иде, шунадырмы Тогларның аңа әллә ни исе китмәде. Артына «Н. Фешин» дип кул куелган, «1920». г. Казань!» дип тә язылган. Константин Николаевич әтисенең сөйләүләреннән белә иде инде, аның әтисе балигъ булганчы әнисе фамилиясен йөрткән—Соколов, шуңа ияләшеп, күнегеп беткән. Әнисе исә кинәт кенә, берни аңлатып-нитеп тормыйча, сугыш алдыннан улына Фешин Николай Николаевич исеменә язылган паспорт кайтарып тоттырган. Хәер, соныннан да улына ул әтисе турында—ни яхшысыннан, ни начарыннан—авыз ачып бер сүз дә сөйләмәгән. Димәк, Константин Николаевичның бабасы, ниндидер Н. Фешин шулай ук рәсемнәр ясаштыргалаган һәм үзеннән истәлеккә шушы кечкенә табигать күренешен калдырган.

Тогларның Казанда бернинди эше-йомышы да, шулай ук танышбелешләре дә юк иде, поезд Мәскәүгә кич соң гына китә, шунлыктан ул, кайсыдыр ресторанга кереп, татар ашлары ашап чыкты да, музейга керергә булды, бәлки, берәр күргәзмә-фәлән карарга мөмкин булыр, ни әйтсәң дә, аңа кайчандыр рәссам язмышын юраган иделәр бит. Шулай итеп, Татарстанның сынлы сәнгать музеена—Казанның элекке губернаторы яшәгән мәһабәт сарайга барып керде.

Музей Тогларның исен китәрде. Юкса гаҗәпләнерлек тә түгел, ул Казанда бик күп талантлы рус рәссамнары яшәп иҗат иткәнлекләрен белә иде, ә Казан дворяннары һәм сәүдәгәрләре Россиядә иң байлардан да саналган бит әле. Гасыр башында бирегә рәсем сәнгатенең соныннан Татарстанның Дәүләт музеена нигез салачак шактый күп танылганнары туплана килгән. Шишкин, Коровин, Репин, Поленов, Крамской, Кусто-

диев, Маковский, Перов әсәрләренен мондагыдай бай тупланмасы Россия музейларында бик сирәктер, булса, Мәскәүдә генә булыр. Тоглар биредә Кандинский, Родченко, Сарьянның баштагы чоры, Филонов, Лентулов, Фальк, Грабарь, Кончаловский эшләрен күреп тә бик куанган иде. Аннары Көнбатыш Европа рәсем сәнгате дә шактый бай куелган, хәер, аларның аерым бер тәртибе-системасы сизелми иде—нәрсә булса, шуны элгәннәр, төгәлрәге, Мәскәү белән Ленинград музейларына алып бетергәннән калганнарын гына.

Музейның экспозициясе икенче катта да бар икән, ишек янындагы язу-игъланга караганда, анда Татарстанның иң өлкән рәссамнары күргәзмәсе ачылган чак иде. Тогларның аларны да карап төшәсе килгән иде. Әмма әлеге күргәзмәгә кереп житә алмады ул, чөнки икенче катның беренче залында ук озакка тукталып калды. Музейларда, гадәттә, түгәрәк буенча әйләнеп йөриләр һәм анда сәгать теле буенча әйләнергә кирәк, ләкин ул ялгышып, кире якка китеп барды. Мөгаен, кешеләр аз булганда моның әлләни әһәмияте дә юктыр. Әмма Константин Николаевич өчен алай булмады шул.

Ул озакка тукталып калган зал рәссамга генә багышланган, аның исемен йөртә һәм рәссамның зур портреты да ишектән керүгә үк элеп куелган икән. Әмма Тоглар залның икенче башындагы ишектән кергәнгә күрә, әлеге автопортретны да күрми узды.

Залдагы беренче әсәрләр үк: табигать күренешләре, натюрмортлар, портретлар, төрле жанрдагы рәсемнәр аның күңелен шундук яулап алды, анарда әле мона кадәр бер дә булмаган ниндидер сирәк, татып каралмаган хис-тойгы уянды: бу рәсем-картиналар ана бер үк вакытта бик күптән дә һәм... бүген генә язылган шикелле күренде. Мондый сәер халәтенә аның әле һичкайчан да кичергәне юк иде, шундый тәэсир көченә ирешергә мөмкин икәнлеген хәтта күз алдына да китерә алмады ул.

Мөгаен, бу Останың сихри серен анларга теләптер, ул һәр картина янында озаклап басып торды, аны төрле яклап—бер якыная төшеп, бер ерагаеп карый-карый өйрәнде. Шуның өченме, аргы ишек янындагы биек кәнәфидә йокымсырап утыручы зал саклаучы карчык аңа игътибар итте. Күрәсең, ул үзе дә бу залын яратадыр, Константин Николаевич янына килде дә керешсез-нисез сөйли башлады:

—Шушындый рәссамны, төрмәгә япкан кебек, ярты гасыр буе диярлек запасникларда тотарга кирәк бит, ә! Аллага шөкер, күзләре ачылды, бер кыю кеше табылып, тәвәккәлләде, бу залны ачканнарына әле ярты ел гына. Сәнгатьне аңлый белүчеләр бу әсәрләрне карап ләззәтләнергә хәзер бөтен илдән киләләр. Бүген халык юк әле—эш көне, көн азагы да, ә шимбә-якшәмбеләрдә безнең залдан халык өзелми.

—Ни өчен соң аны илле ел буе күрсәтми торганнар? Бу әсәрләрдә мин бернинди җинаять тә күрмим. Аларда тормыш үзе, яктылык, ә бернинди сәясәт тә юк,—дип, карчыкның сүзенә кушылды Константин Николаевич.

—Анысы шулаен шулайдыр да, картиналары турында бер сүз дә әйтмим. Ләкин бит Николай Иванович Фешин үзе—эмигрант, 1923 елда Америкага китеп бара да, яңадан беркайчан да әйләнеп кайтмый. Үлгән. Ә заманалар, үзегез беләсез, нинди иде: ике дөнья—ике система. Кем сиңа биредә эмигрантка зал ачып, күргәзмә оештырсын? Рәссамнар үзләре үк, көнчелектән, исемен таптап-пычратып бетерер иделәр. Идеология... Ике мәдәният... Сез яшь әле, ә без ул пролетариат сәнгате һәм идеологик көрәштән гарык булдык. Николай Иванович—барин, әле патша Россиясе заманнарында ук рәсем сәнгате академигы булган кеше...

—Сез кем дидегез әле—Фешинмы?—дип дулкынланып кайтарып сорады Константин Николаевич.

—Әйе, Николай Иванович Фешин,—дип раслап баш какты карчык.—Сез икенче ишектән кергәнсез, бу зал Фешин Залы дип атала, әнә теге ишек янында аның автопортреты да эленеп тора. Барып карагыз әле, нинди затлы-вөҗданлы кыяфәт...

Ләкин Тоглар зал хуҗабикәсенең сүзләрен ишетми иде инде, ниндидер күренмәс көч аны үзеннән-үзе залның теге башына—Россия өчен сирәк булган Фешин фамилияле кеше портреты янына алып китте.

Академик Фешинга хас алсу-сирень төсләрдә, энҗедәй ак кар фонындагы автопортреттан, дулкынланып таң калган Константин Николаевичка... үз әтисе карап тора иде! Әйе, үз әтисе, Николай Николаевич Фешин, халык әйтмешли, суйган да каплаган! Бары тик шунысы гына бар: рәсемнәр ясап ипилек акча юнәтүче, авыл балаларын югары сәнгатькә өйрәтүче бер куллы авыл рәссамы һичбер вакытта да мондый парча жилетлы күркәм костюм киеп йөрмәгән һәм нәфис күбәләкбант такмаган. Калганнары бөтенләе белән тач тере әтисе—киң маңгае өстендәге чәчләре шулай ук буйсынмас тырпаеп торыр, шундый ук кашлары ике якка сикергән булыр, шундый ук ягымлы көлемсерәүле зәңгәр күзләр, нык ихтыярлы тыгыз ияк—монысы анын максатчан үҗәтлеге, холкы-табигате билгесе. Әтисен Тоглар мединститутның икенче курсыннан флотка хезмәт итәргә киткәндә соңгы тапкыр нәкъ менә шушы кыяфәттә күргән иде, әтисенең үләренә ике ел калганда булган икән. Бабасы да үзенең автопортретын утыз сигез яшендә язган—әйтерсең лә, бабасы белән әтисе—ана кандаш кешеләр бер үк яшьтә, бер үк кыяфәттә күренергә теләп, юри шулай сүз куешканнар.

Музей ябылганчы калган бөтен вакытын Тоглар бабасы залында үткәрде. Ул анда үз кулына очраклы гына килеп кергән рәсемне дә очратты, монысы үлчәме белән бераз зуррак кына иде. Мөгаен, тегесе, әбисенә ярты гасыр чамасы элек бүләк ителгәне пленэрга язылган, ә бу музейдагысы остаханәдә эшләнгән, монысында бер кечкенә өстәмә бар: еракта ниндидер шәүлә шәйләнә, әмма ике эш тә бер үк 1920 ел белән билгеләнгән.

Элекке губернатор сараеннан Константин Николаевич бик нык әсәрләнеп чыкты, ул бер үк вакытта шатлана да, кайгыра да иде. Ул тәкъдирдә язылганнан котылып булмау турында уйланды, соң, бер жидесигез ай элегрәк кенә Казанга килгән булса да, ул үз бабасы белән очраша алмас, тамырлары мәңгегә өзелеп калыр иде бит: Фешин залы әле ачылмаган булыр иде. Димәк, тормыш-язмышның барлык киртәкаршылыкларына карамастан, аларга очрашырга язган. Хәзер ул инде әбисе Елизавета Матвеевнаның нинди кадерле-мөһим язулар саклаганын да аңлаган иде. Ихтимал, гомере өзелер алдыннан улына ул анын әтисе фамилиясенең серен ачарга теләгәндер. Нигә шулай озак яшереп саклаганмы? Хәзер Тоглар монысының да җавабын белә. Эмигрант улы булу, Фешин фамилиясен йөртү кәсафәтле-куркыныч булган, карчык, булдыра алган кадәрле, үзенең бердәнбер баласын мәрхәмәтсез-шәфкатьсез заманнан саклап-ышыклап калырга теләгән. Тагын бер җавап бар, анысы да яшәргә хаклы. Башка заман, башка кешеләр, башка әхлак... Әбисе үз гөнаһын үзе генә белгән. Хәзерге заманда сөйгән кешеннән бала табу—нинди гөнаһ булсын ди инде ул? Әмма заманнарны, бигрәк тә атабабаларыбызны хөкем итү хокукы безгә бирелмәгән...

...су кумгәндәй,
вакыт кумә барысын да...

### 6

Мәскәүдәге көннәр-атналар йөгертеп кенә үтә башлады. Тоглар башкалада көннән-көн ныграк тамырлана барды. Ул үзенең Натальяны кунакка чакырырга вәгъдә иткәнен исендә тота, ләкин төзүче-ремонтчыларны ничек кенә ашыктырмасын, Кутузов проспектындагы эшләрне ноябрь урталарысыз төгәлләп бетерергә ышандырмыйлар иде. Аргентинлы исә: «Минем туган көнемә!»—дип шаярта.

Яшь даһи Эйнштейн тагын бер файдалы эш эшләде әле. «Ягуар-стиль» кибетенә барып кайтканнан соң, ул Тогларга якынрак булырга тырышты, Константин Николаевичка аның һәрвакыт кул астында булырга теләве, ана бирелгәнлеге, алыштыргысызлыкка омтылышы ошый иде.

Бервакыт ул каяндыр белеп алган да, туп-туры «Метрополь»га йөгереп килеп тә житкән: Переделкинода кайчандыр колхоз-совхозлар, завод-фабрикалар, акыллы һәм ягымлы райком-обком секретарьлары турында калын-калын романнары белән танылган бер язучы өч метр биеклектәге койма белән әйләндереп алынган бер гектар жирле ике катлы таш дачасын бик ашыгыч сата икән. Дачаның бәясе, Кутузов проспектындагы квартираларга түләгәннәр белән чагыштырганда, бөтенләй көлке иде. Тоглар бу мөмкинлекне ычкындырмаска һәм шәһәр янында да йортлы булырга карар кылды. Урыны бик тә абруй-дәрәжәле, экологик чиста-саф, үзенең Кутузов проспектындагы квартирасыннан да ерак түгел—машина белән төгәл егерме минут кына барасы, мондый уң эш тормышта бер генә була. Сатып алу мәсьәләсен ярты сәгатьтә хәл итеп тә куйдылар, әмма Георгий белән әлеге язучы төрле документлар юнәтеп тагын әле бер атна чапты. Яңа түрәләр иске казанышларны һәм абруйларны танырга теләми, лауреат исемнәренә карап та тормый һәм хәтта язучының күкрәгендәге алтын Гертрудасын (Герой Социалистического Труда исеменнән кыскартып, мыскыллап әйтүләре) да күрмәмешкә салына иделәр. Әгәр дә Георгий, язучыга күрсәтмичә генә, һәр кабинетта юмарт ришвәтләр өләшмәсә, алар әле, мөгаен, тагын берәр ай шулай йөгереп йөрер иде.

Дачага барыннан да бигрәк Городецкий шатланды, кәрт өстәле тирәсендә балта эләрлек төтен эчендә уйнауга караганда, ул саф һавада, табигать кочагында яхшырак уйный икән. Дачаның өч метрлы коймасы да аның күңеленә бик хуш килде. Хәер, аз халыклы Переделкинода кеше коймасы ярыгыннан күзәтү юктыр да әле, биредә бит хосусый милекнең тәмен күптәннән белгән әфәнделәр генә яши.

Бу йорт-дачаны Тоглар шулай ук рәсем сәнгатенә тартылуы сәбәпле сатып алды. Переделкинода яшәп, ул табигать эчендә булыр, аның жәяүләп урманга этюдлар язарга чыгасы, елның төрле фасылларында, бигрәк тә кышын, натурадан рәсемнәр сызгалыйсы килә. Ул үзенең бабасы Николай Ивановичның карның аклыгын-сафлыгын, көннең төрле вакытларында төрле төсләргә керүен шулай оста күрсәтә белүенә соклана, аңа кайвакытларда картиналардагы карның исе дә сизелгәндәй була, академик рәссам Фешин әсәрләренең сихере-сере дә шундый иде шул.

Мәскәүгә кайтып төшкән беренче көненнән башлап һәммәсе дә уңышлы бара иде һәм ырым-шырымнарга ышанучан Тоглар үз тормышында да якты вакытлар башланганына инанды. Городецкий вәгъдә иткәнчә, аның «теге дөньядан» кайтуы уңае белән бик бай мәжлес оештырдылар. Очрашу, иске гадәт буенча, «Пекин» ресторанында үткәрелде, үтеп киткән яшьлек елларын искә төшерү өчен шулай эшләделәр бугай. Кытайлылар ресторанны ничек кенә үзгәртергә-яңартырга тырышсалар да, бу диварлар тамырдаш-корешларны, туганнар-братваны башкача хәтерли шул: кыю-тәвәккәл, яшь, башсыз башкисәрләр итеп хәтерли—элекке кырыс-каты система белән каршылыкка-конфликтка керү өчен батырлык, ихтыяр көче, тормышта үзең сайлап алган юл булу кирәк иде.

Әйе, хәзер «Пекин»да күп нәрсә үзгәргән, әмма мебель-жиһазлар элеккечә, ачылган беренче көнендәгечә калган. «Шулай инде, безнең тормышта шушы «Пекин»дагы өстәл-урындыклар гына үзгәрешсез хәзер»,—дип уйлап куйды Тоглар.

Иң әвәл тамырдаш-корешлар үзләре бик нык үзгәргән, Тоглар кайчандыр үзенә якын булган бу кешеләрнең шундый метаморфозасын күз алдына да китерә алмый иде. Борынгы Рим философларыннан кайсыдыр бик дөрес әйткән: акча һәм хакимлек кешеләрне кискен үзгәртә, дигән. Кытай ресторанының авыр өстәлләре тирәсендә утырышкан элекке

дусларына карап, Тоглар әле: «Танымаслык итеп үзгәртә»,—дип тә өстәр иде. Аның күнеленә кайчандыр Ташкентта ишеткән акыллы шәрекъ сүзләре дә килде: кешене белим дисәң, аңа хакимлек белән акча бир.

Очрашуга һәммәсе дә аерым машиналарда, махсус шоферлар, тән сакчылары һәм ярдәмче референтлар белән килгән, спутник аша элемтә телефоннарын бер дә кулларыннан төшерми үзләре. Аларга өстәлләрне аерым куйдылар, күрәсең, шундый субординация таләп итела иде бугай.

Тогларны Эйнштейн озата килгән иде, ул бу дөньяны үз кулларында тотучыларның бергә җыелышып утыруларын күрергә теләп, ә, бәлки, аларның күзенә чалынып калырга да хыялланып килгәндер. Константин Николаевич башта аны кайсы өстәл янындагыларга утыртырга дип озак баш ватты һәм, ниһаять, Георгийны ярдәмче референтлар янына утыртты, аларның күпчелеге аның яшендәгеләр иде.

Тормышның яңа хуҗаларында каракларча каптырып алу гадәте нык сизелә иде. Аларның күпчелегендәге акыл-зирәклек Россияне, барыннан да битәр Мәскәүне күмеп киткән кыргый капитализмга бик тиз яраклашып өлгергән. Аларның консультантлары да иң югары урыннарда утыручы кинәшчеләрдән талантлырактыр, мөгаен, чөнки братва уңышлы эш өчен бик яхшы гына түләп калмый—хаталансаң-ялгышсаң, расланмаган фаразлар кылсаң, чын-чынлап башыңны да өзеп ташлый.

Тоглар шуны аңлады: «яңа руслар»ның икътисадында һаман да иске караклар кануны хөкем итә—һәркем үз сүзе һәм үз эш-гамәлләре өчен үзе җавап бирә. Җинаятьчел дөньяда күптәннән инде һәрнәрсә соңгы нәтиҗә белән бәяләнә, бу нәкъ менә советлардан соң килгән хакимият һәм аның икътисады ирешергә теләгән нәрсә иде. Шулай булгач, паханнарга яңа тормышка җайлашу җиңелрәк тә иде, бигрәк тә хакимият үтәли принципсыз, ялганчы, башыннан аягына кадәр коррупция һәм ришвәткә баткан чакта, нигә шулай булмасын, ди? Братва үзләре өлешенә төшкән бердәнбер тарихи мөмкинлектән бик оста гына файдаланган да. Хәер, бу мөмкинлекне алар янә шул ук хакимияттәгеләр кулыннан, үзгәртеп коруларның атасы булган Горбачевтан зәңгәр каймалы тәлинкәдә бушлай алды. Шуңа күрә дә Тогларның мәҗлесендә Михаил Сергеевич саулыгына махсус тост күтәрделәр. Ничек инде шундый якын кеше өчен эчмисең, ди? Мәҗлестә утыручыларның икедән өч өлеше Горбачевның 1987 елгы көтелмәгән юмарт амнистиясеннән соң төрмәдән чыкты бит. Хакимият ни өчендер тизрәк котылырга ашыккан дәүләт милкен үзләренә эләктереп өлгерер өчен чыкты алар.

Братва белән, бигрәк тә яңалары белән аралашып-фикерләшеп утырудан Тоглар шуны ачыклады, ул Мәскәүдә булмый торган елларда, хәзерге модалы сүз белән әйткәндә, аның рейтингы (абруй-дәрәҗәсе) һич тә төшмәгән, ә бәлки, күтәрелгәндер дә әле. Монысы өчен Аргентинлы тырышкандыр инде, аңа рәхмәт!

Фешин хөрмәтенә оештырылган бу искиткеч бай банкет биш сәгатькә диярлек сузылды, ләкин вакытның ничек үткәнен берәү дә сизмәде, бары тик сизсә, спутник элемтәсе аша килгән әрсез телефон шылтырауларыннан гарык булган ярдәмче референтлар гына сизгәндер. Нинди генә тостлар әйтелмәсен, нинди генә күз яшьләре түкмәсеннәр, Тоглар аңлап утырды: көтелмәгән финанс очышы, кулларына ишелеп төшкән хакимлек, мәлҗерәп калган дәүләтнең алар юлына бернинди киртә куярлык сәләте юклыгы—болар барысы да бирелә утыручыларның башын әйләндергән һәм иске тамырдаш-корешларның, братваның сукмак-юллары хәзер бик тә нык аерылган икән инде.

Әмма Тоглар моның өчен бер дә борчылмады, заман һәм хәзерге тәрәккыят аның элекке сирәк һөнәрен бөтенләй диярлек юкка чыгарганына да кайгырмады.

Константин Николаевичны бер нәрсә генә куандыра—ул да булса финанс бәйсезлеге, кесәсе тулы акчасы булу аңа сүзләре үтүчән дәрәҗәле кешеләр белән җиңел генә аралашырга һәм шул ук вакытта алардан

ераграк торырга, үзенең бәйсез тормышын алып барырга да мөмкинлек бирә иде. Тоглар бүгенге мәҗлестә үткәне белән, иске дуслары белән очрашудан канәгать иде. Һәм ул бары шушында, «Пекин»да гына үзенең дә юллары ул дуслары белән, мөгаен, мәңгегә аерылганлыгын аңлады.

## Али–баба саквояжы

### I

Карлен Татлян әкренләп Мәскәү тормышына яраклаша, аның котырган ритмына, алдан әйтеп булмаслык көтелмәгәнлегенә, югары хис-тойгыларның түбән хайвани теләкләр белән янәшәлегенә, үкертеп яшәрлек байлык-муллыгы һәм фәкыйрьлек-хәерчелегенә, кичә генә әле ярым җимерек коммуналкаларда хезмәт хакын тартып-сузып ярым ач яшәүчеләрнең кеше ышанмаслык күтәрелешләре һәм шундый ук тизлек белән янә түбән тәгәрәүләренә күнегә бара иде. Тырыш һәм елгыр малайның, бай отель ишек төпләрендә аяк киемнәре чистарта-чистарта, озак һәм үҗәт хезмәте белән картлык көнендә миллионер, заводлар, пароходлар, кыйммәтле кәгазьләр хуҗасы була алуы турындагы американнар легендасы, американнар хыялы, американнар әкияте гомерен нииндидер шул юк-бар миллионнар өчен исраф иткән ул малайга бирелә кызгану хисе генә тудырырга мөмкин хәзер. Америка мифы Россиядә күзгә күренеп тоныклана, бернинди күтәренке дәртләр кузгатмый иде инде. Карлен хәтта американнарны кызганып та куя, тырыш хезмәте белән баеган әлеге малай Америка Кушма Штатларының шартлы символы, йөз процентлы янкиның үрнәге иде бит. Мәскәүдә Карлен тәүге тапкыр Американың матди һәм рухи байлыкларына шикләнеп карый башлады. Бирелә—Россиядә, аның башкаласында һәрнәрсә урысча киң колач белән эшләнә, бирелә җирдәге барлык теләкләре ташып торган яшь һәм чибәр егетләр, американнар аршины белән үлчәгәндә, бер төн эчендә, бер эш-гамәл майтарып, бик юк дигәндә дә бер-ике ай эчендә баеп китәләр. Карлен моны үз күзләре белән күреп тора. Ул Россиягә иң кызыклы заманда килеп юлыкты, яңгырдан соң үсеп чыккан гөмбәләр шикелле яна газет-журналлар пәйда була, яна эстрада коллективлары, оркестрлар һәм балет труппалары калка, Европа һәм дөнья әһәмиятенә ия сәхнә йолдызлары да, Россиядәге тормыш чынбарлыгын, андагы үзгәрешләрне сизенеп, Мәскәүгә ашкыналар, чөнки тулы канлы чын тормыш бары тик башкалада гына кайнап тора иде. Карлен моның да сәбәбен ачыклады: кайсыдыр газеттан ул үзен тан калдырган мәгълүмат укыды—Россиянең сиксән биш процент капиталы-байлыгы Мәскәүдә әйләнештә йөри икән. Әгәр дә Мәскәүдә бер ел тордым дигәндә, аның моңарчы шәһәр читендә—Чертановода өч бүлмәле кысан хрущевкада яшәгән туганнары Казаряннар үзәккә, атаклы Бурленко клиникасыннан ерак та түгел Ямской кыры урамына күчкән икән, шулай булгач, ничек итеп Россиядәге үзгәрешләргә ышанмыйсың да, ничек итеп аңа таң калмыйсың? Әле бит җитмәсә, бөтен бер катын, иң кыйммәтлесен сатып алдылар. Казаряннар уникенче каттагы зур ике квартирага урнашты, алты бүлмәле, ике ванналы, ике туалетлы зуррагына Карленның абзасы белән тутасының бөтен гаиләсе сыйды, ә дүрт бүлмәсенә «Арарат» фирмасы хуҗасы Ашот бер үзе кереп утырды. Хосусый бизнесның гөрләп чәчәк атуы һәм Америка белән бик табышлы сату-алу итү Казаряннар ыруына, хәзергечә әйтсәк—кланына, менә шундый баш әйләнерлек сикереш ясарга мөмкинлек бирде.

Ашот квартирасындагы бер иркен генә бүлмәне Карленга тәгаенләделәр һәм Татлян, озак ялындырып тормыйча гына, туганнары янына күченде. Хәзер инде ул «Лос-Анджелес таймс» газеты хәбәрчесе буларак

ала торган квартир акчасын рәхәтләнеп тота ала иде. Аннары биредә, әрмәннәр арасында,—ә йортның дүрттән өч өлеше әрмәннәрнеке,—ана күренмичәрәк яшәү өчен дә җинелрәк иде. Үзе уйлаганча, аның артыннан иртәме-соңмы барыбер күзәтә башлаячаклар бит. Реформалар-үзгәртеп коручыларның һушларынны алырлык итеп сугуларыннан соң рус разведкасы һәм контрразведкасы әкренләп, әмма ныклап аңына килеп аягына баса, ил-дәүләттә үзенә лаек урынны яңадан яулап алырга омтыла иде. ЦРУда Норман кушаматы алган Карлен Татлян әлегә үзе артыннан «койрык» тагылганын сизми сизүен, шулай да, ул-бу булмагае дип, саклана—Ашотларга күчеп килүе дә шул чараларның берсе булды.

Ямской кыры урамындагы кызыл кирпечтән салынган бу зур йортны телгә үткен мәскәүлеләр бик тиз генә «әрмәннәр йорты» дип йөртә башлады. Шул ук йортның дүртенче катындагы өч бүлмәне Карлен очраклы рәвештә «метелица» төнге клубында танышкан Ереван бандитлары биләп тора иде. Соңрак ул бу гангстерлар белән дуслашып ук китте, алар аны Мәскәүдә тәүге тапкыр «Трефовый туз» дигән төнге казинога да алып бардылар, монысы нәкъ бу уен йортының бөлгән, һәлакәткә тарган көнендә булды. Шунда бит инде Карлен үзен кызыксындырган серне чак-чак кына ача алмый калды, әмма барып чыкмады: «Трефовый туз» казиносында ялган долларларның эзенә төшәчәгенә аның иманы камил иде, «Лос-Анджелес таймс» хәбәрчесе сыйфатында Россиягә килүе дә нәкъ шуны ачыклау ниятеннән иде бит. Ләкин, руслар әйтмешли, начарлыкның да бер яхшы ягы була: шул казинода ул Картье кушаматлы бер көяз егетне очратты. Карленнең эчке сиземләве-интуициясе бу кемсәнең ничектер ялган долларларга бәйләнеше барлыгына ишарәли шикелле—юкса көяз егет долларларын шулкадәр юмарт-җиңел туздырмас иде. Карлен әрмән бандитлары Ваган һәм Армен белән бигрәк тә дуслашып китте. Беренчесенең кушаматы Крис, икенчесенеке—Абрек иде, юкса әле ни тегесе, ни монысы төрмәдә утырып карамаган—Ходай саклаган, әмма Мәскәүнең җинаятьчел даирәләрендә икесе дә зур абруйлы санала. Ихтимал, монысына аларның ирекле көрәш буенча Европа һәм дөнья чемпионатларында ирешкән уңышлары да йогынты ясагандыр. Ә иң дөресе, алар легендар әрмән бандиты Рафик Свога ерак чыбык очы тиешле туганнар һәм тегесе аларны башкаланың җинаятьчел дөньясына шәхсән үзе кертеп өлгергән булырга тиеш.

Үзенең газетта эшләвенә, анда басылып чыккан мәкаләләренә Карлен Татлян бер дә битараф түгел, киресенчә, ул аларны игътибар белән күзәтеп-җыеп бара. Мәскәүнең атналык газеталары аның театрлардагы спектакльләр турындагы күзәтүләрен, төрле репортажларын, күргәзмә-вернисажлардан язмаларын күчереп басканда чиксез шатлана иде. Мөгаен, матбугатка мондый мөнәсәбәт, һәр ташка басылганны хак сүз итеп кабул итү Россиядә, элекке заманнардан калган гадәт буенча, житди саналгандыр. Биредә әле хәзер дә рецензияләрне-бәяләмәләрне, рейтинг-дәрәҗәләрне бәхәсләрдә нигез итеп китерәләр. Карлен үзенең дә Мәскәүдәге мәдәни тормышка сизелерлек йогынты ясый башлавын тиз аңлап алды. Сәнгать кешеләренең яше-карты, танылган-танылмаганы аның белән очрашу җаен эзли башлады, үзенең репортажларында сүз уңаенда гына булса да кемнендер исемен атап китсә, ана бик рәхмәтле була иделәр.

Шулай итеп, рус мәдәнияте буенча белгеч исеме алу мөмкинлеге туды, ә монысы һәр заманда да кыйммәт бәһаләнә торган әйбер.

Әмма Карлен-Норман журналистлык эшчәнлегендә нинди генә тырышлык күрсәтмәсен, барыбер Россиягә ни өчен килгәнлеген, үзенең төп бурычын онытмады. ЦРУдагы чын хуҗалары аның яңарган Россиядәге рухи тормыш турындагы теләсә кемне шаккатырырлык репортажларына төкереп кенә караганлыгын Татлян бик яхшы аңлый иде. ЦРУ өчен иң әһәмиятлесе—Норманның ялган акча ясаучыларны эзләп табуы кирәк—аларны исә биредә, караклар телендә «граверлар» дип йөртәләр, икән,—юкса аны озакламый чакырып алачаклар һәм булачак карьераң киселде

дигән сүз. Ә Карлен Татлян үзенен яңа ватанынын ана шундый җаваплы бурыч йөкләве белән бик горурлана иде. Норман ялган долларларның эзен банклар аша да капшаштырып карады, ләкин аларда андый исәп алып барылмаганын тиз аңлап алды, әгәр дә банкка берәр партия нинди дә булса ялган акча килеп керә икән, анда аның өчен генә тавыш куптарып маташу ихтималы бик икеле. Дөресрәге, җае чыкканда, аларны кайсы булса да башка берәр банкка олактырырлар яки валюталар алмаштыру конторлары челтәре аша берәр әмәлен табарлар, чөнки ул контoралардан долларларны чит шәһәрләрдән яки якын чит илләрдән килүчеләр сатып ала. Шулай булгач, Карлен Татлян дәүләт оешмаларына исәп тота да алмый иде. Россиядәгечә, ничек тә булса бер рәте-җае чыгар әле, берәр нәтиҗә булмый калмас дип юанырга-ышанырга гына кала. Ләкин үз оешмасы булган ЦРУның эш алымнарын ул яхшы белә, анда һәрнәрсә тикшерү-анализлау, исәпләп-санап чыгару, прогноз һәм фәнни фаразлауга корылган. Шунлыктан, Норман, үзенең тисә—тиенгә, тимәсә—ботакка, дигәндәй, сукыр тәкә уенындагыча ысул белән генә эзләнгәнен чамалый иде.

Ләкин Норман үзәктән үзенә эзләнер өчен иң кирәкле мәгълүматларны сорап алып та тора. Бирeдә, Мәскәүдә ул, күзе ачыла төшкәч, шунысын да аңлады: ялган акча ясаучыларның эзен капшап табу өчен, кул астында һәрвакыт дөньяның теләсә кайсы кыйтгасында калкып чыккан ялган долларлар турында иң соңгы хәбәрләр булырга тиеш. Ялган банкнотлар ясау белән шөгыльләнүче һәр үзәк аларны, һичшиксез, Россия аша, Мәскәү аша гамәлгә кертеп җибәрергә омтылырга тиеш дип исәпли иде Карлен Татлян. Чөнки хәзер бит бөтен дөнья белә: ташкала-башкалада котырган миллиардлар, триллионнар әйләнештә йөри, Советлар Союзы таркалганнан соң барлыкка килгән бәйсез дәүләтләрдә, карак банкларга, пластик карточкаларга һәм җирле акчаларга ышанмыйча, һәркем долларлар белән эш итүне кулай күрә. Көнбатышта һәркемгә аңлаешлы кыска «кеш» сүзе «кулда булган саф акча» дигән мәгънәне аңлата, ул русча «наличные» дип, үзгәртеп корулардан соң, кыскартылып, «нал» гына дип йөртелә башлады. Кулда шулкадәр зур сумма саф акчалар йөргән бердәнбер ил булып дөньяда бер Россия генә калды һәм моңа беркем дә гаҗәпләнми дә, шикләнеп тә карамый. Мәскәүдә бер ел яшәү дәверендә Норман ялган доллар икәнлеге ачыкланган акчаларның шактый күләмле карточкасын төзеде. Вьетнамда һәм Кытайда, Италиядә һәм Израильдә, Колумбиядә һәм Венесуэлада, Америкада һәм Англиядә—кыскасы, кайда гына ясалган булуына карамастан, аның яшь хәтере ул ялган акчаларның номерларын һәм серия саннарын яттан әйтеп бирә ала иде. Норман төгәл белеп торды: кайда кайсысын гомерлеккә кисеп ташладылар—бу еш кына андый кәсеп белән ялгыз шөгыльләнүчеләрне тоткач була, хәер, кайвакытларда тулы яшерен валюта цехларын да япкалый иделәр.

Дөньяда бердәнбер супердержавалыкка дәгъва кылган американнар долларның үзләре өчен ни-нәрсә икәнен бик әйбәт белә, доллар барлык кыйтгаларны да, финанс берәмлеге буларак, тулаем яулап алырга тиеш, шуңа күрә дә ялган доллар ясаучыларга каршы бөтен дөнья буйлап рәхимсез көрәш алып барыла, моңа иң яхшы көчләр һәм гаять зур чыгымнар җәлеп ителә. Бу афәт-бәла белән озак еллар көрәш тарихында ЦРУ теге яки бу илдә кулланыла торган төп технологик алымнарны бер системага салган инде. Әйтик, Латин Америкасы илләрендә ясала торган долларларның хилафлыгы-төгәлсезлеге бер төрле булса, Польша һәм Венгриядәгеләрнеке—икенче, ә Ливан һәм Ливиядә өченче төрле була. Әгәр шулай әйтергә ярaса, аларның һәркайсының үз милли төсмерe-колориты бар. Ялган акчаларның шундый яшерен үзенчәлекләрен Иллинойста әзерлек үткәндә Карлен-Норман да бик яхшы өйрәнгән иде. Дөрес, фәнни-техник яңа ачышлар, төсле күчермә-копияләр техникасы барлыкка килү, полиграфиядәге югары технологияләр ялган банкнотларның «милли» төсмерләрен җуйганнан-җуя бара, алардагы житешсезлекләр

гомуми интернациональ рәвешкә әверелә, алар белән көрәшүне дә гаять кыенлаштыра: банкнотларның «географиясе» югалу аркасында, аларның «граверларын» эзләп табу да авырлаша. Норманның үзендә барлык атаклы ялган акча ясаучылар хакында житәрлек мәгълүмат тупланган, аларның һәркайсының фоторәсемнәре дә бар, әгәр дә мәгәр кемдер кайсыдыр төрмәдә утырса, ул аның кайчан чыгасын да белә, ә ирекка чыккач, соңгы фоторәсемен дә ала. «Граверлар» гадәттә яшьләр түгел, инде тормышта кыйналган-суккаланган, токтынлыкта үткәргән вакытлары да аларның төс-кыяфәтләрен бик нык үзгәртә. Карлен-Норман да, аның хужалары да, рус мафиясенең галәмәт көчәеп китүеннән соң, Мәскәүдәге һәм башка зур шәһәрләрдәге жинаятьчел дөнья боссларының ялган акча ясауда танылган «белгечләрне» Россиягә чакыртып алу мөмкинлекләрен дә исләреннән чыгармый иде. Бигрәк тә хәзер, шул урында ук ясалган «товарынны» таратып бетерүе дә бик жинел: бер «лимоннан» да ким алмаган дәүләт түрәләренә ришвәт төртгенме—бар ялган долларларың таралды да бетте, дигән сүз. Шуңа күрә, Карлен, казино яки кыйммәтле рестораннарда булганда, жинаятьчел үткәне йөзенә чыккан кемсәләрнең кемнәр тирәсендә ыгы-зыгы килеп, тыз-быз йөргәннәрен игътибар белән күзәтә, аларны хәтерендә сеңдереп калырга тырыша. Дөрес, әле Карленның күзенә үз картотекасында булган бер генә «гравернын» да чалынганы булмады, ә менә Колумбиядән килгән һәм ЦРУ күптән ауларга йөргән бер эре наркотикчыны ул көтмәгәндә Мәскәүдә, «Националь» кунакханәсе ресторанында очратты. Ул бу хакта АКШ илчелегендәге үз кешеләренә, кунакханәнең холлыннан ук шылтыратып, кичекмәстән хәбәр итте, чөнки мондый уңышлар бик сирәк була. Илчелектәгеләр яшен тизлегендә ФСБ (Федераль Иминлек Хезмәте) кешеләре белән бәйләнешкә керде һәм Колумбия мафиясенең Россиядәге хезмәттәшләре белән элемтә урнаштырырга яки наркотиклар озату өчен рус коридорын ачыклау нияте белән килгән бу хәбәр йөртүчене шунда ук кичке аштан соң каптырып та алдылар.

Татлянның картотекасында күренекле «граверларның» гына түгел, ә зур сумма ялган доллар белән тотылучыларның да фоторәсемнәре бар иде. Болар да еш кына ялган акчаларның ничек таралуы турында мәгълүмат бирә. ЦРУ, ялган доллар турында әз генә ишарә булган яки кайдадыр калкып чыккан акчалата зур суммалар турында нинди генә хәбәр басылса да, аны бөтен дөнья матбугатыннан жентекләп жыеп бара һәм бөртекләп тикшерә. Һәм аларның кызыксындырырлыкларын, әһәмияткә ия булганнарын Карлен Татлян үз компьютерына туплый бара һәм һәр иртәсен шул яңалыклар белән танышудан башлый.

Теоретик яктан да, ялган акчалар ясау мәсьәләсенә кагылышлы мәгълүмат белән дә Карлен нигезле-нык әзерлекле иде, тик менә әлегә уңышлары гына юк. Дөрес, ялган акчалар эзләү өчен Татлян бер хәйлә уйлап тапты табуын. Мәскәүгә китәр алдыннан ул долларларның чынлыгын тикшерә торган детекторлар сатучы берничә махсус кибетне йөреп чыкты,—андый кибетләр Америкада санап бетергесез,—һәм һәрвакыт үз кул астында тоту ниятеннән шундый детекторларның иң камил эшләнгән һәм файдалану өчен иң кулай булган берсен сатып та алды. Әгәр кирәге чыкса яки теге-бу компаниянең үзен кызыксындырган серләрен белү теләге туса, ул елмаеп кына кесәсеннән шул детекторын ала да өстәл тирәсендә жыелып торучыларга булган акчаларын тикшерергә тәкъдим ясый. Мондый очрак йә үзеннән-үзе килеп чыга, йә ул аны юри оештыра, мәсәлән, әжәткә йөз доллар сорап ала да аны шундук хужасы алдында тикшереп карый һәм сүзне үзенә кирәкле якка алып кереп китә иде. Ә ялган акчалар турында сөйләшү бик тә урынлы була, чөнки Россия банкларыннан алган банкнотларга да шикләнеп карыйлар иде бирeдә.

## 2

Бер кичне ул, ниһаять, үзе хыялланган серле йомгакның жеп очын тотты. Карлен, Чикагода чыга торган бер музыкаль журналның заказын үтәп, Юрий Башметның камера оркестры турында мәкалә язган иде. Шуна Юрий Башметның үзеннән кул куйдыру өчен, Крис белән Абрекны да ияртеп, алар Маяковский мәйданына—Чайковский исемендәге концерт залы янына килеп туктады. Карлен залда үзе уйлаганга караганда озаграк тоткарланды, начар яктыртылган Тверская урамына килеп чыккач, егетләрнең лимузины әле һаман китмәгәнен, аны көтеп торганын күрде. Бирегә машина кую тыелган булса да, егетләр китмәгән, арткы ишекләре ачык, аннан күнелле көлешкән кызлар тавышы ишетелә иде.

—Башметның үзе белән бер сәгать әнгәмә корып утыргач, менә безнең театр күзәтүчебез дә килеп житте... Исеме Каро, американ ул,—дип, дуслары Татлянны ике кыз белән таныштырды. Кызлар студентлар, Мәскәү кызлары булса кирәк иде.

—Кызлар Башмет концертына иртәгәгә билет алып торганда, касса янында эләктердек үзләрен. Син инде, рәхим итеп, кызларга маэстроның култамга-автографын алырга тырыш. Алар житди музыка дигәндә, үлеп китә икән,—дип, машина ачкычы белән уйный-уйный әйтеп куйды Армен.

—Бәлки, сиңа, Каро, кызлардан да интервью алу кирәктер? Карале, нинди чибәрләр, акыллылар...—дип, сүзгә Ваган-Крис та кушылды.

—Ул моны, әлбәттә, эшләргә тиеш! Без аны монда бер сәгать көтеп утырдык, гаишникка валюта белән штраф түләдек, үзебез ачтан үләбез, ә ул анда Малер, Шнитке, Гобәйдуллина турында сүз куерта,—дип, машинасын кабыза-кабыза, Армен да ачуланган булып кыланды.

—Ах, музыкада нинди югары белемлеләр! Бәлки, сез әле Эдисон Денисовны да беләсездер?—дип төрттереп сорады кызларның берсе.—Әллә шәхсән үк танышмы?

—Без һәммәсен дә беләбез,—дип баш какты Ваган.—Ә хәзер әйдәгез, «Пекин»га барып, ашап алыйк. Ул якында гына, бары борылырга гына кирәк. Бер унайдан Карленның мәкаләсен дә юып алырбыз—бу аның житди музыкаль журнал өчен беренче әйберсе, Башмет кул куярмы-юкмы, дип бик борчылган иде. Күзеннән күреп торам—маэстрога ошаган. Шунда сезнең белән очрашуны да билгеләп үтәрбез...

Күрәсең, егетләр әлеге кызларга чын-чынлап күз салган, кызлар үзләре дә әйбәт тәэсир калдыра иде. Абрек андый очракларда һәрвакыт: өй кызларын яратам, ди торган иде, ә бу нәкъ шундый очрак иде.

«Пекин»га алар кичәнең нәкъ кызып барган чагында, Тоглар ярата торган вакытта килеп керделәр, үз кәефең булмаганда, башкаларның кәеф-сафа коруыннан да кәеф күтәрелеп китә андый сәгатьләрдә. Ишектәге швейцар, метрдотель килеп житкәнче дип, кунакларны туктатып карамакчы булган иде дә, ләкин Ваган аның авызын: «Урын алып куелган»,—дип, бик тиз япты һәм жилкәсе белән генә бер якка этәреп, кулларын киң жәеп кунакларны залга чакырды. Тартырга рөхсәт ителмәсә дә, зал төтен эчендә иде. Анда инде, ресторанның даими кунаклары Крис белән Абрекны танып, болар каршысына метрдотель үзе ашыга иде. Ул аларны үтеп йөри торган арадан икенче рәттәге бер өстәл янына алып килде, өстәл өстендә, чынлап та, «Урын алып куелган» дигән язу тора иде.

«Кем кайда утыра?»—дип, шаулашып маташканда Карлен кызлар тирәсендә ыгы-зыгы килгән Крис белән Абрекның көтмәгәндә генә бер команда ишеткәндәй, катып калганнарын күрде. Чөнки тегеләр үзләреннән бер өстәл алдарак бик бай сый-нигъмәтле һәм купшы-матур чәчәкләр куелган табын тирәсендәге зур бер төркемне күреп алган иделәр. Шунадырмы, бер мизгелгә үзләренең гүзәл юлдашларын да онытып, ниндидер бик дәрәҗәле танышларына ялагайларча буйсынучанлык белән

икесе берьюлы сәламләп баш иде. Карлен һәрвакыт үз-үзләренә нык ышанган, әрсез дусларының мондый кыланышларын, кемгәдер шулай түбәнсенеп бил бөгүләрен, хәтта еракта да куштанланып тәлинкә тотарга әзер торуларын тәүге тапкыр күрде һәм үз күзләренә үзе ышанмады. Тегеләр ерак та түгел, янәшә генә утыра, яннарына барып исәнләш, бер-ике матур-матур сүзләр әйтеш юкса, ләкин ереванлы гангстерларның абруй-дәрәҗәсе моны рөхсәт итмәгәне сизелеп тора иде. Татлян шундук аңлап алды: ул гел очраклы гына рәвештә Мәскәүдәге җинаятьчел дөньяның иң югары дәрәҗәле кешеләре белән янәшә туры килде һәм сак-сизгер булырга карар кылды. Билгеле инде, тегеләрне ничек булса да фоторәсемгә төшереп алырга кирәк иде. Үзенең биредә кул кушырып утырмаганын, ә башкаланың иң зур җинаятьчел «авторитетлары» белән янәшә эшләгәнен үзәккә тагын бер кат раслау мөмкинлеге иде бу.

Армен сафьян тышлы зур исемлектән әчемлекләр өйрәнеп, ә Ваган аңлавы авыр булган күп сәхифәле кытай ашлары менюы белән танышкан арада,—шулай да ул аңа кытай әлифбасы булып күренми иде бугай,— кызлар чәч-башларын төзәтеп, үзләрен тәртипкә китерергә дип, хатын-кызлар бүлмәсенә кереп китте. Тынлыктан файдаланып Карлен Абректан сорады:

—Күрше өстәл тирәсендәгеләр нинди бик дәрәҗәле әфәнделәр соң? Кара әле, «Пекин» хуҗалары аларга нинди игътибарлы, ихтирам-хөрмәтле, метрдотель дә яннарыннан китеп тормый, ә официантлар бригадалап хезмәт күрсәтә. Ихтимал, нинди дә булса күренекле кешеләрдер, ә бәлки, сенаторлар, конгрессменнардыр, ә?

—Сенаторлар? Конгрессменнар?—дип көлемсерәде Абрек, кулындагы сафьян тышлы исемлекне читкә этәреп, аның әчемлекләрдән нәрсәләр сайлаганы сизелә иде инде. Ул уйчан гына рәвештә бармагы белән өстәлгә суккалап алды.—Ә син, мөгаен, хаклыдыр, кадерлем Каро. Алар бүгенге көннең чын асыл конгрессменнары һәм сенаторлары. Үзләрен илнең хуҗалары, тәртип һәм конституция сакчылары дип хисаплап йөрүчеләр,· Дәүләт Думасында һәм Федерация Советында утыручылар исә бары тик клоуннар гына. Хәер, Кремль марионеткалары булса, мин алар белән шулай ихтирамлы баш иеп исәнләшеп торыр идемме соң? Син мине кемгә саныйсың?

—Алайса хикмәт нәрсәдә соң?—Карлен, бернәрсә дә аңламаган булып кыланып, күзләрен шарландырды.

—Ә эш шунда, дустым, тагын бер елдан бераз артыграк вакыттан соң Россиядә президент сайлаулары... Син аларны күзәт тә хәтереңә сала бар, анда утыручыларның кайсысыдыр, ә, бәлки, берничәседер илдәге хакимиятнең иң югары баскычына менеп кунакларга теләмиме икән? Ә инде дилбегәне кулына бер алса, ул аны ычкындырмаячак. Ә хакимлек—бик татлы нәрсә ул,—дип җанланып китте Армен, аның күзләрендә очкын кабынды.

—Әйе, син хаклы,—дип Карленга да ризалашырга туры килде.—Ә бу шәхесләр, күрәсең, бик кызыклы халык, ахрысы...

—Шулай булмыйча соң!—Армен бу дөньяның иң көчле-куәтле затларына якын торучы бер кемсә булып күренергә тырыша иде. Урындыгы артына сөялеп, ул сүзен дәвам итте:—Әнә тегесе, соры костюмлысы, үз кандидатурасын, һичшиксез, күрсәтәчәк. Аны хәзер акча кызыксындырмый инде, күбенгәнче ашаган ул аны. Алдашып тормыйм, фамилиясен әйтә алмыйм, ә кушаматы—Шаман. Кулында Төмән нефтен, өч-дүрт эре банкны, ике газет һәм бер телеканалны тота. Күчемсез милке турында сөйләп тә тормыйм инде: заводлар, нефть үткәргечләр, сарайлар, пароходлар, яхталар, самолетлар һ. б. һәм һ. б. Янәшәсендә аның дусты, элекке камерадашы, Дантес кушаматлы, фамилиясе Лозовской, исеме Олег, үзе Днепропетровскийдан, «Метрополь»да тулы бер катны биләп тора. Буш вакытларында Дантес бик эредән генә карт уйнап алуга да каршы түгел. Ә аның белән янәшә сулдагысы, әнә шул горур кыяфәтле,

аксыл тройка костюм кигәне—атаклы Алик Тайванлы, кәрт уенында бик күренекле, оста хәрәмләшүче. Чит илләргә чикләрне ачканнан соң, ул еш кына дөньяның иң бай курортларында Мәскәүнең легендар каталасы Городецкий белән икесе бер кулдан уйный, дип сөйлиләр. Анысы Россиядәге җинаятьчел тормышның аяклы энциклопедиясе. Аның кушаматы Аргентинлы, синең аны, безнең белән бергә кергәләп йөргәндә, ябык катраннарда күргәнең дә бар, ул һәрвакыт ак смокинг костюмнан көязләнеп йөри. Алар Тайванлы белән икесе уйнаган урыннарда уенга миллионнар, виллалар-сарайлар, заводлар-шахталар салына. Күптән түгел генә Көньяк Африка Республикасында уйнап ике шахта отканнарын ишеттек, хәзер шуларны кемгә сатарга икән дип аптырыйлар, имеш. Синең штатларда бай клиентларың юкмы? Кыскасы, Көнбатышны калтыратып, Россиядәге кәрт уенчыларының байрагын югары тота алар,—дип көлеп җибәрде Абрек.—Ә менә тегесе, Тайванлыга француз шампаны «Тайттингер» салып торганы, безнең яхшы танышыбыз, «Золотой петушок» ресторany хуҗасы, кушаматы Хавтан, шәп мужик, ни-нәрсәнең ни-нәрсә икәнен аңлап яши. Без Крис белән аның янына сине бер алып керербез әле. Аның ашамлыклары Мәскәүдә иң яхшылардан санала, ә шеф-пешекчесе Петрович аш-су эчендә сихерче дә тылсымчы, бик елдам кеше. Ә менә бүгенге мәҗлеснең баш хуҗасын мин белмим.

—Ә ни өчен син аны баш хуҗадыр дип уйлыйсың әле?—дип сорамый булдыра алмады Карлен, тегеләрне күз кырые белән генә күзәтә-күзәтә.

—Уйлап та торасы юк. Кара, Шаман белән Дантес аңа нинди ихтирам-хөрмәт күрсәтеп утыралар, бер чакрымнан күренеп тора ич. Мин әнә шул өстәл башындагы чандыр гәүдәле, купшы костюмлы, зиннәтле алтын күзлекле кеше турында әйтәм. Ул адәм бөлгән «Трефовый туз» казиносын сатып алган, дип сөйлиләр, аны гел үзгәртеп-янартып бетергән, әмма исемен алыштырмаган. Әле ул тагын «Гелос» фирмасы аукционында Иван Пунинның гасыр башында язылган атаклы «Треф тузы» картинасын сатып алган да, аны зур залга, инглиз камины өстенә элеп куйган.

—Нииндидер эстет икән...—дип көлемсерәде Карлен.

—Ай-һай! Гади эстетка Шаман белән Дантес алай хөрмәт күрсәтеп утырмас иделәр. Моннан ук күренеп тора бит, ничек аны көйләп-иркәләп кенә утыралар... Юк, бу бик югары оча торган кош,—дип, ышанычлы итеп әйтте Армен һәм шундук «сенаторлар» белән «конгрессменнарны» да, Карленны да онытып, җәелеп елмаеп җибәрде—берничә минут югалып торганнан соң тагын да чибәрләнеп киткән кызлар өстәл янына килә иделәр.

Кызлар әйләнеп килгәндә, табын әзер иде инде, беренче тостларны әйтү белән күңелле гөрләшү башланды. Ни генә димә, кавказлылар типтерә белә, бигрәк тә яннарында чибәр кыз-хатыннар булганда. Дусларының комсызланып ашавын күргәч, Карлен аларның чын-чынлап ачыкканлыкларын аңлап алды, аннары «Пекин»дагы сый-нигъмәт тә сүз әйтерлек түгел, бик шәптән иде. Әлбәттә, аны аңлый белгән кеше өчен инде. Оркестр туктаусыз диярлек уйнап торды, күрәсең, акча да, заказлар да бер-бер артлы ява гына үзләренә. Дуслары кызлар белән биергә чыккан араларда, Карлен «сенаторлар» һәм «конгрессменнар» өстәле яныннан узып, берничә мәртәбә тәмәке тартып керде, тәгаен барып чыксын өчен теге өстәлдәгеләрне берничә ноктадан фотога да төшерергә өлгерде. Россиянең киләчәк хакимнәренең җинаятьчел даирәләрендә кайчан да булса шәп кенә табыш та китерергә яки инде... гомеренне өзәргә дә мөмкин. Ул кичне ишелеп төшкән бу уныштан Татлян кызлар белән биеп йөрүче гангстер дусларына караганда да бәхетлерәк булды—ул инде күңеленнән алга таба ни-нәрсәләр эшләр өчен уй-ниятләрен дә төзеп куйган иде. Ләкин кинәт, аның дуслары чираттагы мәртәбә зал уртасында нииндидер чеганча-кавказча биеп маташкан, ә Карлен үзе, кызлар бик яраткан һәйбәт бургунд шәрабе эчкәли-йоткалый, чәнечкесе

белән ялкау гына сян-гу гөмбәсенә тәрткәләштереп утырган чагында, хәбәрчебезгә бәхет тагын бер кат елмайды. Теге күрше өстәл янына ышанычлы адымнар белән... кем дисез?—Картье якынаеп килә иде! Мондый типтерү, кәеф-сафа кору урыннарын бер дә калдырмый йөри торган егетнең килеп керүе очраклы түгеллеге сизелеп тора, ул йә мәҗлескә соңга калган, яки аны мәҗлес барышында чакыртып алганнардыр: хәзерге заманның гадәти күренеше—һәр кунакның тәлинкә-фәләннәре янында кесә телефоннары да ята иде бит.

Бөркет күзле Карлен, табында утыручыларның соңга калган кунакны сәламләп елмайганнарын да, Дантесның исә, егетне каршы алырга дип, урыныннан кузгалганын да күрде. Шул чакта бүген барысы да аның тирәсендә бөтерелгән бик затлы костюмлы әфәнде дә елмаеп, урыныннан күтәрелде, ә кунак егет, иң әүвәл аның янына килеп, кочаклашып күрешкә, бары тик шуннан соң гына калганнары белән кул бирешеп алды. Аны алтын күзлекле чандыр гәүдәле әфәнде янына утырттылар. Яңа килгән кунакның тостын күнелле генә тыңлап утыручыларга караганда, Карлен инде иң якын арада Картьега да, күпбелмеш Аргентинлыга да, Хавтанга да яшерен тыңлый торган телефоннар куярга кирәклеген чамалый иде. Иртәме-соңмы, бу гамәл Россиядә басыла торган ялган долларларның эзенә төшергә ярдәм итәчәк иде.

### 3

Нәчектер шулай атна уртасында, Крис белән Абрек бөтенләй көтмәгәндә генә Лондонга китеп барырга булды. Әйе, көтмәгәндә генә, чөнки Карлен белән аларның башка планнары бар иде: атна кич көнне иртәрәк Санкт-Петербургка кузгаласы иделәр, Татлянның анда бер дә булганы юк, ә гангстер дусларын шунда ниндидер акча эшләре көтә иде. Иске бер исәп-хисапны өзәселәре бар—аларга бурычлы кешенең эшләре әйбәт кенә җайланып киткән икән. Кыскасы, Төньяк Пальмирада бик шәпләп типтереп, бер унайдан Нева буендагы шәһәрнең гүзәллеге турында күп ишеткән американга аның иң матур урыннарын да күрсәтеп кайтмакчы иделәр.

Иртән Карлен дүртенче катка төшкәндә, дуслар ашыга-ашыга ерак юлга җыенып ята иде.

—Ә, Каро, хәерле иртә,—дип баш какты Армен.—Керүең яхшы булды әле, безне аэропортка илтеп куярсың. Берничә көнгә Англиягә очабыз, ашыгыч эш бар. Зинһар, кофе генә пешер әле, син аны әйбәт пешерәсең, бигрәк тә итальян рецепты белән.

Карлен кухняга үтте, өстәл өсте кичә кәефләнеп утырганнан соң җыештырылмаган көе иде әле. Өч зур тәмәке көллегендә өелеп торган төпчекләргә караганда, кунак ир кеше булган һәм озак утырганнар, әмма бик аз эчкәннәр—нибары ике шешә әрмән коньягы «Ереван». Голланд кофе пешергече «Филипс»ка яна тарттырылган «Арабика» кофесы салып торган чагында, Карлен өстәлдәге буш тәлинкәләр арасында ике паспорт күреп алды. Татлянның паспортларга исе китмәде, аларның дипломатик яшел төстә булуы гаҗәпләндерде. Мондый документлар булганда, чит илгә чыкканда да, кергәндә дә беркем дә бәйләнеп тормый, таможня гомумән аларны карап та тормый. Һөнәри сизгерлегенә буйсынып, Карлен паспортларның икесен дә ачып карады, бу дипломатик паспортлар аның дуслары исеменә язылган иде. Документларны урынына куйгач, ул залга парлары чыгып торган кофелы поднос күтәреп килеп керде, авыз ачып бер сүз дә әйтмәде—дуслары аның паспортларны күрүкүрмәве турында уйланып та тормадылар. Әлбәттә, паспортларны кичәге кунак китергәнлеге ачык иде, егетләр аның белән озак кына утырганнар, мөгаен, юеш-салкын Лондонга очып барып кайтырга кирәкле ашыгыч йомышны да шул кунак тапшыргандыр. Карленнын ул кешене белми калуы кызганыч, ул кемсә аның яшерен оешмасын, ихтимал, кызыксын-

дырган булыр иде. ЦРУда лаеклы гына карьера эшләп килүенә әле күп вакыт үтмәгән булса да, атналык отчетын биргәндә, бу юлы Карлен беренче мәртәбә әлеге мөһим мәгълүматны яшереп калдырды: гангстер дусларының дипломатик паспорт белән американнарның НАТО буенча ин якын союздашлары булган англичаннар янына очканын үзәккә хәбәр итмәде.

... Дуслары Англиядән кайтып төшәсе көнне Татлян рус рок-йолдызы концертына барырга җыенган, концерттан соң шул җырчыга табынучы бер бай кызның өенә мәҗлескә чакырылып, ул кызның әтисе Мәскәүдәге бер танылган банкир икәнен һәм аның исемен дә әйткәннәр иде. Ләкин очып кайтып төшкән Арменның телефоннан шылтыратуы бу ниятләрен бозды да куйды: тегесе аны Лондонга бик уңышлы барып кайту хөрмәтенә кич белән кунакка чакырды, Карленга көтелмәгән сюрприз дә әзерләп куюлары турында да тишәте.

—Соң, сезнең суыткычыгыз да буш бит әле,—дип, баш тартып карамакчы булган иде Карлен, аның бу сүзләреннән Армен кычкырып көлде генә.

—Буш булса соң! Без Хавтанга, «Золотой петушок»ка шылтыраттык инде, менә-менә аннан ике официант килеп җитәр һәм бер ресторанныкыннан да ким булмаган табын әзерләп китәргә тиеш. Петрович тырышыр, ул безгә нәрсәләр кирәген яхшы белә. Димәк, бүген чын урыс ашлары-ризыклары ашаячаксың, көтәбез...

Чынлап та, билгеләнгән вакытта Карлен дүртенче катка төшкәндә, залдагы зур өстәлгә, бар кагыйдәләрен китереп, табын корып куелган иде инде. Хавтан хәтта кыйммәтле савыт-саба һәм көмеш чәнечкекашыкларга кадәр җибәргән, күрәсең, дәрәҗәле затларга барып хезмәт күрсәтү аңарда да теләсә кайсы Европа башкаласындагыдан начар түгел иде.

Карлен мәҗлестә тагын кемнәрдер булыр дип көткән иде, әмма табын өч кешегә генә әзерләнгән булып чыкты. Гадәттәгечә, ни башка дуслар, ни кызлар юклыгын күреп гаҗәпләнүенә:

—Кызганыч, Ашот Алма-Атадан кайтып җитә алмады, без аңа шылтыраттык, әле тагын өч көнгә тоткарланачак икән. Без бүген бик мөһим бер вакыйганы юабыз, шуңа күрә беркемне дә чакырмадык, хәтта шамакай халдейләребезне дә кайтарып җибәрдек,—дип аңлатма бирде Ваган.—Ләкин соңрак теләк булса, берәр төнге клубка китәрбез: «Сохо»гамы, «Манхэттен-Экспресс»камы анда. Ә, бәлки, Оля белән Надяга шылтыратырбыз—хәтерлисеңме, без алар белән «Пекин»да утырган идек? Алар синең өчен дә берәр кызны эләктереп килер. Кышкы каникулларында ул кызлар белән кая да булса Фиджигамы йә Таитигамы очып барып кайтырга кирәк булыр әле, ә бәлки, шунда бергәләп Яңа елны да каршыларбыз. Пальма агачлары арасында ярым шәрә килеш Яңа елны каршы алу—могаен, шәптер ул, ә?—дип хыялга бирелде Ваган.

Армен кулларын киң җәеп җибәреп, дусларны табын янына чакырды һәм Карленга урып күрсәтте. Алдан әзерләп куелган сюрпризның кызыгын Америкап егет ялгыш бозудан куркып, Армен ашыгып әйтте:

—Каро, кадерлем, тәлинкәң өстендәге салфетканы күтәр әле. Без бит сиңа, эшебез уңса, Лондоннан бүләк алып кайтырга вәгъдә иткән идек,—диде.

Карлен «Золотой петушок» эмблемасы һәм вензеле төшерелгән салфетканы сак кына күтәрде—кардан да ак инглиз фарфоры өстендә авыр алтын браслетлы алтын сәгать ята иде. Рәвеше белән ул атаклы «Картье-танк» сәгатенә бик охшаган булса да, башка—тагын да нәфисрәк аристократик Швейцария сәгате «Франк Мюллер» иде. Мондый сәгатьләрнең бәяләре атаклы автомобильләрнең, әйтик, «мерседес»ның бәяләренә тиң яки аннан да артып китәрлек. Кунак сәгатьнең акылга сыймаслык бәясен белә иде булса кирәк, шуңа күрә ул аңа аптырабрак карап торгач, Абрек күңелле генә итеп әйтеп куйды:

—Каро, Мәскәүдә байлар кыйммәтле Швейцария сәгатьләренә кызыга башлады: «Ролекс», «Патек Филип», «Пьер Бельман», «Лонжин», «Омега» ишеләргә—ну, син боларны үзең дә беләсең инде. Син безнең дустыбыз, иң күренекле мәскәүлеләр арасында катнашасың, шуңа күрә без сина истәлекле бүләк бирергә булдык,—диде. Бераз тын алгач:

—Шушы «Франк Мюллер» сәгатенә тукталдык. Үзебезгә дә шундый берәрне, әмма төрлерәк ясалганнарын алдык. Әгәр монысы сиңа ошамаса, теләсә кайсыбызныкы белән алмаша аласың, дөрес, мин үземә күн каешлыны алдым, ул бәясе белән бер дә синекеннән ким түгел. Йә, алмашабызмы?—дип сорады.

—Юк, миңа монысы ошый,—дип, соклануыннан таң калган Карлен сәгатьне кулына алырга да куркып утыра иде.—Дөресен әйткәндә, кулымда тулы бер «кадиллак» йөртүне башыма сыйдыра алмыйм әле мин.

—Ну, эш шуннан гына тора икән, Аллага шөкер! Ә мин инде ошатмадын дип уйлаган идем,—дип шатланды Ваган һәм тост тәкъдим итте:—«Франк Мюллер» сәгатьләре безнең һәрберебезгә дә озак хезмәт итсен һәм бары тик бүгенге кебек шатлыклы вакытларыбызны гына күрсәтсен...

Шуннан мәҗлес үзенең җай гына уңаена дәвам итеп китте.

Әмма шунысы сәер, Карлен, әледән-әле беләгендәге затлы-тоныК ялтыраган авыр алтын браслетына караштыргалап утырса да, кинәт кенә шуны тоеп алды: үзләренең сүзләренә караганда, бик уңышлы сәфәр кылып кайтуларына да карамастан, егетләр ничектер киеренке-кыен бер халәттә иде. Карленнның аларны әле беркайчан да мондый хәлдә күргәне булмады. Ул нәрсә булганын сорарга җыена гына башлаган иде, Ваган көтмәгәндә тулы рюмкасын тотып торып басты...

—Кадерле Каро,—диде ул, дулкынланып.—Мин нотык сөйләмәкче булам. Ә син тыңлап утыр... Соңгы көннәрдә ниндидер бик әһәмиятле вакыйгалар булды—безнең өчен, ватаныбыз Әрмәнстан өчен. Әгәр дә без тегендә, Лондонда һәлак булсак яки иртәгә безне Мәскәү урамнарының берсендә атып үтерсәләр—исегез киткән икән, ике бандитны үтергәннәр, дип әйтүчеләр дә табылыр, мөгаен. Бәлки, шулайдыр да. Ләкин өч көн элек без Әрмәнстаныбыз өчен, күп газаплар күргән халкыбыз өчен, бигрәк тә Карабах өчен бик күп тәкъва гадел кешеләр эшләгәннән дә артык изге эш кылдык. Бу хакта мин иң якын кешеләремә-туганнарыма да әйтә алмыйм—без бөтенесен дә сер итеп сакларга сүз бирдек. Юкса, дәүләтара катлаулы хәлләр, гауга-җәнҗал чыгарга мөмкин, без дә рәшәткә артына кереп утырачакбыз. Ләкин без үзебезнең җиңүебез, Карабахтагы әрмән туганнарыбызның азатлыгы өчен өлеш кертүебез турында кем беләндер уртаклашырга тиешбездер бит. Ашот белән сез—иң якын дусларыбыз. Ашот өйдә юк, шулай булгач, без аны синең белән бүлешергә булдык, серебезне тик берүзең генә беләчәксең.

—Ни өчен мин?—дип сорамый булдыра алмады Карлен, эчтән куырыла төшеп, аннары бераз котырткандай итеп әйтеп тә куйды.—Ә бәлки, кирәкмәстер?

—Кирәк, кирәк,—дип дустына ярдәмгә килде Армен.

—Алай булса, тыңлыйм...

—Әйдәгез, башта эчеп куйыйк, аннары мин сөйләп бетерермен...

Алар бокалларын күтәрделәр... Аннары Ваган сөйли башлады, Армен исә аның сүзләрен, нәкъ шулай булды, дип раслагандай, баш кагып утырды.

—...Без Лондонның үзәгендәге бер квартирада, телефоннан шартлы шылтырату көтеп утыра идек, ул сәгатьләрдә без бик күп нәрсәләр турында сөйләштек, уйлаштык. Без башкарып чыгасы эшнең куркыныч икәнлеген бездән яшермәделәр. Әгәр дә полиция безне тере килеш тота-нитә калса, без таларга кергән идек, шәхси үчебез бар иде, дигән сылтау әзерләп куйдык—бернинди сәясәт юк, чөнки эзебез Ереванга сузылыр, Әрмәнстанга күләгә төшәр иде. Рафик Сво абзабыз: сәясәттән

ераграк булыгыз, жир йөзендә бөтен явызлыклар-әшәкелекләр шуннан килеп чыга, дип гел кисәтеп тора иде, ләкин бу очракта сәясәт илебез халкының мәнфәгатьләре белән бәрелешкән иде һәм без баш тарта алмадык. Менә шулай авыр сулап озын-озак көтеп утырганда, Абрек әйтә: «Әгәр без иртәгә һәлак булсак, безне яхшы сүз белән искә алып, үлгәнебезне белгәч, елап-кайгырып, безнен гөнаһлы жаннарыбыз рухына шәм куючы берәр кеше табылырмы икән?»—ди. Һәм без икебез дә синең хакта уйладык, Каро, син бит күршебез, якташыбыз, дустыбыз. Чөнки син безне башта ук ничек булсак, шулай, гангстерлар икәнебезне белеп кабул иттең.

Карлен, риза булмыйча, кулларын күтәрде, ләкин Ваган сүзләрен төзәтеп тормады.

—Әйе, нәкъ шулай. Ләкин син безнең белән теләсә кая барырга да оялмадың, хәтта күршебезгә күчеп килдең, шуңа без сине яратабыз да, Каро.

—Лондонда ни-нәрсә булды соң?—дип сорады Татлян.

—Әллә ни зур вакыйгага да түгел кебек ул үзе, үзебез уйлаганча, гади җинаятькә охшаш бер эш кенә; әмма бик тә әһәмиятле, мин арттырып сөйләмим. Чемодан-чемодан долларлар тотырып,—Лондон банкларында алар исеменә әле зур-зур суммаларга счетлар да ачып куелган булган,—менә шундый ике чечен егете самолетларны, вертолетларны, танкларны кырып кына сала торган атаклы «стингер» ракеталарын сатып алмакчы булып килгән, әле шуның өстенә Англия дан токтан космик элемтә чаралары һәм башка өр-яңа кораллар да алмакчы булган алар. Бу аларның Лондонга беренче генә килүе түгел икән инде, Әзәрбәйжан аша Чечняга озаткан беренче генә партия корал да түгел икән. Болар турында безнен бирелә яшәүче әрмәннәр белеп алган да әллә үзебезнен махсус оешмаларга, әллә чит илләрдәге әрмән партияләре органнарына хәбәр иткәннәр. Син бит беләсең, әрмән диаспорасы булган һәр жирдә—Франциядән алып Аргентинага, Ливаннан алып Канадага кадәр һәркайсында «Дашнак-цутюн» партиясе бик көчле. Безгә бу жаваплы эшне кем тапшырганы ул чаклы әһәмиятле түгел, эшнең асылы шунда: Европага бик тиз генә юл салган чеченнәр үз акчаларына бер очтан Әзәрбәйжан өчен дә корал сатып ала башлаганнар, анда бит коралны—диңгездән ни, һавадан ни—илтү жиңелрәк—бәйсез дәүләт ич.

—Димәк, бу ышанычлы транзит юлы өчен Дудаев Әзәрбәйжанга корал белән түләп торамы?—дип ачыклады Татлян.

—Нәкъ шулай... Хәер, әле бүген чеченнәр, һава юлы ачык булудан файдаланып, нәрсә тели һәм кемне тели, шуны алып та чыга, алып та керә ала. Ләкин Грозныйда, ихтимал, аңлыйлардыр: хәлләр теләсә кайчан үзгәрергә мөмкин һәм, сугыш була-нитә калса, урыслар һава юлын ябып куячаклар—Россиянең ПВОсы да, авиациясе дә шушы көнгә кадәр, Аллага шөкер, бик көчле әле. Ә чеченнәрнең сугышка әзерләнгәнлекләрен сукыр гына күрмәскә мөмкин. Ни өчен Россиядә хәрби складлар бер-бер артлы яна башлады дип уйлыйсың? Бу һич тә диверсия түгел, сатлык генераллар, очраклы янгын ясаган булып кыланалар да, чеченнәргә корал саталар. Көне-төне Чечнягә бертуктаусыз машиналарда, поездларда снарядлар, корал һәм амуниция озатыла тора. Ярар, чеченнәрнең үз эше—анысын бер Алла беләдер, безнең бит үз проблемаларыбыз бар. Безнең махсус органнарның кулында кире кага алмаслык дәлилләр булган: чеченнәр бер өлеш коралны Баку өчен сатып алган, димәк, Карабахка каршы, әрмәннәргә каршы, дигән сүз бу. Бу мәсьәләне дипломатик каналлар аша да хәл итәргә тырышып караганнар, әмма эш зур акчаларга килеп терәлгәч, халыкара санкцияләрдән курку да бетә, дөньяның кайнар нокталарына салынган эмбарго-тыю дигәннәре дә онытыла. Шулай түгелме?

—Әйе, болар миңа таныш...—Карлен Ваганга бераз тын алырга мөмкинлек бирергә теләде, чөнки Лондонда булган вакыйгаларны янадан күңеленнән кичереп, тегесе бик нык дулкынлана иде.

—Менә шул, бу алыш-бирешне бары тик сатып алучыларның үлеме генә туктата ала иде. Шул чагында безне дәштеләр дә инде... Ә без үз эшебезне эшләп кайттык. Чиста итеп эшләдек... Моның өчен безгә Әрмәнстанның әҗере булмый калмас әле, шулай ук Россиянең дә. Шуна күрә, әйдәгез, беркем һәм беркайчан да безнең ватаныбызга начарлык кылырга уйламасын өчен күтәреп куйыйк әле. Әгәр дә андый кабахәтләр янадан да табыла икән, алар юлына аркылы төшәрдәй асыл егетләребез дә һәрвакыт булыр. Аркылы төшәрләр һәм туктатырлар.

Карлен белән Армен сүзсез генә күтәрелделәр дә икесе берьюлы әрмәнчәләп: «Шулай булсын!»—дип бокалларын төбенә кадәр эчеп куйдылар.

Көтмәгәндә Карленнның күзенә яшьләр килде, бу минутларда ул, әле мона кадәр бер дә булмаганча, үзен шул кечкенә Әрмәнстанның һәм аның күп газаплар чиккән борынгы халкының бер кисәге итеп тойды, барлык илләрдән дә көчле-куәтле Америка гражданы булса да, Карлен да әрмән бит.

Армен елмайды, Ваганның җилкәсеннән кагып алды: тынычлан, дус, барысы да тәртиптә, дигән сүз иде бу.

—Әмма, кадерле Каро, Ваган каушавыннан һәммәсен дә сөйләп бетермәде әле. Иң башка сыймаслыгы шул: бу тарихның азагы һич без уйлаганча гына булып чыкмады. Шунысын да әйтергә кирәк, безгә бу четерекле куркыныч эшне тапшыручылар туп-туры әйттеләр: «Безнең бер тиен акчабыз да юк, хәтта авиабилетларга да»,—диделәр. Алар безгә бары тик дипломатик паспортлар гына табып бирделәр. Шулай итеп, үлемгә бару тәвәккәллегеннән тыш, без әле бу куркыныч эшне үз акчабызга башкарып чыгарга да мәҗбүр булдык. Ваган янадан сүзгә кушылды:

—Без аулаган кешеләр искиткеч байлар һәм, безгә аларның бик абруй-дәрәҗәле чечен ыруыннан—тейпларыннан икәнлеген дә әйттеләр. Алар Лондондагы иң кыйммәтле «Лейнсборо» отелендә тукталганнар, тәүлегенә алты меңәр доллар түләп люкс номерында яшәгәннәр. Мин аларны аңлыйм, яшь егетләр, кәпрәеп йөрергә дә яратканнардыр, аннары, күрәсең, аларның да тормышы, Крис белән безнеке шикелле үк куркыныч-тәвәккәллек сорый торган булгандыр.

—Лондонда булганым бар, ә менә «Лейнсборо»да яшәргә туры килмәде,—диде Карлен.

Ваган ана төрттереп куйды:

—Кая инде ул сина, ярлы хәбәрчегә! Анда шундый апартаментлар, егылып китәрсең! Әнә, Армен сөйләр, ул анда, тик утырудан туеп, бөтен буклетларын өйрәнеп чыкты...

—Өйрәндем шул,—дип ризалашты Армен.—Операцияне берничә мәртәбә кичектергәч, тагын нишләргә кирәк иде? Лондонны без күрмәдек тә, шау-шу тынгач, янадан барып кайтырбыз әле, «Лейнсборо»да яшәп тә алырбыз. Отель—башкаланың нәкъ үзәгендә, Гайд-парк белән янәшә. Аннан ерак түгел—Букенгем сарае. Кунакханә, дөрес, үзе әллә ни зур түгел, үткән гасырда ул бинада госпиталь булган. Үзгәртеп төзегәндә һәр номерга миллион доллардан артык акча исраф ителгән, дип сөйлиләр. Байлыгының чиге юк: һәркайда бәллүр, кызыл агач, алтын, мәрмәр! Караватлары нәфис-зиннәтле балдахин чатырлы, диварларына атаклы рәссамнәр картиналарының төп нөсхәләре эленгән, идәннәрендә—кулдан сугылган асыл келәмнәр. Люкс номерларының һәркайсына шәхси дворецкий-хезмәтче куелган, «даймлер» автомобиле беркетелгән, ләкин без аулыйсы киекләр «роллс-ройс»та йөргәннәр, шоферлары да тумышы белән Сириядән чыккан, инде күптәннән Лондонда яшәүче чечен булган.

—Сезгә җиңел булмагандыр, аңлыйм...—дип егетләрнең хәленә керде Карлен.

—Алай гынамы соң!—дип аның теләктәшлегенә шатланып җавап бирде Армен.—Әлбәттә, чеченнәрнең һәр адымы безнекеләрнең күз унында, һәр сөйләшкәннәрен тынлап баралар, барлык элемтә-

бәйләнешләрен тикшерәләр дә янә аларын да яшерен тыңлый башлыйлар. Ләкин шулай булуга да карамастан, көчкә-көчкә генә ычкына алдык: кайдадыр зур сумма акча илтә киткән тән сакчылары без уйлаганнан иртәрәк кайтып керде. Без лифттан чыкканда алар белән маңгайга-маңгай бәрелешә яздык, шул безне коткарды да. Ә номерларында без биш минуттан артык тормадык: чечен егетләре ишекне безгә үзләре ачты, чөнки алар нindидер сөйләшүләр алып бару өчен үзләренә таныш булмаган кешеләрне көтеп утыра иделәр, без менә шул бизнесменнар булып барып кердек тә инде. Тавышсыз ата торган итальян пистолетлары «бернанделли»ларны без шунда, жәза башкарган урында, ташлап калдырдык.

—Юк, син иң кирәклесен, иң кирәклесен әйт!—дип түземсезләнеп ашыктырды дустын Ваган.

—Әйе шул, монысы аның әллә ни нәрсә түгел иде...—Армен ачыктан-ачык шатлана иде, әйтерсең, кушылган эшне жиренә житкереп үтәгәнлекләрен әле хәзер генә аңлаган да, алар әле генә исән-сау кайтып кергәннәр.

—Тагын нәрсә булды соң?—Карлен да мавыгып, азартка бирелеп китте.

—Ышанмассың, дус!—дип шаркылдап көлде Ваган.—Әмма дәлилләребез күз алдында.

Армен голтлатып бер стакан минераль суны эчеп куйды, күрәсең, дулкынланудан тамагы кипкән иде. Аннары сүзне янә үзе башлады:

—Нәкъ шулай! Кыскасы, без чыгып барганда Криснын күзенә хәзер һәркайда модада булган саквояж-сумка чалына. «Дюпон» фирмасы бай сәяхәтчеләр өчен эшләп чыгара инде андый кыйммәтле әйберләрне. Крис сумканы ачса—эче тулы долларлар! Шунда мин болай гына гардероб ишеген ачып карадым. Анда да шундый ук сумка һәм шулай ук туп-тулы акча! Без юләр түгел бит, сумкаларны эләктердек тә—әллүр! Тән сакчыларына барып бәрелүдән Алла саклады. Юкса, баш беткән иде! Әнә алар, саквояжлар. Ышанмасаң, үзең ачып кара. Исән-сау үзебезнең квартирабызга кайтып кергәч, хорафат-ырымнарга ышанган шикелле, бу бәхет безгә Аллага яраклы изге эш кылганыбызның әжере дип уйладык. Бу акчалар да бит сугыш өчен, үлем китерү өчен әзерләнгән булган...

Татлян, бер яктан, бу тарихка ышанып, икенче яктан, үзен бик каты шаяртуларыннан шикләнеп,—Абрек шундый шаяртуларга бик оста бит,—урыныннан торды да ашыкмый гына бик купшы-зиннәтле саквояжлар янына килде. Берсен ачты, икенчесен... Карленга хәтта долларлар исе кыйммәтле күн исен дә басып киткәндәй тоелды. Бу кадәр күп акчаны аның хәтта киноларда да күргәне юк иде...

Артына килеп баскан Крис кулын бер саквояжга тыкты, Армен—икенчесенә, һәм алар, сөйләшеп тә тормыйча, көчле зур куллары күпме эләктерә алса, шул кадәрле доллар төргәкләрен тартып та чыгарды. Ул акчаларны каушап-аптырап калган журналист алдына өстәлгә китереп салдылар:

—Ал, теләгәнеңчә туздыр! Тыныч халыкны кыру-юк итү өчен боларга кемнәрдер бомбалар һәм «стингерлар» сатып алганчы, без аларны типтереп, кәеф-сафа корып тотып бетерербез...

Карлен, бу кичтә икенче тапкыр аңгы-миңге хәлдә, өстәл янына килде дә банк кәгазьләренә төрелгән унмы-уникеме төргәк долларларны аерып алды, үз тәлинкәсенә таба эшереп куйды. Ул нindидер эчке каршылык тоя, талап, кешеләр үтереп тапкан бу акчаларны алырга хакы юклыгын да аңлый, ләкин бу тойгы нindидер кыюсыз-хәлсез, аннары, икенче яктан караганда, ул бит инде шул ук акчаларга алынган алтын «Франк Мюллер» сәгатен кулына киеп куйган да иде һәм ни өчендер ул сәгатьтән дә бер дә аерыласы килми иде.

—Йә, хәзер, күңелләрдән шундый авырлык ишелеп төшкәч,—ә шулай да үз эчендә сер йөртү жиңел нәрсә түгел икән,—әйдәгез, исәнлек-

саулык өчен, яшьлек өчен, сөю-сөелү өчен эчик әле! Яшәү шундый гүзәл, рәхәт бит! Бигрәк тә аны аңлы рәвештә уенга салып, сина отыш чыккач...—дип тост тәкъдим итте, күнеле күтәрелеп киткән Крис. Карлен шунда гына егетләрнең Лондонда нинди тәвәккәллеккә барганнарын чынлап торып аңлады. Кайсыдыр бер мизгелдә Татлян дусларына көнләшеп карап та куйды—алар әле тулысынча аңлап бетермәсәләр дә, бу тормышта үзләрен башкалардан өстен итеп куярлык ниндидер бик мөһим эш башкарган бит.

—Менә әйбәт булды, киреләнеп маташмадың,—дип мактады аны Армен, Татлянның тәлинкәсе янында өелеп торган акча төргәкләренә ымлап.—Ә мин, дөресен әйткәндә, талымчанлык күрсәтерсең дип курыккан идем. Ә син безнең егет, безнең! Моның өчен эчеп куярга да ярый. Егетләр, без бит әле бернәрсә дә ашамаганбыз. Петрович юкка тырышкан булып чыгамы? Йә әле,ябырылдык...

Хавтан официантлары әзерләгән табын янында бик озак утырмадылар, булса—ике сәгатьләп булгандыр. Шуннан артык түгел. Бу мәҗлес Лондоннан күнелсезләнеп-борчылып кайтып кергән егетләрне эретеп җибәрде, аларга яңадан тормыш сөючәнлек, дәрт кайтты һәм егетләр «Сохо» төнге клубына барып кәеф-сафа кылуны дәвам иттерергә булдылар. Кароны ни кыстасалар да, ул, газет өчен материал эшләп бетерәсем бар, дигән сылтау белән, барырга ризалашмады. Иртән очрашып, бергә ашап алырга килешеп, дуслар аерылыштылар.

Долларлар тутырылган пакет тотып, үз бүлмәсенә күтәрелгәч, Карлен тирән күн кәнәфигә чумып, озак, бик озак уйланып утырды. Мәкаләсен бүген язып бетерергә җыенмаган да иде ул, бары тик ялгызы калып, кинәт килеп туган бу хәлне уйлап-аңлап бетерергә теләгән иде.

Бер көннән Карлен үзәккә атналык шифровка җибәрергә тиеш иде, ләкин ул инде Лондондагы «Лейнсборо» отелендә ике кеше үтерелгәнен һәм үтерүчеләрнең фамилияләрен хәбәр итмәячәген белә иде. Килеп туган хәлнең гадәттән тыш хәл икәнлеген ул аңлый: агентның болай алышынуы яшерен оешмалардагы иң оста педагог-стратегларның да башларына килмәс иде. Әгәр дә Карлен Татлянны сатып алган булсалар, хатын-кыз белән башын чуалтсалар, үлем куркынычы белән янаган булсалар—аңлашылыр иде. Әмма... Ырудашларының кан авазы? АКШта моны кем дә булса җитди кабул итеп ала алыр идеме икән? Ә юкка... Тикмәгә генә әйтмиләр бит: кем шәраб эчә һәм кем су эчә—алар икесе ике төрле уйда була.

Үзе каршысындагы тәбәнәк журнал өстәле өстенә таратып ташланган доллар төргәкләренә карап утырса да, ул аларны күрми иде, башында нәкъ урысларга хас бер уй бөтерелә: алга таба нишләргә, ничек яшәргә кирәк? Һәм кинәт аны бер фикер өтеп алды, бу фикер бөтенесен дә үз урынына утыртырга, газаплаган сорауга ачыклык кертергә тиеш иде. Ул гардеробына ташланды, төссез генә твид пинжәге кесәсеннән валюталарны тикшерә торган детекторын алды. Аннары һәр төргәктән ничек туры килсә, шулай берәр акча тартып чыгарды да, аларны җентекләп тикшерергә тотынды. Әмма долларлар чын иде...

## И Париж!

### I

...Константин Николаевич Натальяны Мәскәүгә кунакка чакырырга вәгъдә биргәнен һич тә онытмаган иде, әмма соныннан, Кутузов проспектында квартиралар сатып алып, мавыгып-канатланып киткәч, кызның килүен өй туена туры китереп эшләргә булды—сөеклесен Мәскәүгә килеп төшкән беренче адымнарыннан

ук таң калдырырга уйлады ул, җәннәт кебек шундый квартиранын үзенә әзерләнеп куелганын белгәч, нинди генә хатын-кызның исе-һушы китмәс икән! Ләкин ремонтның акрын баруына караганда, өй туен күтеп тору очрашу шатлыгын шактый озакка сузарга мөмкин иде, ә Константин Николаевич Натальяны шундый сагынды, шундый сагынды, еш кына Ростовта бергә үткәргән бәхетле көннәрен төшләрендә күрә, анын кулларының җылысын, иреннәренең тәмен исенә төшереп моная иде.

Эйнштейн—Георгий Фешинның бөтен борчулы уй-ниятләрен белеп торганлыктан, бу юлы да файдалы егет булып чыкты һәм мавыктыргыч киңәш бирде. Ничектер, көннәрдән бер көнне, Фешинның һаман саен монаеп, күнелсезләнә баруын күргәч, болай диде:

—Константин Николаевич, сез квартирагыз турында вакытлыча онытып торыгыз, Кутузов проспектында ремонт эшләре бетеп, һәр ике бүлмә бизәлгәч-җиһазлангач, ул бит Натальягызга көтелмәгән сюрприз, шатлык өстенә шатлык кына булачак. Ә хәзергә сез аны Мәскәүгә чакырыгыз, үзегезнең яңыгызга—«Метрополь»гә урнаштырыгыз. Әгәр дә инде ул чит илгә чыгу паспортын да алып килсә, без бер атна, күп дигәндә ун көн эчендә сезгә күнелле берәр сәяхәт оештырырбыз, әйтик... Парижга.

—Парижга?—дип гаҗәпкә калды Тоглар, мондый фикер анын башына килеп тә карамаган иде.—Ни өчен Парижга?

—Чөнки Париж—ул гомерлек бәйрәм, Хемингуэй карт шулай дигән. Аннары шунысы да бар, декабрь аенын икенче яртысында бөтен балет дөньясы егерменче гасырның иң күренекле хореографы Джон Кранконың вафатына егерме ел тулган көнне билгеләп үтәчәк. Тантана Парижның «Гранд-опера» театрында уздырылачак, анда балет сәнгатенең барлык йолдызлары, дөньядагы барлык атаклы театрларыннан прима-балериналар җыелачак. Гаҗәп зур бәйрәм, балетоманнарның хыялы булачак ул, ә ул бәйрәмне безнең якташыбыз Рудольф Нуриев оештыра, чыгымнарын да ул үз өстенә ала.

—Ә син бу кадәр җентекләп һәммәсен дә кайдан белеп бетерден соң әле?—дип, тагын бер кат гаҗәпләнде Тоглар, ул үзенең яшь дустын кызыксынып күзәтә иде.

Эйнштейн көлемсерәп куйды, анын тавышына көенү-ачыну бәреп чыкты:

—Мин бит, Константин Николаевич, үземне шулай ук башка тормышка әзерләгән идем—катранда кәрт уйнау сәләтем сонрак һәм очраклы гына ачылды. Балачагымнан мин балет мәктәбендә укыдым, аннары ГИТИС (театр сәнгате дәүләт институты) студенты чагымнан ук балетлар сәхнәләштерергә хыялланып йөрдем, үзем дә начар биеми идем. Бәла дүртенче курста укыганда килеп чыкты—уң аягымның тез капкачы сеңере өзелде—мениск, бер операция ясадылар, әмма уңышсыз булды. Биюләр турында гомерлеккә онытырга туры килде, кайгыдан эчүгә сабыштым, типтерергә тотындым, институттан кудылар, шуннан тормышым түбән тәгәрәде дә китте инде... Соныннан шушы кәрт уенына бирелдем, нык мавыга башладым, ә балет дигәнең күнелемдә мәңгегә утырып калды... Ул бит минем яшьлегем...

—Йә-йә, ул кадәр борынынны салындырма әле,—дип күз кысып куйды Тоглар.—Бая телгә алган балет кумирын турында рәтләбрәк сөйлә әле. Син бит аңа табынган булгансын, дөрес әйттемме?

—Кире кага алмыйм—ул искиткеч хореограф иде. Мин сезнең Парижга, нәкъ менә шул тантанага—балет бәйрәменә баруыгызны телим. Ышаныгыз, сез һич кенә дә үкенмәссез... Шулкадәр бөек биючеләр йолдызлыгын күрү—бу бит күп зыялыларның хыялы.

—Дәвам ит, дәвам ит,—дип аны тагын да дәртләндереп җибәрде Тоглар.—Мәдәни тормыштан шактый артта калган кеше бит мин, сонлабрак булса да, берәз күзем ачыла төшсен. Наталья да, мөгаен, шатланыр: ...—Тоглар, кулларын баш артына куеп, хыялланып көрсенеп алды.

Аның хыяллары янә яшь дусты бүлдерде:

—... Джон Кранко немец балет театрын бөтенләй яңабаштан үзгәрткән шәхес—ул Штутгардт балетын тудырган. Аның театрында көч-дәртләре, талантлары ташып торган күренекле пар—Марсия Хайде белән Ричард Крегин биегән. Кранконың Штутгардт оясыннан бөтен дөньяга танылган театр оештыручылар һәм искиткеч сәнгать әһелләре чыккан. Джон Нонмаер, Иржи Килиан, Уве Шольц, Уильям Форсайт. Нинди исемнәр бит, нинди бөек затлар! Кранко үзе, тиңе булмаган уңыш һәм җиңүләргә ирешкәч кенә, бөтен балет дөньясы аны таныганнан соң, кинәт кенә үлеп киткән, менә шуның өчен ул бөек хореографны хәзер дә яраталар һәм искә алалар.

—Дустым, син китаптан ятлаган кебек сиптерәсең генә Кумирың, чынлап та, кумир булган икән. Үпкәләмә, ул кеше шулай югары бәяләрлек булгандыр шул...

—Әйе, шундый иде,—диде Георгий.—Әгәр дә нотык-лекция шикеллерәк итеп сөйләгән булсам, гафу итегез инде...

Тоглар аптырабрак, сүзсез калган иде. Ул барыннан да бигрәк Аргентинлының өйрәнчеге булган бу егетнең инде барлык якларын да төбенәчә ачып-белеп бетердем, дип йөри иде. Ә менә, кара әле син аңа! Әмма, телгә килгәч, ул башка сүзләр әйтте:

—Мине шулай бераз агартуың өчен рәхмәт сиңа. Чынлап та кумирың кызыклы шәхес булган икән, җирдә үзенең якты эзен калдырып киткән. Мине дә кабындырдың бит әле син. Ә, беләсеңме, синең тәкъдимеңне тагын да үстереп җибәрергә була бит: Парижда тагын берәр атнага калып, Яна елны да шунда каршы алырга, ә! Әмма ул билетлар артыннан йөрү, чакыру кәгазьләре юллау-юнәтү мәшәкате...—Тоглар гаҗиз булып кулларын җәеп җибәрде.—Гала-концертларына эләгеп булмаса, үкенечкә калачак инде, без, урысларның, холкы-табигате шундый бит: булса—бөтенесе дә булсын, булмаса—берсе дә кирәкми.

—Әй, ул якларын хәл итүне үз өстемә алам мин,—дип аны тынычландырды Георгий.—«Содис» дигән бер фирма бар, алар бары тик бай кешеләрнең аерым сәяхәтен оештыру белән генә шөгыльләнә, анда дусларым да бар. Париж алар өчен иң унай шәһәр, элемтәләре ныклы, ә яңа буржуйлар Францияне яраталар. «Содис» аша фестивальгә билетлар алырга була, әмма мин, ышанычлырак булсын өчен, Зур театрдан «Гранд-операга» факс җибәртермен. Сезгә, әйтик, Россиянең балет җәмәгатьчелеге вәкилләре буларак, Кранко юбилеена бәйле барлык спектакльләргә һәм төрле чараларга да алдан урын тәгаенләп куярлар. Әлбәттә, үзегез акча түләп булыр инде анысы. Хәзер Мәскәүнең Зур театрында эшләр шәптән түгел: үзара ызгыш-талаш, ремонт, труппа ике төркемгә аерылган, Парижга барып йөрергә акчалары юк, кемнәрдер Парижга барып, аннан әлеге фестивальгә багышланган видеокүренешләр, программалар, буклетлар, альбомнар да алып кайтса, болар шатланачаклар гына. Монысын ышанып әйтәм. «Содис» сезгә «Гранд-опера» янәшәсендәге менә дигән кунакханәдән номерлар алып куяр, теләсәгез, тәрҗемәчесен-гидын да табар. Хәзер мөмкин булмаган нәрсә юк бит—акчаң гына булсын. Сез шунысын гына әйтегез, мин туристик фирманы, иң югары бәядән түләячәксез, дип ышандыра аламмы?

—Әлбәттә,—Тоглар әкренләп алдагы сәяхәт мәшәкатьләренә тартыла башлаган иде бугай.—Тик тәрҗемәче-гидлар безгә кирәкмәстер. Наталья французча белә, ул ике ай буе Парижда, Кристиан Лакруа сәүдә йортында стажировка үтеп кайткан.

—И, сез әле барыргамы-юкмы, дип икеләнеп торасыз тагын!—балетмейстер була алмый калган егет хәтта кызып китте.

—Минем уемда да юк иде. Тәкъдимен өчен рәхмәт һәм булачак мәшәкатьләре өчен авансын да ал,—диде Тоглар.

Тогларның Парижга барып балет фестивале карарга һәм Яңа елны да шунда үткәрергә дигән тәкъдиме Натальяны да бик нык шатландырды, дөрес, бу унайдан аны эшендә үзен алыштырып торырлык лаек бер кыз табарга туры киләчәк. Кристиан Лакруаның Ростовтагы сәүдә йорты

менеджерлары үз хезмәткәрләрен нык кына йөгәнләп тота икән.

Фешинның чит илгә чыгарга жыенуы беренче мәртәбә иде, шуна күрә ул, төпле акыллы кеше буларак, һәрнәрсәне алдан уйлап, хәл итеп куярга теләде—чит-ят илдә үз хокукларыңны яулап-яклап йөрү акылсызлык булыр иде. Анда үз тирәндә, кирәк чакта сиңа ярдәм итәрдәй, киңәш бирердәй тамырдаш-корешлар да булмаячак. Ул, әлбәттә, акчаның бөек көчен белә, ләкин бит аны кайчан кемгә бирергә кирәген дә абайламый булмас, анда «яңа русларның» әдәпсез-сөмсез, оятсыз кыланышларына шаккатып карыйлар, ди бит.

Чечнядә өч ел әсирлектә булу Тогларны тормыш чынбарлыгыннан шактый ерагайткан, аннан соңгы ярты елында аны хәзерге яңа чынбарлыктан акчалары ышанычлы саклап торса да, бу болгавыр вәзгыять аның аңлау дәрәҗәсен һич тә үстермәгән иде. Сәяхәт-сәфәр кылуны һәркем иң әүвәл үзенең финанс мөмкинлекләреннән чыгып, «кесәсен капшап» чамалый, Тоглар да шулай уйлый, ә акчасы аның кем әйтмешли, әле «бер букча». Әмма көнбатышка акчаларыңны алай тиктомалдан «букчаңа» тутырып кына алып чыгып булмый икән шул, аларны алып чыгу өчен тиешле документлар—рөхсәт кәгазьләре кирәк икән. Менә шунда янә күпбелер Георгийның ярдәме тиде: ул Константин Николаевичка үзенең «Метрополь»дәге күршесе Дантеска кереп чыгарга киңәш бирде. Дантес Мәскәүдәге берничә банкны үз кул астында биетеп тота икән, аңардан Константин Николаевич белән Наталья исеменә валюталарны, янәсе, шул банклардан алганлыклары турында бирәр дистә рөхсәт кәгазе сорарга була бит. Әмма Георгий кисәтеп куйды: шундый һәр счет кәгазендәге сумма ун мең доллардан артмаска тиеш, юкса алар үзеннән-үзе салым полициясе күзенә чалыначаклар. Эйнштейн әле тагын икенче бер юлны да өйрәткән иде: Шереметьево-2 аэропортында таможняда эшләүче берәр үз кешене таба алсаң, ул сиңа валюталарыңны «дипломаты» белән самолетка ук кертеп бирәчәк икән. Мондый ысул «яңа руслар» тарафыннан аэропортларда гына түгел, транспортның теләсә кайсы төрендә—суда, автомобильдә, бигрәк тә фин чигендә яхшы файдаланыла икән. Ләкин Константин Николаевич бу ысулны шундук кире какты: аның законнар бозып йөрисе килми иде, аннары тамырдаш-кореш-братвалар белән дә сирәгрәк очрашканың яхшы. Ләкин эш тагын да җайлырак килеп чыкты...

Тоглар үзенең борчу-мәшәкатьләре турында Дантеска сөйләп, ярдәм итүен сорагач, тегесе йомшак кына көлеп җибәрде:

—Нигә кирәк сиңа андый кәгазьләр? Ә, бәлки, синең кинәт кенә дөнья буйлап сәяхәт кылып кайтасың килер, бер илдән икенчесенә очып йөрерсең—син бит таможняны шул декларация кәгазьләрең белән күмеп ташлаячаксың. Әйдә, иң яхшысы—без сиңа дипломатик паспортлар әмәлләп бирик, яшел тышлыларын. Алар биш ел буена яраклы, рәхәтләнеп йөр дә йөр! Кулыңда шундый паспорт булса, сине тентеп-нитеп тормыйлар да, таможняга алдан хәбәр биреп, берәрсе чакса гына инде. Бик унайлы паспорт ул, бигрәк тә безнең халык өчен, кирәге чыкса, теләсә кайчан илдән сыза аласың, аңладыңмы?—Дантес, үз артындагы сейфын ачып, дипломатик паспортын чыгарып күрсәтте.

—Әйе, житди ксива (паспорт), моның белән курыкмый йөрергә була. Булыша алсаң, юнәтеп бир инде...—дип, Тоглар кулындагы яшел катыргыны әйләндергәләп карады. Әгәр монда эш барып чыкмаса, үзе белән Натальяга моннан да шәбрәк-ышанычлырак итеп үзе шундый паспортлар ясаячагын да уйлап алды.

—Сиңа шуны да эшләмәскә соң, кадерле Тоглар, син миңа заманында өч ксива әмәлләп биргән идең бит, димәк, мин сиңа бурычлы.—Дантес шуннан соң секретарь кызны чакыртып кертте дә, үзен МИДтагы (Чит ил эшләре министрлыгы) кемдер белән тоташтыруын сорады.

Теге түрә кисәге белән сүз кыска булды, күрәсең, ул адәм күптән кармактадыр инде, яки Лозовскойдан туенып торадыр. Трубканы куйгач, Дантес елмайды да, Смоленск мәйданындагы телефон номерын бер кәгазь кисәгенә сызгалап, Фешинга сузды:

—Блат блат белән, ә ике ксива өчен бер биш бакс кертеп чык, ул анда бу мәсьәләне үзе генә хәл итеп утырмый.

Долларларны алып чыгу мәшәкате менә шулай көтмәгәндә генә җайланды да куйды, бер унайдан, бик абруй-дәрәҗәле, VIP—персоналлар булып сәяхәт итәргә дә мөмкинлек туды. Мондый уныш турында Тоглар хыялына да китереп карамаган иде...

## 2

Париж аларны кышкы салкыны белән каршы алды. Орли аэропортында чын-чынлап Россиядәге шикелле җәяүле буран себерә иде. Тоглар күнеленнән генә тагын бер мәртәбә Георгийга рәхмәт укып алды: ул бит эчлегенә баргузин чәшкесе мехы куеп тегелгән «Дормей-престиж» пәлтәсен анын кинәше белән сатып алган иде, ә Натальяга, юлга чыгарга бер атна кала гына, Мәскәүнең бер мода салоныннан алтынсу төстәге каракүлдән тегелгән гаҗәеп зиннәтле манто алдылар. Салон хуҗабикәсе Пруссакова-Барковская ханым аларга халыкара мех аукционнарында мондый каракүлнең сур дип йөртелгәнен һәм гаять кыйммәт торганын, бер тунга бер үк төсмерне сайлар өчен йөзләрчә мехны актарырга туры килгәнен дә сөйләп алырга онытмады. Шуңа күрә элек мондый мантоны Галина Брежнева гына киеп йөргән, хәзер исә Россиянең беренче ледие Наина Ельцина гына шундыйны кия икән.

«Содис» фирмасы өметләренаклады, аларны аэропортта ук каршы алдылар, Рю де Ришелье урамындагы отель дә «Гранд-опера» театрыннан ерак түгел иде. Эйнштейн җибәргән факсның да файдасы тиде—фестивальне оештыру комитетында кунакларны бик җылы каршы алып, алларына спектакль һәм концертларга дип калдырылган билетларны да чыгарып салдылар. Фешин үз кулы белән шактый сумманы түләгәч, администратор бик гаҗәпләнде. Бәлки, аны «чәйлек» акчаның зурлыгы аптырашта калдыргандыр? Ничек кенә булмасын, елгыр-елдам француз бездәге театр администраторларыннан бер ягы белән дә аерылып тормый иде, ул шунда ук кызыксынып сорап та куйды:

—Рус әфәнделәр, өстәмә бәя түләп, әлбәттә, фестиваль ачылу унаеннан уткәрелә торган зур бал—кабул итү мәҗлесенә дә барырга теләмиләрме? Анысы Франциянең Жорж Помпиду исемендәге хәзерге заман сәнгате Мәдәни үзәгендә уткәреләчәк. Ә фестивальнең ябылу кичәсе Елисей кырларындагы сарайларның берсендә булачак. —Французның тагын бер кат гаҗәпләнүенә каршы, рус кунаклар, бәясен дә сорап тормыйча риза булды һәм янә бик мул гына «чәйлек» тә өстәлде. Бөтенләй эреп киткән администратор аларга үзенең визиткасын сузды һәм көнен дә, төнен дә хезмәт итәргә вәгъдә бирде. Дөрестән дә, кайтып киткәнче ул, кунакханәгә әледән-әле шылтыратып, нинди дә булса ярдәм кирәкмиме дип, белешеп торды, анын кинәшләре-тәкъдимнәре бик файдалы булды. Тоглар мсье Жакнын,—администраторнын исеме шулай иде,—үзенә һәрвакыт ярдәм итәргә торучы, күпбелер дусты Эйнштейнны алыштырырдай кеше икәнен күнеленә салып куйды. Киткәндә алар адреслар да алыштылар. Константин Николаевичны Натальянын француз телен бик яхшы белүе дә куандырды, аннары кыз үзен дә, гомерен дөньянын бөек хореографлары юбилейларына йөреп уткәргән кеше шикелле, иркен-табигый тотты—французлар нәкъ менә Натальяны балетка бәйле шәхес дип кабул итте. Беренче кичтә үк, Елисей кырларын тамаша кылып йөргәндә, Тоглар, «Шопард» фирмасынын затлы ювелир кибетеннән сатып алып, Натальясына бик сирәк була торган алсу бриллиантлар һәм яшькелт зәбәрҗәтләр белән бизәлеп эшләнгән, күз явынны алырлык алсу алтын Швейцария сәгате һәм бизәлеше шуна охшаш муенса бүләк итте, анысы да бөтендөньяга танылган шул ук «Шопард» ювелир фирмасыныкы иде. Акчаны бирәдә дә кесәсеннән генә чыгарып түләгәндә, Тоглар үзеннән паспорт-мазар сорарлар дип көткән иде, сорап тормадылар тагын, мондый бай клиентны югалтудан курыкканнардыр инде.

күрәсең. Ә бит Константин Николаевич паспортын юри номерда калдырып килгән иде. Долларларны тиз генә ниндидер катлаулы бер детектор аша үткәреп карадылар каравын, әмма Фешинның иҗат җимешләре француз имтиханын да уңышлы узды...

Икенче көнне Наталья ничек кенә Кристиан Лакруа сәүдә йортына барырга талпынмасын, Константин Николаевич аны Монмартрга алып китте, аның соңгы йөз илле ел эчендә даны чыккан, әллә ничәмә-ничә даһи рәссам шунда йөргән урамны тизрәк күрәсе килә иде. Монмартрга омтылуының тагын бер сәбәбе шул: ул үзенең күренекле бабасының да биредә булганын төгәл белә, кайдадыр асфальт катламы астында аның да басып йөргән эзләре мәңгелеккә уелып калганын тоя иде. Тоглар, туймастай булып, андагы борынгы биналарны, тузан баскан витриналарны карап узды һәм, әлбәттә, урам башындагы Сакре-Кер чиркәвенә кереп чыкмый булдыра алмады. Биредә, тротуарны тутырып тезеп куелган мольбертлар арасында арлы-бирле йөргәндә ул, кайчандыр Казанда ишеткән шикелле, бабасының кан авазын ишеткәндәй булды, үзен гади Костя Фешин итеп кенә түгел, ә күренекле рәссамның оныгы итеп тойды һәм бу хис-тойгы бик күп нәрсәләргә бурычлы итә иде.

Бәлки, Константин Николаевичның үзенә кадәр күп еллар элек бабасының да шушында йөргәнлегеннәндер, Тоглар көтмәгәндә генә вакытлар бәйләнешен тойды, әйтерсең лә, академик Фешинның аңа таба революция һәм социаль тетрәнүләр аркасында өзелеп калган туганлык җебе еллар аша яңадан сузылды, Париж аңа тагын да якынрак, аңлаешлырак булып китте...

Джон Кренко истәлегенә багышланган фестиваль ачылу уңае белән Помпиду исемендәге хәзерге сәнгать Үзәгендә үткәрелгән бал-мәҗлес Натальяны иң әүвәл затлы дамаларның зиннәтле һәм купшы-матур кичке күлмәкләре белән сокландырды, ул хәтта Елисей кырларындагы сарайларның берсендә үтәчәк соңгы бал-банкетка Кристиан Лакруа сәүдә йортында махсус күлмәк тектереп, шуны киеп килү уе белән яна башлады, үзен күнеленнән генә шул кичәдә шундый күлмәктән итеп күрде. Тоглар аның теләгенә каршы килеп тормады, мәгъшукасын куандыру аңа рәхәт кенә иде.

Алтынсу каракүл мантолы, алсу бриллиант һәм зөбәрҗәтләр белән бизәлгән сәгать һәм муенсалы Натальяның бик бай заттан икәнлеге әллә кайдан күренеп торса да, Кристиан Лакруа сәүдә йортында заказлар кабул итүче ханым бераз югалып-буталып калды булса кирәк. Наталья фирма менеджерларыннан Робер Платт исемен әйткәнче, нишләргә белмичәрәк аптырады. Бары тик шуннан соң гына ханым, җиңел сулап:

—Сезгә мсье Платтны чакырып чыгарырга кирәкме?—дип сорады.

Шунсыз үз теләген аңлата алмаячагын төшенгән Наталья: «Әйе, әйе»,—дип баш какты.

Берничә минуттан холлда, мөгаен, Наталья яшьләрендәрәк булса-булыр, житез генә бер яшь кеше күренде. Ростовтан килгән кунак кызын абайлап, ул елмайды, озын кулларын киң җәеп аңа ташланды:

—Натали! Бонжур! Нинди җилләр белән?—дип, бөтен халык алдында аны каты итеп кысып кочаклап, битеннән дә үбеп алды.

Берничә авыз сүз алышканнан соң, француз Натальяны үзе белән алып кереп китмәкче булган иде, ләкин кыз, тәрәзә буендагы кәнәфидә утырып торган Тогларга күрсәтеп, егетне аның янына алып килеп таныштырды:

—Робер Платт, минем француз шефым. Безнең Ростовтагы һәм Россиядәге үзләренең сәүдә йортларына җитәкчелек итә. Ә бу, таныш булыгыз, Константин Николаевич Фешин, рәссам. Без балетмейстер Джон Кранко истәлегенә багышланган фестивальгә килдек,—диде.

—О-о!..—дип сокланып кычкырып җибәрде Робер, Тоглар аның үзенә көнләшебрәк карап алганын да тойды.

Ул вакытта Константин Николаевич аңлап бетерә алмады әле: бөтендөнья өчен абруй-дәрәҗәле тантанага килгән кешегә көнләшеп кенә

карау идеме бу, әллә исә ничектер Наталья белән бәйле булдымы икән? Французның Константин Николаевичның «викуния» тукымасыннан тегелгән, әле жилбәгәй жибәргән «Дормей-престиж» пәлтәсенә дә, «Обвиос» инглиз фирмасында иң кыйммәтле «черрути» тукымасыннан тегелгән костюмына да сынаучан күз ташлап карап алуын да тойды Тоглар. Әлбәттә, Кристиан Лакруа йорты белгече өчен бу нәрсәләр сизелми калмады. Натальяның шулкадәр бай киенүен дә ул, һичшиксез, иң дәрәжәле дөнья стандартларынча киенгән, чәчләре чалара башлаган шушы көяз әфәнде белән бәйләп караган булырга тиеш.

Шунда холлда ук Наталья Роберга фестиваль ябылу уңаеннан булачак йомгак бал-банкет өчен яна кичке күлмәк тектерергә теләгәнен, әгәр дә егет Кристиан Лакруа йортының яңа модельләреннән сайлашып бирсә, бәлки, бер-ике пар язгы-көзге һәм, әлбәттә, аксыл-ачык плащ та алырга җыенганын аңлатты.

—Һи, моның бер кыенлыгы да юк, бигрәк тә үзебезнең Россия вәкилләре өчен,—дип елмайды менеджер һәм кайнарланып сүзен дәвам итте:—шефыбыз мсье Лакруа балетны бик ярата, белүемчә, ул да әлеге балга чакырулы, ана үз иҗат җимешен Россиядән килгән гүзәл кыз өстендә күрү бик күңелле булачак. Әйдәгез, хәзер туп-туры үзенә барып керәбез, мин сезне таныштырырмын.—Мсье Платт куллары белән әйдәп аларны икенче катка менәргә чакырды.

Иркен холлның аргы башында, өскә менеп китә торган киң баскыч янында Тоглар уңайлы-тыныч кына кафе-бар күреп алды һәм Натальяга, үз коллегалары белән аралашырга комачауламас өчен, аны шушында—түбәндә генә көтеп торачагын әйтте.

Платт исә куе яшел келәм җәелгән әлеге мәрмәр баскычтан Натальяны башта күргәзмәләр залына алып менеп китте, анда кием-салымнарның иң соңгы модель-үрнәкләре куелган икән. Ә шуннан соң инде кызны иң атаклы кутюрье белән таныштырды. Ә Тоглар исә, чишенеп, кафе-бар янындагы утыргычларның берсенә барып утырды, анда шундый тәмле кофе хуш ис аңкытып тора, ерак калган утызынчы-кырыгынчы елларның моң-көйләре әкрен генә агыла иде.

Константин Николаевич Натальяны өч сәгать диярлек көтеп утырды. Беренче сәгатеннән соң ул моданың, чынлап та, корбаннарсыз булмаганлыгын аңлады һәм әрәмгә киткән вакыты белән килешергә булды. Ә урамда, юеш-салкын булса да, Париж гөрли иде. Наталья барга балкып, бик канәгать кыяфәттә килеп керде, кулында Лакруаның яңа эшләре проспекты да бар, уңайсызланып кына Константин Николаевичка шактый зур сумма язылган счет кәгазе сузды, әмма Тоглар, карап та тормыйча, квитанцияне кесәсенә тыгып куйды, кызны рухландырып күз кысып алды—янәсе, кайгырма, түләрбез, диюе булды—аннары Натальяга шампан шәрабе бирүләрен сорады. Тогларга мәгъшукасын куандыру, аны шундый бәхетле итеп күрү рәхәтлек бирә иде. Аннары алар барның тәрәзәсе янындагы өстәлчек янына барып утырдылар, Наталья хуш исле капуччино кофесы эчеп ләззәтләнгән арада Тоглар сөеклесенең заказлары өчен акча түләргә китеп барды. Касса янында көтелмәгән аптырашлы хәл килеп чыкты, түлисе сумма йөз меңнән дә артып киткән, француз франклары белән генә дә түгел, ә саллы долларлар белән икән, бу кадәр сумманы акчалата алырбыз дип берәү дә көтмәгән. Бу юлы да югалып калган кассиршаны шул арада килеп җиткән Платт коткарды: ул акчаны алырга кушты, күрәсең, Россиядә эшләгән менеджер «яңа русларның» дөнья буйлап шулай чемодан-чемодан акча күтәреп йөрүләренә күнеккән иде инде. Долларларны бирегә дә ниндидер гадәти булмаган вакуумлы детектор аша үткәреп тикшерделәр, Тоглар валютасы тикшерүчеләрне янә җинде!

Натальяның заказлары өчен түләгән чекларын тотып әйләнеп килгән Тоглар хыялланып әйтеп куйды:

—Бүген кич бик шәп берәр ресторанга барып, андагы тәмле ашсуларны ашап кайтсак, яхшы булыр иде, анда зур джаз оркестр уйнап

торсын иде, ну, элекке матур заманнардагы кебек, сәхнәгә өчәр кат тезелгәне булмаса да ярый, әмма кырышылып беткән квинтетлар, электр секстетлары да түгел инде, һичьюгында өч-дүрт труба, саксафоннар, бер төркем тромбоннар.—Үзе ни өчен шулай кирәклеген аңлатып та бирде:—Ул операдагы шикелле—көчле хоры булмаса, иң күренекле җырчының да тавышы тиешенчә янгырамый, һәрвакыт фон булу кирәк. Джаз да нәкъ шулай—ул иң элек оркестрдагы жиз уен коралларының көчле-куәтле булуына бәйле.

Ростовта төшенә дә кермәслек күлмәк-костюмнар тектерергә заказ биреп, аларның бер-ике көннән әзер булачагына чиксез куанган бәхетле Натальяның да Константин Николаевичны нәрсә беләндер шатландырасы килде. Шуңа күрә ул Тогларны култыклап алды да шаяртыбрак:

—Менә хәзер отельгә кайтырбыз да, мсье Жакка шылтыратып, Парижда шундый ретро-ресторан бармы-юкмы икәнлеген сорарбыз. Мин дә синең белән, әйтик, Гершвин музыкасына рәхәтләнеп танго биер идем,—диде.

Отельгә кайттылар.

Мсье Жак, Парижның төнге тормышын яхшы белгән берничә эстетка шылтыратып, шундый бер ресторан барлыгын белеште. Аның эчке бизәлеше-интерьеры да, җиһазлары да, хәтта официантларының киемнәренә хәтле шундый иске ретро рухында икән. Ул ресторан бик бай, үзләрен әллә кемгә санап, борын күтәреп йөрүчеләр аны бик ярата, шунда элекке салмак тормышны сагынып, джаз тыңлап утыралар икән. Ресторанның исеме—«Леди Астор».

### 3

Соныннан, Парижга сәяхәт кылып кайтканнарын исләренә төшергәндә, Тоглар белән Наталья икесе дә, Франциядә үткән иң истәлекле вакыйгаларының берсе итеп, нәкъ менә шул «Леди Астор» ресторанының шәмнәре яктысында үткәргән онытылмаслык кичне әйтәчәкләр. Ә бит юкса алар Парижда бер генә матур кич үткәрмәделәр, фестивальнең һәр көне үзе ни тора иде—кайбер көннәрдә бер үк спектакльдә ике-өч берәр пәрдәле балетлар, дисеңме, ә ул исемнәр—йолдыз өстендә йолдызлар иде инде! Ә инде фестиваль ачылуга, аннары ябылуга багышланган бал-кичәләр турында сөйләп тә торасы юк! Бигрәк тә соңгы бал-банкетта Натальяның Кристиан Лакруада тектереп алган искиткеч күлмәге белән балкып йөрүе, банкет вакытында бөек кутюрьеның берничә мәртәбә алар янына килеп китүе—болар онытылырлыкмы соң?! Кристиан Лакруа үзе әле матбугат фотохәбәрчеләре алдында Наталья белән рәсемгә дә төште, кызны французларга таныш булмаган Ростовтагы үз сәүдә йортында эшләүче Россия хезмәткәре дип тәкъдим дә итте. Хәер, Наталья үзе дә борын чөеп йөргән французларга яраткан Ростовны бик гади генә итеп аңлатып та бирде. Ул Ростовны үз якташы Михаил Шолоховның атаклы «Тын Дон» романында матур итеп сурәтләнгән рус казакларының башкаласы дип атады. Кайчандыр Парижга җиңүчеләр булып, биеп торган атлары өстендә килеп кергән кызыл папахалы, чалгый мыеклы казакларның токымы әле дә булса шунда яшиләр, диде. Аның дулкынланып сөйләгән бу кыска нотыгын кул чабып каршы алдылар һәм калган кич буена Наталья гел кунакларның күз уңында гына булды.

Ә «Леди Астор» ресторанында исә төнне, һәр рус ресторанындагыча, өстәлдән-өстәлгә йөреп, бер-берсен сыйлашып, оркестрантларга кыйммәтле шәраб һәм коньяклар җибәреп, юмарт «чәйлек» акчалар сибеп, үзләре яраткан көй-музыкаларны кабат-кабат уйнатып, бер-берсе белән визиткалар алышып, мөгаен, кемнәрдер әле бер-берсенә мәңгелек мәхәббәт һәм тугрылыклы булырга вәгъдә итеп тәмамладылар. Кыскасы, Париждагы «Леди Астор» исемле инглиз ресторанында булсалар да, нәкъ урысча итеп, кирәген биреп типтерделәр инде. Әле бу шау-шулы «гүләй-мүләй» башланганчы ук Тоглар кинәт тәкъдим ясады:

—Ә бәлки, безгә Яңа елны да шушында үткәрергәдер, ә?—диде.

—Мин бик бәхетле булыр идем, сөеклем, миңа биредә бик тә ошый,—дип, шатлыгыннан балкып китте Наталья.

Константин Николаевич эшне озакка суза торган кеше түгел. Яңа елга бер атнадан аз гына күбрәк вакыт калып бара иде,—ул «Леди Астор»ның баш администраторын эзләп китте. Әмма Яңа ел балына өстәлләр Раштуа бәйрәменә кадәр үк, күптән алынып беткән булып чыкты. Католиклар Парижы ул бәйрәмне православный Мәскәүлеләрдән бераз алданрак үткәрә икән. Тогларны үзенең мондый җирләргә күп йөреп шомарган булуы коткарды: Россия башкаласындагы шикелле итеп, ул кесәсеннән саллы гына доллларлар төргәген тартып чыгарды да өстәл өчен ике бәя түләргә әзер икәнлеген әйтте. Администраторның карашы шундук җылынды, рус телен ватып-җимереп:

—Руслармы? Мәскәү?—дип сорады. Уңай җавап алгач, ул ачыклый төшеп, кызыксынды.—Ничә кешелек өстәл кирәк булыр?

—Ике кешелек,—дип, ике бармагын күрсәтте Тоглар.

—Алайса, эш башка. Сезгә залда ике кешелек кенә урын табарбыз дип уйлыйм,—диде дә администратор, урыныннан кузгалып, Тогларның кулын дусларча кысты.

Тоглар моңа кадәр Натальяга ни үзе турында, ни ата-бабалары турында әле бернәрсә дә сөйләмәгән иде—ничектер, җае чыкмады, кыз үзе дә сораштырып тормады, аны ничек булса, шулай кабул итте. Әлбәттә, Тогларның ана үзенең күренекле бабасы Николай Иванович Фешин турында сөйлисе, кызны Казанга алып барып, аңа музейдагы Фешин залын, бабасының ишектән керүгә үк эленеп куелган автопортретын күрсәтәсе килә. Наталья бер карауда аларның бер-берләренә охшашлыкларын танып алыр иде юкса. Әмма һаман да әле вакыты ул түгел, әле ул мизгелләр килеп җитмәгән төсле тоела иде.

Әлбәттә, Натальяны Кутузов проспектындагы яңа квартирасына алып кайткач, ул ана студия-остаханәсен дә күрсәтәчәк, үзенең күренекле бабасы турында, һичшиксез, сөйләячәк, атаклы рәссамнан калган һәм үз кулына очраклы гына килеп эләккән бердәнбер картинасын да күрсәтәчәк. Шул чагында, бәлки, Наталья Тогларның рәссам булырга тыелгысыз теләге барлыгын, үз мөмкинлекләрен иҗатта сынап карыйсы килүен аңлар иде.

Монмартрда йөргәннән соң ук ул Натальяны Луврга алып барган иде. Әмма бервакыт аның янадан шунда барасы—үз рухына якын булган импрессионистлар залын ялгызы гына тынычлап карыйсы килеп китте. Наталья, гадәтенчә, ул көнне дә Кристиан Лакруага тектерергә биргән костюмнарын киеп-үлчәп карарга чыгып киткән иде. Бу юлы Луврда Тогларны көтелмәгән уңыш каршы алды. Хәзерге заман рәссамнары залында ул Рудольф Нуриевның бәйрәмчә киемнәрдән язылган югары зәвыклы портретын күрде. Иң әһәмиятлесе шул иде: портретны Россия рәссамы Эдуард Шаһиев язган булып чыкты. Парижга китәр алдыннан гына Тоглар аның «Эстет төше» дип аталган зур картинасын үз студия-остаханәсенә элеп куяр өчен сатып та алган иде.

Париждагы көннәр шәмдәлдәге шәм кебек эреп бетеп килә, мәгъшукасы белән беренче сәяхәт тәмамлана, Наталья да әзер киемнәрен күтәреп, бәхетле балкып, ешрак кайта башлады, бу мизгелләр Константин Николаевичка да зур куаныч була иде. Наталья еш кына Ростовка—өйләренә, дус кызларына шылтырата, һәммәсе дә аның тизрәк кайтуын көтә икән. Әнисенең хастаханәгә кереп ятканын белгәч, кыз үзе дә кайтырга кабалана башлады, әнисе өчен кирәкле кыйммәтле даруларны җыйды. Наталья, Мәскәүдә туктап тормастан, Шереметьево-2 аэропортыннан Домодедово аэропортына күчә дә, шуннан туп-туры Ростовка оча булып чыкты.

Фестиваль ябылу уңаеннан Елисей кырларында бал-банкет үткәреләсе көнне Тоглар белән Наталья, шәһәрдә йөреп, кунакханәгә иртәрәк кайттылар. Балга киеп барасы кичке бәйрәм күлмәге ике көн инде номерда ята, башка әйберләре дә кайтып китәргә әзерләп, тутырып куелган иде. Әлеге күлмәкне инде әллә ничә мәртәбә киеп, Константин Николаевич алдында бөтерелеп

йөреп күрсәткән Наталья көтмәгәндә генә чәчен янача ясатып кайтырга җыенды, кичәгә бару өчен шулай кирәк икән, янәсе Тоглар да ана иярергә булды, алар бит Парижда ике атналап торды да, чәчне төзәттереп алу комачауламас, аннары француз чәчтарашларының эшен күзәтү дә кызык булыр.

Алар икәүләп беренче катка төшеп киттеләр, хатын-кызлар һәм ирләр салоннары да шунда иде. Натальягә унайлырак булды, хатын-кызлар залында буш кәнәфи бар иде, ә ирләр залында Константин Николаевичка бераз көтеп торырга туры килде, ике оста да житез-өлгер Фигаро токымыннан—итальяннар иде булса кирәк, әмма икесе дә буш түгел иде. Кечкенә унайлы холлдагы мәрмәр өстәл өстендә газет-журналлар, төрле проспектлар ята иде. Француз отельләрендә әлегә рус газет-журналларын тотмыйлар икән, вакыт тизрәк үтә торсын дип, Тоглар кулына бик бай, төсле фоторәсемле атналык журнал алды—телне белмәсән дә, фоторәсемнәргә карап күп нәрсәне анларга була иде. Ләкин журналны ахырынача актарып утырырга туры килмәде, икенче-өченчеме битендәге бер рәсем Тогларнын игътибарын озакка җәлеп итте. Бик шәп ак кәгазьгә Лондондагы кыйммәтле «Лейнсборо» отелендәге бай-зиннәтле люкс номеры рәсеме урнаштырылган иде. Фоторәсемнен төсләр-төсмерләре белән артык мавыгып китепме, Тоглар башта рәсемдәге ин мөһим нәрсәгә—анын эчтәлегенә игътибар итмәгән булган икән. Чия-кызыл фарсы келәме җәелгән бүлмә идәнендә, икесе ике яктарак тәгәрәшеп, икесе дә бер үк төсле ак костюмлы ике яшь егет үлеп ята иде. Тогларга егетләрнен йөзләре таныш төсле тоелды, тагын да игътибарлырак карагач, ул анлап алды—әйе шул, нәкъ шулай икән: ул аларны бик яхшы белә, Грозный егетләре агалы-энеле Цуцаевлар икән болар. Рәсемдә сул якта, тәрәзәгә якынрак ятканы Алихан исемле, анысы өлкәнрәге, ә икенчесе—тынычрак һәм уйчанрагы Аслан иде. Икесе дә атаклы чечен ыруыннан, генерал Дудаевка якын кешеләр, анын ышанычлылары һәм хәтта яраткан егетләре иде. Бу Цуцаевлар Чечнянын яшерен акча сугу остаханәсен шәхсән үзләре күзәтеп тордылар. Тоглар ирексездән кулындагы «Юлисс нардан» сәгатенә карап алды, бу сәгатьне ана бүләккә Цюрихтан Алихан алып кайтып биргән иде. Тогларнын чечен әсирлегеннән качып китәренә өч көн кала егетләр атаклы Күктүбәне карап кайтырга, шунда, җай чыкса, бер унайдан ялган долларларга андагы казиноны һәм тагын бер-ике белгән санаторийны сатып алырга дигән максат белән Кырымга китеп барган иделәр.

Рәсемгә карап утыра торгач, Тоглар кинәт кенә ачынып, Цуцаевларны кызганып куйды—яшьләр, чибәрләр, белемле, тормыш сөючән егетләр иде бит—кем аларнын башына житте икән сон? Һәм Лондонда бит әле! Ярый, Мәскәүдә үтергән булсалар, анлар да иден. Тоглар шул ук вакытта, бу көтелмәгән һәм мөһим хәбәрдән сон, үзенен шатланырга тиешлеген, бәлки, биеп җибәрергә, берәр шешә әйбәт шампан шәрабе эчәргә кирәклеген дә анлый иде—анын белән бит бары шушы Цуцаевлар гына аралаша, калган барлык чеченнәр өчен ул ышанычлы яшерелгән иде, бу исәпкә сакчылар керми. Бары тик Цуцаевлар гына анын эш процессын тулысынча белә, алар гына Англиядән ин катлаулы аппаратураларны алып кайта һәм алар гына Тогларны чын-чынлап аулый-тота ала иде. Димәк, исәпләп карасан, Ичкериядә басылып чыккан ялган долларларнын серен дә бу егетләр үзләре белән теге дөньяга алып китте, дигән сүз. Тоглар үзе бу хакта авыз тутырып кычкырып йөрмәс бит инде.

Мөгаен, отельне янгыратып, «Азат! Мин ирекле!»—дип кычкырырга да кирәк булгандыр. Ростовка барып житеп, «Редиссон-Ростов» кунакханәсе номерына кергәч, ул кайчандыр шулай куанып кычкырып җибәргән иде бит. Әмма Тоглар бернинди дә шатлык кичермәде, киресенчә, күнелендә нindидер пошыну-борчылу үсеп килгәнен генә тойды.

*Дәвамы киләсе санда.*

# ШИГЫРЬДӘ—НАЗ ИЯЛӘРЕ



*Күзәтеп киләм: безнең хатын-кызларның беришесе әдәбиятка—шигырьгә бик яшьтән килә, тиз танылa (бу бигрәк тә соңгы елларда, күз алдыбызда булганнан чыгып әйтәм), шулай иртә килеп, күренеп, аннары озак эзләнүләр чорын үткәрә, «бишектәге бишкә тәрләнә» дигәндәй, үсә-үсә үзен таба, хәтта күренекле шагыйрәгә әверелә (Клара Булатова, Лена Шагыйрьҗаннар һичшиксез, шулай дип ышанам). Һәм шундый шагыйрәләребез бар—болары күпчелек булса кирәк,—тормышта башта үз урынын табып, дөньяны кузаллау, яшәү тәҗрибәсен—шигъри фәлсәфәгә, фикер һәм сурәт дөньясына әверелдерү куәсенә ия булгач кына, тумыштан бирелгән табигый сәләтләре (ә ул бик күпләргә бирелгән! Бигрәк тә безнең татарда...) уянып, ачылып китеп, дөрләп яна, яза башлыйлар... Сажидә апабыз шундый иде, Резеда Вәлиева, Флера Гыйззәтуллина, Бикә Рәхимоваларның да шагыйрьлек язмышы шулай булды... Эльмира Шәрифуллинаның да гомеренең авыр сынауларыннан, тетрәнүләрдән соң, күңел яраларын ил гаме, халык кайгыларына кушу сәләте ачылып китте: хатын-кыз буларак та дөньяны үзенчә күрү, тасвирлау аша шигърилеккә килде бу шагыйрәбез. Мәгълүм юбилее уңаеннан быел дөнья күргән поэмалары, шигырь бәйләмнәре дә сөенечле уйларга этәрә.*

*... Без бүген шигырьләрен тәкъдим итеп, хатын-кызлар гына билгеле торган, чуак җәй бәйрәме кебек матур юбилей елында бер-ике сүз әйтергә җыенган авторыбыз Флера ханым Тарханова да шулар кауменнән. Әйе, «язмышларны энә күзеннән үткәрергә шигърияткә килгән хатыннар» нәселеннән ул. Шигъри исеме, аты-затына бер борынгылык, хәтта мәгълүм бер болгарлык та биргән Тарханова фамилиясе белән инде шактый вакыт күренеп килә ул матбугатта. Берничә китабы да дөнья күрде. Флераның язганнарына карата берничә сүз белән генә шулай дип әйтергә җөрьәт итәр идем: бүгенге татар хатын-кызының иң типик язмышы, бәхете, югалтулары, табышлары, шатлык-сагышлары, эзләнүләре, ялгышлары, үзенчә саф алтыны—акылы, исәрлеге, мәхәббәте, яшәү тәҗрибәсе һәм инде (шуны) «оныкларына васыятьләре»—барсы да табигый ярашкан бу шигырьләрдә. Шунсы истәлекле булды: беренче лирик бәйләмнәре басылгач та, аксакал әдип Гомәр ага Бәширов шагыйрәнең үзенчәлеген танып, нечкә-назик, хәтта ки нәфис җан иясенең эзләнүләрен, бу дөньяда өзгәләнүләрен тирән аңлап язып чыккан иде... Аннары башка каләмдәшләре дә язды—»Синең җылы сулышың» китабына, шактый популяр булган күпсанлы җырларына карата сөенеч уртаклашып, киңәшләр белән... Иң соңгы дөнья күргән «Йөрәгемә яшерелгән серләр» китабына карата Зөлфәт тә бик матур шигъри эссесын язып бастырды..*

*Шулай: «Шигъриятта күпме илаһият—шагыйрь дусты булса шагыйрә...» дип үзем дә уйлана идем бит яшьтә... Безнең әдәбиятта да, рус, дөнья шигъриятендә дә аерым бер Наз иясе-шагыйрәләр белән дуслык—үзе бер тема, матур бер фал бугай. Флерабызның да шигырь язмышында шагыйрьләр белән мөнәсәбәт, аралашу, хәтта бәхәсләр, полемика*

*да булды шикелле—язганнарыннан моны сизү кыен түгел. Әйе, мохит тә күпне сөйли, зур стимул бирә ала. Иҗтимагый тормышны да якын алган, Исхакыйны тудырган Яуширмә туфрагыннан калыккан милли җан да булсаң.*

*Ә бәлки, Гомер—үзе үк бер сер, мәңге язып бетмәс Шигырьдер ул? Сер булса, әлбәттә, Сөю биргән тылсым инде: кайсы шагыйрәбез ансыз гына ачыла алсын?*

*Ә безгә, ир-ат шагыйрьләргә шуны икърар итү тиештер: билләһи, рәхәт бит янәшәдә нәфис затлар булганда. Көчлерәк, дәртлерәк язасы килә. Шагыйрәләргә дә кайчак «өф-өф итеб»рәк карарга кирәк, бәлки?.. Юк, һич тә ташлама ясап түгел. Моны үзләре дә теләмәс иде алар. Көчле һәм горур заттан бит бу «тарханбикә»ләр. Чын татарча заттан—Газизә апа Сәмитова, Мозаффария ханым, Гыйффәт туташлар кебек.... Һәм һәрберсе—аерым дөнья, аерым холык!*

Рәдиф ГАТАШ.

# Флера Тарханова

## ИСЕМЕБЕЗДӘ—СЕР, КӨЧ БАР...

### Ни кызганыч!

**Сине күтәп ала алмый интектем мин,**
**Төннәремдә мендәр тешләп яшь түктем мин,**
**Язмышымны бер чорнадым, бер сүттем мин,**
**Эзләгәнем табалмадым—ни кызганыч!**

**Тавышыңны ишеттем дип, колак салдым,**
**Һичбер аваз килмәгәнгә, гаҗиз калдым,**
**Керфекләрем янә кайнар яшькә мандым,**
**Юлың ятмый бу якларга—ни кызганыч!**

**Бөелеп торган хисләремнән кайчак тулам,**
**Сине йөрткән уйларымнан качмак булам,**
**Күңелемне башкаларга ачмак булам,**
**Тик буйсынмый йөрәккәем—ни кызганыч!**

**Юлларыма киртә булып нигә яттың?**
**Дөрли-дөрли шашкан утлар нигә яктың?**
**Бәгыремә нинди уклар киереп аттың?**
**Ычкыналмыйм кармагыңнан—ни кызганыч!**

### Үзең тагын килдең төшләргә

**И Ходаем, оныталмыйсың ахры—**
**Күпме гомер үтте бит инде,**
**Барган җирләреңдә урын табып,**
**Тыныч кына миннән кит инде!**

**Фани дөньялардан бакыена**
**Киткән чакта, инде бик күптән,**
**Әйткән идең: «Яңа йортка күчәм,**
**Килә алмам инде мин бүтән».**

Сүзләреңдә генә торалмыйсың—
Тотасың да килеп керәсең
Төшләремә, мине яратуың
Һаман кайнар, сүнми күрәсең.

Кичә тагын йөрдең сабыр гына,
Төсең үзгәрмәгән әллә ни—
Яшь чактагы килеш, ә менә мин—
Инде хәйран вакыт дәү әни.

Ниләр бимазалый җаннарыңны,
Ни әйтергә миңа телисең?
Сер ачасы килгән кеше сыман
Бөтерелеп янда йөрисең.

Әйт тә инде шушы сүзләреңне,
Тынычлыкта калдыр син мине,
Әллә инде синең беркайчан да
Китәсең дә миннән килмиме?

И Ходаем, онытылмыйсың ахры—
Аерылмыйсың миннән һичләр дә,
Бәхилләшеп киттең бит, югыйсә,
Үзең тагын килдең төшләргә.

## Соңгы сәлам

Авыр хәбәр килеп җитте, тетрәндереп,
Ни дисәң дә, фани дөнья гаҗәеп тар:
«Исемеңне кат-кат әйтеп дөнья куйды,
Исемеңдә синең, әйтче, нинди сер бар?

Газраиле килеп баскач каршысына,
Якасыннан тотып алгач, елады зар,
Бары синең исемеңне тәкърарлады—
Әйтче, синең исемеңдә нинди көч бар?

«Чакыртыйкмы?»—диде сине белгән берәү,
«Юк-юк»,—диде, агарынды, куркып китте:
«Бу хәлемдә мине ул күрмәскә тиеш,—
Тик ул гына белгән йөзем сулды, кипте.

Ул бит мине яшьнәп торган матур чакта,
Үзен үлеп яратканда кире какты,
Ул вакыттан бирле күпме гомер үтте,
Күпме сулар бәргәләнеп, дулап акты.

Тормышым тормыш булмады аннан башка,
Гомер үтте кайчак башны орып ташка,
Дөньялыкта рәхәт күрү язмагандыр,
Бәлки менә ахирәттә булыр башка.

Һәр иртәдә күз алдымда булды йөзе,
Көндезләрен озата йөрде сөрмә күзе,
Ни сөйләсәм, телдә булды аның сүзе,
Тик беркайчан күренмәде бары үзе.

Соңгы сәламемне аңа җиткерегез,
Гомер буе оныта алмаган, диегез,
Булдыралса, каберемә килеп китсен,
Соң булса да, бер уч туфрак алып сипсен.

Һәм әйтегез: рәнҗеп китмим мин аңарга,
Хәтта шатмын күңелемдә ул да барга,
Сүрелмәгән сөюем белән бергә китәм,
Йә, хушыгыз, борчымамын сезне бүтән»,—
диде дә ул авыр сулап, күзен йомды,
Яшь бөртеге тәгәрәп төште, аңын җуйды,
Килгән һәркем бу эшләргә хәйран булды,
Барысы да тып-тын торды, күңеле тулды...»

Авыр хәбәр очып кына килеп җитте—
Киң булса да, фани дөнья гаҗәеп тар:
«Исемең белән бу дөньядан китеп барды,
Әйтче, зинһар, исемеңдә нинди көч бар?»

## Оныкларга әйтер сүзем

Кешеләргә ярдәмчел бул һәрвакыт -
Үрнәк алыр күпләр синең ишедән,
Шәфкатьле булмасаң әгәр син үзең,
Мәрхәмәтлек көтмә башка кешедән.

Аңгыралык кылә кайчак тумыштан,
Ә кайчакта чеп-чи надан булмыштан,
Зирәк булсаң, исәп йөртсәң—юл ачык,
Яшәү җирең булмас тишек алачык.

Мин баймын, дип, борын чөймә һичкайчан,
Тормышы авыр кешегә үч итеп,
Рәнҗеше көттермәс—сизми калырсың:
Кителеп төшәр тормышыңның бер чите.

Серләреңне чишмә, эшне белмичә,
Теләктәшлек күрсәтә дип бу бичә,
Кайткан сүзең салмасын дисәң чиргә,
Авызыңны чамалап ач бар җирдә.

Милләтеңнең бөеклеген онытма,
Үз җиреңне каплаттырма «болыттан»,
Кардәшеңә изгелекләр кыла бел,
Үзеңә кылган яхшылыкны күрә бел,
Бисмилланы әйтеп башла юл башың,
Һәрвакытта сөю булсын юлдашың:
Сөйсәң илне, сөйсәң ата-анаңны,
Истә тотсаң һәрчак газиз Ватанны—
Сәбәп булыр канатың талмавына,
Ирешерсең халкыңның данлавына!



## Рөстәм Акъегет

### ЯЗМЫШ АТЛАНТИДАСЫ

⁂

**Атлантида!—Беркет моны, хәтер!**
**Атлантида!—Уян, йоклаган!**

**Шул чак кемдер, тыныч кына әйтә:**
**«Атлантида, имеш, булмаган...»**

**Яшәешнең, имеш, язы була,**
**була, имеш, аның бер кышы...**

**Атлантида, бәлки, булмагандыр,**
**яши килә ләкин язмышы...**

### Ике хатирә

⁂

**Тышта болытларны**
**шәрә ботак тарый,**
**жылы өйдә әни эрли йон...**
**Таралып ята**
**песи янәшәдә...**
**Гади манзара.**

**Вакыт үткән саен**
**күңелләрдә күпме уй-тоем?!.**

⁂

**Кышкы иртә.**
**Саран кояш.**
**Песнәк күзләп,**
**мәче тора тәрәз төбендә.**
**Мич ягылган.**
**Әни оек бәйли.**
**Моңсуланып**
**ерагая йөзе**
**тоньк офык—**
**кыз чагында алган көзгедә.**

Рөстәм АКЪЕГЕТ *(1951)—шагыйрь, «Ак болыт шәүләсе», «Янды бер шәм таңнарда» һ. б. китаплар авторы. Казанда яши.*

## Хөкем

*Кодрәте киң:*
*йә тамчылап та бирми,*
*йә чиләкләп коя.*

Алла бар ул!
Иртән кешедән көлгәнне
хурга калдыра кичкә.
Малга хирес бәндәләрне
мәхрүмнәр итә хистән.

Ялгызлык белән түләтә
Һәр азган-тузганына...
Беркем калмый, җавап бирә
үзенең узганына.

Алла бар ул!
Тик нигә соң
кызгану юк аз гына?—
Гарип колын
хөкем иткән
Мәхәббәт җәзасына...

Җәйләр җитте... сүз катмадым.
Әйтер сүз: җиләк пеште...
Көз килде дип, ым какмадым,
өзелеп алма төште...

## Әгәр кунсам керфегеңә

Мин ләйсән яңгыр идем лә,—
булдым кар,
булдым боз,
булдым болыт...
Хәзер инде гаҗәпләнмә,
рәнҗемә дә,
әгәр кунсам
керфегеңә
ялгыш күз яше булып...

## Октябрь

Барысы онытылган—
вәгъдәләр,
антлар,
күз яшьләре...

Октябрь.
Шәрә болытларда
яна миләш тәлгәшләре...

## Көзге җил

—Мин—җил бары,
Мин үтешли генә.
озакка түгел,—диден,—исәбем...
Иркәләдең...

Кәүсә калды,
җирдә—
яфракларның юктыр исәбе...

## Урман кызы

Абагалар,
серле борылмалар,
якты аландагы рәшә...

Урман кызы,
үзең булмасаң да,
дөнья тулы
синең барлыгыңа ишарә!..

## Кызлар хаты

Яшь иде шул...
Тагын ни язарга,
дип утырганда,
хатка нокта куйды
күз яше...

## Йолдыз гыйшкы

Йолдыз атылды,
су өстендәге үз чагылышында
сөйгәненең күреп сурәтен...
Йолдыз белән сүнде чагылыш,
кавышу иде—шул
сүнү сәгате...

❧

Гөлләремне үбеп үтте,
ялап үтте буран итәге...
... Чәчәкләргә
коелырга,
коелырга иртә иде.
Көзге буран
үзе болай,
юаш, назлы, иркә иде...

## Урманда

Яңа гына киселгән төпкә
кунды агач яфрагы...
Хәл җыйды да,
очып китте тагы...

Шуны карап бактым әле
күздән югалганга чаклы:
күзге урман...
бер ялгызым...
дөнья моңсу, якты...

## Әбиләр чуагы

Ә күк шундый зәңгәр,
шундый зәңгәр—
тамчы булып тама зәңгәрлек!
Шундый иркен дөнья,
шундый җиңел!—
Пәрәвезләр оча,
мамык оча
һаваларга Җирне күтәреп!..

## Яшерен генә

Җилләр назлап уятканчы
яфрак-үлән талган йокыга...
Тып-тын.
Ай чыга.
Зөһрә кызның
күз яшьләре
яшерен генә
әйләнә бара чыкка...

## Җәй айлары

Печән чаптым,
яттым пакусларга...
Җир—бер бишек,
Ә мин—бер бәби.
Күктә кошлар.
Ояларьі—кояш,—
Әйләнәләр оя тирәли.

# Çəçmə əsərlər
# Чәчмә әсәрләр



**Равил Вәлиев**

## БИШ ПАТРОН

хикәя

Әжемнән шактый ерактагы Кенәл авылында Асылбикәнең Мәнүсә исемле укытучы апасы яши. Ире мәктәптә завхоз. Тормышлары таза, көйле. Колач җитмәслек нарат бүрәнәләрдән салынган алты почмаклы өй, өр-яңа каралты-кура, бөтен ишегалларын тутырып йөргән мал-туар. Биек койма белән әйләндереп алынган алма бакчасы?..

Ләкин бөтен җире көйле шушы гаиләнең бер китек ягы бар иде. Бергә күпме гомер итеп, аларның балалары булмады. Менә шуңа күрә, Асылбикәнең ире сугышка китеп берничә көн үтүгә, апасы Мәнүсә Әжем юлын таптый башлады:

—И газиз сеңлем минем!.. Бу каһәр төшкән сугышны бик озакка сузылачак диләр! Биш балаң белән ничекләр генә итеп кыш чыга алырсың?—дип сайрарга керешә ул, чәй эчеп, бераз кәефләр күтәрелгәч.

—Нишләтәсең... Язмыштыр инде, апам!—дип каршы төшә Асылбикә.—Бүтәннәр ни кичерсә, безгә дә шул язгандыр.

—Язуын язгандыр да... Бер кызыңны миңа ияртеп җибәрсәң, укасы коелмасые әле.

—Илдә чыпчык үлмәс ди, апаем!

—Үлүен-үлмәс тә...—ди, ике ияк булып асылынып төшкән тулы йөзле апасы, симез бармак очларын энә белән төртеп тишелгәндәй кечкенә, дымсу күзләренә тидереп.

—Әйттем ич инде... Нихәтле генә кыен булмасын, аеры-саеры яшәмәвебез хәерле.

—Шулаен шулай да,—дип килешергә мәҗбүр була апасы һәм үкси-үкси елый ук башлый.—И сеңлем җаным, аңламыйсың да инде хәлләремне... Синең берьялгыз башына тагын дүртәү калачак бит әле... Өрмәгән җиргә дә утыртмыйча, кунак кызы итеп кенә яшәтериек ич... Балламайда гына йөздерер иек...

Бер атна түзде Асылбикә апасының тәкъдименә күнмичә, ике атна түзде. Ләкин бу хакта өченче мәртәбә сүз кузгалыр алдыннан, аның тормышын шактый кыенлатып җибәргән бер күңелсез хәл булып алды.

Асылбикәнең ире байтак еллар мәктәп директоры булып эшләгән иде. Ул сугышка китәр алдыннан гына химия укытучысы Хәсби Бикташев белән икесе арасында зур гына низаг чыгып алды. Гражданнар сугышы елларында бер кулын югалтып кайткан Хәсби салырга ярата. Берчакны хәтта тәҗрибәләр ясау өчен әҗәл даруы урынына гына бирелә торган спиртка кул сузгалый башлаган. Монарчы түзеп килгән мәктәп директоры Бикташевны эшеннән алу мәсьәләсен кузгатты. Ләкин көтелмәгәндә сугыш башланып китү аркасында, бу мәсьәлә ярты юлда тукталып калган иде.

Күп ирләр фронтка китеп беткәнлектән, тылдагыларның бәясе бермә-бер артты. Көннәрдән-беркөнне Бикташев та мәктәп директоры булып алды.

Озак та үтмәде, ул башлангыч класслар укытучысы Асылбикәне бүлмәсенә чакыртып кертте:

—Хәлләр ничек, иптәш Кәбирова? Иреннән хатлар киләме?—дип хәл белешкәндәй итте ул пеләшләнеп өлгергән баш түбәсен сынар, ләкин бик көчле кулы белән сыпырып алгач. Аннары кесәсеннән шырпы кабы чыгарды да аны ике тезе арасына кыстырды. Күптән күнегелгән төгәл хәрәкәт белән шырпысын сызып, тәмәкесенә ут алгач, чулак сукса—нык сугар дигәндәй, бүленеп калган сүзен дәвам итте.—Эшләр менә болайрак тора иде бит әле, Асылбикә Хәкимовна!.. Колхозга яңа персидәтел килүен инде ишеткәнсендер дип уйлыйм. Аның да хатыны укытучы икән. Причум, махсус педагогик белемле!

—Мин дә Артышлы педучилищесын тәмамлаган идем,—дип сүз кыстырасы итте Асылбикә.

—Белә-әм... Әмма да ләкин училище училище инде ул!—дип кырт кисте Бикташев.—Ә институт, бетерелмәгән булса да, инс-ти-тут!

Иелгән башны кылыч кисми дисәләр дә, горурлыгына тиярлек сүзләр ишеткәч, Асылбикәнең дә сер биреп торасы килмәде:

—Институтны бетереп булмый—тәмамлап кына була!—дип төрттереп куясы итте ул, үзе дә сизмәстән.

Ярымхәрбиләрчә тектерелгән китель кесәсеннән кульяулыгын алып, Бикташев кинәт кып-кызыл булып кан йөгергән йөзен сөртеп куйды.

—Дөрес әйтәсез, иптәш Кәбирова! Күренеп тора—телне начар белмисез икән! Тик...

—Ә унбиш еллык стажымны кая куясыз?

—Тәҗрибә, әлбәттә, әйбәт нәрсә. Ләкин бит сезне берәү дә эшсез калдырырга җыенмый, Асылбикә Хәкимовна! Персидәтелебез күчеп килгән Печмәнтау авылы мәктәбенә башлангыч класслар укытучысы кирәк икән. Рәхим итегез—файдаланыгыз бай тәҗрибәгезне!

—Алты чакрымдагы авылга көн саен йөреп укытыргамы?—дип каршы төшеп карады Асылбикә.—Ә берсеннән-берсе кечкенә биш балам белән нишләрмен? Бу сезнең тарафтан күрсәтелгән кешелексезлек дип атала түгелме соң, иптәш Бикташев?

Ачудан йөзе тимгел-тимгел бүртенеп чыккан мәктәп директоры тагын өстәлдәге тәмәке кабына үрелде:

—Ә-ә, исегезгә төштеме? Теге чакта мине мәктәптән куарга җыенып, ирегез бик кешелекле кыланды дисез инде, алайса? Дөнья менә шулай ул—бер алдын, бер артын күрсәтә!..

Бөтенләй эшсез калмас өчен, горурлыгына зыян китереп булса да, газиз балалары хакына Бикташев тәкъдиме белән ризалашырга туры килде. Печмәнтауда башлангыч мәктәп кенә иде. Авылы кечкенә, укучылары азрак булганлыктан, хезмәт хакы да сизелерлек кимеде. Бу исә Мәнүсә апасының тәкъдиме белән килешү—алты яшьлек йөрәк парәсен бәгыреннән өзеп, туганнары тәрбиясенә биреп җибәрү өчен үзенә күрә бер этәргеч булды.

Ләйсирәне Кенәл авылына озатып бер ай чамасы узгач, уйламаганда-көтмәгәндә, фронттан солдат посылкасы килеп төште. Бик хәсиятләп кадакланган агач тартма эченнән бер кап сохари, берничә кисәк кер

сабыны, разведчиклар киеп йөри торган искерәк кенә плащ-палатка һәм... бинт белән төрелгән биш патронлы обойма килеп чыкты. Ут эчендә йөргән солдат кешедән тагын ни көтәсең ди инде. Онытмыйча җибәргәч, болары өчен дә бик рәхмәт.

Ләкин Асылбикә башта ук бернәрсәгә төшенеп җитә алмады. Ярый, сохари белән кер сабыны аңлашылсын да ди. Плащ палатканың да, мөгаен, кирәге чыкмый калмас. Ә менә бакыр пулялар тезелешкән биш патронлы обойманы ничек аңларга? Посылка савыты тулып торсын өчен генә салынгандыр дияр идең,—әнә бит хатының азагында, әлеге патроннарны күздә тотып, аның Сәмигулласы «Мин кайтканчы саклагыз!» дип өстәп куюны да кирәк тапкан.

Тугыз яшьлек Марс белән биш яшьлек Фаилгә исә иң ошаганы плащ-палатка белән нәкъ менә әлеге обойма булды. Малай кеше малай кеше ул: авызга капсаң эреп китә торган сохари турында да онытып, алар ишегалдында әтиләре кебек «разведчик» булып уйнарга чыгып киттеләр.

Асылбикә, авыр уйлары белән ялгыз калып, посылка савытында килгән өчпочмаклы хат юлларыннан тагын бер кат күз йөртеп чыкты. Сәер! Сәмигулла бит аның бер ай элек язган хатын алып укыдым дигән. Димәк, уртанчы кызларын Кенәлдәге апасы тәрбиягә алып китүе хакында белгән. Алай булгач, нигә соң ни яхшыдан, ни яманнан бу турыда берике сүз язуны кирәк тапмаган? Хуплыймы?.. Әллә үпкәләгәнме, Раббым?

Әнә шулай уйларга, ни кылырга белмичә көн дә узып китте. Күпме эзләп тә борчулы уйларының очын-кырыен таба алмагач, ташландык сулы чиләген күтәреп, кичке эңгер-меңгердә Асылбикә ишегалдына чыгып китте. Чыкса, ни күрсен! Бияләй хәтле генә гәүдәсенә әтисе җибәргән хәрби киемне бөркәнеп алган да, куе үлән арасыннан шуыша-шуыша, бер кулына утын агачыннан ясалган «автоматын» тоткан Фаил өсте ябулы бәрәңге базына таба якынлашып килә. Ул беравз шуыша да, туктап, автоматыннан тырылдатып ала: «Та-та-та-а!..» Аннары тагын шуыша башлый.

Асылбикә, чиләген түгәргә дә онытып, кечкенә Фаиле янына килеп җитте:

—Син нишлисең монда, улым?

—Абый белән лазведчик булып уйныйбыз,—диде Фаил, «автомат»ыннан һаман ут яудыруын дәвам итеп.

—И улым, улы-м!..—диде Асылбикә, елмаюын баса алмыйча.—Син әйткән разведчиклар дошман тылында шыпырт кына йөриләр бит алар. Үзләренең дошманнарына алар беркайчан да беренче булып ут ачмый.

—Белә-әм...—дигән булды Фаил, ниһаять, «ату»ыннан туктап һәм күп белүче укытучы әнисенә сокланып карап куйды.

—Абыең кайда, улым?—дип кызыксынуын дәвам итте Асылбикә.

—Акупта.

—Ә-ә... Димәк, бәрәңге базында! Ә син кая шуышасың?

—Акупта утырган дошманның ничә пүлесе калганын белү өчен!

Бу «тапкыр» сүзләрне ишеткәч, ирексездән, Асылбикә елмаеп куйды, дошманның күпме гаскәре барлыгын белү өчен түгел, ә аның ничә пүлесе калганын ачыклау өчен разведкага бару начар түгел, әлбәттә. Болай итеп бары мәктәп бусагасын атлап керергә өлгермәгән нарасый балалар гына эшли һәм сөйләшә ала!

Ләкин «пүле» сүзе колакка чалынгач, әтиләре җибәргән биш патронлы обойма исенә төшеп, Асылбикәнең йөрәге тагын «дерт!» итеп китте: тиктормас Марс бәрәңге базында алай-болай шырпы сызып уйнамый микән?!

—Улым!—диде ул, ачык ишекле баз авызына якын ук килеп.—Тиз генә чык әле!

Баз авызыннан тиктормас Марсның үрмәкүч пәрәвезе бөркәнгән башы калыкты:

—Ни булды, әни?—диде ул, әтисенеке кебек зәңгәр күзләрен челтчелт йомгалап.

—Каяле, теге чын уенчыгыңны бир әле әниенә!
—Обойманымы?
—Шуны инде, шуны...
Тиктормас Марсның йөзе кинәт баздагы кызыл балчык төсле кызарып чыкты:
—Менә... Берсе төшеп калган...—диде ул, каушавыннан тотлыга-тотлыга.
Асылбикәнең чигәсендә, ачыттырып, кан тамыры тибеп куйды:
—Кайда, кайчан?
—Үлән арасыннан шуышып уйнаганда.
—И улым, улы-м! Әтиең кайткач, ни әйтәбез инде?
—Ә без аны Фаил белән барыбер табачакбыз!
—Үлән арасыннанмы?
—Менә күрерсең, әни!
—Шулай дисәң генә инде...
Чүпрәк белән әйбәтләп төрде дә, өйгә алып кереп, куркыныч һәм сәер көчтәнәчне Асылбикә балалар күзе төшмәслек җиргә яшереп куйды.
Ләкин күңеле барыбер тынычланмады.
Асылбикә бу төнне озак кына йоклый алмыйча азапланды. Инде йоклап киттем дигәч тә, әллә нинди авыр төшләр күрә-күрә, саташып бетте...
... Имеш, аның Сәмигулласын фронт хәтле фронттан кунакка кайтарганнар икән. Төн икән инде. Ул бусага аша мыштым гына атлап керде дә җиделе лампага башта ут кабызды. Аннары исәнләшү юк, нитү юк—үзе сугышка киткәндә муенына сарыла-сарыла озатып калган уртанчы кызын үлепләр сагынуы хакында әйтә башлады. Алып бирде Асылбикә ак биләүгә төрелгән Ләйсирәне. Әти кеше бу кадерле төргәкне башта байтак озак күкрәгенә кысып торды. Аннары ал тасмалы биләүне ипләп кенә сүтә башлады.
Җанлы төргәк сүтелеп беткәч, каушавыннан Асылбикә хәтта һушын җуя язды, ак биләү эчендә бәләкәй Ләйсирә түгел, ә... дүрт патронлы теге обойма ята иде!
Сәмигулласының исә, бу тамашаны күреп, ник бер чәч бөртеге селкенеп карасын! Әйтерсең, ул фронт хәтле фронттан газиз гаиләсен сагынып түгел, ә менә шул сәер «көчтәнәч»ен күрер өчен кайткан!
Ул арада, канәгатьсезлек билгесен белдереп, Сәмигулланың кин маңгаендагы куе-калын кашлары бергә килеп кушылды:
—Ә уртадагы бер патрон кайда?
—Марс белән Фаил разведчик булып уйнаганнарые...
Сәмигулланың исә һаман үз туксаны-туксан:
—Мин сезгә биш патронлы обойма җибәргәниемие бит?
—Иртәгә иртән үк табарбыз без аны... Бер дә борчылма, Сәмигулла бәгырем!
—Юк, сез югалтмагансыз! Биләүдәге биш патронның берсен сез Кенәлдәге Мәнүсә апабызга биреп җибәргәнсез!
—Мәнүсә апага?.. Акылыңа кил, Сәмигулла, ниемә кирәге булсын инде хатын-кызга ул патрон дигәннәреңең?
—Их, Асылбикә, Асылбикә! Әле һаман аңлап житкермәгәнсең икән...
Сәмигулла ишекне каты итеп япты да, саубуллашып-нитеп тормый гына, чыгып китте...
Асылбикә ниндидер тавышка сискәнеп уянды. Йөрәк дөп-дөп тибә. Салкын тиргә баткан тәне никтер бертуктаусыз дерелди. Юк, баягынак Сәмигулла ишекне каты итеп япмаган—бу шулай күкеле сәгатьнең иртәнге дүртне сугуы булган икән! Көннәр көзгә авышканлыктан, бигүк яктырып өлгермәгән иде әле. Ләкин, авыр төш күреп тагын саташудан куркыпмы, Асылбикәнең инде урында ятасы килмәде. Тиздән көтүгә ялгыз кәҗәсен дә куасы булыр.
Үзе яткан агач сәкене шыгырдатмаска тырышып акрын гына уры-

ныннан торды да, түр якка чыгып, балаларның өсләрен карап керде. Олы кызы белән төпчегенең юрганнары ачылмаган иде. Ә менә иданга тәгәрәшкән нәни «разведчиклар»—Марс белән Фаил аркылы-торкылы килешеп беткәннәр. Юрганнары, гадәттәгечә, бер читкә тәгәрәгән. Асылбикә аларның өсләрен иплэп кенә япты да тагын почмак яктагы сәкегә килеп утырды. Элек бу сәкедә алар гел Ләйсирә белән йоклый торганнар иде. Бүген исә уртанчы кызының урыны буш.

Буш!

Асылбикә кинәт эсселе-суыклы булып китте. Туктале, тукта!.. Сәкедә бер урын буш... Балаларның дүртесе изрәп йоклый, бишенчесе Кенәлдә... Аның Сәмигулласы фронттан җибәргән обоймада да биш патрон иде түгелме соң? Ә ул төштә күргән ак биләүдәге обоймада, никтер, алар дүртәү генә калган иде...

Биш патрон—биш бала!

Димәк, Сәмигулланың фронттан сәер «күчтәнәч» җибәрүе юкка гына булмаган икән шул! Күрәсең, уртанчы кызларын апасы тәрбиясенә биреп җибәрү турындагы хатка каршы ул ни дип җавап язарга белмәгән. Ялгышкансыз дияр иде—сынар канат белән сугыш елларында биш балалы тормышны өстерәп кара син! Дөрес эшләгәнсез дияр иде—йөрәкнең монын белән һич кенә дә килешәсе килми!

Үзе өчен күп нәрсә ачыкланса да, Асылбикә һаман тынычланып бетә алмады әле. Кайсы гына яктан килеп, ни генә уйлама—Ләйсирәне апасы тәрбиясенә биреп җибәреп, ул ялгышкан, ахрысы!

* * *

Асылбикә килеп кергәндә, хуҗалар мәктәптән кайтмаган иде әле. Өй ишеген ачып җибәрүгә, нindидер ят ис тоеп, ул йөзен чытып куйды. Әллә керосин-мазар түккәннәрме дип, тиз генә өй эчен күзләргә керешт. Юк, ул-бу түгелгән нәрсә күренми иде.

Түрдә, бөтен дөньясын онытып, аның өзелеп сагынган Ләйсирәсе курчаклы уйнап утыра иде. Башына чалмага охшатып, озын сөлге уралган... Ул уенга шул хәтле бирелгән иде ки, хәтта әнисенең килеп керүенә дә игътибар итмәде бугай.

Менә Асылбикәнең аяк астында идән сайгагы шыгырдап куйды:

—Кызым!.. Бәгырькәем минем!

Таныш тавыш килүгә, кулындагы курчагын бер читкә куярга да онытып, бәләкәй Ләйсирә әнисенең җылы кочагына атылды:

—И әнием, әнием!.. Нигә шулай озак килми тордың?—диде ул, озын керфекле күзләрен сөртеп.—Мин сине шундый сагындым!

Асылбикәнең дә кинәт кенә күнеле тулып китте:

—Мин дә сине бик, би-ик сагындым, кызым!—диде ул, Ләйсирәне кочагына тагын да катырак кысып.

Күз яшьләреннән тизрәк арыну өчен, ул бераздан сүзне икенче якка борып җибәрүне кирәк тапты:

—Апаң мәктәптән кайтып җитмәдемени әле, кызым?

—Апа түгел... Ул мина әни дип әйтергә куша!—диде Ләйсирә, ниһаять, үксүеннән туктап.—Әни! Бер кешенең ике әнисе була микәнни?

—И кызым, кызы-ым... Бу каһәр суккыры сугышның берәүләрне бөтенләй ятим калдырып, икенчеләрне ике әниле итеп куйган чаклары да була икән шу-ул!—дип Асылбикә Ләйсирәнең ак сөлге уралган башыннан йомшак кына сыйпап куйды. Кинәт Ләйсирә йөзен чытты:

—Абау-у!

—Ни булды, кызым? Ул сөлгене башына ниемә дип бәйләден? Каяле, чишеп карыйк әле...

—Әем... Чишмәскә куштылар...

—Кемнәр?

—Әни белән әти.

—Кемнәр, кемнәр, кызым?

—Әй лә... Мәнүсә апам белән Зәки җизни инде.

—Нигә дип чишмәскә куштылар?—дип кызыксынуын дәвам итте Асылбикә.

—Курыктылар бугай.

—Нәрсәдән, кызым?

—Өйләренә ис таралудан.

«Өебезгә» түгел—«өйләренә»! Йөрәгенә килеп тигән бу сүзне ишеткәч, апалары җәннәтенә әле һаман ияләшеп җитә алмый икән дип, Асылбикә үз кызын чын күңеленнән тагын бер мәртәбә җәлләп куйды. Һәм, әлеге хисләреннән арыну өчен, баягы төпчеңүен дәвам итте:

—И-ис?—дип кабатлап сорарга мәҗбүр булды ул, ниһаять, эшнең нидә икәнлегенә төшенә башлап.—Нинди ис ул—әллә керосинныкымы, кызым?

Җавап урынына Ләйсирә нәни иңбашларын гына сикертеп куйды һәм тагын сулкылдый-сулкылдый елый башлады:

—Үз өебезгә... кайтасым килә... әнием, бәгырем!

—Сабыр, кызым, сабыр... Каяле, сүтеп карыйк әле башыңны.

Ләйсирә бу юлы карышып маташмады. Ул хәтта ниндидер кутырга ябышкан сөлге читен куптарып алганда да баягы кебек чырыйлап кычкырмады.

Бөтен баш түбәсен каплап алган әлеге кутырны күргәч, Асылбикәнең үз тәне пешеп киткәндәй булды:

—Бусы ниткән нәрсә инде тагын, кызым?

—Әем... Сөйләмимим!

—Нигә, матурым?

—Җизнәм берәүгә дә әйтмәскә кушты.

—И кызым, кызы-ым... Үз әниеңә дә сөйләмәгәч...

Үз әниең дигән сүз чыккач, монарчы беркемгә дә сөйләнмәгән серен бәләкәй Ләйсирә газиз әнкәсе белән бүлешми кала алмады...

* * *

Сабын-ширпы кебек нәрсәләр җитмәү, юньләп юына һәм киенә алмау аркасында, көннәрдән беркөнне Кенәл мәктәбе укучылары арасында да бет таралды. Аңа ияреп йөри торган тиф авыруы килеп чыкмасын өчен, башны керосин белән юарга кирәк икән дигән сүзләр йөри башлады.

Бәләкәй Ләйсирә мәктәпкә йөрми иде әле йөрүен. Ул анда киләсе көзгә барачак. Әллә мәктәптән кайткан иптәшләре белән уйнаганда иярә күрмәсен дипме, әллә саклангынны Ходай саклар диепме, Зәки җизнәсе бер кичне Ләйсирәнең башына да керосин сөртеп карыйсы итте. Каяндыр мамык кисәге алып килде дә, тузан кунып беткән шешәдәге керосинга манып «шикле» чәч бөртекләрен эшкәртергә кереште. Ләкин Зәки җизнәсенең күзләре, лампа филтәсе бик аз чыгарылганлыктан, бик үк күреп бетерми иде шул! Ул почмак якка чыгып, мич алдыннан озын чыра алып килде дә аны пыяла куык эченә тыкты, лампа филтәсен чыгарып тормыйча гына, чыраның көйри башлавын көтәргә кереште... Ниһаять, чырага ут эленде. Чәч төпләре яхшырак күренсен дип шуны якынрак китерүе булды, Ләйсирәнең башына ут капты.

—Ке-ро-син!!! Керосинга ут төшә күрмәсен!..—дип кычкырып җибәрде җизнәсе һәм куллары белән өстәл астын кармалый-кармалый, тузанлы шешәне эзли башлады.

Шешә табылып Ләйсирәнең чәченә чират җиткәнче, күпмедер вакыт узып та өлгерде. Ярый әле, янәшәдә юынтык сулы чиләк тора иде. Җизнәсе шул чиләкне Ләйсирәнең чытыр-чытыр яна башлаган

башына каплады. Һәм бераздан, авыртудан бигрәк гарьләнүдән сулык-сулык яшь коярга керешкән «кызы»ның чәчләрен сөлге белән урап куйды.

* * *

Мәнүсә кайтып кергәндә, Асылбикәнең күзләрендә яшь кибеп өлгермәгән иде әле.

Мәнүсә исәнләшеп, хәл белешеп, берни булмагандай мәктәпкә киеп йөри торган күлмәген салып, зәңгәр халатын киеп куйды. Үзе тезде дә тезде:

—Сенел жаным!.. Дөресен әйткәндә, Ләйсирәбез үзе бик уңган кыз булып чыкты. Әле менә әнисенә ияреп, мәктәпкә дә йөргәли башлады. Тик бүген генә, башына ис тигәнгә күрә, бармый калган иде...

Нинди ис тию ул? Асылбикә бу турыда кызыксынып тормады, чөнки апасының тәмле теленнән бер-бер артлы очып кына торган «Ләйсирәбез», «әнисенә ияреп» кебек сүзләр йөрәгенә ук булып кадалган иде.

* * *

Ниһаять, юлга кузгалыр чак та житте. Күреп-яратып бетерә алмаган, сөелеп туймаган газиз әнисен озатышырга дип, бәләкәй Ләйсирә дә урамга чыкты:

—Авыл очына хәтле генә барам!..—дип ялваргач, өстәвенә, үтә юка да киенгән булгач (жәйге сандалилары, бер кат күлмәге белән әллә ни ерак китә алмаячак), хужалар анын теләгенә каршы килмәделәр.

Ләкин, кәжә бәтие кебек, терт тә терт әнисе янәшәсеннән теркелдәгән Ләйсирәгә һич тә, һич тә салкын түгел иде. Әйтерсен, анын иннәренә сихри канатлар үсеп чыкты. Юк, алмалы һәм баллы, сыерлы һәм майлы Кенәлгә караганда, бәрәңгеле һәм кәжәле үз авылы кадерлерәк иде ана. Анын бик тә Саяра апасы (идән юарга булышмыйсын дип, орышса-орышыр иде әле шунда!), Марс абыйсы һәм Фаил энесе янына (сүзләрен тынламаганда, беләктән чеметсәләр-чеметерләр иде әле шунда!) кайтасы килә иде. Инде Сәрия сеңлесе дә сөйләшергә өйрәнеп житкәндер. Инде песикәй белән кәжә бәтиләренең ничек сагындыруын әйтеп тә торасы юк.

Тик бу хакта әнисенә ничек белдерергә? Әнә инде авыл очына да житеп киләләр. Анын бит, әнисеннән аерылып, бер дә кире борылып китәсе килми.

Ләйсирә язмышы турында уйланып барганга күрәме, тиешле турыга килеп житүләрен Асылбикә дә сонлабрак абайлады:

—Әбәү, кызым... Артыграк та китеп өлгергәнбез түгелме?—диде дә, күчтәнәчле сумкасын тузанлы юл читенә куеп, Ләйсирәне ике куллап күкрәгенә кысты.—Йә, хушлашыйк, кызым! Юкса, кире кайтырына ерак булачак.

Ләйсирә сабыйлык ашкынуы белән әнисенең муеныннан кочаклап алды:

—Тагын бераз гына барыйм инде, әнием!

—Югалтмаслармы сон үзенне?

—Әнә теге эскерткә хәтле генә, әнием!—диде Ләйсирә, барасы офык читенә таба нәни кулын сузып.

—Ай-һа-а-й... Шактый атлыйсы икән бит әле! Армассынмы сон, кызым? Кире кайтасынны онытма!

—Ю-юк... Мина синең белән бергә атлавы бик жиңел, рәхәт, әнием!

—Шулай дисәң генә инде, кызым!..

Менә сөрелгән кара жир уртасында ерактан ук күзгә ташланып, ялтырап утырган салам эскерте турысына да килеп життеләр. Асылбикә

хушлашырга кирәклек турында әйтергә теләп, авызын ача башлаган иде дә, кызының бәгырь түреннән чыккан йөрәк тавышын ишетеп, тагын ризалашмый булдыра алмады:

—Әнә теге офык читендәге ялгыз агач турысына хәтле генә барыйм инде, әнием!

—Ярый соң, алайса...

Ничек ризалашмыйсың ди! Дөресен генә әйткәндә, кызының пешүдән кутырланып беткән башын күргәч, Асылбикә үзе дә аны Әҗемгә кире алып кайтып китәргә бик теләгән иде. Ләкин тагын ялгыз калачак апасын җәлләпме, ничектер, бу хакта сүз кузгатырга җай гына тапмады.

Тиздән хушлашачаклары хакында уйлап атлый-атлый, әнә шулай офык артыннан офык үтелде. Инде юлның яртысына җителде, инде алда маяк булырдай салам эскертләре һәм ялгыз агачлар да калмады бугай...

Ниһаять, ныклы бер карарга килеп, Асылбикә барган җиреннән туктап калды:

—Ярый, кызым, икенче очрашканга тикле сау булып тор!

—Хуш, әнием...

Кечкенә Ләйсирәнең тавышы бу юлы дерелдәвек иреннәре арасыннан теләр-теләмәс кенә, калтыранып кына чыкты.

Асылбикә ялгызы гына бераз араны үтте дә, күңеле тулып, кинәт артына борылып карады. Гаҗәп, Ләйсирә әле һаман борылып китмәгән, күзләрен мөлдерәтеп, әле һаман әнисенә карап тора иде!

Шулчак әллә нәрсә булды, капма-каршы кырлы ике магнит кисәге сыман, тарту көченә буйсынып, ике йөрәк бер-берсенә ташланды:

—И кызым, кызы-ым!..—диде Асылбикә, әнисеннән күреп үксиүкси елый башлаган Ләйсирәне кайнар кочагына кысып.—Мин бит сине бөтенләйгә алып китәргә килгәнием, күз нуры-ым! Әйдә, кайтып китик туган өебезгә, булмаса...

* * *

Әниләренең кайтуын өй тәрәзәсеннән гел күзәтеп-көтеп торган, ахрысы, кечкенә Фаил арыган юлчыларны капка төбенә үк чыгып каршы алды:

—Таптык, әни, таптык!—дип шәрран ярды ул, тегеләр килеп җитәрҗитмәстән.

—Нәрсәне, улым?

—Әти җибәргән бишенче пулене!

—Менә әйбәт булган, улым!—диде Асылбикә, арыган куллары белән Фаилне күтәреп алып.—Димәк, хәзер бишебез дә бергә җыелдык! Менә башта апаң белән исәнләш, бер дә сагынмадыңмыни соң?

—Сагындым, әни, бик сагындым... Исәнме, Ләйсирә апам!

—Саумы, энем!

Ләйсирә энисе күкрәгеннән җиргә төшеп өлгергән Фаилне көчсез куллары белән кочаклап алды. Бу мизгелдә аның керфекләре чыланган иде. Чөнки ул, күпме айлар чит авылда яшәп, газиз энесен генә түгел, каршыдагы яшел чирәмле ишегалдын, әнә шунда терт-терт сикерешеп уйнап йөргән кәҗә бәтиләренә тикле бик сагынган иде!

**Редакциядән:** *Гаҗәп хәл! Соңгы берничә елда әдәбият-сәнгать, мәдәният дөньясында юбилейлар күбәеп китте. Һәм аларның иң күбе утызынчы еллар ахырында һәм кырыгынчы елларның башында туганнарның бәйрәме булды. Әйтерсең лә халкыбызны мәрхәмәтеннән ташламаган Табигать анабыз гарасатлы еллар киләсен, озакламый җир шарын миллионнарны һәлакәт упкынына салачак сугыш ялкыны чолгап аласын алдан белгән һәм рухи дөньябыз саекмасын өчен шул елларда туган*

*сабыйларга талант орлыгын мулдан сибеп калдырган. Язучы, үткен каләмле публицист һәм дөнья агышын нечкә тоемлаучы журналист каләмдәшебез Равил Вәлиев тә дөнья ачысын нәни чагыннан ук татый башлаган, тырышып-тырмашып үз юлын тапкан әнә шул тырыш буыннан. Быелның 20 августында аңа да 60 яшь тула.*

*Равил татар әдәбиятына мәшһүр затларны биргән бәрәкәтле Арча районында, 1942 елда Яңа Кенәр авылында туган. Туган якларында урта белем алгач ул Арча педагогия училищесында укый, авыл мәктәбендә укытучы була, армия сафларында хезмәт итә һәм Казан дәүләт университетының татар теле-әдәбияты бүлеген тәмамлый. Университетны тәмамлаганнан соң газета редакциясендә, телевидение студиясендә эшли, ә республикабызда гигант КамАЗ заводлары корыла башлагач, яшьлек романтикасы аны төзелеш мәйданнарына алып китә. Баштарак ул гади ташчы була, язылачак әсәрләренең геройлары белән иңгә-иң торып, яңа Чаллының беренче йортларын салыша, күргән-кичергәннәрен исә көндәлек дәфтәренә теркәп бара. Гомумән, Равил Вәлиевнең хезмәт биографиясе күпкырлылыгы, төрлелеккә бай булуы белән аерылып тора. Ташчылыктан соң ул тагын газета редакциясендә, ремонт-инструментлар заводы төзелешенең матбугат үзәге җитәкчесе була, аннан бетончы һәм монтажчы сыйфатында завод корпусларын коруда катнаша, һәм аннан соң тагын газета-журнал редакцияләрендә.*

*Равил Вәлиев әдәби иҗат белән мәктәптә укыган елларыннан ук шөгыльләнә. Аның беренче китабы—"Шәһәр булсын бүләгем" исемле документаль повесте исә 1973 елда Татарстан китап нәшриятында басылып чыга һәм укучыларның җылы бәясенә лаек була. Әсәр очеркистларның 1974 елда Мәскәүдә уздырылган Бөтенроссия семинарында да тикшерелә һәм уңай бәя ала. Тормышны актив өйрәнүче язучы тагын берничә елдан укучыларга "Таяну ноктасы" исемле икенче китабын бүләк итә.*

*Р. Вәлиев документаль проза белән бергә, хикәяләр һәм повестьлар да яза. Алар үз вакытында Татарстан вакытлы матбугаты битләрендә дөнья күрде. 1986 елда Татарстан китап нәшриятында басылып чыккан "Мәңгелек ут җылысы" китабына әнә шул повестьлары һәм хикәяләре тупланган.*

*Хәзерге вакытта Равил Вәли улы Вәлиев "Шәһри Казан" газетасында баш редактор урынбасары булып эшли. Ул республикабызның, татар халкының үткәненә, бүгенгесенә һәм киләчәгенә баглы күпсанлы актуаль мәкаләләре, сәяси темага язылган публицистик язмалары белән укучылар арасында абруй казанды.*

*Каләмдәшебезне алтмыш еллык юбилее белән чын күңелдән котлыйбыз, ныклы сәламәтлек, иҗат уңышлары һәм бәхет телибез.*



## Нәҗибә Сафина

### ҖЫРНЫ—ҖЫРГА, СЕРНЕ—СЕРГӘ...

#### Мәйданнарда ачыла җан

Әй, күңелләрнең чишелгән, очынган мизгелләре!
Кояшы сүнгән күзләрнең очкынланган көннәре!

Ялтырап кояш чыгуы болытлар арасыннан,
Җаннарның аралануы ямансу ярасыннан!

Бар дөньяга түгелүе кояшлы сагышларның,
Кушылуы бер-беренә җан—канат кагышларның!

Тургайларның бер мизгелгә тынып, тыңлап торуы...
Сабан туең гөрли илдә, ата-баба ыруы!

Телдән телгә, илдән илгә моң ага, сагыш ага,
Моң-сагыш, кайгы-хәсрәтне кояшлы җырлар «чага»!

Мәйданнарга чыга тальян, менә ни чишә җанны!
Сөлге тоткан көрәшчеләр алачак бүген данны!

Моң-шатлык кушып чигелгән сөлгеләр каралмыйлар.
Яңгырлар коеп яуса да, мәйданнар таралмыйлар!

Килә-китә ява яңгыр, җырлар чыланмый икән!
Халык чынлап бәйрәм итә, юри кыйланмый икән!

Чүлмәкләрне чәлпәрәмә коеп төшерә колга...
Баганадагы әтәчне малай төшергән кулга!

---

Нәҗибә САФИНА—*шагыйрә, публицист; «Таң кошы», «Әгәр дә уйлаганда», «Аккош күле» һ. б. китаплар авторы. Казанда яши.*

Парлап бәйләнгән аяклар тәки ярашып бара,
Нәрсә ул парлап йөгерү, син капчык киеп кара:

Богауларның, капчыкларның ни икәнен белгәнгә,
Җиңгәннәргә мәртәбә зур, асыл бүләк—җиңгәнгә!

Мәйдан әйләнеп узыша елтыр күзле малайлар!
Киләчәккә—фатиха!—дип, куанышa агайлар!

Колгадагы сөлгеләрнең барыбер чиккәне матур,
Бары мәхәббәт алдында тезләнгән егет батыр!

Әй, күңелләрнең күкләргә менеп күкрәгән чагы!
Сабантуйдан олы бәйрәм—бармы соң җирдә тагы!

## Әй, туган тел

Әй, туган тел, бәйләнгәнсең
Җанымдагы һәрбер хискә.
Фани дөнья йөзләрендә
Мин эшләгән һәрбер эшкә.

Әй, туган тел, бәйләнгәнсең
Уйларымның һәр очына.
Хәтта бәйсез дип уйлаган
Зәңгәр күкнең һәр кошына.

Әй туган тел, нигеземә,
Тамырыма бәйләнгәнсең.
Тамырларны яшәтүче
Яфракларга әйләнгәнсең.

Бәйләнгәнсең искән җилгә,
Тәпи баскан туган җиргә.
Әйләнгәнсең Иделемнән
Җанга аккан олы җырга.

Әй, туган тел, бәйләнгәнсең
Урамга да, Уралга да.
Себерләрне Себер иткән
Ап-ак карлы буранга да.

Бәетләргә бәйләнгәнсең,
Әкиятләргә әйләнгәнсең.
Мәңгелеккә бару юлын,
Туган телем, шәйләгәнсең.

Әй туган тел, әй генәм лә,
Җанны җанга, җирне җиргә,
Җырны җырга, серне сергә
Бәйли торган бәй генәм лә!

~

Төн карасы тәрәзәмнән
кerә дә кerә.
Һич туктамый «зимагур» эт
өрә дә өрә.
Җил оныткан тукталышын,
исә дә исә.
Яфракларны кәүсәсеннән
кисә дә кисә.
Кем оныткан кара төндә
кайтырга өйгә?—
Атлый да атлый туктамый
һаман бер көйгә.
«Зимагур» җил, «зимагур» эт,
ул да «зимагур»...

Талчыккансың, тәрәз ачам,
әйдә, миңа кер!

«Уф»—диде дә кереп ятты
тәрәз төбемә,
Баш астына яфрак салып,
салкын җил генә…

Эт тә өрми, җил дә йөрми,
атламый беркем.
Чакырсаң да, җилләр генә
керәчәк беркөн…

## Халәт

Эшлисе эш баштан ашкан,
Җангынамнан хисләр ташкан.
Күк кырында яшьнәп йөри,—
Мәхәббәтем шундый шашкын.

Их, яшен булып яшьнәсәм,
Йә чаптар булып кешнәсәм,
Кайнар кояш булып янсам,
Ләйсән яңгыр булып тамсам…

Ә мин исә эш тә кырмыйм,
Гел сөю турында җырлыйм.
Теләгем—яшьлектә яшьнәү!
Бу хакта хәерле дәшмәү…

Дәштең исә, яшен ата,
Күңел яшьлегенә кайта…
Күк бишегендә сабый чак
Күкрәү булып елап ята…

## Булуы кыйммәт

Син үзеңнең зурлыгыңны
бел, диләр миңа.
…«Мин—зур!»—дисәм,
кычкыралар:
—Ни җитми сиңа?

Ә миңа бит зурлык түгел,
милләтем кирәк.
Ә ул булса,
яшибез без,—
булуы кыйммәт!

…Юкса Идел белән Урал
Тирән дә, биек тә бит,
Мөселман халкы бу җирдә
Борынгы, бөек тә бит…

Ачалса әгәр күзен—
Танып алачак үзен.
…Томаласаң да авызын,
Ярып әйтәчәк сүзен.

Мәңгелекнең ни икәнен белми,
Иләнгәндә гомер иләгендә,
Мин җылысын тойдым сабыемның,—
Биләвендә ята беләгемдә.

Авылыннан китсә дә кеше,
Кавеменнән китмәсен.
Кавеменнән киткән кеше
Бәхет өмет итмәсен!

Ярдан ярга бәргәләнә—
ватыла боз.
Туган җир һәм
торган җиргә бәреләбез,—
ватылабыз...
Ә кеше без...

Рәхәтләнеп ява карлар,—
Күк бәгыреннән өзелсә...—
Туңган күз яше алар.

Җанда янган утны күрми,
И бәндә...
Утын эзләп, китереп чапты
Имәнгә...

Очкан чакта уйланырга
Вакыт бик тә, бик тә тар.
Карларны—җилләр...
Кешене
Ашыктыра вакытлар.

—Синең йөздә нинди сырлар?
—Әйтмим, сер бар...
—Синең йөздә пар буразна?
—Әйтмим әле, түз беразга...
—Синең йөздә ачы сагыш йөзеп бара?
—Син белергә телисеңме?
Җанны кара:
Ул—язмышлар ярылганда
алган яра.

Мин сине дә укып чыктым,—
Сәер китап булдың син.
Күңелгә җыр да, сагыш та,—
Ачы булып тулдың син.

Җырың—сөю мизгелләре,
Сагышы—югалтулар.
Ачылары—хакыйкатьнең
Җимешләрен татулар.

Мин сине дә укып чыктым.
Авыр китап булдың син;
Җаныңа гасырлар сыйган
Дәвер-китап булдың син!



## Индус Таһиров

# ТАТАРЛАР— МӘҢГЕЛЕК ХАЛЫК

### 1. Бүгенге вәзгыять

МӘҢГЕЛЕК турындагы язмамны бүгенге вакыйгалардан башлыйсым килә. Аның сәбәбе бик гади. Без бүген әнә шул мәңгелек тамырларыбызга төрле рәвештәге балта чабуларның шаһитләре. Татарны бетерү өчен ниләр генә кылынмый, нәрсәләр генә эшләнми. Сүземне шушы елның 17 мае көнне Татарстан Дәүләт Советының Россия Дәүләт думасы белән берлектә оештырылган «Проблемы совершенствования законодательной базы федеративных и межнациональных отношений» исемле зона семинар-киңәшмәсе башланыр алдыннан булган кечкенә генә эпизодтан башлап җибәрәсем килә. Семинарга төрле республика һәм өлкәләрнең парламент җитәкчеләре һәм галимнәр җыелган иде. Үзебездән дә шактый күп кеше чакырылган. Төп кунак—Россия Дәүләт Думасы рәисе Геннадий Николаевич Селезнев. Казанда аны шаулатып каршы алдылар. Чат саен милиция, юллар бикләнгән. Хәтта Дәүләт Советы бинасына кадәр килеп җитү дә проблема. Иртәрәк килгән кешеләр Дәүләт Советы каршында сөйләшеп торабыз. Бервакыт мыш-мыш килеп, манма тиргә баткан Штанин әфәнде пәйда булды. Ул бичара әнә шул киртәләрне үтә алмый иза чиккән икән. Һәм: «Настолько переусердствовали, что проехать невозможно», дигән җәберле сүзләр ычкындыруын сизми дә калды. Аңа җавап итеп: «Это результат приведения наших законов в соответствие с российскими», дип көлештек. Уңайсызланды, боргаланды, сыргаланды, ләкин бу сүзләргә җавап таба алмады, йотып җибәрергә мәҗбүр булды. Әле өстәвенә кемдер: «Наткнулся на собственные вилы, пеняй на себя», дип өстәп тә куйды. Ул тагын берәүнең әллә уфтанып, әллә шатланып «То ли еще будет», дигән сүзләрен ишетКәндерме, юктырмы, халык шау-гөр килеп залга агылды. Эпизод та шуның белән онытылган сыман булды.

---

Индус ТАҺИРОВ *(1936)—тарихчы-галим, Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты рәисе, Татарстан Фәннәр Академиясе академигы. Казанда яши.*

Кайберәүләр, Дәүләт Советында бердәнбер пырдымсыз депутатыгыз бар, шуны да кулга ала алмыйсыз, диләр. Шушы бәдбәхетне якасыннан алучы да, яңаклап җибәрүче дә юк бит, дип әйтүчеләр дә бар. Бу сүзләрдә хаклык юк, дип әйтеп булмас иде. Тик менә проблеманы кемнеңдер якасыннан алып кына хәл итеп булмый шул. Мондыйлар меңләгән, алар белән Россия тулган. Һәм иң зәһәрләре Думага һәм Мәскәү Кремленә оялаган.

Хәер, акыллы һәм мәкерле хәрәкәт итүчеләр дә юк түгел. Болары дустан да дус булып кылана, еландай телләрен чыгарып Татарстанны мактаган булалар. Алай гына да түгел, Россиянең федератив үсешенә куркыныч яный, унитар һәм империалистик көчләр уянды, дип ясалма күз яшьләре дә чыгарып куйгалыйлар. Менә Селезнев та шундыйлардан. Шушы семинарда ул Татарстанны үтереп мактады, җитәкчелегенең зирәклегенә соклану белдерде. Әмма Федераль үзәкнең төбәкләр белән договорлар төзүе вакытлы чара гына булды, договорлар үз эшләрен эшләделәр һәм нотыгын хәзер аларны юкка чыгару вакыты җитте, дигән сүзләр белән җөпләде. Русча әйтмешли, «начал за здравие, кончил за упокой». Менә бүгенге үзләрен демократ итеп күрсәтергә тырышкан кешеләр шундый. Коммунистлары да шовинистлары да бер. Мондыйларга карата «мягко стелет, жестко спать», дип тә әйтәләр. Чыннан да шулай.

Договорлар дигәндәй, бу бәндәләр иң беренче чиратта Россия һәм Татарстан арасында төзелгән договорны истә тоталар. Нәкъ Маяковский әйткәнчә: «Мы говорим партия, подразумеваем Ленин». Договорлар диләр, әмма Россия һәм Татарстан арасындагысын гына күзаллыйлар. Башкалары чүп тә түгел. Чөнки алар заманында сәяси уен коралы рәвешендә С. Шахрай тәкъдиме белән безнең договорның әһәмиятен төшерер өчен генә төзелгән буш кәгазьләр иде. Алар бүген дә уен коралы гына. Селезневлар һәм башка Путин җырын җырлаучылар договорлар кирәкми, алар үз рольләрен үтәделәр, диләр. Шушы гына көтеп торган, ясалма, беркемгә дә кирәкми, берничек тә гамәлдә булмаган «договор»лар Путин өстәленә өелә башлады. Мондыйларның саны егермедән артты. «Ник соң әле Татарстан читтә калырга тиеш, ул Россиянең уртак хокуки кырына кермиме икән ни?» Бу һәм менә шундый ризасызлыклар тудырып, Татарстанны да договорыннан баш тарттырырга тырышу гамәле генә. Шикләнер урын юк, нәкъ шулай.

Бу ни өчен эшләнә? Татарстанны ялгыз калдырып сындыру өчен. Ни өчен Татарстан һәм Башкортстан, татарлар һәм башкортлар арасына чөй кагыла? Шул ук максат. Татарстанны ялгыз калдырып, Бөтенроссия халык санын алган вакытта татарларны бүлгәләп, тураклап ташлау да, татарны, республикабызны зәгыйфьләндерү максатыннан башкарыла.

Зәгыйфьләндерү моңа гына кайтып калмый. Аның төрле юллары кулланыла. Инде ике елдан артык дәвам иткән Татарстанның законнарын Россиянеке белән тәңгәлләштерү процессы, бетмәс-төкәнмәс прокурор протестлары тамчы ташны телгәләгәндәй суверенитетыбызны акрынлап юкка чыгаруга юнәлтелгән. Инде Конституциябезгә чират җитте. Дәүләт Советы аның яңа редакциясен кабул итте. Без моңа яңа туган шартларда котылгысыз компромисс итеп карадык. Инде туктарлар, дип тә уйладык. Шактый ябыккан, инде сөяккә генә калган төп законга да ризалаштык. Россия президенты бу Конституцияне мактагач, Татарстан парламентарийларын компетентлы һәм нәтиҗәле эш алып бардылар, дип башкаларга мисал итеп куйгач, тынычланырга да мөмкин кебек иде.

Ләкин Россия генераль прокурорының Идел буе округы буенча урынбасары өр яңа протест әзерләгән булып чыкты. Әлбәттә, үз белдеге белән генә түгел. Инде шушы мескенәеп, чекрәеп калган Конституциянең нәрсәсе ярамады икән соң?

Эш болайрак тора. Конституциянең шушы вариантын төзеп бетереп, аны Дәүләт Советына чыгарыр алдыннан мөхтәрәм Президентыбыз Минтимер Шәймиев төрле мөмкинлекләрдән файдаланып, яңа вариант проектының төп принципларын Мәскәү белән килештерү эшен башкара. Проект 18 февраль көнне Россия Президенты аппараты җитәкчесе Дмитрий Козак исеменә җибәрелә. Тегесе аны Президент каршындагы

Баш дәүләт-хокукый идарә начальнигы Л. И. Брычевага юнәлтә. һәм 20 февраль көнне куелган сроктан да алдарак аңа заключение өлгереп тә житә. Мин аның тулы эчтәлеген сөйләп укучыларны ялыктырасым килми. Төп таләпләр Татарстан суверен дәүләт, ә аның Президенты суверенлыкның гаранты булмаска тиешлеккә кайтып кала. Шулай ук Татарстанның үз гражданлыгы да, халыкара һәм тышкы икътисади элементләре дә булмаска тиеш. Заключениедә ваклану шул кадәргә житкән ки, хәтта Татарстанда премьер-министр посты да булмаска һәм хөкүмәтне президент үзе житәкләргә тиеш, дигән таләпкә кадәр бар.

Мәгълүм ки, 28 февраль көнне Дәүләт Советы X сессиясе Конституциянең яңа вариантын беренче укылышта һәм аннан соң тулаем кабул итте. Депутатлар суверенлык принцибыннан баш тартмадылар. Конституциянең беренче маддәсендә Татарстанның суверен дәүләт икәнлеге ачыктан-ачык язылган. Димәк, депутатлар Мәскәү басымына бирешмәгән. Хөкүмәт төзү тәртибе дә Мәскәү таләбенчә түгел. Татарстанның үз гражданлыгы да сакланган. Премьер-министр посты да сакланган.

Яңа протест менә шушы һәм Конституциядәге башка суверенлык принцибына корылган маддәләрне юк итүгә юнәлтелгән.

Мәскәү әле моның белән генә дә чикләнмәячәк, басымын тагын да арттырачак. Моңа да әзер булу кирәк. Дәүләт Думасының 5 май көнне Россия халыкларының телләре турындагы законга илдә тик кирилл әлифбасы гына кулланылырга тиеш дигән төзәтмәне беренче укылышта кабул итүе дә шуңа ишарә.

Бу безнең латинга күчүебезгә мөнәсәбәт. Алай гына булса бер хәл иде. Түгел шул. Бу гомумән кеше хокукларына һөҗүм. Әгәр дә бүген адәм баласына үз фикерен үзе теләгән хәрефләр белән белдерү тыелса, иртәгә аның фикер белдерү, ә берсекөнгә туган телендә сөйләшү хокукыннан да мәхрүм ителүе ихтимал. Ә моннан тоталитар дәүләткә бер адым гына кала.

Шунысы игътибарга лаек, бу закон проектының авторлары арасында милләттәшләребез дә бар. Болар үзләренең бу гамәлләре латин язмасына түгел, ә милләтебезнең хокукый халәтенә, аның статусына мөнәсәбәт икәнлеген аңлыйлармы икән? Хыянәтме бу, әллә эшнең асылын аңлап житкермәстән, өстән төшкән әмерне үтәү генәме икән?

Күрәсез, мөхтәрәм укучылар, болар бер-берсенә бәйләнмәгән очраклы фактлар гына түгел. Бу милләтебезгә юнәлтелгән тулы масштаблы һөҗүмнең башы.

Без шактый чигендек. Ләкин башка чигенер җаебыз калмады. Буйсынып, сыгылсак, бөгелсәк, без борынгы Карфаген хәлендә калачакбыз. Сүз данлыклы Ганнибал иле турында бара. Гениаль полководец хыянәтче олигархлар тарафыннан илдән куылып, дөнья куйганнан соң мәкерле Рим Карфагенны юк итү юлына баса. Баштарак, ул, дустанә кыланып, имештер гомумкоралсызлану принцибыннан чыгып, ил башында торган олигархларны, халыктан яшертен арсеналдагы коралны шәһәрдән чыгаруга ирешә. Аннан соң, шул ук «дустанә» яшәү бәрабәренә сугышу филләрен чыгаруны таләп итә. Шул ук рәвештә катапультлар да дошман кулына күчә. Инде ниһаять олигархларның үзләренә чират житә. Рим алардан заложниклыкка үзләренең 300 баласын бирүне таләп итә. Бер бөгелсәң бөгеләсең, бер сыгылсаң сыгыласың икән. Бу таләпкә каршы торырдай көч калмаган була шул. Тарихчылар аналарның балалары төялгән пароход артыннан батып үлгәнчегә кадәр йөзә барганлыклары хакында язып калдырганнар.

Бу эпизод, сезгә хөрмәтле укучыларым, Казан олигархларының бертуктаусыз хан алыштыруларын, Сөембикә ханбикәне Мәскәү кулына тапшырганда халыкның аны алып киткән көймә күздән югалганчыга кадәр елый-елый озата баруын хәтерләтмиме? Үткән дәвернең 149 елында Карфаген халкының үз шәһәрләрен каһарманнарча яклавы казанлыларның 1552 елдагы бәйсезлек өчен барган тиңсез сугыштагы батырлыкларын исегезгә төшермиме? Ә бит охшашлык, хәтта хатын-кызларның, каһарманлыкларына кадәр. Карфаген хатын-кызлары дошманга каршы сугышта катапультлар ясау өчен чәчләрен кисеп баулар ишкән булсалар, Казанда

дошман гаскәре хан сараена бәреп кергәч, сафларга тезелгән 2-3 меӊ гүзәл зат каршы чыгып, аны чигенергә мәҗбүр итә.

Бу ике шәһәрнеӊ язмышлары да охшаш. Римлылар Карфагенны алгач, аныӊ урынын сөреп ташлыйлар һәм шул урынны Африка дип атыйлар. Казан да ерткычларча җимерелә, талана. Калган халкы куыла.

Бу чагыштыру ни өчен кирәк булды икән, диярсез. Моны мин тарихтан сабак ала белергә кирәк икәнлеген аӊлату, зәгыйфьләндерү сәясәтенеӊ борын-борыннан килгәнлеген күрсәтү максатыннан чыгып эшләдем, хөрмәтле укучыларым.

## 2. Татар–Башкорт арасы

БУ ПРОБЛЕМАНЫ куюым да очраклы түгел. Чөнки халыкларны бүлгәләп, бер-беренә каршы кую сәясәте дә бүген генә барлыкка килмәгән. Ул борынгы Кытай империясендә дә һәм бигрәк тә Рим империясендә киӊ кулланылган. Россиядә дә бу сәясәтнеӊ шактый традицияләре бар. Ул төрки халыклар арасында табигый туганлыкны бозып, аларны дошманлаштыруга юнәлтелгән. Татар-башкорт мөнәсәбәтләре дә шушы сәясәтнеӊ чагылышы. Шушы ике туганнан-туган халыкны бер-беренә каршы кую эшен патша хөкүмәте башлаган, коммунистлар дәвам иткән.

Ләкин татарлар һәм башкортлар арасындагы якынлыкны беркем дә, берничек тә җимерә алмаган. Инде күп еллар шушы ике халык арасындагы мөнәсәбәтләрне өйрәнеп йөрүче Америка профессоры Хафез Малик болар икесе бер телдә сөйләшә, әгәр ул телдә татар сөйләшсә, бу тел татар теле була, әгәр аӊарда башкорт сөйләшсә, ул башкорт теле була, дигән фикергә килгән. Күрәсеӊ, ерактан карасаӊ яхшырак күренәдер.

Ләкин бу башкорт милләте юк, аны тик кемдер уйлап кына чыгарган, дигән фикер тулысы белән ялгыш. Ибн Фазланныӊ «Иделгә сәяхәтендә» дә, XI гасырныӊ атаклы филологы Мәхмүт Кашгарлы һәм башка сәяхәтчеләр һәм галимнәр аларныӊ шул вакытта ук булганнарын бәян итеп калдырганнар. Аларныӊ милли хәрәкәтләрен дә берәү дә уйлап чыгармаган, болары да тарихи хакыйкать.

Бүгенге көндә әнә шул үткән чынбарлыкка гомердә булмаган гамәлләрне кушып сөйләү рәвеше барлыкка килде. Әллә нинди уйдырмалар туа тора. Салават Галләмов дигән берәү бөтендөнья цивилизациясе башкортлардан башланган, дип яза. Аныӊча, инглиз вә норвегиялеләр дә алардан тамырланган икән. Ә инде борынгы Крит цивилизациясен «ниндидер греклар»га бирү, бөтенләе белән ахмаклык икән *(С. Галямов. Великий Хау Бен: Исторические корни башкордско-английского языка и мифологии.—Уфа.—1997.—С. 186).* Ярый, әгәр, адәм көлкесенә калмастан, дөнья җәмәгатьчелеген көндерүгә ирешсәләр. Ләкин «ай-һай», чөнки бу гамәлләр тик көмит уенын гына хәтерләтә.

Ә менә татарны юкка чыгарырга тырышу гамәле бик үк көмит түгел, анысы безгә турыдан-туры кагыла. Минем хәтта Әкрәм Бейш яки Г. Шафиков әсәрләрендәге кебек һәрбер битендә диярлек татарга ягылган ялаларга да артык игътибар бирәсем килми. Чөнки сукыр нәфрәт белән язылган китаплар теләсә нинди тәнкыйтьтән дә түбән булалар. Ә менә Бөтендөнья башкортлары Корылтаеныӊ элеккеге рәисе Нияз Мәҗитов язганнарга җитди игътибар итми булмый. Чөнки аныӊ позициясе, бер яктан, тарихи документлардан кирәкле рәвештә генә йолкынган фактларга нигезләнгән булса, икенче яктан ул Башкортстан җитәкчелегенеӊ официаль позициясенә якын тора. Аныӊ раславынча, Башкортстандагы татар дип санала килгәннәрнеӊ күбесе башкорт икән. Алай гына да түгел, Татарстанга кергән Минзәлә өязендә дә тулысы белән татарлаштырылган башкортлар яши икән. Шулай булгач, шул өязгә кергән Актаныш районы халкы да, әлбәттә, инде шул исәптән мөхтәрәм Президентыбыз Минтимер Шәймиев тә башкорт булып чыга. Ә бит чынбарлыкта Минзәлә җирләре Казан ханлыгына кергән һәм анда татарлар яшәгән. Минзәлә өязендә генә түгел, гомумән Уфа губернасыныӊ

күпчелегеп татарлар тәшкил иткән. 1920 елның февралендә Башкортстан хөкүмәтендә тупланган материалларга караганда, анда нибары 355. 700 башкорт булып, татарларның җан башы 1.332.370 кеше тәшкил иткән. Боларның бер өлеше элек-электән шунда яшәгән булса, шактые Казан егылганнан соң төрле гасырларда изелүләрдән, түзә алмастай салым кысымыннан, чукындыру сәясәтеннән качып киткән татарлар. 1719 елда ук Казан губернаторы Салтыков 46. 841 ясаклы татар хуҗалыкларының 19.932 бушап калганлыгы, анда яшәүчеләрнең башкортлар янына күчеп китүе турында Сенатка хәбәр итә. Аның урынына килгән яңа губернатор Волынский күп булса бары ни 20 ел элек кенә 35-40 мең тәшкил иткән башкортларның саны 100 меңнән артты, дип яза. Бу үсешнең Казан, Сембер өязләреннән күчеп киткән татарлар икәнлеген күрсәтә. Күренекле башкорт галиме Р. Г. Кузеев XIX гасырның икенче яртысында бу процессның тагын да арта төшүе хакында яза. Шул гасырның икенче яртысының 40 елында гына да аларның саны 545 меңнән 1.312.241 меңгә җитә. Татарлар саны исә 1857—1897 елларда, региондагы төркиләрнең уртак балансы тигез сакlануына да карамастан, тик 1.320 меңнән 1.619 меңгә генә җиткән. Галим моның татарлар хисабына «яңа башкортлар» барлыкка килүе белән аңлата. Патшаның 1855 ел 19 апрель указы нигезендә Башкорт-Мишәр гаскәренә типтәрләрне дә китереп кушалар. 1856 елда бу гаскәр яшәгән җирләр 28 кантонга бүленеп, анда 480.317 мең башкорт, 110.595 мең мишәр, 260.975 типтәр һәм барлыгы 851.887 кеше була. 1858 елда гомум сан 981,6 меңгә җитә. Шуларның 544,8 меңен башкортлар, 436,8 меңен татарлар тәшкил итә. Шуннан соң күп тә үтми бу гаскәр тик Башкорт гаскәре генә, дип атала башлый. «Менә шушы үзгәрешләрдән соң,—дип яза галим,—статистик белешмәләрдә татарлар йомышлы башкорт катламына (сословные башкиры) кертелеп санала башлыйлар». Галим ясаган нәтиҗәгә караганда, XIX гасырның ахырында башкортлар составында 350-400 мең мишәр һәм типтәр саналган *(Р. Г. Кузеев. Народы Среднего Поволжья и Южного Урала. Этногенетический взгляд на историю.—М., Наука.—1992—С. 162—163).* Н. Мәҗитов исә мишәрләр башкортлар белән бер милләт тәшкил иткәннәр, димәкче була. Ул 1855 елның 19 апрелендәге патша указына таянып, мишәрләрне башкортлаштыра. Бу указда кешенең этносын билгеләү өчен «башкир из мещеряков», «башкир из тептярей» дигән төшенчәләр булуын ул бөтенләй белмәмешкә салына. Галим татарларны башкорт итеп санау чын башкортлар арасында зур ризасызлык тудырганлыгын да күрмәмешкә салына. Ә бит алар татарларны гаскәрдән чыгаруны сорап Екатерина II гә хат та язалар. Чөнки, имештер, бу татарларны күп вакыт командир итеп билгели торган булганнар һәм алар башкортларны кыса торган булалар. Тик бу бернинди нәтиҗәгә дә китерми. Указ көчендә кала. Этнограф Д. Н. Соколов үзенең 1904 елда язылган хезмәтендә башкортларны ике төркемгә бүлә. Аларның берсе этник төркем булса, икенчесе башкортларның өчтән берен тәшкил иткәне яңа башкортлардан торган була. Шушы ук фикер Б. Х. Юлдашбаев, Р. Г. Кузеев, Д. Исхаков тикшеренүләре белән дә раслана *(Р. Г. Сибагатов. Башкортстан татарлары. Тел, тарих, мәдәният мәсьәләләре.—Казан.—2002.—8 б.).*

Н. Мәҗитов исә, катламнарның күптән бетерелгәнлеге белән дә, заманында миллләттәшләренең татарларны үзләренә кушуга каршы булганлыгы белән дә исәпләшмәстән, шул татарларны инде бүген, XXI гасырда, башкорт итеп яздырмакчы була. Имештер, бу башкортлар татарлаштырылганнар гына һәм бүген үзләренең тарихи тамырларына кайтырга тиешләр. Ә кайберәүләр Н. Мәҗитовны да уздырып җибәрәләр. Алар Р. Кузеевтан интервью рәвешендә мәкалә эшләп, галимгә республикада башкортлар санын 40—50 процентка җиткереп була, дигән фикерне тагалар. Р. Кузеев исә, ул вакытта каты авырый һәм инде интервью бирерлек хәлдә булмый.

Башкорт булып язылган татарларга карата кыерсытулар, кыек караулар бетәрме икән соң? Шул ук Ә. Бейш 1920 елларда татарлар башкорт булып язылып, җитәкче урыннарга үрмәләделәр, дигән гаеп ташлады. Димәк, хәзер дә татарларны башкорт итеп язсалар да, аларны барыбер чын башкорт итеп танымаячаклар, җитәкче постларга җибәрмәячәкләр.

Татарлар аларга тик башкортка сан тәэмин итү өчен генә кирәк. Халык санын алу кампаниясе бетүгә үк, барысы да иске хәленә кайтачак.

Шунлыктан бүгенге татар хисабына башкорт санын арттырырга тырышу ике халыкка да зарарлы. Беренчедән, шул ук Р. Кузеев язганча, халыкның күпмедер өлешендә татар-башкорт уртаклыгы барлыкка килә. Монда катнаш никахларны онытмаска кирәк. Әгәр дә яшьләр бер-беренә гыйшык тоталар икән, Н. Мәҗитовтан, хәтта Р. Кузеевтан да сорап тормастан, гаилә корып гөрләшеп яши башлыйлар. Әнә бит Рафаэль Жданов:

Табигатьнең бар бизәге
Миңа сине мактады.
Башкорт кызыннан да гүзәл,
Мәңгелек яр тапмадым.
Рәхмәт сиңа аппагым,—

дип яза *(Рафаэль Жданов. Гомер.—«Мәгърифәт».—Уфа, 2000.—36 б.)*. Без белер-белмәс гамәлләребез белән әнә шушы катнаш гаиләләр эченә ут ташламабызмы икән? Мондый гаиләләр меңләгән бит ул. Татар телен туган телләре итеп санаган, нигездә татар мохитендә яши торган моңарчы «паспортлы башкорт» булып саналган кешеләрне авыр хәлгә куймабызмы икән? Ә бит Башкортстанда аларның саны 200—300 меңгә җитә.

Кайберәүләр, бәлки, инде ниһаять башкорт авыллары итеп язылган татар телле урыннарда башкорт телен укытып, аларны чын башкорт итәрбез, дип уйлыйлардыр. Ләкин бу ялгыш фикер. 80 елларда моны эшләп карадылар. Тик бер нәмәкәй дә барып чыкмады. Балаларның башкорт телен өйрәнү дәрәҗәсе инглиз телен белү дәрәҗәсеннән артмады. Артмаячак та. Чөнки халыкның яшәү теле, аның ана теле—ул татар теле. Тукай теле. Бу хаклык аңардан беркайчан да аерылмаячак.

Әмма халыклар арасында упкын барлыкка киләчәк. Хәтта үзләрен традицион рәвештә башкорт итеп санаган татарлар да үз асылларына кайтмасмы икән?

Моның икенче варианты да бар. Әйтик, татар телле башкортларның саны гаять күбәеп китте ди. Бу «башкортлар» чын башкорт яшәешен, аның телен эретеп, юкка чыгармасլармы икән? Бу бит санда түгел, гамәлдә башкортның татарлашуына юл ачу була. Шулай итеп, башкортлар кәгазьдә генә калмасмы икән?

Без исә һәрвакыт башкорт халкына теләктәшлек белдерә килдек. Язучыларыбызны артистларыбызны, галимнәребезне башкорт әдәбиятына, сәнгатенә күпләп җибәрә тордык. Бу сыйфатлы татарлар башкорт тормышын, аның яшәешен бизи килделәр. Башкортның тамырын ныгыттылар. Без башкортның мәңге яшәвен телибез. Ул беркайчан да бетмәсен. Аның исән-имин булуы безнең тормышка да ямь өстәп тора.

## 3. Халыкны бүлгәләү сәясәте һәм милли идеология

РОССИЯ Фәннәр академиясенең этнология һәм антропология институты шушы елның октябрь аенда үткәрелергә тиешле Бөтенроссия халык санын алу кампаниясе өчен халыклар исемлеге төзегән. Анда татарлар алты кисәккә бүленгән. Себер татарлары аерым, ә гомум татар составына тик әстерхан татарлары һәм мишәрләр генә кертелгән. Монда башка татарларга урын юк. Аның каравы керәшеннәр һәм ногайбәкләр аерым милләтләр итеп күрсәтелгәннәр. Милләттәшләребезнең Казанда яки Уфада яшәгәннәрен кая куярга уйлаганнардыр бу исемлекне төзүчеләр, Алла белсен. Бу бүленешнең, әлбәттә, бернинди фәнни нигезе юк һәм була да алмый. Диалекталь аермалар, яшәү урыны һичничек тә милләт нигезләмәсе була алмый. Татар халкын милләт буларак уртак традицияләр, гореф-гадәт, бербөтен рухи дөнья, газиз ана телебез, Тукай

теле берләштерә. Татар яшәгән һәммә җирдә гөрләп үтә торган Сабантуйлар, җыр-моң дөньясы—барлык татарның да уртак мирасы.

Бу татарга каршы эшнең фәнни нигезе булмаса да, сәяси максаты ярылып ята. Ул да булса, татарны бүлгәләү һәм телгәләү, аны зәгыйфьләндерү. Һәм, ахыр чиктә, аны бөтенләе белән юкка чыгару.

Бу сәясәттә татарларны Татарстаннан аеру беренче урынга чыгарыла. Әнә шул мин әйткән этнология һәм антропология институтының директоры В. Т. Тишков күптән инде шул хыял белән яши. Ул берничә мәртәбә Татарстанның башка төбәкләрдәге татарларның тормышына катнашырга хакы юк, дип язып чыкты. Ниһаять, аңа хыялын «законлы» рәвештә тормышка ашыру мөмкинлеге бирелде. Исемлекне аның институты төзегән. Инде сүз чыккач, бу кешенең милләт төшенчәсен ничек аңлаганлыгын әйтеп китми булмый. Аныңча, кешегә милләте тумыштан бирелми икән. Аның милләте төрле сәяси, мәдәни үзгәрешләрдән яки миграция нәтиҗәсендә үзгәрергә дә мөмкин икән *(Российская газета.— 2002, 31 май)*. Шуның өчен, хөрмәтле укучыларым, кайдадыр китеп торуы аркасында күпмедер вакыт күрми торган туганыгыз яныгызга француз яки немец булып кайтып төшсә, аптырамагыз. Моны мәртәбәле профессор «үзе» дөрес дип тапкач, шулай булырга тиештер, дип уйлагыз. Үзегезнең милләтегезне үзгәртеп куйсалар да шаккатмагыз. Ә инде татарны башкорт итәргә тырышуларга бөтенләй исегез китмәсен.

Тик шулай да. Кызганыч ки, сүз Тишков турында гына бармый. Чөнки Россиядә, бигрәк тә аның элитасында, мондыйлар күп. Аларның тегермәненә суны урыннардагы шовинистик көчләр коеп тора. Түбән Новгородта, Новосибирскида, Омскида һәм башка җирләрдә мөселман зиратларын җимерү, мәсхәрәләү, күп шәһәрләрдә мәчетләр салуны тыю, татарны йомшату, аны куркыту, юкка чыгару сәясәтенең чагылышы. Мәгълүм ки, соңгы елларда Россиядә татарның йогынтысы арта бара, татар факторы ныгый. Бу исә күпләрне борчый. Зур һәм кечкенә «Жириновскийлар», «бетсен татар», «бетсен Татарстан», дигән уй-хисләргә куәт биреп торалар.

Без бу сәясәткә үзебезнең милли идеологиябез тирәсендә туплану белән җавап бирә алабыз. Шушы уңайдан милли идеологиягә дә мөнәсәбәт белдерү кирәктер. Сүзне идеологиянең милләтебезнең үткәненә, бүгенгесенә һәм киләчәгенә карашлар һәм идея системасы икәнлеген аныклап китүдән башлау дөрес булыр. Милли идеология милләтебезнең халәтенә диагноз куюны һәм аның яшәешен тәэмин итүне максат итеп куя. Милли идеологиянең, һәрбер башка идеологиянеке кебек үк, ниндидер өстенлекләре (приоритетлары) була. Алар милләтнең төп терәге, аның язмышын хәл итә торган нигез ташлары була.

Нәкъ менә шуннан чыгып, гамәлдә милли идеологиянең һәрвакыт булган һәм бүген дә бар икәнлеген асызыклап китәргә тиешбез. Тарих аны һәр чорда яшәү рәвешендә төгәлләштерә килгән. Татарлар бәйсезлекләрен югалтып коллыкка төшкәч ул татарларның милләт буларак исән калуына, Тукай сүзләре белән әйткәндә, телебезне, лөгать, гадәт вә әхлагыбызны саклап калуга юнәлтелгән. Һәм дөресен әйтергә кирәк, Октябрь инкыйлабына кадәр милләтебез үз-үзен саклау системасын булдыра алды. Беренчедән—ул үз мөмкинлекләренә көйләнгән мөстәкыйль мәгариф системасын тудырды. Икенчедән—гореф-гадәтләрен, милли традицияләрен саклардай мөстәкыйль яшәү рәвешенә ия була алды. Һәм инде өченчесе—татарлар рус дәүләтендә, башка халыклар арасында үз урыннарын билгели алдылар.

Менә шуларны исбатлый торган кайбер фактлар. 1870 елда ук татарлар турында Сембердә чыккан бер җыентыкта болай дип язылган: «Татары не потеряли своей народности... подчинились русским только политически, но не морально. До сих пор татары удерживают свою индивидуальность» *(Симбирский сборник.—Симбирск.—1870.—С. 156)*. Шушы ук җыентыкта татарларның акыллы, хезмәт сөючән һәм мәгърифәтле халык икәнлекләре бәян ителгән. Аларның кунакчыл, юмарт һәм ярдәмчел икәнлекләренә басым ясалган. Татарларга карата уңай фикердә тормаган профессор Знаменский да аларның мәгърифәтле, китап сөючән халык

иконлеген таныргa мәҗбүр булып, болай дип язган: «Не мудрено, что, благодаря своим многочисленным школам и печати, татарское население в настоящее время почти сплошь грамотное и с презрением смотрит на русских крестьян, страдающих безграмотностью, да кстати уже и на всю русскую образованность вообще... Между татарами существует крепкое убеждение, магометанским книгам нет конца, а русским книгам есть конец, и что когда русские дочитаются до этого конца, то обрятаться к магометанским книгам и сами сделаются магометанами. По своей привычке к книге. Татарин довольно быстро выучивается русской грамоте, как это замечено в полках: солдаты из татар скорее делаются грамотными, чем русские» *(Очерки по родиноведению. Казанская губерния.—Казань.—1912—С. 79).* Бу сүзләрне татарларны, йомшагырак итеп әйткәндә, бик үк сөеп бетермәгән кеше язган булганлыктан, аларга кайбер төзәтмәләр кертелергә тиеш. Мәсәлән, татар кешесе беркайчан да кемне дә булса кимсетмәгән, берәүгә дә өстән карамаган. Киресенчә, югарыда телгә алынган «Симбирский сборник»та язылганча, татары «народ гостеприимный и щедрый, помогают всем, даже русским». Знаменскийга ышансаң, ул татарларның чисталыгын да ясалма гына, дип исбатламакчы була. Ә менә татарларны объектив рәвештә тикшергән этнограф Н. И. Воробьев башка галимнәрнең һәм үзенең тикшерү нәтиҗәсендә болай дип яза: «Мы на основании наших довольно многочисленных наблюдений над татарской деревней определенно заявляем. Что татары в массе живут гораздо чище многих народностей края» *(Н. И. Воробьев. Казанские татары. (Опыт этнографического исследования).—Казань.—1920, С. 240).* Юк, җәмгать, янәшәбездә яшәгәннәрнең һәммәсе дә диярлеге татарларны ярату-яратмауларына карамастан, аларның башка халыкларны таң калдырырдай сыйфатларын, өстенлекләрен таныргa мәҗбүр булганнар. Башкортлык идеологы булган күренекле тарихчы Б. Х. Юлдашбаев юкка гына татарлар Октябрь инкыйлабына кадәр үк «мисали рәвештә ислам миллэтенә әверелделәр», дип язмагандыр.

Иң кискен борылышлар вакытында, милләтебезгә инкыйраз янаган чорларда, дистәләгән каһарманнар, акыл иярәре табыла торган. Алар үз гамәлләре белән халкыбызга яшәү көче өсти килгәннәр.

Үткән гасыр башында Россия өстендә революцион давыллар күтәрелеп, милләтебез язмышы кыл өстендә калган бер чорда Шиһабетдин Мәрҗани, Ризаэтдин Фәхретдинов, Гайнетдин Әхмәров, Газиз Гобәйдуллин, Һади Атласи, Галимҗан Шәрәф кебек тарихчы галимнәребез халкыбызның үткәнен, аның гүзәл сыйфатларын фәнни нигезгә салып, киң массаларда милли горурлык хисләрен уята алганнар.

Элек Вятка губернасына кергән хәзерге Әгерҗе районындагы данлыклы Буби мәдрәсәсе шәкертләре халыкка «үзебезнең дәүләтебез, ханнарыбыз булганлыгын без беркайчан да онытырга тиеш түгелбез», дип аңлата килгәннәр. Сөембикә манарасы, аңа багышланган риваятьләрне сөйләп, аның тарихи аңын, горурлык хисләрен уятканнар. «Мөхәммәдия», «Хөсәения» һәм башка мәдрәсә шәкертләре вә укытучылары да бу изге эштән читтә калмаганнар. Галимҗан хәзрәт Баруди, Бәдретдин Апанаев, Гаяз Исхакый кебек йөзләгән затлы шәхесләребез сөргеннәргә сөрелүдән дә, зинданнарга ябылудан да куркып тормаганнар. Гаяз Исхакый әйткәнчә, «килер бер көн, безнең урамда да бәйрәм булыр», дип халыкта киләчәккә ышаныч һәм өмет тудыра килгәннәр.

«Үзебезнең китап телен, әдәбиятын булдырган, гүзәл тарихы һәм үткән юлы булган халык беркайчан да югалмаячак. Башыбызга төшкән фаҗига тик вакытлы хәл генә. Болар бар да юкка чыгар. Халкыбыз уяна, үзен күмгән кабер туфрагыннан арына. Татарның киләчәге томанлы түгел, ул бик тә ышанычлы». Бу сүзләрне 1911 елда ук «Вакыт» газетасында Троицкида яшәүче бер милләттәшебез язган. Алар, әйтерсең лә, бүген язылган! Чыннан да, халкыбыз утка салсалар да янмаган, суга салсалар да батмаган. Беркайчан да бернинди төшенкелеккә дә бирелмәгән.

Ләкин милләтебезнең акыл иярәре һәрвакыт еракка караганнар, сак вә уяу булырга өндәгәннәр, Гаяз Исхакый кисәткәнчә, инкыйразның һәрвакыт, хәтта 200 елдан соң да янап торганлыгын онытмаска кирәклеген

әйтә килгәннәр. һәм кисәтеп калу белән генә чикләнмәстән, аңардан котылу юлларын да күрсәткәннәр. Аларның фикеренчә татарның мәңгелеген аның инде барлыкка килгән милли яшәешенә хокукый нигез салу гына тәэмин итә ала. Революциягә кадәр моның ике юлы билгеләнгән. Беренче юл—Россиядә татарлар өчен милли-мәдәни мөхтәрият булдырып, татарның рухи тормышын мәстәкыйльләштерү. Икенче юл—милли дәүләтчелекне торгызу. Беренче идеянең башында Садри Максуди торган булса, икенчесен Галимҗан Шәрәф, Ильяс Алкин житәкләгәннәр. Шушы ике юлны берләштерү нигезендә Идел-Урал берлеге идеясе барлыкка килә. Революциядән соң халкыбыз өчен чын-чынлап инкыйраз яный башлагач, Гаяз Исхакый бу идеяне төрле яклап исбатлый һәм халык күңеленә сеңдерү максатыннан чыгып шул исемдәге тарихи әсәрен яза.

Бүгенге милли идеологиябезнең нигезендә дә ике төп приоритет ята. Аның беренчесе—Татарстанның суверенлыгы булса, икенчесе—дөнья татарларының Татарстан тирәсендә рухи берләшүе. Менә бу һәммә кешегә аңлашырдай гап-гади идеология һәм ул Бөтендөнья татар Конгрессының уставына салынган.

Шунлыктан безнең өчен иң әһәмиятлесе аның ни рәвештә тормышка ашуы. Бүген без суверен Татарстан бармы, аның тирәсенә татарлар тупланамы, дигән сорауларга җавап бирергә тиеш булабыз. Әлбәттә, боларның берсе дә гади сорау түгел һәм аларга гади җавап та юк. Тик, шулай булуга да карамастан, оптимистик карашлар өстенлек итә. Монысы фикер генә түгел, чынбарлык, 1990 елның 30 августыннан башланган Татарстанны суверенлаштыру процессы зур авырлыклар белән булса да дәвам итә. Республика Конституциясенең яңа вариантында да 1992 елның 21 мартындагы референдумда белдерелгән халык фикеренең төп нигезе сакланып калды. Анда Татарстанның суверен дәүләт буларак, Россия белән мөнәсәбәтләренең ике яклы договор нигезендә корылуы, республиканың үзенең гражданлыгы булуы ныгытылган. Конституциянең 14 маддәсендә Татарстанның республикадан читтә яшәүче татарларга ярдәм күрсәтергә хаклы икәнлеге дә күрсәтелгән.

Инде татарларның республикага мөнәсәбәте хакында. Декларация кабул ителгән республикага мөнәсәбәте хакында. Декларация кабул ителгән көннәрдә, референдум вакытында татарлар төн йокыларын калдырып шушы вакыйгаларның барышын күзәтеп тордылар. Дөньяның төрле почмакларыннан Казанга бертуктаусыз телефон шылтырап торды. Кызыксыну арттаннан-арта барды. Уңай нәтиҗә барлыкка килгәч, барлык татарлар тантана хисләре кичерделәр. Телефон аша, телеграммалар аркылы меңләгән котлау хисләре җиткерелде. Шуның белән татарлар үзләренең Татарстан тирәсендә оешкан рухи берлеккә омтылган милләт икәнлекләрен исбатладылар. Елдан-ел аларда Татарстанны тарихи ватаннары, Казанны рухи башкалалары итеп тану хисләре ныгый килде. Алар Татарстан язмышын үз язмышлары итеп саныйлар, мондагы һәрбер үзгәрешкә үз мөнәсәбәтләрен белдерә киләләр. Сөйләшкәндә Татарстан Президентын «безнең Президентыбыз», дип атыйлар. Болар татар халкының гамәлдәге һәм язма рәвештә билгеләнгән идеологиясе барлыгын раслый.

Бүген нәкъ шушы идеология нигезендә бердәмлегебезне тәэмин итү, милли горурлык хисләрен хәрәкәткә китерү зарури. «Эт өрә торыр, бүре йөри торыр», дигән халкыбыз. Шулай булган һәм шулай булыр да.

Бүген дә нинди дә булса төшенкелекләргә урын булмасын иде. Бүленәбез, юкка чыгабыз, дигән фикерне халык бүген дә кабул итмәс. Бетәбез, үләбез, дигән коткыга да урын табылмас! Татар халкы бөек, даһи һәм күркәм ул. Ул үлә һәм бетә торган халык түгел.

Чыннан да, әгәр дә халык мәнфәгатьләрен кайгыртабыз дибез икән, аның үз-үзен хис итүенә игътибар бирергә тиешбез. Ул бүген төшенкелектәме, әллә татарлыгы белән горуланып яшиме? Нижгар өлкәсенең Сергач районында яшәүче колхозчы Әхмәт Баюсов «Без татар милләтеннән, Мөхәммәт өммәтеннән, и Ходаем ташлый күрмә безне киң рәхмәтеңнән», дип үз милләте белән горурлана. Ул:

Татар юкка чыга, диген
Ялган сүзләр тарала.
Татар туа, татар үсә,
Татар тагын ярала»,—

дип яза һәм «татар юкка чыга диген сүзләр наданнар сүзе» һәм «юкка чыгучылары да бер генә булыр меңнән» *(Без Тукай токымыннан. «Туган як» нәшрияты.—Сергач.—2001.—15 б.)* дип өстәп куя. Бу шигъри юллар Сергачта чыккан җирле шагыйрьләрнең әсәрләр җыентыгыннан китерелде. Җыентыкта шигырьләре тупланган уналты авторның барысы да татарга дан җырлый, үзләренең Тукай токымыннан булулары белән горурлана. Зур Рбишча авылында яшәүче укытучы Нуриям Закирова: «Тырышучылар булды Тукай телен эзсез югалтырга мәңгегә. Сакладым мин аны күз алмамдай, тел тидермәм гомер гомергә»,—дип яза. Аңа кушылгандай, Сара Таһирова «Гасырларда яңгырар», «И туган тел»... Бу бәхет бирелгән күпләргә»,—дип Тукай теленә дан җырлый.

Халкыбыз татарны таркатырга тырышучыларга да лаеклы җавап бирә:

Кайберәүләр сине күптән тели
Таркатырга дүрт-биш кисәккә.
Колак салма, ялгыш ул сүзләргә,
Буш киңәшне алма исәпкә!
Бүлгәләнмә мишәр, типтәргә син,
Болгар дип тә әйтмә үзеңә...
Аерылганны аю ашар, диләр,
Сөендермә бүленеп бүресен!
Безне туплап мәңгелеккә илтсен,
Татар дигән гомум бер исем!

Бу сүзләрне Сембер мишәре Рифкать Хисмәт язган *(Рифкать Хисмәт. Үз сукмагым.—Ульяновск.—2000.—6-7 б.)*. Шушы шигырьне ул шушы елның 23 апрель көнне Ульяновск өлкәсе татарларының милли-мәдәни автономия конференциясендә укыды. Һәм аның татарга дан җырлаган сүзләре залдагы йөзләгән кешенең алкышлары белән капланды. «Без татарлар, тик татарлар гына, һәм халык санын алу вакытында, тик шулай гына язылачакбыз», диде җыелган халык.

20—22 майда Нижгарда, Красноктябрьск, Сергач һәм тагын берничә район мишәрләре белән булган очрашулар вакытында да шул ук фикерләр яңгырады. Мишәрләр татар булып яралганнар һәм шулай булып калачаклар да, диде алар.

Татар халкы үзенең тарихында бик күп фаҗигаләр кичерде. Аны аттылар да, суйдылар да. Утка да салдылар, суга да ташладылар. Ә ул янмады да, батмады да. Шик юк, ул бүгенге сынауларны да лаеклы үтәр. Бу сынаулар аны чыныктырачак кына. Чөнки аның тамырлары тирән, мәңгелеккә тоташкан.



**Флюра Зыятдинова**

# РОССИЯ ФЕДЕРАЛИЗМЫНЫҢ ЯҢА МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ

РОССИЯ—күпмилләтле ил-дәүләт. Хәзерге Россия Федерациясе киңлекләре бик күп халыкларның—шул исәптән, татарлар һәм башкортларның, чувашлар һәм мариларның, хаккас һәм тувалыларның, чиркәс һәм карачайлыларның—кыскасы, алтмыштан артык милләтнең тарихи ватаннарын «йоткан». Бу милләтләр вә халыклар барысы да Россиянең теге яки бу җирләрен хәзер дә үз ата-бабалары җирләре—изге ватаны итеп саный.

Шул нисбәттән, татар милләтенең дә мең елдан артык дәүләтчелеге булганлыгы белән санлашмау һәм сәяси, һәм кешелеклелек ягыннан зур әхлаксызлык булыр иде. Россиядә яшәүче күпсанлы халыкларның милли хисләрен таптап узу, аларга игътибар итмәү илне тиз көннән таркалу юлына китерергә бик мөмкин. Соңгы елларның ачы тәҗрибәсе шуны искәртә: эреме-вакмы—башка халыклар да, рус халкы шикелле үк, үз милли горурлыгын бик үткен тоя һәм аны кискен рәвештә яклап калырга әзер тора.

Илнең күпмилләтлелеге аның дәүләт төзелешендә ачык чагыла һәм федеративлык принцибы 1993 елның декабрендә кабул ителгән Конституциядәге беренче маддәдә әйтеп үтелгән. РФ Хөкүмәте каршындагы Законнар эшләү һәм чагыштырма хокук белеме институты Конституциягә Аңлатма әзерләгән, анда «Россия кебек күпмилләтле дәүләттә дәүләт төзелешенең федератив формасы бигрәк тә аклана, чөнки федерация Россиядәге күпмилләтле халыкларның гомуми-уртак мәнфәгатьләрен һәр милләт һәм халыклар мәнфәгате белән табигый рәвештә яраклаштырып алып барырга мөмкинлек бирә» диелгән. *(Конституция. 1994 елгы Аңлатма.)*

Конституциягә икенче Аңлатмада «Россиядә яшәүче халыкларның тарихи һәм милли-мәдәни күптөрле үзенчәлеген искә алганда, нәкъ менә эзлекле федерализм—Россия Федерациясенең һәм аның субъектларының төп мәнфәгатьләрен сәяси-юридик яктан яраштыручы иң отышлы оптималь форма» диелгән *(Конституция. Топорнин, Батурин һәм Орехов редакциясендәге Аңлатма).*

Федерализм этносәяси каршылык-конфликтларны чишәргә ярдәм итүче иң киң таралган модель-үрнәк булып тора. Классик федератив дәүләтләр—Америка Кушма Штатлары, Канада һәм Швейцария, шулай ук Германия Федератив Республикасы, Австрия һәм Австралия мисалы федератив системаның өстенлекләрен бик ышандырырлык итеп дәлилли.

Федерализмның асыл мәгънәсе аның исемендә үк ачык чагыла. Федерализм төшенчәсе латин сүзе «foedus»тан алынган, ул исә «союз» дигәнне аңлата.

Бу үрнәк модельнең эффектив нәтиҗәлелеге сәбәбен аның тарафдарлары болай аңлата: федерализм сәясәтне гомумдәүләт дәрәҗәсеннән төбәкләр дәрәҗәсенә төшерә һәм этник төркемнәргә җирле автономия бирә, шуның белән ота.

---

Флюра ЗЫЯТДИНОВА— *Россия Федерациясенең Дәүләт Думасы депутаты, Дәүләт Думасында Халыкара эшләр комитеты рәисе урынбасары, социология фәннәре докторы.*

Үзләренең үсешендә һәм оешу чорында күп кенә дәүләтләр федерализация баскычларын үткәннәр. Иҗтимагый тормышны нәкъ менә федерализм принципларында оештыру аларга нык-тотрыклы булырга, дәүләт булып калырга һәм хәзерге шартларда лаеклы рәвештә тыныч-имин яшәргә ярдәм иткән.

Америка Кушма Штатлары, бер федератив союзга берләшкәнче, 1784 елның 4 мартына кадәр унбер ел буена конфедератив дәүләтләр союзы булып яшәгән, аңа кадәр исә гасыр ярым буе аерым-аерым мөстәкыйль Британия колонияләре булган. Киңәя-киңәя, Америка Кушма Штатлары үзләренә башка хокукый традицияләре булган төбәкләрне дә—испан Флоридасын, француз Луизианасын, британ Орегонын, Техастан Калифорниягә кадәр җәелгән мексикан провинцияләрен, рус Аляскасын, бәйсез Гавайяны да алганнар. Боларның һәркайсысы Америка федерализмына үз өлешен керткән, әмма ышанып әйтергә була, нәкъ менә 1776 елда Филадельфиядәге конгресста Бәйсезлек Декларациясе белән бер үк вакытта унөч Британ колониясе игълан иткән хәрби союз Америка федерализмына нигез салган, аның һәр штатында үз законнары, үз суд системасы гамәлдә калган.

Германия Федератив Республикасы җирләре-төбәкләре дә элекке бәйсез герман дәүләтләренең күп кенә сыйфатларын саклап калган. Кайчандыр алар артык ныклы булмаган «Герман милләтенең изге Рим империясе» дигән союзга берләшеп яшәгән, аннары Франция кул астындагы Рейн һәм Австриянең Герман союзына кушылганнар, соңрак инде тотрыклырак Пруссия белән берлектә Герман империясен төзегәннәр. Бавария, Пруссия, Вюртембург, Ганновер, Баден, Гессен, Мекленбург төбәкләре һәм ирекле ганзай шәһәрләре Бремен, Гамбург, Любекларның үзенчәлекле дәүләтчелек традицияләре гасырлар тирәнлегеннән XXI йөзгә кадәр килеп җиткән.

Австрия федерациясе исә турыдан-туры Габсбург империясенең үзидарә ителүче кнәзьлек һәм архиепископияләреннән оешкан.

Швейцария союзы 1315 елдан 1848 елга кадәр суверен кантоннар конфедерациясе булып торган.

Һиндстан субконтиненты 1947 елның 15 августына кадәр, ягъни Һиндстанның бәйсезлеге турындагы Закон көченә кергәнче, бердәм дәүләт була алмаган. Башта күпсанлы җирле дәүләтләр, аннары Британия кул астындагы кнәзлекләр һинд дәүләтчелекләренең катлаулы күпчелеген тәшкил иткәннәр. Шулар инде законлы рәвештә Һиндстан союзы булып берләшкән.

Күрәсез, Россия кебек күпмилләтле дәүләтләр өчен дәүләт төзелешенең иң камил принцибы булып федерализм калган. Федерализм автоном берәмлекләрнең уртак максатларына ирешү өчен кирәкле гомуми оешмаларга тиешле хакимлек һәм вәкаләтләр бирелү хаҗәте туган иҗтимагый тормышның һәр өлкәсендә кулланыш таба.

Россия хәзер демократик үзгәрешләр чорында оешып тернәкләнгән федерализм моделенең яңа сыйфатка әверелә баруын кичерә. Соңгы вакытта тормышка ашырыла торган трансформациянең характерлы үзенчәлекләре дәүләт төзелешендәге реформалар белән билгеләнә. Бер яктан караганда, бу административ реформалар Россия Федерациясен идарә итүнең кризисын бетерүгә булышты. Россиянең беренче Президенты Ельцинның сәламәтлеге какшавы һәм Дәүләт Думасы белән туктаусыз тарткалашып торуы аркасында Федераль Үзәктә килеп туган «паралич»тан ил, ниһаять, котылды.

Хәзер инде Федераль Үзәк Конституция буенча тигез хокуклы һәм сәяси процесста катнашучы барлык субъектларга да югарыдан басым ясау механизмы—«башкарма вертикаль» дигән нәрсәне булдырырга омтыла.

Дәүләт төзелеше өлкәсендәге барлык үзгәрешләрдә Федерация субъектларының мөстәкыйльлелеген йомшартуга юнәлтелгән караш чагыла, бу, аерым алганда, Федерация Советын формалаштыру тәртибен үзгәртү белән дә раслана.

Россия федерализмының яңа структур кысалары Федераль Үзәкне Федерация субъектларына карата мөнәсәбәтендә артык зур вәкаләтләр белән тәэмин итә һәм төбәк вәкиллекләре принцибын чикли. Шулай итеп, бүгенге чынбарлыкка таянып әйтсәк, Россия дәүләтчелегенең тенденцияләре унитаризм режимына таба баруын күрсәтә.

Федераль Үзәк белән Федерация субъектлары арасында салым керемнәре

өлешен билгеләү дә шул юнәлештә карап үзгәртелде. Ельцин вакытында ул 50гә 50% булган булса, хәзер исә Үзәк файдасына—56,6%, ә региональ бюджетларга 43,4% итеп кенә калдырылды. Башта ул әле бөтенләй 70кә 30% итеп бүленергә билгеләнгән иде, әмма, Россия Федерациясенең салым кодексындагы 2 бүлекне кабул иткәннән соң, ул хәзерге күләмнән 40 % ким калдырылды. Табигый ки, Россия Федерациясенең төп финанс документларындагы бүленешнең мондый төс алуы үзбаш донор булган Мәскәү, Санкт-Петербург, Свердловск һәм Самара өлкәләрен, Татарстан һәм Башкортстан кебек республикаларны сәяси яктан йомшартты. Бу омтылыш-теләк РФ хөкүмәтенең 2001 елга расланган өстәмә керемнәр бюджетын тышкы бурычларны каплау файдасына янадан бүлү турында Дәүләт Думасына закон проекты кертүеннән соң тагын да ачыклана төште.

Реформаларны мондый юнәлештә алып барырга тырышу Россия дәүләтчелегенең федератив юлдан үсеше мөмкинлегенә билгеле бер дәрәҗәдә шик белән карарга мәҗбүр итә.

Хәзерге вакытта артык үзәкләштерергә омтылыш көчәйгәннән-көчәя бара. СССР заманнарында теге яки бу урамга яңа исем бирү өчен рөхсәт сорап та Мәскәүгә йөргән чакларыбызның ачы тәҗрибәсе онытыла.

Сәясәтчеләрнең билгеле бер өлеше, шул исәптән кайбер төбәк җитәкчеләре дә Федерация субъектлары хакимият башлыкларын Үзәк тарафыннан билгеләү тәртибен яңадан торгызу ягына авышалар. («Иҗтимагый фикер» Фондының 2000 ел июлендә үткәргән сорашуы нәтиҗәләре шуны күрсәтә: 36% сәясәтчеләр шул тәртипне яклый, 60%ы әлегә каршы килә. Хәвефле саннар болар...).

Мондый киләчәкнең ким дигәндә ике генә тискәре ягын искәртеп үтик:

1. Россия киңлекләренең гаять зур булуы һәм җирле шартларның күптөрлелеге аркасында, хәтта XIX гасыр азагында да Үзәктән идарә итү бик авыр булган. Илнең һәр почмагында кичектергесез мәсьәләләрне чишү һәм килеп туган каршылыкларны хәл итү сәләтенә ия булган җирле башлыкларга хаҗәт туган. Хәзерге чорда исә, төрле этнос һәм конфессияләргә караган миллионнарча россияннарның социаль, мәдәни, икътисади ихтыяҗлары төрлечә булганлыктан, аларның ихтыяҗ һәм таләпләренә Үзәктән торып кына тиз һәм нәтиҗәле җавап биреп бетерү, алар белән идарә итү булмастай эш икәне һәркемгә ачык.

Кызганыч ки, нәкъ менә яхшылап уйланылган милли сәясәт булмау сәбәпле, СССР һәм Югославия, Чехословакия кебек күпмилләтле дәүләтләр бик тиз таркалды да. Моны аңлау хәзер бигрәк тә мөһим. Россия дәүләтен федералистик принципларда төзү нигезләрен тарайту уңай нәтиҗәләр бирмәс, киресенчә, этно-милли каршылыкларны тирәнәйтер генә. Үзәкнең төбәкләр эшенә акылсыз тыкшынуының ачык мисалы Дәүләт Думасы депутатларының бер өлеше татар язуын латин имласына күчертүне тыярга тырышуында да күренә. Юкса, ул гамәл Россия Федерациясе Конституциясе буенча да, халыкара хокук нормалары буенча да Татарстан Республикасының фәкать эчке үз эше генә бит.

Кирәкмәгән артык вәкаләтләрне федераль дәрәҗәгә күтәреп, аларны президент һәм аның администрациясенә туплау илнең сәяси һәм социаль-икътисади үсеше өчен уңай нәтиҗәләр бирмәгән кебек, күптән түгел генә кайбер төбәк башлыкларының «юрганны үзләренәрәк тартырга» тырышулары да шулай ук кирәксез гамәлдер. Хәзерге Конституция нигезендә Үзәк болай да гаять зур административ мөмкинлекләргә һәм өстәмә вәкаләтләргә ия, аны тагын да көчәйтеп торасы юк, Россиянең сәяси культурасы җитәрлек дәрәҗәдә югары.

Дәүләт системасында «тыеп тору һәм каршылык күрсәтү» механизмнары реаль булмаса, «башкарма вертикальне» үзгәртү мөмкинлеге чынлыкта бернәрсә белән дә чикләнмәгән булачак.

Соңгы вакыттагы тикшеренүләрдә Россия федерализмына төп куркыныч һәрнәрсәне колачлап алган үзәкләштерүгә омтылыш булачак дип күрсәтелә. Америка эшмәкәрлек институты галиме Л. Арон Россиядә җиде федераль округ төзүнең «Россиядәге реаль федерализмга, шулай ук демократиягә куркыныч янау булачагын, ахыр чиктә ил-дәүләт бөтенлегенә зыян китерәчәген» әйтә. «Андый законнардан баш тартырга яки аларны бөтенләй үзгәртергә кирәк»,—ди ул. *(The wall street journal, 2000.)*

Россия Конституциясендә игълан ителгән федерализм бары тик социаль юнәлешле икътисады һәм рухи үсеше югары булган гражданнар җәмгыятенең чын-чынлап демократик нигезләрен баянган вакытта гына коры сүз булып кына

калмаячак. Бүген федерализм төшенчәсенең классик мәгънәсен һич онытырга ярамый, федерализм—ул билгеле бер сәяси-хокукый мөстәкыйльлекләрдән файдаланучы территориаль берәмлекләрнең берләшүе. Федерация субъектларының мөстәкыйльлек дәрәҗәсе РФ Конституциясе һәм Союз Договоры белән билгеләнгән, шулай итеп, федерализм—союзлар дәүләте дигәнне аңлата. Кызганыч ки, соңгы вакытта Россиянең сәяси үсеш тенденцияләре федерализм принципларының бик нык юыла барганын, моның бик җитди социаль-сәяси нәтиҗәләргә китерү мөмкинлеге барлыгын искәртә.

Миңа, милли республикадан сайланган депутат буларак, дәүләтнең һәрьяклап уйланган-үлчәнелгән нәтиҗәле милли сәясәтен эшләү өчен Россия Федерациясе Президенты каршында милли сәясәтнең Координацион Советын төзү кирәктер шикелле тоела. Ул Совет рекомендация-киңәшләр эшләп бирер һәм федераль министрлыкларның милләтара мөнәсәбәтләргә кагылган эшчәнлекләрен үзара килештереп-яраштырып торыр иде. Милли сәясәтнең нәтиҗәлелеге юнәлешендәге икенче җитди адым РФ Федераль собраниесының югары палатасын милли билгеләргә карап оештыру, ягъни Милләтләр Палатасы төзү булыр иде. Ул федерациябезнең күпмилләтле асылын чагылдырыр иде.

Тотрыклы милли вәзгыять мисалы итеп үзебезнең Татарстан Республикасының тәҗрибәсен күрсәтәсем килә. Республикада хәзер 3,8 миллион халык яши. Шуның яртысыннан артыгы—татарлар. 40 проценттан күбрәге—руслар. Калган өлешен йөздән артык милләт вәкилләре тәшкил итә. Татарстанны тикмәгә генә «дуслык җире» дип атамыйлар, аның иң зур казанышы—милләтара килешеп, диннәрнең аралашып яшәвендә.

«Россия дәүләт хакимияте органнары белән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында вәкаләтләрне үзара уртаклашу һәм эшгамәлләрнең чикләрен билгеләү турында» Шартнамә, бик күп сәясәтчеләрнең тануынча, яңа демократик федерация төзү юлында бик әһәмиятле маяк булды, реформаларны төбәкләрнең үзенчәлекләрен искә алып үткәрү өчен шартлар тудырды.

Соңгы ун елның төп йомгагы Татарстанның икътисад өлкәсендә җитештерү җегәрен саклап калу һәм башка барлык тармаклар белән дә нәтиҗәле идарә итү булды. 1995 елның икенче яртысыннан башлап сәнәгатьтә үсеш күзәтелә, нәтиҗәдә Татарстан Россия Федерациясе субъектлары арасында унөченче урыннан дүртенче урынга күтәрелде.

«Татнефть» «кара алтын» чыгаруны тотрыклы рәвештә ел саен арттыра бара. Түбән Кама һәм Казандагы нефтехимия гигантлары продукция эшләп чыгару (шул исәптән экспорт өчен дә) темпларын ышанычлы тизләтеп киләләр. Яңа типтагы автомобильләр, самолетлар, корабльләр, компрессор һәм вакуум техникасы, нефть һәм электротехника өчен кирәкле җиһазлар, төрле приборлар эшләүче предприятиеләр аякка басты.

Республиканың азык-төлек кәрзине бәясе үзендә җитештерелгән азык-төлек хисабына илдә иң түбәннәрнең берсе булып кала бирә. Авыл хуҗалыгы продукциясенең тулаем күләме буенча Татарстан Россиядә Краснодар краеннан кала икенче урында тора.

Ун ел эчендә республикада бер генә югары уку йорты, бер генә театр яки музей дә ябылмады. Киресенчә, аларның саны арта гына бара.

Татарстан—Көнчыгыш һәм Көнбатыш цивилизацияләре тоташкан төбәк, аның мәдәни байлыгының күптөрлелеген шул билгели. Республиканың милли-мәдәни тормышы әле беркайчан да бу кадәр төрле һәм төсмер-буяуларга бай була алмагандыр. Әйе, географик мәйданы, табигый байлыклар запасының хәтсез булуы, сәнгатьнең күп төрләре, алга киткән авыл хуҗалыгы Россия Федерациясе икътисадында Татарстанның урынын билгели.

Республиканың Дәүләт Советына ел саен укыла торган Мөрәҗәгатьләренең берсендә Татарстан Республикасы Президенты Минтимер Шәймиев, аерым ассызыклап, Татарстан тиз үзгәреп тора торган дөньяның бер өлеше, дип әйтеп узды. Җир шарында бара торган зур, глобаль үзгәрешләр сәүдә, хезмәт күрсәтү, мәгълүмат алмашу, мәдәниятләр үсешендәге күп кенә географик һәм сәяси киртәләрне алып ташлады. Бу шартларда республикабыз ул процесслардан читтә кала алмый, тышкы дөнья белән үзара мөнәсәбәтләрнең иң отышлы формаларын табарга тырыша. Чит илләр белән эшчәнлек алып бару Татарстанның икътисади

һәм социаль үсеше стратегиясен тормышка ашыруда нәтиҗәле чара, республиканың социаль-икътисади үсеше һәм дөнья икътисадына әкренләп кушыла-берләшә баруының бик мөһим факторы булып тора. *(Татарстан Республикасы Президентының Дәүләт Советына Мөрәҗәгате. Казан, 2001.)*

Россия Федерациясе белән төзелгән Шартнамә һәм 1994 елда кул куелган килешүләр Татарстанга, тулаем алганда, тышкы элемтәләр булдыру һәм аларны үстерү өчен уңай шартлар тудырды. Узган гасырның туксанынчы еллары ахырына Татарстан үз үсешенең сыйфат ягыннан яңа чорына аяк басты, байтак кына сәяси-хокукый килешүләр һәм шартнамәләр, шулай ук үзгәртеп корулар барышында тупланган тәҗрибәләр нигезендә алга таба житди адым ясарга реаль җирлек туды. Сүз Татарстанның Дәүләт Советы кабул иткән икътисади һәм социаль прогрессы Дәүләт Программасында тупланып чагылыш тапкан икътисади реформаларга аерым караш, аларны дәвам итү һәм тирәнәйтү турында бара.

Бу Программага салынган максатларны тормышка ашыру үзебезнең үзенчәлекле моделебез рәвешендә берләштерелгән идеяне билгели. Республиканың Россия һәм дөнья күләмендә конкуренциягә сәләтле булуына ирешү бурычы куела, ә үрнәк модель сыйфатында социаль юнәлтелгән икътисад моделе тәкъдим ителә. Аны үстерү исә тышкы һәм эчке инвесторларны эзләү һәм җәлеп итүнең акыллы уйланылган сәясәтенә бәйле.

Татарстан инвестицияләр өчен кызыксындырырлык объект. Аның өлешенә Россиянең чит илләрдән ала торган инвестицияләренең җиде проценты туры килә, күләме буенча ул Мәскәү һәм Санкт-Петербургтан кала өченче урын дигән сүз. Татарстанда законнарны камилләштерүгә, тышкы икътисади эшчәнлекнең норматив-хокукый нигезләрен булдыруга зур игътибар бирелә. 1994 елдан гамәлгә кергән «Татарстан Республикасындагы чит ил инвестицияләре турында» Закон, шуңа охшаш федераль законнардан аермалы буларак, халык хуҗалыгы өчен аерым әһәмияткә ия инвестиция проектларының салым һәм гарантия буенча өстәмә ташламалар алу мөмкинлеген искәртә.

Татарстан хөкүмәте инвестицион процессны оештыруны тәэмин итү өчен житди адымнар ясый. Инвестицияләргә ярдәм итү буенча гомуммилли үзәк төзү бу юнәлештәге мөһим адымнарның берсе булды. Ул үзәк бердәм инвестиция сәясәтен булдыра һәм аны тормышка ашыру белән шөгыльләнә, дәүләтнең, финанс һәм финанс булмаган оешмаларның чит ил инвестицияләренә гарантия бирүе өчен хөкүмәт, базар икътисады системасын булдырып, чираттагы бюджетында Татарстан Республикасының финанс йөкләмәләрен тәэмин итүне дә күз алдында тота.

Республиканың халыкара оешмалар—БМО, ЮНЕСКО, Европа Советы, Халыкара валюта фонды, Гарәп дәүләтләре белән элемтәләре ныгый. Хөкүмәткә республиканың вәкиллекләрен булдыру кирәкле башка халыкара оешмаларның исемлеге әзерләнде. Алар—ЮНИДО (Сәнәгать үсешенә ярдәм итү буенча Берләшкән Милләтләр Оешмасы), МИГА (Инвеситицияләрне саклау буенча Дөнья Банкы Оешмасы), ЮНКТАД/ГАТТ, ЕБРР.

Халыкара хезмәттәшлекне киңәйтү максатыннан республика уналты чит илдә үзенең даими сәүдә-икътисад вәкиллекләрен булдырды (Франция, Германия, АКШ, Украина һ. б.)

2000 елда Татарстанның тышкы сәүдә әйләнеше 3,2 миллиард доллар, шул исәптән экспорт 2,8 миллиард доллар тәшкил итте.

Республика көнбатыш һәм көнчыгыш партнерлар белән хезмәттәшлекне тигезрәк сакларга тырыша. Күп кенә предприятиеләрнең технологик яктан шактый артка калган булуы, республика сәнәгатен технологик камилләштерү өчен, Татарстанны алдынгы технологияләр эзләүдә активрак булырга мәҗбүр итә. Шундый эзләнүләрнең уңышлы мисалы итеп Америка компаниясе АВВ һәм АКШның Экспорт-импорт банкы белән халыкара хезмәттәшлекне күрсәтергә була. Алар Татарстанның нефть эшкәртү сәнәгатен модернизацияләргә ярдәм итәләр.

Россиянең тышкы элемтәләрен үзәкләштерүне бетерү һәм бу процесска яңадан-яңа субъектларны һәм чит ил партнерларын тартуы Татарстанда «Тышкы икътисади элемтәләр концепциясе»н эшләү ихтыяҗын тудырды. Без аны эшләдек һәм Министрлар Кабинеты аны 1993 елның декабрендә раслады. *(«Татарстан Республикасының тышкы икътисади эшчәнлеге стратегиясе һәм аны тормышка*

*ашыру механизмы турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 31. 12. 1993 елгы №759 карары).*

Төп стратегик бурыч әлеге документның биш бүлегендә бирелә. Ул тышкы икътисади эшчәнлекне үстерүнең максатлары һәм төп бурычлары, хокукый, мәгълүмат һәм оештыру мәсьәләләрен булдыру, тышкы икътисади эшчәнлек өчен квалификацияле белгечләр әзерләү һәм аларның санын арттыру кебек проблемаларны үз эченә ала. Концепция авторлары, республиканың тышкы икътисади эшчәнлеге өчен хокукый нигезләрне камилләштерми торып, бу максатларга ирешү мөмкин түгел, дигән фикерне ассызыклап үтәләр.

Тышкы элемтәләр өлкәсендәге стратегия көн тәртибенә килешүләр һәм Шартнамәдә каралган йөкләмәләрне нәтиҗәле үтәү мәсьәләсен куя, ул исә халыкара элемтәләрне Россия Федерациясе белән бүлешеп эшләүне, чит ил партнерлары белән хезмәттәшлекне һәр ике яктан да эзлекле рәвештә ныгыта баруны таләп итә. Концепция авторлары бу очракта халыкара килешүләр төзү һәм халыкара оешмалар белән хезмәттәшлек итүне Татарстан Республикасы Конституциясенең 62 нче маддәсендә каралганча һәм Россия Федерациясе белән ике арада төзелгән Шартнамәнең тышкы икътисади элемтәләр өлкәсендәге вәкаләтләрнең чикләрен билгеләү турындагы 3 нче маддәсендә күрсәтелгәнчә алып барырга тәкъдим итәләр.

Татарстанга әле Россия белән федератив мөнәсәбәтләрдә үз урынын табу, Россиядә һәм чит илләрдә килеп туган субъектив һәм объектив каршылыкларны җиңү өчен зур эш башкарырга туры киләчәк. Бу процесс үзенең дәвамлылыгы, компромисска ирешүдәге катлаулылык дәрәҗәсе белән Россия федерализмының ныклап аякка басу чорына тәңгәлләшәчәк. Чөнки, Президентыбыз Минтимер Шәймиев кат-кат искәрткәнчә, Татарстан үзенең киләчәген бары тик Россия белән бәйли.

## Йомгак

Федераль хакимият органнары белән аның субъектлары хакимияте органнары арасында халыкара һәм тышкы икътисади элемтәләр өлкәсендәге эш-гамәлләрнең чикләрен билгеләү һәм аларны белеп башкару мәсьәләсе иң авыр мәсьәлә булып тора. Бары тик һәр ике якның да үзара килешеп эшли алуы гына бу элемтәләрнең уңышлы булуын тәэмин итә ала. Хокукый нигезләрне ныгыту, дөньяның төрле илләрендәге аерым төбәкләр белән үзара тәҗрибә уртаклашу, үзара файдалы икътисад һәм сәүдә элемтәләрен һәр як белән бергәләп көчәйтү, төбәкләрнең бары тик үз хокуклары булган үзара файдалы хезмәттәшлекләренең анык программаларын эшләү—болар һәммәсе дә, һичшиксез, халыкара хезмәттәшлек итүче төбәкләрнең, тигез хокуклы партнерлар буларак, дәрәҗәләрен генә күтәрәчәк.

Россия Федерациясенең агымдагы вәзгыяте федератив системаның киләчәктә дүрт юнәлештә үзгәрергә мөмкинлеген күзалларга ныклы нигез бирә:

1. Федерация субъекты белән Федерация арасындагы мөнәсәбәтләрдә үзәкләштерүне алга таба да киметә бару, «түбәннән—югарыга» принцибына таянып, тышкы икътисади элемтәләрдә субъектларның тулы мөстәкыйльлеге хокукларын тану. Бу очракта Федерация һәр субъект үз мәнфәгатеннән чыгып Үзәккә тапшырган вәкаләтләргә генә ия була ала.
2. Ике арадагы мөнәсәбәтләрне «югарыдан—түбәнгә» принцибыннан чыгып үзәкләштерү, тышкы икътисади элемтәләрдә федераль үзәк вәкаләтләрен көчәйтү һәм субъектларның андый элемтәләрен Үзәкнең ныклы контролендә тоту.
3. Конституциядә, Федератив Шартнамәдә, башка килешүләрдә билгеләнгәнчә, вәкаләтләрне үзара бүлешүнең хәзерге нормаларын саклау, Россия Федерациясе субъектларының тышкы элемтәләр урнаштыру хокукларын анык билгеләп контрольдә тотуны махсус законлаштыру һәм карарлар белән ныгыту.
4. Федерациянең таркалуы һәм яңа конфедератив килешү төзү.

Сәясәтчеләр бу дүрт юнәлешнең һәммәсе турында да көннән-көн

активрак фикер алыша, соңгы—дүртенче юнәлешнең бөтен дөнья икътисады өчен чиктән тыш куркыныч нәтиҗәләр китереп чыгарачагын искәртәләр.

Россия федерализмын ныгыту юлларын эзләү максатында, «Үзәк—субъектлар» мөнәсәбәте үзенең тарихи нәтиҗәлелеген һәм бөтен ил мәнфәгате өчен тотрыклы булуын раслаган чит илләр тәҗрибәсе, һичшиксез, кызыклы булыр.

Россия Федерациясе дә, Федератив Шартнамә дә Россия Федерациясе субъектларының мөстәкыйль тышкы элементләр урнаштыру өчен кирәкле хокукларын һәм мәсьәләләрен тулысынча күрсәтеп бетерә алмый. Алар бары тик агымдагы Законнарны чыгару барышында гына ачыклана ала һәм аны «хәрәкәтчән» дип йөртергә кирәктер. Чөнки ул РФ Конституциясенә генә бәйле түгел, ә Россия Федерациясенең башка Законнарына да бәйле була.

Узган гасырның туксанынчы елларындагы һәм яңа гасыр башындагы соңгы вакыйгалар күптөрлелеге белән аерыла, төбәкләрнең халыкара элемтәләрен ныгыту-үстерү кирәклеген раслап тора.



## «Казан утлары» елъязмасы

**Моннан 65 ел элек (1937)** «Совет әдәбияты» журналында «Матур әдәбиятны дошман калдыкларыннан тазартырга» дигән баш астында Татарстан Совет язучылары Союзы идарәсенең **Хәсән Туфанны** һәм **Фатих Кәримне** Совет язучылары Союзыннан чыгару турындагы карары *(№ 6-7)* басылып чыккан, шул ук саннарда **Латыйф Җәләйнең** «Урта Тигәнәле бәете» мәкаләсе, **Нәби Дәүли, Мифтах Вәдүт** шигырьләре дөнья күргән. Укучыларга **Максуд Сөндекле, Нур Баян** *(№ 8)*; **Сибгат Хәким, Әхмәт Юныс** *(№ 9)*; **Шәйхи Маннур** *(№ 10)*; **Муса Җәлил** *(№ 11)* шигырьләре, **Идрис Туктарның** «Ике егет» романыннан өзек *(№ 10)* тәкъдим ителгән.

**Моннан 60 ел элек (1942)** «Совет әдәбияты» журналында **Хәйретдин Мөҗәй** һәм **Муса Җәлил** шигырьләре *(№ 1-2)*, **Фатих Хөснинең** «Йөзек кашы» *(№ 3)* повесте, **Афзал Шамовның** «Буранлы төндә» *(№ 4)* хикәясе, **Фатих Кәримнең** «Идел егете» *(№ 6)* поэмасы, **Габдрахман Әпсәләмовның** Карелия фронтыннан репортажы *(№ 7)*, **Шәйхи Маннурның** фронт шигырьләре *(№ 7)*, кырым татар совет шагыйре **Кәрим Җаманаклы** шигырьләре *(№ 8)*, **Латыйф Җәләйнең** «Ватан сугышы чорында татар совет әдәбияты» дип исемләнгән мәкаләсе *(№ 9-10)* дөнья күргән.

**Моннан 55 ел элек (1947)** «Совет әдәбияты» журналында **Гариф Гобәйнең** «Замана балалары» *(№ 5-6)* повесте, **Ләбибә Ихсанованың** «Көмеш елга» *(№ 12)*, **Габдрахман Әпсәләмовның** «Ак төннәр» *(№ 1—3)*, «Яшерен минутлар» *(№ 11)* повестьлары, **Мирсәй Әмирнең** «Тормыш җыры» пьесасы, **Низами Гәнҗәвинең** Нәкый Исәнбәт тәрҗемәсендә «Хөсрәү вә Ширин» *(№ 9)* поэмасы, **Сибгат Хәкимнең** «Фазыл чишмәсе» *(№ 5)*, «Вәгъдә», «Уракчы кыз» *(№ 8)* шигырьләре дөнья күргән.



## Фирдәүс Гарипова

# САН АЛУДАГЫ СЫРТ САНАУ

### Көпә–көндез талау

СОНГЫ ВАКЫТЛАРДА Рәсәйдә халык санын алу тирәсендә барган вәзгыятьнең максаты: сибелергә мәҗбүр ителгән татарны тагын да бүлгәләү, ваклау, санын азайту һәм, ахыр чиктә, эретеп йоту, ягъни ассимиляцияләү. Чөнки аз санлы, таркалган халыкны бетерү җиңелрәк. Янә килеп, Урта Идел буйларындагы көчле республиканы төрле юллар белән какшату һәм якын киләчәктә аны губернага әйләндерү. Татарларның саны республикадагы башка милләтләр саныннан аз булса, бу ихтималның тормышка ашуы бик мөмкин, Ходай сакласын. Халык әйтсә хак әйтә: «Аерылганны аю ашар, бүленгәнне бүре ашар». Бу гыйбарә юкка гына барлыкка килмәгән. Алар халыкның тормыш тәҗрибәсенә, күзәтүенә таянып туганнар. Оста уйланган бу сәясәт бер кан һәм бер җан булып яшәгән бербөтен гәүдәне тугыз кисәккә бүлү белән бер инде. Утырып уйлар уйласаң, әрнүдән йөрәгең шартлар: татар тарихыннан көчләп югалттырылган зиннәтле рухи һ. б. кыйммәтләрне нинди үлчәүләргә салырга һәм нинди юллар белән, ничек үлчәп бетерергә? Киләчәктә моның өчен җавап тотучылар булырмы? Яисә Аллаһы Тәгаләнең сабырлыгы төкәнеп, бөтен империяне берәр афәт, зилзилә селкетерме?

Борынгы заманнардан ук дәүләт төзү күнекмәләренә ия булган татарның дәүләте явызларча җимертелде. Шуннан соң аның денен җаныннан суырып алу кебек коточкыч вәзгыять—чукындыру калкып чыкты. Туган туфракны, туган җирне ташлап төрле урыннарга тузгып утыру, кагылу-сугылу һәм кангыру, аны йола-кануннарсыз, гореф-гадәтләрсез, телсез һәм моңсыз калдыруга корылган сәясәт—болар барысы да татар башына төшкән авыр афәтләр. Соңгы максат итеп татарны бетерүгә корылган мондый вәзгыятьтә дәүләтсез халыкның 500 елга якын изелү һәм коллык хәлендә яшәп, әле дә исән калуы—феноменаль күренеш. Исән калуның нигезендә милләтебезнең аеклыгы, тамырлары, традициясе, йола-кануннары, гореф-гадәтләре, теле, дине һәм моңының бик нык һәм борынгы булуы ята. Әдәбияты, теле, мәдәнияте, әхлагы һәм дәүләт төзү күнекмәләре югары үскән милләт буларак, татар халкы дөньяның төрле кыйтгаларындагы мөстәкыйль дәүләтләр белән бер яссылыкта торып, дустанә яши белер һәм кирәк икән ярыша да алыр иде. Аның һәр гамәлгә карата үз фикерен, үз уен әйтерлек гыйлем һәм тәҗрибә туплаган, житлеккән дәүләт эшлеклеләре, галимнәре, зыялылары, эшмәкәрләре (әгәр аларга юл бирелсә) h. б. бар. Җир өсте һәм җир асты байлыклары мул, ләкин үз дәүләте, мөстәкыйльлеге булмау аркасында ул куләгәдә кала килә, үз сүзен кистереп әйтерлек хокукы юк. Әйе, чал гасырлар белән үлчәнә торган мондый кыйммәтләргә ия халыкның, күзгә төшкән ак кебек, кемгәдер һәм нәрсәгәдер комачаулавын күрү һәм чамалау авыр түгел.

---

Фирдәүс ГАРИПОВА—*Филология фәннәре докторы, профессор. Ике дистәдән артык гыйльми китаплар авторы («Татарстан гидронимнары сүзлеге», ике томда; «Татар гидронимикасы», «Инешләрдән иңгән моңнар» h.б.). Казанда яши.*

Шуна да һаман таланды һәм талануын дәвам итә. Соңгы утыз ел эчендәге талауның өстәмә тагын бер котсыз формасын ут күршеләребез башкорт «туганнарыбыз»дан күрәбез. Аның артында Мәскәү тора. Милләтебезнең намусы һәм горурлыгы Габдулла Тукай «... тотса Мәскәүләр якан...» дип юкка гына язмаган. Мәскәү канаты астында икәнлекләрен белгән кайбер башкорт экстремистлары чаманы бөтенләй югалттылар. Татарлыклары каннарында, җаннарында, рухларында, иманнарында һәм геннарында булган, Башкортстанда көн итеп ятучы ике миллион татарны башкорт итеп яздыруга интенсив әзерлек бара. Татар һәм башкорт тарихын, телен фальсификацияләп язган хезмәтләр нигезендә Башкортстандагы татар халкын башкорт дип яздырып, бераздан аларга башкорт телен, мәдәниятен көчләп тагу нинди нәтиҗәләргә китерер, бу вәзгыять нигезендә нинди милләт ясап булыр икән? Уйлар, уйлар... Әгәр бу кыямәт тормышка ашса, андагы татарларның киләчәк буыны гасырлар буена ата-бабадан кадерле мирас итеп алган телен ярты-йорты беләчәк һәм ахыр чиктә телсез калачак һәм милләтебезнең бай әдәби һәм мәдәни хәзинәсен өйрәнүдән мәхрүм булачак. Моны геноцид дип әйтмичә ни диярсең һәм гөнаһын кая куярсың? Башкорт экстремистларының татарга каршы юнәлтелгән бу авыр һәм кара казалары, татар башына төшкән башка казалар кебек үк, Галиҗәнап тарих тарафыннан беркетелеп барачак. Башкортның кайбер галимнәре тырыша-тырмаша татарга чокыр казый. «Кешегә чокыр казыма, үзең төшәрсең» дигән хакыйкать онытылмасын иде. Шуны һәрдаим истә тотарга кирәк, татарны бүлгәләү һәм Башкортстанда аны башкорт дип яздыру максаты тормышка ашса, тиз көннән башкорт та бүлгәләнәчәк. Нинди төркемнәргә бүлеп буласын Мәскәүдә әллә кайчан һәм Уфада да бик әйбәт беләләр. Андый гамәлләр берәм-берәм, чиратлап башкарылалар. Юкка гына халык телендә: «Бүлгәлә дә хакимлек ит» дигән мәкаль яшәми. Хәзерге мондый гыйбрәтләр күз алдыбызда, ә элгәреләре—тузан белән капланган борынгы чыганакларда...

Башкортстанда үз көчләре белән дөнья көтә торган гади халык: татарлар, башкортлар, руслар, чувашлар, мари, мордвалар һ. б. бергә яши башлаганнан бирле гомер бакый дустанә көн итәләр. Үзләренең иманнары һәм кыйблалары кая караганлыгын алар бик әйбәт беләләр. Ясалма рәвештә тудырылган бу мәрәкәдә гади халыкның бер катнашы да юк.

Бай табигатьле, Аллаһы Тәгалә тарафыннан бирелгән җир өсте һәм җир асты байлыклары күп булган Идел-Урал төбәгендә көн иткән татар, башкортлар кулга-кул тотынышып бассалар, Рәсәйнең үзәк өлешендә корычтай нык Берләшмә барлыкка килер иде һәм федераль империализмның моның белән исәпләшмичә чарасы калмас иде. Әмма... Шушы җәһәттән борынгы чорларда булып үткән күп гыйбрәтле вакыйгаларның берсен искә алып китү урынлы булыр.

Тарихтан билгеле булганча, Византия империясе чикләрендә күп сандагы төрки кавем-кабиләләр: бәҗәнәкләр, угызлар, команнар һ. б. яшәгәннәр. Византия императорлары үз тәхетләре янында тирә-юньнәрендәге төрки кабилә-кавемнәрнең телләрен яхшы белә торган, интригаларга оста, махсус хәзерләнгән агент-дипломатлар тотканнар. Алар төркиләр арасына кереп, астыртын гына төрки кавемнәрне бер-берсенә каршы котыртканнар. Нәтиҗәдә бер кабилә икенче кабиләне кырып бетерә торган булган (дошманнарыбыз безне берәм-берәм бетерергә уйлыйлар дип нәтиҗә ясый белмәгәч, ник кырмасыннар да, ник асып-кисмәсеннәр, ник бетермәсеннәр?). Ә исән калганнарын бераз вакыттан соң, Византия империясе гаскәре килеп, кырып салган. Әтисенең батырлыклары турында күп язган Византия императоры Алексей Комнин кызы принцесса Анна Комнина төрки кавем-кабиләләр, аларның тормыш-көнкүрешләре, йола-кануннары, гореф-гадәтләре, Византия империясе белән мөнәсәбәтләре, сугышлары, төркиләрнең бер-берсен юкка чыгарулары турында да күп мәгълүматлар калдырган[1]. Анна Комнина укымышлы, һәр әйбер һәм вакыйгалар белән кызыксынучан, күп язган, күп белгән шәхес булган. Ул калдырган хезмәтләрдә кызыклы һәм гыйбрәтле хәлләр, вакыйгалар бик күп. Мондый типтагы хезмәтләрне

---

[1]Комнина Анна. Сокровенное сказание о делах царя Алексея Комнина (1081—1118). Под ред. проф. Карпова.—Спб., 1859, ч. I

уку һәркемгә үз гадел кыйбланны сайлау һәм яшәү өчен күп тәҗрибә бирә. Башкортның кайбер галимнәренә шушындый типтагы хезмәтләрне укып гыйбрәтле сабак алырга иде дә бит...

Татар халкы тарихын өйрәнү барышында башкорт тарихы да татар галимнәренең һәрдаим игътибар үзәгендә булды. Бу өлкәгә караган проблемалар күренекле тарихчылар М. Г. Госманов, М. И. Әхмәтҗанов, Р. Г. Фәхретдинов, Д. М. Исхаков һ. б. хезмәтләрендә күтәрелде. Алар һәм башка галимнәр хезмәтләрен тарихи чыганакларга нигезләнеп төпле һәм объектив итеп яздылар. Кайбер башкорт галимнәренең татар проблемасын ясалма кабартулары, ана экстремистик рухта якын килүләре, татар тарихын, телен фальсификацияләгән хезмәтләр язулары, татар галимнәре алдына башкорт тарихын тагын да тирәнтен, борынгы тарихи чыганакларны күтәреп, тел факторын катнаштырып, системалылык белән һәм комплекслы итеп язуны өр-яңадан көн тәртибенә куйды. Чыганаклар— тарих шаһитлары, алар тарихи чынбарлыкны объектив чагылдыралар һәм аларга каршы бару мөмкин түгел. Көн кадагына суга торган җавап рәвешендә, фәнни объективлык рухында, борынгы карталарны, бик борынгы тарихи чыганакларны нигез итеп алган хезмәтләр бер-бер артлы басылып чыга торалар. Шундый яссылыкта дөнья күргән хезмәтләр рәтенә Марсель Әхмәтҗановның 2001 елда «Мәгариф» нәшриятында басылган «Меңьеллык татар нәселе»[1] дип аталган китабын китерергә мөмкин. Китабының беренче бүлегендә автор башкортларның килеп чыгышларын, кемнәр булуларын, яшәгән урыннарын, алар турында урта гасыр чыганакларында сакланган хәбәрләрне бер ноктага җыеп бирә. Бу бүлекчәгә җыелган документаль фактлар кайбер башкорт галимнәренең тешенә тияр тиюен. Әмма документаль булгач берни дә эшли алмыйсың. Документ ул ташка сугылган мөһер.

Урта гасырларда сызылган карталарны алга куеп, тәфсилләп тикшереп, мондагы мәгълүматларның шул ук гасырларда дөнья күргән тарихи чыганакларда урнаштырылган фәнни материаллар белән туры килүе нигезендә Марсель Әхмәтҗанов түбәндәге фикерләрне әйтә.

Иң борынгы карталардан саналган Мәхмүт Кашгари хезмәтендә башкортлар яшәгән җирләр Иртыш елгасы буйларында күрсәтелә. Бу урында хәзер Себер татарлары яши. Аларны күршедәге казакъ халкы иштәк дип атый. Себер татарларының күршеләре булган башкортларны да казакълар иштәк дип йөртәләр. Иртыш буйларында, татарларга күрше булып, угыр кавеменең ханты-манси халкы да көн итә. Аларны урыслар әүвәлдә остяк дип атаганнар.

Гарәп географы Идриси тарафыннан 1154 елны сызылган дөнья картасында башкорт кабиләсе урнашкан җирләр Кама елгасының югары агымы ярларында итеп күрсәтелә.

Итальян картографлары бертуган Пициганилар тарафыннан 1367 елда эшләнгән картада Каманың башланган урынында пасхерти (башкортлар) кабиләсе яшәве күрсәтелә. Шул ук информация 1375 елда сызылган «Каталон атласы»нда да кабатлана.

XVI—XVII гасырларда сызылган карталарда: (Баттиста Агнезе (1525 ел), Сигизмунд Герберштейн (1556 ел), Антоний Джекинсон (1565 ел), Гессель Геритс (1613 ел), Адам Олеарий (1647 ел) һ. б. бүгенге Башкортстан Республикасы җирләрендә татарларның Нугай Урдасы дәүләте булганлыгы күрсәтелә.

Беренче урыс картографларыннан Петр Годунов (1667) һәм Семен Ремезов эшләгән сызымнарда башкорт кабиләсе яшәгән урыннар итеп Урал һәм Агыйдел елгалары башланган регион күрсәтелә. Бу регион бүгенге көндә Чиләбе төбәгенә карый.

Йомгаклап әйткәндә,—дип яза М. Әхмәтҗанов, карталарда башкорт-иштәкләрнең XI гасырда—Себердә, XII гасырда Төньяк Уралда яшәүләрен, XIV йөз тарихи чыганакларында да шул ук регионда калуларын раслаучы фактлар бәхәсләргә урын калдырмаслык итеп теркәлгән.

Борынгы башкортларның этник яктан кемлеге проблемасы тарихи язма

[1]Әхмәтҗанов Марсель. Меңьеллык татар нәселе. Татар шәҗәрәләре һәм этник тарихыбызга бер караш.—Казан, 2001.

чыганакларда шактый ачыклана,—дип яза Марсель Әхмәтҗанов һәм түбәндәгечә йомгак ясый:

1. Иң борынгы башкортлар Иртыш елгасы тамагында, Җаек (Урал) елгасы югары өлешенең унъяк ярында, Кама елгасының югары өлешендә урнашкан булганнар.

2. Бу башкортлар барысы да угыр телләре диалектларында сөйләшкәннәр. Алар, XVI гасыр башларында татар дәүләтләре кул астына эләгеп, Себер, Казан ханлыкларында һәм Нугай Урдасы составында татарлашып беткәннәр.

Пермь якларындагы угыр-башкортлар Казан шивәсен үзләштергәннәр; Чиләбе һәм Урал буендагылар Нугай Урдасы татарлары тел үзенчәлекләрендә татарлашканнар, Себердәге Иртыш буе угырлары нугай-кыпчак сөйләшләрен үзләренә алган.

3. Себер угырлары татарлашсалар да, күршеләре аларны, борынгыча, иштәк дип атауны дәвам иткәннәр.

Көньяк Уралдагы татарлашкан угырларны да күршеләре (аеруча казакълар) иштәкләр дип атаганнар.

Пермь ягындагы угырларны да нугай татарлары иштәкләр дип йөрткән. «Иштәк» кушаматы Нугай Урдасы татарлары һәм казакълар тырышлыгы белән үзатама-этнонимга да әйләнеп китә.

4. Җирле Болгар дәүләте кул астында калган угырларга «башкорт» исеме Идел-Кама болгарлары тарафыннан тагылган атама була. Венгрлар болгарлар килгәнче үк Урал буйларыннан киткәнгә, алар бу кушамат-этноним белән таныш булганнар. «Башкыр», «башгыр», «башкорт» этник атамасы болгар теле мәдәнияте аркылы мордваларга, урысларга, мөселман дөньясына тарала һәм таныла.

5. Хәзерге Башкортостан Республикасы территориясе Бөек Нугай Урдасының төп җирләре булып, анда иштәкләр азчылыкны тәшкил иткәннәр. Нугай Урдасы XVII гасыр урталарында таркалып беткәч, аның буш җирләренә көньяктан һәм төньяктан иштәкләр (башкортлар) кереп урнаша, ә урыс хөкүмәте үзенең иштәкләренә, калган нугайларга караганда, льготаларны, «башкорт» дип раслап, мул бирә. Нугай Урдасының элекке гражданы булу халыкка льгота бирмәгәч, ул вакыйгалар өлешчә, тарихи хәтер булып, риваятьләрдә һәм язма тарихларда, топонимнарда, шәҗәрәләрдә генә сакланган.

Бүгенге Башкортстан Республикасындагы татар халкының күп өлеше— әүвәлге Нугай Урдасы дәүләтенең гражданнары, һәм алар мондагы төп «башкорт» дип саналган иштәкләрдән борынгырак. Шунлыктан алар—иштәк-башкортлардан ассимиляциялэп ясалган түгел, ә бәлки, табигый татар кабиләләреннән формалашкан халык. Нугай Урдасындагы татар кабиләләреннән килүче нәселләрендә сакланган шәҗәрәләрнең «башкорт» дип саналган иштәкләргә бер бәйләнеше дә юк. «Башкортлык»—алар өчен фәкать социаль термин. Социаль терминнар белән эш итсәң, татардан, башкорт кына түгел, солдат, лашман, алпавыт, морза, чемоданный, тархан, игенче, казакъ, чуваш, ясак һ. б. дистәләгән милли этнонимнар әвәләргә мөмкин[2]. Марсель Әхмәтҗановның бу хезмәте татар һәм башкорт тарихыннан, теленнән, мәдәниятеннән әкият ясарга маташучы кайбер башкорт галимнәренә чын фәннең нинди булуын күрсәтә торган бер принципиаль тикшеренү өлгесе.

Татар гуманитар фәннәре өлкәсендә эшчәнлек алып барган галимнәр гаделлек, сабырлык, киң күңеллелек белән, югары фәнни-теоретик яссылыкта иҗат итәләр, конфронтация турында уйлап та карамыйлар. Әмма алар фәндә һәм кешелектә тарихилыкны, гаделлек-принципиальлелекне алга куеп, халкыбызның рухи мирасын өйрәнү, саклау, алга таба үстерү, рухи талауларга каршы тору юнәлешендә эшлиләр.

Башкорт топонимистлары да хезмәтләрен татар тапонимиясен талау рухында язалар. Мондый авторлардан Ф. Хисаметдинова, А, Камалов һ. б., тарихчы Ә. Әсфәндияров һ. б. күрсәтергә мөмкин. Бу авторлар Татарстан Автономияле Республикасы һәм Башкортстан Автономияле Республикасы оешканда татарлар компакт тəстə оешып яшәгән төбәкләрнең Башкортстан ягында калуын «онытып», Республикаларының төньяк-көнбатышындагы татар авылларын башкортка әйләндерү сәясәте белән генә канәгатьләнмичә, Әгерҗе, Азнакай, Актаныш,

Сарман, Әлмәт, Баулы, Алабуга, Мөслим, Лениногорск, Нурлат (элекке Октябрь), Бөгелмә, Минзәлә, Кукмара, Чүпрәле, Апас, Тукай районнарында урнашкан татар авылларында да башкортлар яши дигән абсурдка барып җитәләр.

Шунысы игътибарга лаек, Урта Идел һәм Урал топонимиясен бер система итеп өйрәнгәндә, ул нәкъ бертөсле, бер системага нигезләнеп барлыкка килгән, башкорт топонимиясе өчен хас булган аерым үзенчәлекләр юк. Башкорт топонимистлары тарафыннан башкорт топонимиясе үзенчәлеге итеп карала торган каран компоненты төркиләр яшәгән күп җирлекләрдә, аерым алганда, төрекмән, гагауз топонимиясендә, Кырымда, Ука (Ока) суы бассейнында, Татарстанның Тау ягы, Казан арты, Кама аръягы төбәкләрендә очрый.

Дүртөйле районындагы Бишнарат авылы, Федоровка районындагы Кече Чытырман, Бала Чытырман, Болгар авыллары, Илеш районындагы Бүләр авылы, Әлмәт районындагы Бөгелмә бистәсе, Янавыл районындагы Булат Елга авылы, Авыргазы, Балтач, Илеш, Нуриман, Эстәрлебаш районнарындагы Бүләк авылы, Миякә районындагы Кече Кәркәле авылы, Кырмыскалы районындагы Олыкүл авылы, Чакмагыш районындагы Рәҗәп авылы атамалары; Мәләвез районындагы Буташ елгасы, Краснокама районындагы Иске Каенлык җирендәге Кендекле күл, Зианчура, Әбҗәлил, Белорет, Бүздәк, Зилаир, Күгәрчен, Мәләвез районнарындагы Олы елга, Белорет районындагы Ташлы елга, Әлшәй, Бишбүләк, Илеш, Караидел, Мәләвез районы авылларындагы Ташлы Күл, Кырмыскалы районы Шәрипкул авылындагы Тирәкле күл, Зианчура районындагы Тирәкле елга, Хәйбулла районындагы Тирән үзәк, Әбҗәлил, Баймак, Күгәрчен, Күмертау, Мәләвез районнарындагы Ялтыр күл, Миякә районындагы Карлыган күле, Мәчетле районындагы Төлкеле күл атамалары ясалышы, номинация, мотивация принциплары татар топонимиясендәге топонимнар һәм гидронимнар ясалышыннан берни белән дә аерылмыйлар. Бу өлкәдә нинди дә аермалыклар эзләп көчәнү нәтиҗәсез эш.

Башкортстанның төньяк-көнбатыш һәм көнбатыш районнарында яшәүче татарлар сөйләше күп галимнәр: А. Г. Бессонов, Н. Ф. Катанов, А. А. Юлдашев, Ж. Алмаз, Ә. Ш. Әфләтунов, Л. Т. Мәхмүтова, һ. б. тарафыннан өйрәнелгән һәм мондагы халыкның татар телендә сөйләшүләре кире какмаслык итеп дәлилләнгән. Татарча сөйләгән, уйлаган, фикерләгән, татар рухы бөтен халәтендә, җанында, канында булган халыкка ясалма башкорт телен көчләп тагу, башкорт итеп яздыру нинди нәтиҗәләргә китерер? Әкиятләрдә генә чагылыш таба алган мондый хәлнең тормышка ашу-ашмавы Башкортстан татарларының үз сүзләрендә һәм кыйблаларында нык торуларына да бәйле. Татар, башкорт проблемаларын татарны таптап, татарның рухи мирасын көпә-көндез талау, аны халык буларак ассимиляцияләргә тырышу юлы белән түгел, бер-беренә ярдәм итеп, кулга-кул тотынышып, дустанә рәвештә хәл итәргә кирәк.

## Чираттагы тозак

ХАЛЫК САНЫН алу белән бәйләнешле рәвештә керәшеннәр мәсьәләсе дә калкып чыкты.

Тарихи чыганаклар күрсәткәнчә, татарларны көчләп христиан диненә күчерү 1552 елдан, Иван Грозный Казан ханлыгын яулап алганнан соң башланып китә.

Керәшеннәрнең тел үзенчәлекләрен һәм йола-канунарын өйрәнгән галимнәр: «Керәшеннәр—христиан динендәге татарлар. Керәшен сүзе рус телендәге крещен, крещенный дигән сүздән татар теленең яңгырашына җайлаштырылып, үзгәртелеп кабул ителгән»,—дип язалар[1].

Галимнәр керәшеннәрне, христиан диненә күчерелү вакытларына мөнәсәбәтле рәвештә «иске» һәм «яңа» керәшеннәргә бүлеп йөрткәннәр. Казан ханлыгы рус дәүләте тарафыннан буйсындырылганнан соң, ягъни XVI гасыр урталарыннан башлап, 1731 елга кадәр христиан диненә күчерелгән татарлар

[1]Баязитова Ф. С. Керәшеннәр. Тел үзенчәлекләре һәм йола иҗаты.—Казан, 1937.

«иске керәшеннәр» дип йөртелгән. 1731 елда миссионерлык эшен тагын да кинрәк җәелдерү һәм үстерү максаты белән махсус комиссия (новокрещенская комиссия) оештырыла. Бу комиссия төзелгәннән соң христиан диненә күчерелгәннәрне—«яңа керәшеннәр» дип атый башлыйлар.

Хезмәт вазифаларыма мөнәсәбәтле рәвештә мин 1971 елдан бирле күп төбәкләрдә экспедиция-сәфәрләрдә йөрдем, халык белән аралаштым. Шул аралашу җирлегендә язып алынган материалларны, күңелемдә туган фикерләрне һәм кайбер тарихи фольклор чыганакларыннан алынган мәгълүматларны укучылар белән уртаклашмакчы булам.

Мин керәшеннәр яши торган авылларда да күп булдым, шактый гына мәгълүматлар тупладым, аларның тел үзенчәлекләре, тормыш-көнкүрешләре, уй-фикерләре, гамәлләре белән таныштым. Аудый (Авдотья), Сандра (Александра), Кәтүк (Екатерина), Гөрпинә (Агриппина), Татый (Татьяна), Палый (Пелагея), Әүдәки (Евдокия) һ. б. апаларның тәмле ризыкларын, ак һәм кара мунчаларының сихәтле парларын, йомшак урыннарын, кече һәм киң күңелләрен, кунакчыл гадәтләрен, игелекле гамәлләрен еш исемә төшереп рәхмәт әйтәм. (Исәннәрегез сәламәт һәм бәхетле яшәгез, вафатларыгызның урыннары җәннәттә булсын!).

1973 елның бер көнендә мин Киров өлкәсенең Малмыж районында керәшеннәр яши торган Нослы авылына килдем. Бу авыл Балтач районындагы Смәел авылыннан 2-3 чакрым ераклыкта урнашкан. Мине Анна исемле апага фатирга керттеләр. Аның йортында мин дүрт кич кундым. Сөйләшер сүзләребез күп булды. Анна апа таба ашлары пешерде, мунча якты, ә мин үз эшемдә булдым, информантлар белән сөйләштем. Хуҗабикә апам һәм авыл өлкәннәре миңа кызыклы мәгълүматлар яздырдылар, гыйбрәтле вакыйгаларны күп сөйләделәр.

Анна апа һәм авыл өлкәннәре миңа үз авыллары халкының Татарстандагы Балтач районында урнашкан Смәел авылында туганнары яшәвен сөйләделәр. Халык әле туганлык җепләрен онытмаган. Смәеллеләрнең дә кайбер нәселләре Нослы авылында туганнары көн иткәнлеген беләләр икән. Авыллар бер-берсенә дустанә мөнәсәбәттә көн итә. Анна апа һәм авыл халкы ерак бабаларының татар икәнлекләренә, заманасында көчләп чукындырылганнарына инанып яшиләр. Нослыда халык татарча сөйләшә, христиан дине тота. 1887 елда авылда миссионерлык мәктәбе (миссионерская школа) оештырыла. Анда кызлар укыган.

Шунысы игътибарга лаек, Нослы авылы тирәсендәге географик берәмлекләрнең үзенчәлеге нәкъ татар топонимиясе системасыныкы кебек. Гадәттә су чыганаклары атамаларын галимнәр борынгылыкка китә дип исәплиләр. Нослы халкы тормыш-көнкүрештә түбәндәге атамаларны кулланып яши: Ходай елгасы, Тегермән елгасы, Әләй елгасы (Әләй—Алексей исеменең кыскартылган төрдәше), Шомыртлы куак елгасы, Микулай коесы (Николай исеменең үзгәртелгән төрдәше), Урыс үзәне (урыс авылы янындагы үзән), Татар баш (Нослы белән Балтач районының Шөшенәр авыллары арасындагы басу), Каенлык турылары, Татар межасы, Суык чишмә, Кирәмәт чишмәсе, Сөләйләр чишмәсе—Суляев фамилиясе йөрткән кешеләрнең йортлары янындагы чишмә һ. б.

Чистай районындагы татар авылы Мөслим янында гына керәшеннәр яши торган Бахта авылы урнашкан. Миңа күп мәгълүматлар яздырган Анна Петровна Ванифатьева һәм башка өлкәннәр Бахта авылындагы аерым нәселләрнең туганнары Мөслим авылында яшәгәннәрен әйттеләр. Бу хакыйкатьне Бахта авылының өлкән буыны бик әйбәт белә. Мөслим авылының өлкәннәре дә Бахтаның кайбер нәселләре белән туганлык җепләре бар икәнлеген исләрендә тоталар. Ике авыл халкы да дустанә яшиләр, ярдәмләшәләр һәм киңәшләшәләр.

Бахта авылында беренче дини мәктәп, Анна Петровна язмаларыннан күренгәнчә, 1874 елларда ачыла һәм анда поплар укыта.

Бахта халкы телендә гомер-гомергә шушындый атамалар кулланылып килә: Бахта елгасы, Иманай елгасы, Ындыр елгасы, Чишмә елгасы, Каен чишмәсе, Олы күл, Кул (урман буенда) һ. б. Мисаллардан күренгәнчә, керәшеннәр телендә татар топонимнары кулланыла. Алар татар топонимиясе системасында үзләренең законлы урыннарын алып торалар. Халык христиан дине тота, әмма телләре татар. Керәшеннәрнең сөйләм телендә сакланган үзенчәлекләр, татар сөйләшләрендә очрый торган үзенчәлекләрнең бер кыйпылчыгы буларак игътибарга

лаек. Керәшеннәр сөйләшендә очрый торган кайбер лексик берәмлекләрнең борынгылыгы, халыкның татарлардан беркадәр аерымланган (изоляцияләнгән) хәлдә яшәве, татар йогынтысыннан саклар өчен төрле урыннарга күчереп утыртылулары, христиан диненә күчерелгәч, телгә бу дин белән бәйләнешле лексик берәмлекләр кергә нисбәтле.

Мөселманлыкны ташлап христиан диненә чыккан кешеләргә көнкүрештә жинеллекләр тудырыла. Ләкин халыкның күбесе үз динендә калып, авырлыкларга бирешмичә яшәүне яисә үлемне кулайрак күрә. «Риваятьләр һәм легендалар» томында шушы тирәләр белән бәйләнешле «Әбүбәкер» дип аталган легенда урнаштырылган. Патша Россиясенең татарларга карата милли һәм дини изү сәясәте алып баруның бер күренеше монда ачык чагылыш таба. Риваятьнең эчтәлеге моннан гыйбарәт.

Нарат-Елганың Мөслим ягындагы кыр капкасыннан алып Мөслим сыртына кадәр жирләр сукаланмаган булган. Халык аны печән чабып файдаланган. Менә бервакыт, жиләкләр пешеп өлгерә башлаган чакта, уникe яшьлек бер кыз бала хәзерге таш утыртылган зират турысында жиләк жыеп йөри икән. Шул вакыт якыннан рус туе үтеп бара икән. Туйдагы кешеләр гармуннар уйнап, жырлап барганнар. Туй алдындагы мәдәк (яшь киленне утыртып, егет өенә алып килә торган өсте ябулы арба, кибитка) арбасының алдына икона беркетелгән булган. Туйдагы кешеләрнең күбесе исерек икән. Әлеге жиләк жыеп йөрүче кыз туйның янына ук килгән. Шул вакыт бер егет бу кызны мәдәк арбасына күтәреп салган. Кызны алып киткәннәр. Кыз кычкырган, елаган. Шул вакытта Нарат-Елга авылының Әбүбәкер исемле урта яшьтәге бер кешесе килеп чыккан. Әбүбәкер туйны туктаткан да кызны бирүләрен сораган. Тегеләр бирмәгәннәр. Әбүбәкернең кулында балтасы булган, ул урманнан кайтып килә икән. Ул, каты ачуланып, кызны жибәрүләрен таләп иткән. Тегеләр кызны арбадан төшерергә мәжбүр булалар. Ләкин Әбүбәкерне жибәрмичә, Нарат-Елгага кайтып, старостага алып баралар да, исемен, фамилиясен язып алалар. «Менә бу кеше туебызны туктатып, иконабызны хурлады»,—дип әйтәләр. Әбүбәкерне судка бирәләр. Суд аны үлем жәзасына хөкем итә. Әгәр чукынса, үлем жәзасын алмаштырырга булганнар. Ләкин Әбүбәкер мона риза булмаган. Аны төрле рәвештә жәзалаганнар. Соңыннан мунча себеркесенә керосин сибеп, себеркене аркасына бәйләп, ут төртеп яндырганнар. Әбүбәкерне, васыяте буенча, туйны туктатып, кызны коткарган урынга кабер казып күмгәннәр. Таш утыртканнар...

В. Н. Витевский һ. б. галимнәрнең мәгълүматларына караганда, патша хөкүмәте чукындырылган кешеләргә күп өстенлекләр биргән. Алар дәүләтнең күпсанлы төрле түләүләреннән, армия хезмәтеннән азат ителгәннәр, жир һәм акча белән бүләкләнгәннәр, кеше башыннан йөри торган төрле жәзалардан азат ителгәннәр. Мондый кешеләргә 3 елга төрле өстенлекләр бирелү 1731 елгы Указ белән дә ныгытылган. Ләкин унайлы очрак булу белән керәшеннәрнең күбесе мөселманлыкка кире кайткан. Гажәп түгел, дин—ана карынына ген белән кергән, ана сөте белән ныгытылган иман. Аны указлар, шикаятьләр, көчләүләр, асу-кисүләр белән тиз генә чыгарып ташлап булмый шул. Татар халкы тарихындагы мисаллар әнә шул турыда сөйли.

Теләче районында Олы Кибәхужа авылы бар. Казан ханлыгы егылганнан соң, бу авыл халкы да көчләп чукындырыла, авырлыкларны күп күрә. Чукындырылганнан соң авыл Макса елгасы буйлап Мишәгә таба бер чакрым арырак күчереп утыртыла. Халык чукындырылса да ислам дине тотуын дәвам итә. Бервакытны авылга Бикуш исемле карт килеп урнаша. Ул мөселманлыкны ташламаска кирәк дип, яшерен рәвештә генә агитация алып бара (Бикуш карт—фәлсәфә фәннәре докторы, профессор Яхъя Абдуллинның бабасы). Авыл халкы мөселманлыкка кире кайтуны сорап патшага үтенеч кәгазьләре (прошениеләр) яза. Олы Кибәхужа керәшеннәренең шундый үтенеч кәгазьләренең берсе 1867 ел, 4 июль датасы белән «Аграрный вопрос и крестьянское движение в Татарии XIX века» *(М.—Л., 1936, 247—249 битләр)* дигән тарихи чыганакта беркетелеп калган. Алар рәсми төстә мөселманлыкка кире кайтаруын үтенеп патша Александр Икенчегә мөрәжәгать итәләр.

Олы Кибәхужага рәсми рәвештә мөселманлыкка чыгарга рөхсәт бирелә

бирелүен, ләкин халык алдына бер шарт куела. Мөселманлыкка чыгарга теләүчеләр 80 тал чыбыгы белән суктыруны кабул итәргә тиеш булалар. Бикуш карт та әйтелгән санда тал чыбыгы белән суктырылырга риза була. Ул исән кала һәм ачыктан-ачык рәвештә мөселман дине тота башлый. Бу җәза мөселман диненә кире кайткан һәрбер кешегә эләгә. Күп кеше җәзаны күтәрә алмыйча үлә. Тал чыбыгы белән суктырылмыйча гына мөселман диненә кире кайтучылар Себергә сөрелә. Авылда мөселман диненә кире кайту 1864 елдан 1880 елга кадәр дәвам итә. Шушы еллар эчендә авыл халкы тулысынча мөселманлыкка кире кайтып бетә.

Кире мөселманлыкка кайту өчен көрәш көчле була. Төрмәгә утыртулар, чыбык белән суктырулар, сөргенгә сөрүләр гадәти хәлгә әверелә. Ләкин халык бирешми, күп авыллар кире мөселманлыкка кайта.

Керәшеннәрнең кире мөселманлыкка кайтуларына каршы патша хөкүмәте кискен чаралар күргән. Аларны туган җирләреннән рус авылларына яисә христиан динен нык саклый торган керәшен авылларына күчереп утырткан. Н. Черняховский мәгълүматларына караганда, 1827—1828 елларда кире мөселманлыкка кайткан өчен, хөкүмәт карары белән 90 гаиләне Казан губернасындагы туган нигезләреннән кубарып, Оренбург губернасында урнашкан Чиләбе өязендәге рус авылларына таратып утырталар.

Югарыда искә алынган чыганакта («Аграрный...») хәзерге Биектау районының Зур Солабаш авылы атамасы да теркәлеп калган. Авылда зур бер чуалышка нисбәтән авыл исеме, аның тарихындагы бер кара вакыйгага мөнәсәбәтле рәвештә бу китапка кереп кала.

Авыл халкы чукындырылганнан соң, 1866 елның 6 июнендә Зур Солабаш авылында бер керәшен татарының хатыны Акулина Павлова вафат була. Аның ире Максим Федоров (татарча исеме: Ишимъяр Ишимов) хатынын күршедәге урыс авылы Рус Алаты зиратына күмдермәс өчен, аны вакытлыча үз өенең ишек алдына күмә. Килгән тикшерүчеләр мәетне алып китәргә теләгәч, авыл хатын-кызлары мона комачау итү өчен кабер өстенә сузылып яталар, шул сәбәпле мәетне алып китә алмыйча, хакимият кешеләре буш китә.

Авыл халкы чукындырылганнан соң бирелгән ир-ат һәм хатын-кыз исемнәре дә бу чыганакта теркәлеп калган. Менә алар: Ишимъяр Ишимов (Максим Федоров), Тимергали Халитов (Яков Алексеев), Бибимәдинә Тахтарова (Федосья Семенова), Бибилатыйфа Халитова (Акулина Семенова), Бибифатыйма Халитова *(Ирина Иванова: 236—239 битләр).*

Татарларны христианлыкка көчләп күчерү читтәге төбәкләрдә дә барган. Мондый сәясәт халык хәтерендә сакланып калган легенда һәм риваятьләрдә дә чагылыш тапкан. Бу җәһәттән «Татар халык иҗаты»ның «Риваятьләр һәм легендалар» томына урнаштырылган *(Казан, 1987, 74-75 битләр)* «Югалган авыл» дигән легенда гыйбрәтле.

Моннан байтак еллар элек миссионер Богослов, үзенең әтрәде белән, Әҗе тирәсендәге (Рязань өлкәсенең Ермишин районындагы авыл) авылларны христианлыкка кертеп йөргән. Ул кайсы авылларда көчләп, үлем белән куркытып, кайсы авылларда хәзинәдән җир-су бирергә вәгъдә кылып, максатына ирешә икән. Менә ул Әҗенең шәрекъ тарафында шул эшләрне эшләп йөргәндә, чукынган мишәрләрдән берничә кеше анар тау астында Әҗе дигән бер татар авылы барлыгын сөйләгәннәр һәм берникадәр акча бәрабәренә бу авылга юлны күрсәтүне үз өсләренә алганнар. Әлеге миссионер теге кешеләрне юл күрсәтүче итеп үзенең әтрәде белән Әҗе халкын христиан ясарга юлга чыккан. Җәй башы булганлыктан, һәр елдагы шикелле, авылны өч яктан ташкын суы чолгап алган икән. Богослов Әҗегә якынлашкач, тау өстеннән караса—түбәндә диңгез шикелле зур ташкын суы җәелеп ята. Ул, бу манзараны күргәч, аптырап, житәкләүчеләргә бәйләнә башлый. Аларны үзен һәм әтрәден суга батырып үтерергә теләүчеләр дип уйлап, алга барудан туктый. Тегеләр үзләренең ярым-йорты русчалары белән түбәндә татар авылы барлыгына ышандырырга теләп никадәр сөйләсәләр дә, Богослов аларга ышанмыйча, башларын кистереп, Әҗегә житмәенчә кире кайтып китә вә шул кайтышында Яна Сала дигән татар авылын көчләп христианлыкка кертә дә, Түмәнгә (Мордовиядәге Темников шәһәре) карап юл тота.

Хәзер Новоселовка дип йөртелә торган рус авылы элек Яңа Сала исемле татар авылы булып, бөтен халкы белән көчләп чукындырылган. Шул вакыт Бадраковлар, Әжегә качып килеп, чукынудан котылып калганнар. Хәзер Новоселовкада Бадраков фамилияле руслар байтак кына бар. Шуның өстенә Әжедә хәзер Байчыгов фамилиясе белән йөри торган кешеләр дә Яңа Саладан Әжегә качып килеп тора башлаган бер гаиләдән таралганнар. Боларның кан-кардәшләре булган рус Байчыговлар Яңа Салада хәзер унберләп гаилә саналадыр.

Элегрәк бу христиан Байчыговларның хатыннары Әже урманнарына җиләк, гөмбә җыярга килгәндә туры татар кардәшләренә төшеп кунак булалар икән. Шулай ук татар Байчыговлар да Яңа Салага барганда, православный кардәшләрендә кунак булып, берникадәр хөрмәт күрәләр икән. Хәзерге заманда болар арасында мондый кардәшлек мөнәсәбәте калмаган инде. Хәтта бик күбесе үткәндәге хәлләрен онытыр дәрәҗәгә килгәннәр. Богословны исә, Түмән буенда йоклап яткан вакытында, Янгузов авылының бер егете чәнчеп үтергән дә, үзе качкан. Башлыклары үлгәч, аның кул астындагы кешеләрнең бөтенесе кайсы-кая таралып беткәннәр.

Беренче Петр 1682 елда (Петр I нең татар морзаларын чукындыру турындагы указлары 1713 һәм 1715 елларда чыга) «Мөселман алпавытлар һәм мирзалар егерме биш көн эчендә чукынмасалар, аларның бөтен крестьяннары вә күчми торган милекләре мөсадәрә кылыныр» дигән указ чыгаргач, тирә-яндагы Янзаличев, Килдишев, Маисов, Кугушев, Кудашев, Мирлин, Маманов, Балашов, Шәкуров шикелле татар байлары, җирләрендән вә крәстиән биләүдән аерылмас өчен, бер-бер артлы чукынганнар.

Бу чукынган татар мирзаларының башта Әже тирәләренә Кырымнан күчеп килгәнлекләрен билдерә торган бәгъзе бер галәмәтләр бу көндә бөтенләй юк түгел. Гомумән бу тирәләр белән Кырым арасында борынрак ниндидер бер мөнәсәбәт булган. Хәтта бу көнге Бигишевләрнең дә бер вакыт Кырымнан килеп Әжегә урнашулары турында дөреслеге бик ачык мәгълүм булмаган кайбер риваятьләр телләрдә йөри.

Татар халкы күтәрелмәслек авырлыклар күреп, әле дә исән яшәвен дәвам итә. Үзәге нык булгач, аны экстремаль шартларда да сындыра алмаганнар.

Керәшеннәр, керәшен татарлары безнең кан-кардәш туганнарыбыз. Мона каләр бергә-бергә яшәдек, моннан соң да гомергә бергә дустанә булып көн итәрбез дигән ныклы өметтә калабыз...

Бу мәкалә ярдәмендә халыкка әйтәсе килгән сүзем шул: халык санын алу вакытында татарны бүлгәләргә ирек бирмичә, акыл белән, ата-бабаларыбыз рухына тугрылыклы калып һәм бер йодрык булып килик. Милләтебезнең газаплары һәм югалтулары күп булды: ул сыналды, ләкин сынатмады. Әйдәгез, чираттагы тозакка төшмичә, көпә-көндез талауларны тибәреп, тыгыз сафларда, арабыздан җил үтмәслек итеп басыйк та, татар дип язылыйк—бергә һәм бердәм булыйк. Бүгенге ныклыгыбыз, берләшкәнлегебез ул—безнең киләчәктәге иминлегебез.

*Татарстан язучыларының XIV корылтае*

# "КАЗАН УТЛАРЫ" ЯКТЫРАК БАЛКЫР!

1999-2002 ЕЛЛАРГА ХИСАП

Татарстан әдипләренең һәм, гомумән, кайда яшәүләренә карамастан, барлык татар язучыларының иҗатын пропагандалауда, төрле кыйтгаларга сибелгән халкыбызның милли рухын, әдәби-эстетик зәвыгын тәрбияләүдә төп функция үтәгән "Казан утлары" XIII съездан соң узган өч еллык вакыт арасында да үзенә йөкләнгән шушы катлаулы һәм изге максатына, төп мәсләгенә тугрылыклы калды. Төп миссиясен тел-теш тидермәслек итеп уңышлы үтәп бару белән бергә ул икътисади-мәдәни бәйләнешләр зәгыйфьләнгән, әдәбиятлар һәм халыклар арасында электән яшәп килгән элемтәләр, хәтта туганлык җепләре өзелә барган катлаулы заманда әдәби процессны оештыру кебек гаять четерекле бурычны да үз өстенә алды. Редколлегиянең 1999, 2000, 2001 елларда үткәрелгән һәм журналның еллык эш йомгакларына багышланган киңәйтелгән утырышларында да сүз нәкъ шулар хакында барды. Утырышларга редколлегия әгъзаларын гына түгел, әдәбиятыбыз аксакаллары белән бергә танылган җәмәгать эшлеклеләрен, сәясәтчеләрне, халык депутатларын, Татарстан хөкүмәте вәкилләрен, күренекле галимнәрне чакыру гадәткә керде. 1999 елдагы утырышларның берсе әдәби тәнкыйтьне "терелтү" мәсьәләләренә багышланган иде. Шуның нәтиҗәсе буларак, журналда «Иң яхшы тәнкыйть мәкаләсе»нә конкурс уздырыла башлады, бу жанрда эшләүчеләр активлаша төште. 2000 елдагы утырышта исә, сүз нигездә, әдәби алмаш тәрбияләү һәм татар телендәге басмаларның тиражларын күтәрү юллары хакында барды. Гадәттә, өлкән әдипләрдән юллама-фатиха белән бергә тәкъдим ителүче "Яңа исемнәр" рубрикасы көчәйде, дистәләгән яшь шагыйрь һәм прозаикның әсәрләренә журнал битләрендә урын бирелде. 2001 елдагы киңәйтелгән утырышта катнашучылар (анда премьер-министр урынбасары З. Вәлиева, Татарстан хөкүмәте вәкилләре һәм халык депутатлары катнашты), гомумән, татар китабын халыкка җиткерү, китап сәүдәсен яңадан юлга салу чараларын эзләү кебек мөһим проблемага кагылдылар. Аннан соң бу тема депутатлар ярдәме белән Дәүләт Советы залларына үтеп керде, матбугатта яңгыраш таба башлады. Быелгы бер утырыш тулысы белән "Рухият" нәшриятының "Шәхесләребез" сериясендә чыккан китапларга багышланды. Утырышларда әйтелгән төп фикерләрнең сөземтәсен журнал битләрендә тәкъдим итү дә нәтиҗәсез калмады, укучыларда һәм әдәби җәмәгатьчелектә зур кызыксыну уятты.

Рухи тормышыбызның төп тармакларын эченә алган, безнең өчен мәсләк саналган кайбер нигез-принципларны, юнәлеш-рубрикаларны тезис рәвешендә генә булса да укучыларыбызга искәртеп узыйк. Менә алар:

**–тарихы мең еллап исәпләнгән татар әдәбиятының күркәм традицияләрен дәвам итеп, бүгенге татар язучыларының иң яхшы әсәрләрен бастыру, шулай ук, әдәби мирасыбызның бүгенге көн өчен гыйбрәтле сәхифәләре белән таныштыру;**

**–Татарстанның дәүләтчелеген яклау, ныгыту юлында эзлекле эшчәнлек алып бару; дәүләт теле буларак татар телен киң кулланышка кертү;**

**–Татарстанның дөньядагы роле, икътисады, социаль халәте турында язмалар белән беррәттән, Россия биләмәләрендә һәм чит илләрдәге татар хаяте белән укучыларны даими таныштыру; "XXI гасырда–татар халкы" рубрикасында күренекле галимнәрнең, сәясәтчеләрнең, әдипләрнең фикерләрен бәян итү;**

**–сәнгать төрләре буенча махсус басмалар булмауны истә тотып,**

**традицияләрне дәвам итеп, театр, музыка, сынлы сәнгать казанышларын яктырту; сәнгать өлкәсендәге олуг шәхесләрнең иҗатлары турында язмалар урнаштыру;**

**–халкыбызның әхлагын, гореф-гадәтләрен саклау юнәлешендә максатчан эш алып бару; дин тәгълиматы турында гыйльми мәкаләләр, ислам әхлагы, дини бәйрәмнәр турында мәгълүматлар бирү;**

**–укучыларыбызны дөнья әдәбияты классикасының иң яхшы үрнәкләре белән таныштыру;**

**–әдәби алмаш тәрбияләүне күз уңында тотып, "Остаханә", "Яңа исемнәр" рубрикаларында яшь язучыларның иҗат үрнәкләрен дөньяга чыгару; чит төбәкләрдә туган телебездә иҗат итүче талант ияләренә аерым игътибар итү;**

**–әдәби процессны барлап, үсеш тенденцияләрен ачыклап, әтрафлы тәнкыйть мәкаләләре бастыру, "Яңа китаплар" сәхифәсендә төрле нәшриятларда чыккан яңа китапларга рецензияләр һәм күзәтүләр оештыру;**

**–күренекле әдипләрнең юбилейларын, гомумән, татар дөньясындагы атаклы шәхесләрнең истәлекле даталарын билгеләп үтү; гарәп һәм латин имласында уку үрнәкләре бирү; "хроника" сәхифәсендә иҗтимагый-мәдәни тормыш вакыйгаларын объектив һәм оператив яктырту...**

Әлбәттә, чын тормыш беркайчан да язма канун кысаларына сыеп бетмәгән шикелле, журнал эшчәнлеге дә, табигый, югарыда саналган бүлем-юнәлешләр белән генә чикләнми. Заман үзенең яңа таләпләрен, яңа проблемаларын, яңа идеяләрен өстәп тора.

## Узган өч елда нинди әсәрләр дөнья күрде?

1999 елда 257 авторның төрле күләмдәге әсәрләре дөнья күргән. Шуларның күбесе – бүгенге әдәби хәрәкәттә актив катнашучылар. Ел дәвамында биш роман басылып чыкты. Өлкәнрәк язучылар хәтерли булыр: "проза жанрында быел бер роман туды" яисә "ике корылтай арасында өч роман язылды" дип сөйләнгән чаклар бар иде. Шуларга өстәп, егермегә якын повесть һәм хикәя, ике пьеса, ике поэма... һәр санда диярлек күләмле публицистика һәм тәнкыйть мәкаләләре, тарихи һәм фәнни хезмәтләр, әдәби мирас хәзинәләре, әдәбият-сәнгать яңалыклары...

Шундыйрак саннарны калган ике елга карата да әйтергә мөмкин. 2000 елда күләмле әсәрләрдән дүрт роман, сигез повесть һәм унөч хикәя, ике пьеса басылып чыкты. 2001 елда да саннар шул тирәдә тирбәлә. Романнар–биш, повестьлар–алтау, хикәяләр–ун, драма әсәрләре–өч.

"Шигърият" бүлегендә хәлләр мондый: 2001 елда журналда илле шагыйрь катнашты. 1999 һәм 2000 елларда да шигырь авторларының саны шул тирәдә булган иде. Арада күләмле поэмалар, шигъри бәйләмнәр дә байтак.

Журнал эшчәнлегенең төп юнәлешләреннән булган "Әдәби тәнкыйть", "Публицистика", "Фән", "Сәнгать", "Тарих", "Әдәби мирас" һәм башка рубрикаларда ел саен ике йөзләп автор катнаша. Моннан тыш, редакция укучы хатларына игътибарны көчәйтте. Сан саен диярлек Россиянең төрле төбәкләрендә, чит илләрдә яшәүче милләттәшләребезнең хатлары басылып чыга, алар ул якларда көн күрүче кан-кардәшләребезнең нинди уй-фикерләр белән яшәвен ачык күзалларга ярдәм итә.

Соңгы өч ел эчендә язучыларыбыз нинди әсәрләр белән катнашты? Авторларыбыз кайдан һәм алар кемнәр?

Романнар[1]: **М. Әмирханов** "Тәкъдир", **З. Зәйнуллин** "Агыйделнең аръягында", **Я. Зәнкиев** «Өтелгән мәхәббәт» *(Түбән өлкәсе)* , **В. Имамов** «Утлы дала» *(Чаллы)*, **К. Кәримов** «Ком сәгате», **Ф. Латыйфи** "Ишелеп төшкән бәхет", "Бәйсез этләрне атарга" *(роман-нәсер)*, **Р. Мирхәйдәров** "Иртәләгән сагыш" *(Мәскәү)*, **С. Поварисов** "Оҗмахка бер адым" *(Уфа)*, **Ф. Садриев** "Бәхетсезләр бәхете" *(Мөслим)*, **Ф. Сафин** "Саташып аткан таң" *(Чаллы)*, (**Р. Сибат** "Ялгызак" *(Киров өлкәсе)*, **А. Хәлим** "Татар вакыты" *(Чаллы)*, **З. Хөснияр** "Терсәк сугышы".

Повестьлар: **Г. Ахунов** "Тимерханның эзләнүләре", **Т. Әйди** "Венада

[1]Исемнәр алфавит тәртибендә бирелде.

очрашу", **Н. Әхмәдиев** "Амбирак яки кара каен кайгысы" *(Әлмәт)*, **М. Вәли** "Мәхәббәт мажаралары" *(новеллалар сериясе)*, **Ә. Галиев** "Чигенгәндә", **Г. Галиева** "Тулгак", **Н. Гариф** "Мәмеш Бирде", **Г. Гыйльманов** "Албастылар" *(хыялый кыйсса)*, **Н. Гыйматдинова** "Аргы очта, бирге очта", **З. Зәйнуллин** "Гарасатлы юллар", **Б. Камалов** "Дөмбер Даниял", **М. Кәбиров** "Сары йортлар сере" *(Уфа)*, **М. Маликова** "Алтын ятьмә", **Ә. Моталлапов** "Нигез" *(Актаныш)*, **Х. Мөдәррисова** "Бәйге хакы" *(Башкортстан)*, **С. Сабиров** "Алтын балдаклы абыстай", **Ә. Сафиуллин** "Җепнең очы", **А. Тимергалин** "Игезәкләр", **Р. Фәизов** "Тәнре хөкеме", "Гаделлек иясе" *(Арча)*, **Р. Хисмәтулла** "Оныкларым, сез бәхетлеме?" *(Чаллы)*.

Хикәяләр: **Ә. Гадел, Т. Галиуллин, Н. Гариф, А. Гыймадиев, М. Закир, М. Зарипов, С. Зыя, З. Зәйнуллин, Р. Мөхәммәдиев, Р. Рахман, Ә. Сафиуллин, К. Тимбикова, Р. Фәизов, А. Хәлим, М. Хуҗин, З. Хөснияр, Ф. Яруллин, Ф. Яхин** һ. б. авторлар.

Журналда шагыйрьләрдән **Г. Афзал, М. Әгъләм, Н. Әхмәдиев, Роберт Әхмәтҗан, Ә. Баян, К. Булатова, Ш. Галиев, Н. Гамбәр, Р. Гаташ, Ф. Гыйззәтуллина, И. Гыйләҗев. Җ. Дәрзаман, Ш. Җиһангирова, Р. Идиятуллин, Р. Закиров, Зөлфәт, К. Латыйп, Ш. Маннап, З. Мансуров, Р. Мингалим, М. Мирза, Г. Морат, Г. Мөхәммәтшин, С. Мулла Гали, Р. Рахман, Г. Рәхим, Б. Рәхимова, Ә. Рәшитов, Н. Сафина, Ә. Синугыл, Сөләйман, Р. Фәйзуллин, Р. Фәйзуллин (Акъегет), В. Фатыйхов, А. Хәлим, Л. Шагыйрьҗан, Э. Шәрифуллина, И. Юзеев, Р. Юныс, Ф. Яруллин, Л. Янсуар** шигырьләре зур бәйләм иттереп тәкъдим ителде. 1999 елда **Р. Харис**ның «Бүре күзе», 2000 елда «Һарут белән Марут», 2001 елда «Хыянәт» исемле поэмалары басылып чыкты. 2000 елда журнал укучылар **Ә. Рәшитов**ның "Эзли-эзли ул борынгы эзне", **М. Шабаев**ның "Ярты төн бәйрәме" поэмалары белән таныштылар.

Публицистика өлкәсендә **Т. Әйди, Ә. Борһанов, М. Госманов, Ф. Дунай, М. Зарипов, Б. Камалов, Ф. Латыйфи, Т. Миннуллин, Р. Мостафин, Ф. Сафин, Н. Сафина, В. Юныс, М. Юныс** аеруча уңышлы эшләделәр.

Казанның 1000 еллыгын зурлап үткәрү турында Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы Президентларының Указлары кабул ителгәннән соң "Казан утлары" журналының фәнни-публицистик эшчәнлегендә башкалабыз юбилеена әзерләнү һәм борынгы шәһәргә нигез салынуның тарихи аспектларын, аның бүгенгесен һәм киләчәген яктырту төп юнәлешләрнең берсенә әверелде. Аларны әзерләүгә РФ һәм ТР Фәннәр Академияләренең күренекле галимнәре–тарихчылары һәм тюркологлар, күренекле язучылар һәм сәнгать белгечләре җәлеп ителә, шулай ук республикабыз һәм Казан шәһәре хакимияте житәкчеләре белән күләмле әңгәмәләр үткәрү күздә тотыла.

Авторларыбыз катламы шактый киң: **Ә. Борһанов, М. Госманов, Р. Галләмов, М. Зәкиев, Д. Исхаков, Ә. Мөхәммәдиев, И. Таһиров, Р. Фәхретдинов, Ф. Хуҗин, Р. Хәкимов, Р. Шаһиева** һ. б.

"Казанга мең ел" циклының рубрикалары:

**Меңъяшәр Казан—яшәр!** — Казанның 1000 еллыгы уңаеннан шәһәребезнең бүгенге йөзе, архитектура ягыннан нинди үзгәрешләр кичерәчәге хакында мәкаләләр сериясе.

**Архивлар ни сөйли?** — Мәскәү, Казан, Санкт-Петербург, башка шәһәрләрнең архивларында Казан тарихына кагылышлы документларны, язучылар һәм галимнәрнең шәхси архивларындагы язмаларны һәм мәгълүматларны классификацияләп эзлекле рәвештә журналда бастыру.

**Дәверләр алышынганда.** — Гомуми яшәеш, халык язмышы, милли әдәбият-сәнгатьнең үткәне һәм киләчәге турында анализлы мәкаләләр сериясе.

**Казан Кремле нинди төс алыр?** — Казан Кремлен реконструкцияләүнең барышы, перспективалары, проблемалары.

**Халык буларак татар кайчан оешкан?** — Моңарчы тупланган тарихи, археологик һәм чиктәш фәнни мәгълүматларга нигезләнгән аналитик язмалар.

1999-2002 елларда журнал битләрендә юбилейга мөнәсәбәтле түбәндәге гыйльми язмалар, проза һәм поэзия әсәрләре дөнья күрде:

**В. Имамов** "Утлы дала" (роман), **Р. Фәхретдинов** "Казан ханлыгы", **М. Шабаев** "Бер китап язмышы", **Ә. Рәшитов** "Эзли-эзли ул борынгы эзне" (поэма), **Н. Га-**

**риф** "Мәмеш Бирде" (повесть), **Р. Шаһиева** "XVI гасыр ядкяре", "Казан тәхете" "Казанның җәмигъ мәчете", "Татар "Илиада"сы каһарманы", **Р. Нәбиев** "Монгол яуларына тагын бер караш", **Р. Галләмов** "Татар халкы оешуга яңа караш", **Ф. Хуҗин** "Чал тарихлы башкала", **С. Алишев** "Татар халкының дәүләтчелек өчен көрәш елъязмасы", **И. Насыйбуллин** "Казан ханлыгының чикләре каян узган?" һ. б.

Редакциядә бүгенге көндә унсигез кеше эшли. Шуларның тугызы иҗади хезмәткәр. Аларның исемнәре республикада һәм әдәби җәмәгатьчелеккә яхшы таныш. Татарстанның халык шагыйре, Г. Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты **Равил Фәйзуллин**, Г. Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты, шагыйрь **Марс Шабаев**, шагыйрь **Рәдиф Гаташ**, прозаиклар **Флүс Латыйфи**, **Камил Кәримов**, **Марат Закир**, шагыйрь һәм әдәбият белгече **Наис Гамбәр**, тәнкыйтьче **Мансур Вәли-Барҗылы**, балалар язучысы **Алмаз Гыймадиев** һәм барлык гамәли хезмәткәрләребез журналны вакытында яхшы сыйфатлы итеп чыгару өчен зур көч куялар. Иҗади хезмәткәрләребезнең күбесе республикабызның мактаулы исемнәренә лаек булды.

Журналның тиражы тотрыклы. Бүгенге көндә ул 9 мең данә чамасы тәшкил итә. Бу – Россиянең калын әдәби журналларыныкына караганда да сизелерлек артык дигән сүз. Быел исә әбүнәчеләребез саны тагын 500 кешегә артты.

Редакциянең компьютер үзәге булдырылганнан соң журналның техник һәм сәнгати бизәлеше, эчке дизайны яхшырды, редакциягә кергән материалларны оператив эшкәртү мөмкинлеге туды.

Быелның май аенда журналның чыга башлавына 80 ел тулды. Халкыбыз тормышы елъязмасында рухи бер зур бәйрәм буларак, юбилей тантаналары август ахырында III Бөтендөнья татар конгрессы көннәрендә үтәчәк.

**Вахит Имамов,**

*Татарстан Язучылар берлегенең Чаллы бүлеге җитәкчесе*

## КҮҢЕЛНЕ БОРЧЫГАН УЙЛАР

Яна корылтайга җыелдык... Өч елга бер генә үтә торган корылтай булгач, ике арада башкарылган эшләр хакында исәп-хисап тотарга һәм, әлбәттә, алда торган бурычлар, үзебез кичереп яшәгән сызланулар турында да әйтергә тиештер инде без.

Чаллы язучылар оешмасы соңгы 3 елда да бернинди тукталу, таптану белмичә яшәвен дәвам итте. Башкарылган һәрбер эш яки һәрбер юнәлеш хакында бәйнә-бәйнә сөйләп тору, мөгаен, урынсыздыр. Чаллыдагы әдәби мохит, әдәби дөнья белән кызыксынган күпләр өчен безнең язучыларыбызның эшчәнлеге болай да ару гына таныштыр, дип уйлыйм. Исәп-хисабыбыз коры сүзләр белән генә узып китмәсен өчен фәкать ике санны гына искә алып үтәм. Кама буенда һәм Чаллы төбәгендә яшәүче язучылар һәм яшь каләмдәшләребез ике съезд арасында 80гә якын шигырь, проза һәм публицистика җыентыгы чыгаруга ирештеләр. Чаллының үзендә һәм районнарга чыгып үткәрелгән әдәби кичә һәм әдәби очрашуларның саны 150 дән артып китте. Шулай да соңгы елларда безнең Чаллы төбәге һәм, гомумән, татар язучылары өчен иң зур сөенеч—ул да булса Чаллыда «Мәйдан» дигән яңа әдәби-нәфис журнал нигезләнү. Әйе, Аллага шөкер, узган елда Чаллыда шәһәр хакимияте, аның башлыгы Рәшит Хәмәдиев хәерхаһлыгы һәм, әлбәттә, Чаллы язучылар оешмасы тырышлыгы белән «Мәйдан» журналы дөньяга чыга башлады һәм кыска гына вакыт эчендә ул үзенең кабатланмас йөзен дә табып өлгерде. Үзебезнең үк кайбер каләмдәшләребез ничек кенә итеп тырнак астыннан кер эзләп яки төрттереп маташмасын, «Мәйдан» ул—бүген бөтен Россиядә аерым бер шәһәр бюджетына нигезләнеп чыгарыла башлаган бердәнбер журнал, эчтәлеге,

формасы белән дә ул бердәнбер. Корылтаебызда республика житәкчеләре катнашудан файдаланып шуны гына сорыйсы һәм үтенәсе килә: «Мәйдан» журналы киләсе елдан да калмыйча республика бюджетына кертелсен һәм чынлап торып бөтен татар халкының, татар язучыларының уртак журналына әверелсен иде. Бер миллионга якын халыкны үз авызына каратып торган Чаллы каласы һәм Чаллы төбәге өчен «Мәйдан» кебек мөстәкыйль бер журнал чыгу һич тә артык түгел. Элек Уфада, Оренбург, Троицкида гына түгел, хәтта Минзәләдә дә аерым журналлар чыгып килгән бит әле. Татарстанның икенче зур шәһәре булган Чаллыга да мөстәкыйль журнал кирәк һәм бик тә кирәк!

Инде күнелне тырнаган борчу һәм сызлануларны әйтеп үтәсе килә. Менә алары, чынлап та, бихисап. Сүзне озынга сузмас өчен санап чыгу урынлырак булыр.

1. Гәрчә инде 22 ел буе яшәсә дә, Чаллы язучылар оешмасының бүгенге көнгә кадәр берниндн дә бюджетка куелганы юк. Әйе, менә шушындый әкәмәт көлкеле хәл! Оешма бар, әмма ул ни республика, ни шәһәр бюджетында тормый. Үзебез арендага алган бинага, тоткан жылылык һәм энергиягә, коммуналь чыгымнарга түләү, пенсионерларга һәм авырып киткән язучыларга ярдәм итү, үлемкитем очраклары өчен безгә беркем тарафыннан да һәм бер тиен дә акча бирелми.

2. Казанда яшәүче язучыларның (исәннәренекен дә һәм арабыздан китеп барганнарыныкын да) юбилейларын яки искә алу кичәләрен үткәрәләр. Бик тә кирәк эш, без бер дә каршы түгел. Әмма шул ук вакытта Чаллы каласында исә Кама буенда тагын бер төркем татар язучылары яшәп ята бит әле. Аларның да юбилейлары булып тора, алар да хөрмәтләү-зурлауларга бик лаек кешеләр. Ләкин ни хикмәт, Чаллы язучыларының 50, 60, 70 еллык юбилейларын үткәрү өчен безгә шулай ук бер генә тиен дә акча бирелми. Алай гына да түгел, Чаллы төбәгендә яшәүче язучыларның инде 15 ел буена берниндн мактаулы исемнәр алганы юк. Без Рәшит Бәшәргә, Мәхмүт Газизовка, инде арабыздан китеп барган Зәһирә апа Гомәровага «Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре» исеме бирүләрен сорап документлар жибәреп карадык, ләкин йә «яше үткән», йә «фәлән кәгазе житми» дип, аларны безгә кире борып кайтардылар. Инде һаман шушы ук теманы дәвам итсәк, Казанда язучыларның юбилейларына багышланган китаплар, Аллага шөкер, чыгып кына тора. Ләкин ни галәмәт, алар арасында безнең Чаллы каласында яшәп дөнья куйган Кадыйр Сибгатуллин, Ямаш Игәнәй, Хәниф Хөснуллин, Газиз Кашапов, Эдуард Касыймовларга багышланганнары гына юк.

3. Без ел саен кабынып, Габдулла Тукай исемендәге премия тирәсендә бара торган хәлләрне күзәтеп барабыз инде. Г. Исхакый, А. Алиш, Ф. Хөсни исемендәге премияләр тирәсендә барган көрәш, тарткалашу дә безгә яхшы таныш. Мин быел Тукай премиясенең Себердәге Якуб ага Зәнкиевкә бирелүен әйтмим. Әмма башка елларда Тукай исемендәге яки башка премияләр өчен тарткалашу фәкать Казан язучылары арасында гына бармыймыни? Ә ярты миллионнан артык халкы булган Чаллы—ул Татарстан республикасының бер өлеше ләбаса. Башка вакытларда «бердәмлек, бергәлек» дип сөйләнергә һәммәбез дә яратабыз бит. Ә нигә соң ярты миллионлы Чаллыда бүген бер генә Тукай премиясе лауреаты да юк? Татар публицистикасын сөйрәп баручы Айдар Хәлим, Фәүзия Бәйрәмова, йә булмаса татар балалар прозасын сөйрәп баручы Рәшит Бәшәр ул исемгә лаек түгелмени? Һәм бу мәсьәләне тагын да тирәнәйтә төшсәк, Тукай премиясен хәл итә торган дәүләт комитеты составында ни өчен йә Чаллыдан, йә Әлмәттән бер генә язучы яки сәнгать эшлеклесе дә юк?

Безнең татар әдәбияты бүген алга барамы, чәчәк атамы соң? Аеруча әдәбиятның умырткасы булган прозаны алыйк. Әмирхан Еники, Мөхәммәт Мәһдиев, Гариф Ахунов, Аяз Гыйләжев кебек корифейларыбызны югалткач татар прозасы аксакалларсыз, алай гына да түгел, байракчысыз калды. Прозаның намус барометры булып торган шушы остазларыбызны югалтканнан соңгы еллар әдәбиятында «роман» дип мөһер сугылган шактый сәер язмалар күренгәли башлады. Ун табаклык нииндидер бригада көндәлекләрендә дә «роман» мөһере, 7-8 табаклык фәлсәфәдә һәм хәтта 4-5 табаклык хатирәләрдә дә «роман» мөһере. Әйтерсең лә, болар яһүдләрнең Мандельштамнары белән ярыша башладылар! Профессиональ язучы булып йөргән кешеләрдә дә үз-үзләренә карата таләпчәнлек бетте. Нәтижәсе

шул—татар прозасы ваклана башлады, татар укучысын әдәбияттан читкә этәрә башладык. Ә чынлап торып, кулны йөрәккә куеп саный башласак, 7 миллион халык дип йөргән милләттә, 300 әгъза бар дип йөргән Союзда бүген чын Роман, зур хәрефләр белән атала торган, татар милләтенең язмышын-михнәтләрен чагылдыра торган Роман яза алучыларның саны бер дистәдән дә артмый. Прозада әле тагын гаять аяныч хәлдә калган бер өлкә бар—ул да булса тарихи роман жанры. Бу жанрның нинди мескен хәлгә калуын исбатлау, ачыклау өчен бер генә мисал китерү дә житә. Безнең милләтнең иң авырткан, иң яралы жире—безнең дәүләтебезне югалтуыбыз, 1552 ел фажигасе. Ни үкенеч, «безнең бер мең еллык язма әдәбиятыбыз бар бит», дип күкрәк суккан әдәбиятта бүгенгә көнгә кадәр шушы иң олы фажигага багышланган һәм барча әдәбият дәреслекләренә кертелергә лаек булган бер генә роман да юк.

Нигә соң безнең проза болай коргаксыды? Һәм, гомумән, нигә безнең әдәбият олы талантларга коргаксыды? Әдәбиятка, аның киләчәк язмышына битараф булмаган кешеләр, мөгаен, күзәтәдер: әдәбиятка соңгы елларда яшьләр килү бетте. Бүген без көндез чыра яндырып эзләсәк тә, 40 яшьтән дә яшьрәк булган, әмма инде роман яки житди повесть яза алырдай бер генә талант иясен дә таба алмыйбыз. Бүген без Тукай яки Такташ кебек 20-30 яшьлек талантлар турында сүз дә алып бара алмыйбыз. Соңгы бер дистә елда шәһәрләрдә дистәләгән татар мәктәпләре, татар гимназияләре ачтык, шуларга меңнәрләгән татар балаларын бирдек. Әмма ул мәктәп һәм гимназияләрдә чип-чиста татар мөхите дә, чип-чиста татар теле дә юк. Авылларлагы мәктәпләребез корыды. Нәтижәдә кулларына каләм алып саф татарча яза ала, яки кулларына гармун алып саф татар көйләрен уйный ала торган татар балалары бик санаулы калды. Өстәвенә, хөкүмәт язучылар хезмәтенә тиешенчә каләм хакы түләмәгәнгә күрә, татар язучысы үзе язган китапны дөньяга чыгару өчен яна байлар яки житәкчеләр каршында хәер сорашып йөри торган хәлгә куелганга күрә—әдәбиятның дәрәжәсе бик нык төште. Язучылар берлегендәге әгъзалар санын фәлән кешенең баласы, туганы яки якташы исәбенә арттырып була ул. Әмма ләкин талантларны алай табып та, үстереп тә булмый! Һәм, ни үкенеч: татар әдәбиятының бүгенге аяныч хәле турында ни хөкүмәт, ни житәкчеләр чаң сугарга бер дә ашыкмыйлар.

Моннан 95 ел элек үк бөек Тукаебыз «Безнең милләт үлгәнме, әллә йоклаган гынамы?» дип бик тә сызланып язып чыккан иде. Әйе, йокыда идек без ул вакытта. Шуннан соң 1917 нче елда бер уянып алдык, дәүләтле булабыз, дип өметләндек. «Автономия» дигән сөяк ыргытып ул чагында безне беренче кат алдадылар. Моннан 15 еллар элек, 80 нче еллар ахырында, тагын бер кат уянгандай булдык. Татар милләтен уятуда безнең язучыларыбыз башлап йөрде. Әллә никадәрле митингларда, мәйданнарда булдык. Инде бу юлы да «дәүләтле булабыз, мөстәкыйль булабыз», дип өметләнгән идек. Тагын алдадылар. Һәм, беренче чиратта, без—язучылар һәм сәнгать кешеләре—алландык шикелле. Чөнки без сәүдәгәрләр дә, алып сатарлар да түгел шул, бездә хәйләкәрлек, елгырлык юк. Митингларга йөрдек, азатлык дәгъвааладык, ә ул чордагы беркадәр иркенлектән файдаланып үз мәнфәгатьләребез турында кайгырта белмәдек. Нәтижәдә Язучылар берлеге ни Мәскәүдән, ни үзебезнең хөкүмәттән Язучылар берлегенең мөстәкыйль, махсус нәшриятын булдыру өчен акча таләп итә белмәде. Берлек бүген бер генә нәшрият эшчәнлегенә дә күрсәтмә бирә яки аннан ни дә булса таләп итә алмый, чөнки бүген һәр өлкәдә базар экономикасы. Элек язучыларның китапларын дөньяга чыгарып килгән Татарстан китап нәшрияты да эш күләмен нык киметте, чөнки татар әдәбиятын, татар китапларын саклап калу өчен ана хөкүмәт тарафыннан дотация яки өстәмә түләү тиешле дәрәжәдә бирелми. Ягъни бик күп язучылар өчен бүген нәшриятларның юлы ябык. Аннары икенче мәсьәлә. Хәтта нәшриятларда китап чыгару бәхетенә ирешсән дә, анда каләм хакын тиеннәр белән генә түлиләр. Тагын шул ук бәла: хөкүмәт тарафыннан язучының хезмәтен бәяләү-олылау юк, ничә еллар буена гонорарлар күләмен юньләп арттыру юк. Сүз язучының, талантларның кадере турында бит! Бу өлкәгә керсәк, үт күршеләребез—Башкортстан язучыларыннан көнләшерлек. «Халык язучысы», «халык шагыйре» дигән мактаулы исемнәр бирү аларда да бар, бездә дә бар. Ләкин «халык язучысы» булган талантларга Башкортстанда хөкүмәт хисабына

катлы-катлы коттеджлар төзеп бирәләр, ә бездә, әнә, Әлмәттә халык шагыйре булган Гамил Афзалның ярымкарангы, кысан фатирына ремонт үткәрү өчен кирәкле акчаны да нефтьчеләр каршына барып теләнәләр. Ә язучылар өчен иҗат йорты булдыру турында инде әйткән дә юк! Корылтай артыннан Корылтай уза тора, вәгъдәләр су буе тезелә, ләкин бу мәсьәлә һаман сакаллы бер проблема булып кала бирә. Менә шулай: җәмгыять һәм хөкүмәт өчен бүген кирәксез бер кашык булып яшәп ятабыз без. Берзаманны бу җәмгыять һәм хөкүмәтнең ашы да булыр, бәлки. Ләкин бик шикләнәм, ул чакны табын янына чакырып утыртырга татар язучылары табылыр микән?!

**Разим Вәлиуллин,**

*Әлмәт Язучылар оешмасы җитәкчесе*

## НЕФТЬ ТӨБӘГЕНДӘ ӘДӘБИ МОХИТ

Әлмәт Язучылар оешмасы нефть районнары белән эшләгәнгә һәм алардагы әдәбият-иҗат көчләрен берләштергәнгә күрә, табигый ки, әдәби хәрәкәттә, язучыларның иҗатында нефть темасы һәрвакыт калку яңгыраш таба килде. Бу корылтайлар арасындагы елларда да шулай булды. Барлык берлек әгъзалары диярлек һәм яшь авторларыбыз әдәби һәм публицистик әсәрләр, язмалар белән вакытлы матбугатта чыгыш ясадылар. «Татнефть»нең 50 еллыгына, «Җәлилнефть» идарәсенең 500 миллионынчы тонна нефть бирүенә багышланган тантана һәм вакыйгаларны бәян иттеләр.

Соңгы елларда Әлмәт Язучылар оешмасы бу төбәкнең сәнәгать ягыннан, җир асты байлыклары ягыннан гына түгел, ә әдәбият-сәнгать көчләренә бай булуы ягыннан да атаклы һәм мартәбәле икәнен күрсәтү буенча иҗтиһат итә.

Моның өчен берничә гасырлар элекке тарих төпкеленнән башлап бүгенге көннәргә кадәр мөрәҗәгать итү, репрессиягә эләгеп, көчләп онытгырылган, мираслары юкка чыгарыла язган, әмма дөнья тәрәккыятенә, татар милләтенең әдәби-мәдәни байлыгына зур мирас калдырган Ризаэтдин бине Фәхретдин, Гыйльман ахун Кәрими, Фатыйх Кәрими, Һади Атласи, Рәшит Ярулла, Ләбиб Гыйльми, Афзал Таһири һәм башка мәшһүр шәхесләребезнең исемнәрен, иҗатларын, кылган гамәлләрен халыкка кире кайтару, аларның ядкарьләрен мәңгеләштерү буенча эзлекле, җитди эш алып барыла. Зур хезерлек белән шәхесләрнең юбилейлары, төрле форумнар үткәрелде.

1999 ел Әлмәт төбәгендә Ризаэтдин бине Фәхретдин елы дип билгеләп үтелде. Бик күп чаралар үткәрелде. 2000 елның мартыннан 2001 елның мартына кадәр Фатыйх Кәрими елы үткәрелде. (Фатыйх Кәрими 1870 елның 30 мартында Миңлебай авылында дөньяга килгән. 1937 елда Сталин палачлары тарафыннан атып үтерелгән.)

Еллыкны үткәрү өчен Әлмәт Язучылар оешмасы, әдипләребез имзасы белән җирле газеталарда хакимият, «Татнефть» җитәкчеләре, оешмалар, эшмәкәрләр исеменә мөрәҗәгать белән чыкты. Язучылар оешмасы белән берлектә мәдәният, мәгариф идарәләре, китапханәләр, мәктәп-гимназияләр җиң сызганып эшкә керeште. Кыскасы, мөрәҗәгать киң җәмәгатьчелек тарафыннан яклау тапты. Март-апрель айларында шәһәрнең № 1, 7, 17 мәктәпләрендә, Ризаэтдин Фәхретдин исемендәге татар гимназиясендә, техник лицейда кичәләр, ачык дәресләр үткәрелде («Язучылар дәрес бирә» циклыннан). Безнең катнаш һәм ярдәм белән Оренбургта фәнни-гамәли

конференция узды. Гыйнвар аенда Оренбург өлкәсенең Богырыслан шәһәрендә дә татар зыялылары, милли хәрәкәт һәм дин әһелләре белән берлектә конференция үткәрелде.

Фатыйх Кәриминең туган авылы Миңлебайда берничә ел элек ачылган музей экспонатлар белән баетылды. Нефтьчеләр иганәчелеге, ярдәме белән әле генә дә күп тарихи ядкарь сатып алынды. Һәм, ниһаять, бер елдан артык әзерлек чаралары күрелгән Республика күләмендә фәнни-гамәли конференция 17 август көнне Миңлебайда узды.

Әлеге зур форумда Казаннан, Әлмәттән, Сарманнан, Алабугадан, Җәлилдән һәм башка төбәкләрдән хакимият, сәнгать вәкилләре, язучылар, галимнәр, дин вә җәмәгатьчелек әһелләре катнашты.

Бу көнгә «Татнефть»нең «Рухият» фонды «Фатыйх Кәрими» исемле фәнни-биографик җыентык бастырып чыгарды.

Хәсән Туфанның 100 еллыгы уңаеннан шулай ук ел дәвамында әдәби-музыкаль кичәләр, очрашулар, әдәби укулар уза. Беренче зурлап әзерләнгән шундый кичә 1 март көнне район мәдәният йортында узды. «Гомер эзләрең буйлап» дип аталган бу кичәне Разим Вәлиуллин алып барды һәм Х. Туфан, аның Әлмәттә булган чорлары турында истәлекләр сөйләде. Язучылардан Миргазыян Юныс, Илдар Әхсәнов, Клара Булатова һәм башкалар чыгыш ясады, Х. Туфан шигырьләренә язылган җырлар яңгырады.

1994 елдан башлап, 4 номинациядә Әлмәт хакимияте белән берлектә «Рафаил Төхфәтуллин исемендәге премия» бирәбез. Аның комитеты, уставы, эш документлары бар. Бу еллар эчендә 35 шәхескә лауреат исеме бирелде.

Һәр елны нефть төбәге районнарында һәм шәһәрләрендә яз көне Г. Тукайга багышланган «Туган тел» бәйрәмнәре, шигъри митинглар үткәрәбез. Традиция буенча, көз көне Саҗидә Сөләймановага багышланган әдәби-шигърият айлыгы үткәрелә. Бу айлык кысаларында яшь һәм башлап язучыларның әсәрләреннән әдәби битләр, конкурслар уздырабыз. Яхшы дип табылган әсәрләрдән балалар шигърияте альманахы бастырып чыгарабыз. Мәсәлән, 2001 елда шундый альманахта 150 мәктәп баласының шигырьләре дөнья күрде.

Ике корылтай арасында барлык каләм ияләребез фидакарьләрчә хезмәт итте, уңышлы әсәрләр тудырдылар. Гамил Афзал, мәсәлән, ике китап бастырып чыгарды. Әдип Маликов «Гомер мизгелләре» исемле документаль әсәрен тәгалләп, «Рухият» нәшриятында дөньяга чыгарды. Энҗе Мөэминова—ике китап, Илдар Әхсәнов биш поэма, күпсанлы шигырьләр бастырып чыгарды. Миргазыян Юнысның сигез томда әсәрләре тупланып нәшриятка тапшырылды һәм бер мәҗмугасы инде китап сөючеләргә барып ирешТе. Дамир Гарифуллин—өч, Клара Булатова—1, Азат Ганиев—1, Әсгать Салах—3, Нур Әхмәдиев—3, Разим Вәлиуллин—3, Фоат Садриев—2, Илдус Гыйләҗев—1, Фәйрүзә Исмәгыйлова—1, Альберт Хәсәнов—1, Рәшит Шиһап 3 китап нәшер иттеләр.

«Рухият» нәшрияты нефть төбәгендә яшәүче 51 авторның шигырьләрен туплап, укучыларга саллы китап бүләк итте. «Син дә шагыйрь, мин дә шагыйрь» исемле бу китапта нефть төбәгендә эшләүче Әлмәт «Кызыл каурыйлар» (җитәкчесе—Әхмәт Фәтхи), «Җәлил чаткылары» (җитәкчесе—Илдус Мәрданшин), «Моңсар» (җитәкчесе—Мәхтүм Мостафин), «Чишмә» (җитәкчесе—Рәмзия Габделхакова), «Гөлстан» (Нәфис Гәрәйшин), Сәгадәт Әхмәтшин җитәкләгән Баулы берләшмәсе һәм башкалар, нефтьчеләр, төзүчеләр, укытучылар, авыл хуҗалыгы хезмәтчәннәре үз иҗат җимешләрен киң катлам җәмәгатьчелеккә тәкъдим иттеләр.

Шәхесләрнең исемнәрен мәңгеләштерү өлкәсендә башкарган эшләребез байтак. Габдулла Тукайның Әлмәттә 1972 елда ачылган һәйкәленә реставрация ясап, яңартып, мәйданын бүгенге көн таләпләренә туры килерлек итеп үзгәртеп кора алдык. 15-20 елларга сузылган иҗтиһатның нәтиҗәсе буларак Г. Тукайның һәйкәле Лениногорск шәһәрендә дә ачылды. Әлмәт районының Кичүчат авылында Ризаэтдин бине Фәхретдин музее зурайтылып, яңа экспонатлар белән баетылып яңадан ачылды. Миңлебай авылында Фатыйх Кәрими музее аякка басты. Нефть төбәге шәһәрләрендә язучыларның исеме белән урамнар атау да уңышлы дәвам итә.

Оешмабыз актив тормыш позициясе белән яши. Без нефть төбәгенең рухи мирасын, әдәби панорамасын тудыра алдык.

**Мансур Вәли,**

*әдәби тәнкыйть остаханәсе җитәкчесе*

# ТӘНКЫЙТЬНЕ ҖАНЛАНДЫРУ—УРТАК БУРЫЧ

Сүзебезнең башында ук шуны искәртеп үтәсе килә:

Безнең әдәби җәмәгатьчелек тәнкыйтьнең торышыннан беркайчан да канәгать булмады. Хәтта атаклы Ибраһим Нуруллиннар, Фәрваз Миннуллиннар, Нил Юзиевлар заманында да!

Ни өчен шулай килеп чыга соң?

Моның берничә зур сәбәбе бар. Шул сәбәпләрне ачыкламыйча, без әдәби тәнкыйтьне үстерә алмаячакбыз...

1. «Сөбханалла» дип әйтик—милләтебезнең иҗади мөмкинлекләре бик тә зур: бездә әдәби әсәрләр шактый ук мул күләмдә языла тора, басылып чыга тора. Димәк, алар хасил иткән фәлсәфи һәм эстетик проблемалар мәйданы да гаять зур! Ә безнең тәнкыйтебез исә, әлеге гаять киң мәйданны фәлсәфи һәм эстетик яктан эшкәртеп, үзләштереп өлгерә алмый! Икенче төрле итеп әйткәндә—атның алдарак, арбаның арттарак барырга тиешлеге кебегрәк, котылгысыз бер закончалык килеп чыга.

2. Совет чоры башланганнан бирле һәм әле соңгы елларда да бездә чын мәгънәсендәге бәйсез, иркле матбугатның булганы юк. Әнә шуна күрә, чын мәгънәсендә иркле матбугат булмаганга күрә, бездә чын әдәби тәнкыйть—гадел, кыю, үткен фикерле һәм кызыклы әдәби тәнкыйть үсәр өчен иң кирәкле шарт, төп нигез юк.

3. Безнең милләтнең иҗади практика белән шөгыльләнүче катламы—ягъни язучылар, шагыйрьләр катламы—шактый куәтле, күп санлы, ә менә әлеге иҗади процесс һәм әсәрләр хакында тирәннән, үзенчәлекле рәвештә фәлсәфи, эстетик яктан фикер йөртүче, әнә шул эш белән системалы рәвештә шөгыльләнүче зыялылар катламы исә чагыштырмача юка, ягъни азрак санлы.

Тагын бер сәбәп. Һәрбер автор да диярлек үзе язган әсәр турында югары фикердә була һәм, бер караганда, аны моның өчен гаепләп тә булмый шикелле. Чөнки әсәр—ул аның баласы кебек бит инде... Әнә шуңа күрә һәр автор да үз әсәренә матбугат, әдәби тәнкыйть тарафыннан игътибар көтә. Ә тагын да ачыграк итеп әйтсәк: һәр автор да диярлек бары тик мактау гына, җылы сүз генә көтә. Андый мөнәсәбәт юк икән—автор күнелендә ризасызлык туа, теленә исә «бездә тәнкыйть юк» дигән кискен сүзләр менә.

... Без сүз йөретә торган соңгы 3 ел турында уйланганда да әдәби тәнкыйтьтән канәгатьсезлек белдерергә сәбәпләр күп. Чөнки бу елларда бик күп һәм кызыклы әдәби әсәрләр, китаплар, хәтта менә дигән күптомлыклар дөнья күрде—ә аларга эстетик яктан бәһа бирү, аларны анализлау эше тиешле дәрәҗәдә актив бармады.

Кешелек дөньясының һәм, аерым алганда, безнең ил җәмгыятенең яшәү рәвеше үзгәрү аркасында, әдәби иҗат процессы үзе дә бик үзенчәлекле чор кичерә. Әнә шул хакта тирәннән уйланган, бүгенгене һәм перспективаны ачыкларга тырышкан җитди тәнкыйди хезмәтләр дә сирәк күренә... Соңгы елларда актив иҗат итүче бик талантлы әдипләребез, шагыйрьләребез бар—аларның иҗат портретларын тудыру өстендә дә безгә нәтиҗәлерәк эшләргә кирәк булгандыр...

Әмма, гадел булыйк: югарыда күрсәтелгән һәм тагын башка байтак җитешсезлекләр белән бергә, әдәби тәнкыйтебездә уңай күренешләр дә юк түгел бит.

Аерым алганда, соңгы корылтайдан соң ук, һәм тиз арада, әдәби тәнкыйть буенча махсус остаханә оештырылу—Язучылар берлегенең матур эше булды. Юк, ул остаханәдә тәнкыйтьчеләр үз казаннарында гына кайнап ятмыйлар. Алар әдәби процесска тәэсир итәрдәй чараларны байтак уздырдылар. Мәсәлән, «Идел»

журналының 2000 нче елгы октябрь санында Вахит Имамовның «Могикан» исемле повесте дөнья күргәч, тәнкыйтьчеләр һәм прозаиклар җыйналып «Хәзерге повесть турында» бик мәгънәле фикер алышу уздырдылар... Шулай ук шагыйрьләр остаханәсе белән берлектә үткәрелгән «Бүгенге поэмалар турында» сөйләшүгә дә иҗатчылар һәм тәнкыйтьчеләр күп килгән иде... Анда да кызыклы гомумиләштерүләр ясалды, җитди күзәтүләр, тирән мәгънәле чыгышлар булды... Һәр ике җыелышның материаллары матбугатта басылып чыкты, димәк алар тагын да кинрәк даирәгә барып иреште... Без, бергә җыйналып, әдипләребезнең иҗат портретларын язу эшенең ничек торышын да тикшердек... Икенче бер утырышта рецензия жанрындагы хәлләрне барладык... Ә остаханәнең тагын бер утырышын «Ватаным Татарстан» газетасына барып үткәрдек. Ул «әдәби тәнкыйтьне ничек җанландырырга?» дигән сорауга багышланган иде. Анда да күп иҗатчы катнашты, ул очрашуның тулы язмасы зур сәхифә булып газетада басылып чыкты.

«Казан утлары» журналында иң яхшы рецензиягә яисә әдәби тәнкыйть мәкаләсенә ачык иҗади конкурслар уздыру да, җиңүчеләргә бүләкләр бирү дә—редакциянең матур традициясенә әверелеп килә. Бу чаралар тәнкыйтьчеләрдә сизелерлек җанлану тудыра.

Ике корылтай арасында уздырылган «Туксанынчы еллар әдәбияты» дигән һәм ел буена барган зур сөйләшү дә иҗатчылар өчен җитди яңалык булды, күп санлы мәкаләләр «Казан утлары»нда басылып чыкты.

Татарстан Язучылар берлегенең әдәби тәнкыйть буенча бирелә торган Җамал Вәлиди исемендәге еллык премиясен булдыру да тәнкыйтьчеләрнең авыр шөгыленә стимул тудыру дип саналырга тиеш... Премияләр дигәннән: иҗат берлегебезнең һәр әдәби жанр буенча бирелә торган премияләрен булдыру—шулай ук мөһим чара. Бу—безнең иҗади казанышларыбызны билгеләүнең бер ысулы. Ләкин менә шигърият тармагының гына әлегә мондый, махсус премиясе юк. Аны булдырырга вакыт җиткәндер сыман. Шигърият буенча елга бер мәртәбә бирелүче, олуг шагыйребез Һади Такташ исемендәге премия булса—ямь өстенә ямь дип кенә кабул ителәчәк бит!

Соңгы елларда нәтиҗәле эшләүче тәнкыйтьчеләрдән Рифат Сверигинның, Рәфыйк Шәрәфиевнең, Әнвәр Шәриповның, Гөлчәчәк Галиеваның, Фәрит Бәшировның иҗат берлегебезгә тәкъдим ителүе һәм күбесенең инде аңа керүе—шулай ук җаваплы баскычны атлау булып тора.

Әдәби тәнкыйть язмаларын даими рәвештә һәм системалы биреп барып, «Казан утлары» журналы һәм «Мәдәни җомга» атналык газетасы әдәби процесс өчен юл күрсәткеч маяк ролен үтиләр. «Казан утлары» журналының җитәкчелеге, аерым алганда халык шагыйре Равил Фәйзуллин, бу жанрга ихлас кайгыртучанлык күрсәтә, әдәби тәнкыйть бүлегенең һәрбер кызыклы идеясенә яшел урам ача, ярдәм итә.

«Шәһри Казан» газетасы һәм аның җомга көннәрендә чыгучы «Илһамият» кушымтасы үзендә кыю, кызыклы мәкаләләр еш бирелү белән аерылып тора. Соңгы арада Рәмис Аймәт белән Нәсим Акмал эшли башлагач бу газета бигрәк тә җанланды: анда аерым әдипләргә багышланган тулы сәхифәләр бирелә, анкета сорауларына җаваплар урнаштырыла, проблемалы мәкаләләр еш чыга. Без «Илһамият»не үзенчә бер әдәби газета дип кабул итәбез.

Ике корылтай арасында талантлы каләм белән язылган бик күп әдәби тәнкыйть әсәрләре дөнья күрде. Фәүзия Бәйрәмованың «Казан утлары»нда басылган «Ак һәм кара көрәше» дигән, Дания Заһидуллинаның «Албастылар...» турындагы хезмәте, Лена Шагыйрьҗанның «Сүзләр...» дигән әсәре, Бикә Рәхимованың «Бакыр тышлы, көмеш тышлы...» язмасы—истә калырдай матур күренеш иделәр!

Бу елларда Рифат Сверигин проза турындагы саллы мәкаләләре белән, Фәрит Хатипов хикәяче Мәгъсум Хуҗинның бер әсәрен җентекләп анализлавы белән, Равил Рахмани Миргазиян Юнысның иҗади портретын тудыруы белән, Азат Әхмәдуллин бүгенге драматургия турысындагы мәкаләләре, «Әле нокта куймыйбыз исемле» җитди хезмәте белән безгә үрнәк күрсәттеләр.

Ике корылтай арасында шулай ук Рифә Рахманның «Шәһри Казан» битләрендә, Нәҗибә Сафинаның бөтен газета-журналларда да диярлек, Әлфәт Закир-

жановның «Ватаным Татарстан» һәм «Казан утлары»нда, Айдар Хәлимнен «Мирас»та һәм башка басмаларда гаять үзенчәлекле тәнкыйди язмалары урын алды.

Халык шагыйре Равил Фәйзуллин, күренекле шагыйрьләр Рәдиф Гаташ белән Зөлфәт үз каләмдәшләре турында тирән эчтәлекле житди мәкаләләр бастырдылар.

Авыр чор булса да, әдәби тәнкыйть китаплары да чыккалап тора. Ижади берлегебез житәкчесе Фоат Галимуллинның «Әле без туганчы» исемле кин колачлы хезмәте, Тәлгат Галиуллинның «Шигърият баскычлары» исемле китабы, Равил Фәйзуллинның мәкаләләрдән торган ике томлыгы, Фәрит Бәшировның тәүге китабы—безне сөендерделәр.

Бу чорда Дания Заһидуллина белән Фәрит Бәширов докторлык, Рифә Рахман кандидатлык диссертацияләре якладылар һәм сафларыбызны теоретик яктан нык әзерлекле кадрлар буларак тагын да ныгыттылар.

Әйе, әдәби тәнкыйть тармагында күзгә күренерлек уңышларыбыз да бар—аларга күз йому ярамас. Ләкин, шулай ук килешергә кирәк,—тәнкыйтькә кыюлык, активлык житми. Менә бу яна корылтайдан сон, әдәби тәнкыйтебезне жанландыру—ижади берлегебезнен ин төп эшләреннән берсенә әйләнсен иде. Ә бәлки безгә «Әдәбият» дигән аерым басма булдыру мәслихәттер? Менләгән укучыларга, студентларга, укытучыларга, язучыларга һәм журналистларга—бөтен әдәбият сөючеләргә ярдәмче һәм хәзерге зур әдәбият дингезендә юл күрсәтүче булыр иде бит ул. Әдәби тәнкыйтьне үстерү ул басманың ин төп максаты булыр иде!

Ничек кенә булмасын: тәнкыйтьне жанландыру—уртак бурыч. Бу корылтайдан сон без барыбыз бергәләп әнә шул мөһим эшкә тотынсак иде!

## Рафис Корбан

## БАЛАЛАР КИТАБЫНА МӨНӘСӘБӘТ

Балалар әдәбияты беребез өчен дә чит түгел. Бу гүзәл бакчага кереп чыкмаган бер генә язучы да юктыр. Алма урларга түгел, алмагач йә чәчәк утыртырга кергәлиләр. Әмма, дөресен генә әйткәндә, ижатларын тулысы белән бары тик балалар әдәбиятына гына багышлаган бер генә язучы да юк бүген безнен арада. Шулай да балалар өчен аеруча уңышлы, талантлы әсәрләр ижат итүчеләр бар. Һәм алар Аллага шөкер, шактый! Докладны әзерләгәндә мин ике корылтай арасында балалар өчен китап чыгарган язучыларнын исемлеген төзедем. Ул исемлек жәмгысе 50 ләп автордан тора.

Мин иллеләп язучынын китабы дидем. Ләкин китапларнын ин яхшылары, «менә ичмасам китап бу!» дип сокланып укырдайлары, нигездә ике нәшриятта басылган—Татарстан китап нәшриятында һәм «Мәгариф»тә.

Бүгенге балалар китапларынын сыйфаты хакында «Казан утлары» журналынын быелгы апрель санында «Мәгариф» нәшрияты директоры Мөдәррис Вәлиевнен «Сөенсеннәр әле сабыйлар» дигән мәкаләсен күбегез укыгандыр. Балалар китабы проблемалары хакында «Мәгариф» нәшрияты каланчасыннан торып кына язылмаган, төпле, урынлы мәкалә бу. Әйе, «Мәгариф»нен төп вазифасы—уку-укыту әсбапларын әзерләп бастыру. Ә инде балалар китабын нәшер итү «Мәгариф» өчен, Шәүкәт Галиевнен бер шигырендә әйтелгәнчә, «төп эштән сон башкарыла торган төп эш» булып кала. Менә шуна күрә дә һәртөрле тикшерүләр вакытында «Мәгариф» нәшрияты житәкчеләренә дә, шулай ук Татарстан китап нәшрияты житәкчеләренә дә әлеге төпченүче, таләпчән тикшерүчеләр каршында үзләренен хаклыкларын исбатлап

шактый гына тир түгәргә туры килә. Имеш, хөкүмәт тарафыннан бирелгән акча «нецелесообразно» сарыф ителгән.

Мөдәррис Харисович балалар өчен китап чыгаруны президентыбыз фатихасы белән һәм хөкүмәтебез карары нигезендә эшләнә дип язып, булган проблемаларны никадәр генә йомшартырга тырышса да, мәсьәлә һаман да хәл ителмәгән килеш кала бирә. Ә мәсьәлә шуннан гыйбарәт: балалар өчен китапларны гафу ителмәслек дәрәҗәдә бик аз чыгарабыз! Татарстан китап нәшрияты, мәсәлән, 1999 елда—13, 2000 елда—10, 2001 елда—13 балалар китабы бастырып чыгарды. Быел 15 ләп булыр дип көтелә. «Мәгариф» 1999 елда—4, 2000 дә—8, 2001 дә—6 балалар китабы чыгарды. Язучыларыбызның затлы-затлы китапларын чыгарган «Рухият», «Раннур» нәшриятлары да балалар китабы чыгарырга бик атлыгып тормыйлар. Әлегрәк балалар өчен матур-матур берничә китап чыгарган «Заман» нәшрияты да бу изге эштән туктап калды. Сәбәп ачык—балалар китабының үзкыйммәте югары. Ул табышлы эш түгел. Ә әлеге нәшриятлар табыш алу өчен эшли. Шуна күрә, балалар китабын чыгару нигездә дәүләт дотациясендә яшәүче нәшриятлар эше булып кына кала. Ә ул нәшриятларның, әйткәнемчә, балалар китабына булган ихтыяҗны тулысынча канәгатьләндерерлек дәрәҗәдә эшләргә мөмкинлекләре юк. Юрганнарына карап аякларын сузарга мәҗбүрләр. Елына әнә шул 10-15 балалар китабы белән чикләнергә туры килә.

Татарстан язучыларының беренче съездында балалар әдәбияты хакында ясаган чыгышларында Муса Җәлил белән Фатих Кәрим: «Бездә әле балалар язучыларының хезмәтләрен исәпкә алмау, ул язучының иҗатына зурлар өчен язылган әсәрләр белән бер дәрәҗәдә бәя бирмәү шушы көнгә кадәр яшәп килә»,—дип әйткән булганнар. Кызганычка каршы, хөрмәтле каләмдәшләр, моннан 68 ел элек әйтелгән бу сүзләрне бүген, егерме беренче гасырга чыккач та кабатларга мәҗбүрбез. Зур үкенеч белән шуны әйтәсем килә: мин Татарстан язучыларының соңгы дүрт корылтаенда катнаштым, бүгенгесе—бишенчесе һәм һәрберсендә дә балалар әдәбияты хакындагы докладларда нигездә бер үк сүзләр кабатлана—балалар әдәбиятына, балалар китапларын чыгаруга мөнәсәбәт тиешле дәрәҗәдә түгел! Кызганыч. Моның сәбәбе бер генә—ул да булса, балалар әдәбияты, балалар китабына карата дәүләт сәясәте булмау. Балалар әдәбиятын һаман да икенчел итеп күрү. Яна кеше тәрбияләү эшендә балалар әдәбиятының әһәмиятенә тиешле бәяне биреп бетермәү.

Балалар китабына мөнәсәбәт ул безнен җәмгыятебезнен йөзен күрсәтә.

Бүген бездә ятим балалар проблемасы килеп туды. Мин Бауман урамы буйлап эшкә йөрим. Андагы урам малайларын күреп йөрәк әрни. Бу да, мәгълүм бер дәрәҗәдә, китапка мөнәсәбәт күрсәткече бит! Мәскәүдә Президент Путин «беспризорниклар» мәсьәләсен күтәргән булды. Бездә дә нәрсәдер шаулашкан булдылар. Ләкин бит болар барысы да чираттагы компанейщина гына! Ә ныклап бер эш тә эшләнми! Телевизордан ни генә күрсәтмиләр: үтереш, суеш, секс, урлашу, бандитизм! Шуларны гына карап үскән, китап укымаган балалардан нәрсә көтәргә мөмкин?!

Балалар китабы хакында шулай җаелеп, хәтта ике съезд арасында дөнья күргән китапларга тәфсилле күзәтү ясамыйча да, тукталуымның сәбәбе шунда: мин бүген «бары тик балалар китабы чыгару белән генә шөгыльләнүче аерым нәшрият булдырырга кирәк!» дигән иске тәкъдимне яңадан күтәреп чыгарга телим. Мөдәррис Вәлиев моннан берничә ел элек язучыларыбызның «Балалар әдәбияты яклауга мохтаҗ» дип аталган хат белән республика житәкчеләренә мөрәҗәгать итүләре әзсез калмады дип билгеләп үтсә дә, минемчә, ул хат әле дә актуальлеген югалтмады, хәтта әле көтелгән нәтиҗәсез дә калды кебек. Чөнки китапларыбызның саны, язучыларның китап чыгару мөмкинлекләре нык кимеде. Классикларыбызның балалар өчен язган әсәрләрен яңадан бастырып чыгару юк дәрәҗәсендә! Мирасны кайтару, балалар әдәбияты мирасын кайтару да юк. Ибраһимовларны онытканда бер булса да чыгаргалап торабыз, ә менә Мәҗит Гафури, Нәҗип Думави, Һади Такташ, Фатих Кәрим, Абдулла Алиш, Муса Җәлил, Хәйретдин Мөҗәй, Мөхәммәт Әхмәтгалиев, Әхмәт Фәйзи, Бари Рәхмәт, Зәкия Туфайлова, Әминә Бикчәнтәева, Шәйхи Маннурларның балалар өчен язган әсәрләрен бүгенге балаларыбыз каян алып укысын? Исән язучыларыбыз да балалар өчен иҗат иткән ин яхшы әсәрләрен кабат-кабат бастырудан мәхрүм.

Мәрхүм Хәкимҗан Халиков, гомере буе балалар өчен иҗат итеп, үзенен каты тыш белән, затлы итеп чыгарылган бер китабын да күрмичә арабыздан китеп барды.

Быел чыккан «Сакаллы малай» дигән китабын да күрмичә җан тәслим кылды. Гомере буе балалар өчен иҗат итеп, ничәмә буын балалар өчен матур-матур хикәяләр, повестьлар язган, үзгәртеп кору матавыкларына килеп кергәч, 70 яше тулган көнгә дә китабын бастырып чыгару бәхетеннән мәхрүм калган, инде 80 яше тулып килгәндә шул хәл кабатланмасмы дип куркып яшәүче күренекле әдибәбез Ләбибә апа Ихсанова, быел лаеклы ялга чыгучы әдибәбез Эльмира Шәрифуллина, шулай ук гомере буе балалар матбугатында эшләгән, матур-матур хикәяләр, повестьлар, әкиятләр иҗат иткән Роза Хафизова, шагыйрә Мәрзия Фәйзуллина һәм тагын бик күпләр шатланып җинел сулыш алмас иде микән балалар китабы нәшрияты оештырылса?! Гомерләре буе балалар әдәбиятына хезмәт итеп тә, балалар өчен 4-5 елга бер китап чыгару бәхетен генә татучы күренекле әдипләребез Шәүкәт Галиев, Рабит Батулла, Җәүдәт Дәрзаман, Рәшит Бәшәр, Энже Мөэминова, Адлер Тимергалиннар сөенмәс иде микән?! Әйе, балалар китабына дәүләт сәясәте булмыйча торып, балалар китабы нәшрияты оештырылмыйча торып, балалар өчен төрле жанрлардагы, төрле юнәлештәге, төрле эчтәлектәге, төрле максатларны күз алдында тотып чыгарылган китапларны күрербез дип һич тә өметләнеп булмый.

Кыскасы, мин үз чыгышымны, хөрмәтле каләмдәшләр, сезгә шундый мөрәҗәгать белән төгәлләргә телим: бүгенге корылтайда республикабызда балалар китабы нәшрияты оештыруны сорап Президентыбызга һәм хөкүмәт җитәкчеләренә мөрәҗәгать белән чыгарга, бу хакта корылтайның резолюциясенә язарга һәм бүген сайлана торган яңа идарәгә әлеге нәшриятны оештыру буенча конкрет эш башкару бурычын йөкләү турында махсус карар кабул итәргә кирәк!



## «Казан утлары» елъязмасы

**Моннан 50 ел элек (1952)** «Совет әдәбияты» журналында **Әмирхан Еникинең** «Рәхмәт, иптәшләр!» *(№ 8-10)* повесте, **Таҗи Гыйззәтнең** «Данлы көннәр» *(№ 7)* пьесасы басылган.

**Моннан 45 ел элек (1957)** «Совет әдәбияты» журналында **Ибраһим Газиның** «Онытылмас еллар» романының икенче кисәге *(№ 2)*, **Нәби Дәүлинең** «Тормыш белән үлем арасында» *(№ 6-8)* әсәре, **Рафаил Төхфәтуллинның** «Авылдашым Нәби» *(№ 5-6)* повесте укучыларга тәкъдим ителгән.

**Моннан 40 ел элек (1962)** «Совет әдәбияты» журналында **Гариф Ахуновның** «Хәзинә» *(№ 8-10)* романы, **Салих Батталның** «Сигезенчесе кем?» *(№ 6-7)* повесте, **Ибраһим Газиның** «Онытылмас еллар» әсәренең өченче *(№ 6-12)* кисәге, **Булат Сөләйманов** *(№ 4)* һәм **Сажидә Сөләйманова** *(№ 1, № 12)* шигырьләре урын алган.

**Моннан 30 ел элек (1972)** «Казан утлары» журналында **Шамил Бикчуринның** «Каты токым» *(№ 5-7)* романы, **Аяз Гыйләҗевның** «Урталыкта» *(№ 8)* әсәре, **Гөлшаһиданең** «Минем кала алуым» *(№ 12)* повесте, **Мөхәммәт Мәһдиевнең** «Фронтовиклар» *(№ 1-4)* романы, **Резеда Вәлиеваның** «Толымнарын...» *(№ 10)* шигыре, **Миргазиян Юнысның** «Энже эзләүчеләр» хикәясе *(№ 10)* дөнья күргән.

# ТӨРКИЯДӘГЕ ИКЕ МИЛЛӘТТӘШЕМ

Язмышның кырыс вә рәхимсез җилләре тарафыннан җир йөзенә сибелгән татарларның сан буенча төп өлеше Төркиягә туры килә. Милләттәшләребез ул илгә төрле чорларда, төрле яклардан—Русиянең Идел-Урал буйларыннан, Себер кинлекләреннән, Кытай, Япония, Кореядан дулкын-дулкын, төркем-төркем булып барганнар һәм хәзерге көндә Төркиянең дүрт-биш шәһәрендә, өч-дүрт авылында тәмам җирләшеп гомер кичерәләр.

Төркиядә яшәгән төрки-татарларның төгәл санын бирү дә кистереп кенә әйтә алмыйм, чөнки бу четерекле эш белән берәү дә, беркайчан да шөгыльләнмәгән. Алай да матбугат битләрендә кайбер якынча саннар очрый. Узган гасырның җитмешенче елларында Анкарада чыгып барган «Казан» журналында мәгълүм татар-төрки профессоры Надир Дәүләт «Төркиядә Казанлылар» дигән мәкалә бастырган. Анда ул шул заманда Анкарада 900-1000, Истанбулда 500-600, Иске шәһәрдә 300-400, Измирдә 20-30, башка шәһәрләрдә 90-100 чамасы «Казан төреге» яшәвен хәбәр итә *(«Казан».—1975.—15 сан.— 31 б.)*. Шул ук вакытта мәкаләдә Төркия авылларында яшәүче татарлар хакында бер ни дә әйтелми. Моннан ун еллар элек Казанда оешкан «Ватан» җәмгыятендәге мәгълүматлар буенча Төркиядә гомер итүче татарлар саны ун меңгә якын дип исәпләнә иде. Мин үзем менә шушы санны дөреслеккә якындыр дигән фикердә торам. Монда шунысын да истән чыгармаска кирәктер: Төркиядә яшәүче татарларның шактые инде төрекләшкән дияргә була, чөнки телләр якынлыгы, дини мохит бердәмлеге һәм мәдәни тормыштагы уртаклыклар табигый рәвештә төрекләшүгә булышлык иткән. Нәтиҗәдә, байтак татарлар ерак тамырларын хәтерләсә дә, туган телләрен онытып, бүген инде төрек булып йөриләр. Моның мисаллары бихисап, тик аларга бу урында тукталып тормыйбыз...

Әйе, бусы шулай. Әмма Төркиядә гомер итүче татарлар арасында үз милләтен онытырга теләмәгән затлар да аз түгел. Боларның төп өлешен Төркиягә 1950 еллардан соң Ерак Көнчыгыш илләреннән күченеп килгән татар зыялылары тәшкил итә. Алар бүген дә Русиядәге сәяси вәзгыять белән кызыксынып, Татартстанның, татар халкының язмышы өчен борчылып, хафаланып яшиләр. Үзара очрашканда алар туган телләрендә сөйләшүдән, милли моңнарны тыңлаудан, милли ашларны авыз итүдән әйтеп бетергесез ләззәт һәм тәм табалар...

Минем бу мәкаләмдә гомерләре Төркия белән бәйләнгән шундый ике зат турында сүз бара. Аларның берсе—Фәрит Бичури, икенчесе—Мәхмүт Әлүкәй. Икесе дә Төркиядә тереклек итүче татарларның мәдәни һәм җәмгыяви тормышында хөрмәтле урын биләүче мәгълүм шәхесләр, икесе дә Казанда булып, монда үзләренә дуслар тапкан ачык күңелле, самими кешеләр. Әмма бу урында кайгылы бер хәлне искә төшерергә мәҗбүрбез. Моннан ел ярым әүвәл һич көтмәгәндә Мәхмүт әфәнде Әлүкәй бу якты дөньяны калдырып мәңгелек йортка күчте... Урыны оҗмахта булсын!

Төркиядә очрашкан вакытларымда мин бай рухлы бу ике милләттәшемнең гомер юллары турындагы истәлекләрен язып бардым. Берничә дәфтәр җыелды. Гаҗәеп хатирәләр. Алар кызыклы һәм гыйбрәтле, чөнки алар гадәти түгелләр. Бу истәлекләрдә мөһаҗирлек язмышына дучар булган татарларның йөрәк тибеше ишетелә, алар—халкыбыз тарихының онытылмаска тиешле кыйммәтле сәхифәләре.

## Фәрит Бичури

Аның белән очрашулар хәтердә уелып калучан. Сәбәбе шулдыр, ул дөньяви хәлләрне, сәясәт нечкәлекләрен, төрле халыклар тарихын әйбәт белә, саф татар телендә сөйләшә, теле үткен, вакыты белән ачы... Мин ул сөйләгәннәрне композицион яктан тәртипкә китереп җыйнакладым. Истәлекләренең эчтәлеге шул хәлендә калды.

—Минем тәкъдир дәфтәремдә шаккатырлык хәлләр язылган дип әйтә алмыйм,—дип башлады ул сүзен беренче күрешкәндә. Бу күрешүебез 1995 елның маенда Бичуриларның Мәрмәр дингезе буендагы дачасында булган иде.—Язмышым юллары Кытайда башланып, Төркиядә дәвам итте, күрәсең, шушында тәмамланыр да. Тәкъдирнең ата-бабаларым яшәгән җирдән аерып, ят илләр белән бәйләве күңелдә төрле уйлар уята, бу миңа гайре табигый бер хәл булып күренә. Дөрес, татар халкы тарихына күз салсаң, анда һиҗрәт кылучылар, бәхет эзләп чит җирләргә китүчеләр бихисап булган. Бу сыйфаты белән безнең халык алдынгылар рәтендә тора шикелле.



*Сулдан уңга: Фәрит Бичури һәм Илбарис Надиров. Истанбул, 2002 ел.*

Мин 1946 елның августында Харбин шәһәрендә туганмын. Булачак әтием Таһирның гаиләсе Кытайга Русиядәге кызыл кузгалыштан соң Пензадан күченеп килгән. Ул вакыт әтием әле сабый гына була. Әнием Сатыйга Кытайда 1920 елда дөньяга килгән. Ул бүген дә Истанбулда безнең белән матур гына гомер кичерә. Аның әти-әнисе хәзерге Башкортстанның Бөре районы Борай авылыннан. Бабам Шәрәфи зур байлардан саналган. Ул яшәгән йорт әле дә исән, анда хәзер музыка мәктәбе. Русиядә булган чакларымда мин Борай авылындагы туган-тумачалар белән күрешеп торам. Күрешкән саен, миндә туган җиргә якынлык тойгысы көчәя бара дисәм, бу арттырып сөйләү булмас.

Әтием белән әнием Харбинда 1942 елда өйләнешкәннәр. Тик озакламый Кытайда яшәүче төрле милләт мөһаҗирләре тормышында газаплы чор башлана. Илленче еллар башында Кытай коммунистлары оештырган «культура революциясе» андагы мөһаҗирләрне дөнья буйлап кабат куалый. Кытайдан татарлар гына түгел, руслар да, яһүдләр дә Америка, Австралия, Канада, Төркия кебек илләргә күчеп китәргә мәҗбүр булалар... Шулай итеп, әти-әнием ике яшь баланы—Фәридә апам белән мине алып Төркиягә киләләр. Мин шушында урта белем алдым, лицей бетердем, университет тәмамлап инженер-механик булдым. 1970 елда Истанбулда яшәүче татар кызы Рәшидә белән гаилә кордык. Аның әтисе чыгышы белән Бөредән, әнисе—Пензадан. Рушан һәм Йолдыз исемле ике кыз үстердек. Зур кызыбыз югары белем алып, әйбәт кенә эшләп йөри, кече кызыбыз әле институтта укый. Сүз ара сүз дигәндәй, бер уңайдан Рушанның 1991 елда Казанда булуын һәм «Идел» халыкара яшьләр лагерында ял итүен дә искә төшерәсем килә. Шул вакыттан башлап Рушан Казандагы дуслары белән элемтә тота. Шуларның берсе—«Азатлык» радиосының күптәнге хезмәткәре Лилия белән алар көн аралаш диярлек Интернет челтәре аша хәбәрләшеп торалар. Без гаиләбездә татарча сөйләшәбез, милли музыка тыңларга яратабыз, кызларыбыз Казанда басылган татар китапларын рәхәтләнеп укыйлар. Гомернең гаилә белән бәйле өлеше турында менә шуларны әйтәсем килде.

Фәрит Бичури белән безнең икенче әңгәмәбез 1998 елның маенда Истанбул үзәгендәге «Таксим-Селект» дигән кунакханәдә булды. Бу юлы мин

аннан Төркиягә килгәннән соң мондагы татарларның иҗтимагый-мәдәни тормышында катнашуы белән бәйле истәлекләрен сөйләвен үтендем. Әмма ул сүзен ерактан башлады һәм Төркиядәге татарлар тарихының аз билгеле сәхифәләре хакында кызыклы гына мәгълүматлар хәбәр итте.

—Тарихтан белүемчә—диде ул,—татарларның берничә меңнән торган зур төркемнәре Русиядән Төркиягә XIX гасыр ахыры, XX гасырның башында күченеп килгәннәр. Аларның төп өлешен хәзерге Татарстанның Бөгелмә, Шөгер, Аксубай якларыннан, Уфа, Оренбург, Самара тирәләреннән, Омск янындагы авыллардан чыккан крестьяннар тәшкил иткән. Ул вакытлардагы төрек падишаһы Солтан II Габделхәмит аларга Искешәһәр, Конья, Кутаһия шәһәрләре янындагы буш җирләргә урнашырга рөхсәт биргән. Нәтиҗәдә, Әфәнде Көпрүсү, Зинҗирликуйу: Куруһуйук, Бөйруделик исемле татар авыллары барлыкка килгән.

Аннары Фәрит Бичури бу авылларның кайберләрендә үзенең дә булганлыгын искә төшерде.

—Дөресен әйткәндә, ул авылларда милли тормыш билгеләре елдан-ел кими бара,—диде ул уфтанып.—Ни өчен дисәң, аларда татар мәктәпләре булмау сәбәпле, яшьләр туган телләрендә сөйләшүне онытып баралар, милли рух бирердәй клублар да, матбугат та юклыгы үзен нык сиздерә. Табигый ки, андый шартларда төрекләшүдән котылу мөмкинлеге юк диярлек...

Үзенең тарихи истәлекләрен дәвам итеп, Фәрит Бичури янә мөһим генә хәбәрләр сөйләде. Аның әйтүенчә, Төркиядәге татар мөһаҗирләренең икенче катлавын узган гасырның 50-60 елларында Ерак Көнчыгыш илләреннән күчеп килгән милләттәшләр тәшкил итә. Болар инде шәһәри татарлар, күпчелеге Харбин, Хайлар, Муклен, Тәнзин кебек шәһәрләрдә яшәп, шәһәр мәдәнияте рухында тәрбияләнгән, укый-яза белүче, чит телләрдә сөйләшә алучы һөнәрле татарлар. Кагыйдә буларак, алар Төркиянең эре шәһәрләрендә яшиләр. Бу татарлар Кытайда һәм башка илләрдә торганда күңелләренә сеңгән милли гореф-гадәтләрне дәвам итәргә теләп, үзләре урнашкан Төркия шәһәрләрендә мәдәни мохит булдыру, яшьләр өчен күңел ачу урыннары табу, матбугат оештыру юлларын эзлиләр. Башкача әйткәндә, әүвәлдән милли идея белән сугарылганга күрә, алар монда да татарны саклау турында уйланалар. Бу эшләрне башкару мәшәкатьләрен, табигый, яшьләр үз өсләренә алалар. Шул уңайдан Фәрит Бичури 1963 елның көзендә Истанбулда оешкан «Тукай яшьләр клуб»ын хәтергә төшерде.

—Мин инде 17 яшьлек егет идем,—дип дәвам итте ул истәлеген.—Дәртле, гайрәтле чак. Кытайдан Истанбулга күчеп килгән гаиләләрдә минем кебек яшьләр байтак иде. Тукай клубын оештыруны бергәләп башкардык. Бу эшкә мәгънәви юнәлеш, милли эчтәлек бирүдә безгә өлкәннәр киңәш-ярдәм итеп тордылар. Монда иң әүвәл татар тарихы буенча мәкаләләр, шигырь китаплары язган танылган табиб Әхмәт Ләбиб Каранны хөрмәт илә телгә аласым килә. Казан тирәсендәге Каран авылында туган бу акыл иясе чын мәгънәсендә милләтче иде. Тукай клубына һәм шул ук 1963 елда басыла башлаган «Тукай бюллетене» исемле кулъязма журнал өчен дип ул безгә үз йортының астагы катын бирде, без шунда җыелыша идек. Тукай клубының мәдәни эшчәнлеге 1969 елга кадәр дәвам итте. «Тукай бюллетене» дә шул елларда чыгып барды. Алар бер-беренә тыгыз бәйле иде.

Тукай клубын мин Төркиядәге татарларның милли-мәдәни тормышына җан биреп торган бер үзәк булды дияр идем. Истанбулда корылган булса да, клуб оештырган Тукай кичәләренә Анкара, Искешәһәр, Измир һәм башка шәһәрләрдән, авыллардан халык төркем-төркем килә иде. Без андый кичәләрне елына дүрт-биш мәртәбә үткәрә идек. Кайвакыт бишәр йөз кеше җыела иде. Клубта үзебезнең кечкенә оркестрыбызны булдырдык. Кичәләр барганда ул милли көйләр уйнап тора, татарча җырлар җырлата, биюләр биетә иде. Иң яраткан күмәк җырыбыз «И туган тел» иде. Үзебезнең театр түгәрәген дә оештырдык. Хәтеремдә, һәвәскәрләребез сәхнәдә Галиәсгар Камалның «Беренче театр», «Өйләнү түгел, сөйләнү», Гаяз Исхакыйның «Җан Баевич» комедияләрен уйнап күрсәттеләр. Кичәләр үткәрүдән, театр уеннарыннан

кергән акчаны аренда өчен, музыка кораллары, костюмнар әзерләү өчен тота идек. Татарстан белән бәйләнешләр бөтенләй өзелгән еллар иде. Алай да без Америка, Финляндиядә яшәүче татарлар ярдәмендә Илһам Шакиров, Фәридә Кудашева, Рәшит Ваһапов, Әлфия Авзалова пластинкаларын, җыр-нота китапларын клубта булдырырга тырыша идек.

Монда тагын Тукай клубының Төркиядә яшәгән аерым татар галимнәре һәм журналистлары белән очрашулар үткәрүен дә искә төшерү кирәктер. Андый очрашуларда мин Абдулла Баттал Таймас, Рәшит Рәхмәти Арат, Әхмәт Тимер, Ләбиб Каран, Әхмәтвәли Меңгәр, Мәхмүт Таһир, Рифат Мөхтәсиб, Наилә Бинарклар катнашканын әйбәт хәтерлим... Бу зыялылар безгә татар тарихының төрле мәсьәләләре буенча лекцияләр укыйлар, сорауларыбызга җаваплар бирәләр иде. Ахырдан без алар өчен чәй мәҗелесе тәртипли идек...

«Тукай яшьләр клубы»ның төп максаты Төркиядәге татарларның рухи тормышын эчтәлекле итү иде. Берүк вакытта без үзебезне төрекләргә таныту максатын да күз алдында тоттык. Клуб оештырган концертларга төрекләрне, шулай ук төрек-татар катнашындагы гаиләләрне дә чакыра идек. Мондый аралашулар ике халык мөнәсәбәтләрен ныгытуда азмы-күпме булышкандыр дип уйлыйм.

«Тукай бюллетене» турында да берничә сүзем бар. Әйтүемчә, ул кульязма журнал иде. Күләме кечкенә, бит санын хәтерләмим инде. Аена бер мәртәбә чыгып килде. Аны 100-150 данәдә күбәйтеп бастыра идек. Журналда Төркия татарлары тормышыннан кыска-кыска мәгълүматлар, танылган зыялыларыбыз хакында хәбәрләр, Тукай клубының эшчәнлеге белән бәйле парчалар, мәдәни хәяткa караган белдерүләр төп урынны алып тора иде. Без журналны Төркиядә генә түгел, Америка, Финляндия, Алмания һәм башка илләргә дә тарата идек. Янә шуны әйтүне дә кирәк саныйм. Тукай клубы һәм дә «Тукай бюллетене» белән бәйле вазыйфаларны башкару бер төркем яшьләр җилкәсенә төште. Шуларның берничәсен искә төшерәсем килә. Алар—Надир Дәүләт, Фәри Аги, Адилә Айгүн, Рәшидә Дәвеш...

Алда әйткәнемчә, яшьләр клубы да, бюллетень дә 1969 елда яшәүдән туктадылар. Әмма тормыш тукталмады. 1970 елда Анкарада «Казан төрекләренең мәдәни һәм ярдәмләшү җәмгыяте» оешты. Аны үзенә күрә «Тукай яшьләр клубы»ның шул заманга яраклы бер дәвамы дип санарга була кебек. Җәмгыять үз тирәсенә яшьләрне һәм өлкәннәрне җыйды, Төркиянең төрле шәһәрләрендәге татарлар белән элемтәләрне көчәйтте, аралашуларның яңа юлларын билгеләде. Бу җәмгыятьнең Истанбул белән бәйле кайбер эшләрен үзем башкарган чаклар да була иде. Җәмгыятьнең беренче рәисе итеп Рәүф Кереш дигән зыялы татар сайланганы истә калган. Үкенечкә күрә, «Казан төрекләре» җәмгыяте озын гомерле булмады, 1979 елда төрле сәбәпләр аркасында ябылды да кабат торгызылмады.

Шунысы игътибарга лаек, 1970 елда Анкарада «Казан» журналының беренче саны дөнья күрде. Моны без «Татар бюллетене»нең уңышлы дәвамы дип кабул иттек. «Казан» журналы турында Татарстанда беләләр дип уйлыйм. Ул 1980 елга хәтле чыгып килде. Ун елга якын арада аның 23 саны басылды. Кызыклы, файдалы басма иде. Аның кыйбласы Төркиядә яшәүче татарларга гына түгел, чит илләрдәге татарларга да төбәлгән иде. Ул журналда үземнең дә берничә мәкаләм басылды. Редколлегиясендә танылган тюрколог Әхмәт Тимер, Мәхмүт Таһир, Рифат Мөхтәсиб, Надир Дәүләт, Наилә Бинарклар эш алып барды, ә доктор Мәхмүт Әлүкәй журналның шәрәфле редакторы булды. Бу журнал татар диаспорасы тарихын өйрәнүчеләргә менә дигән чыганак булып тора дип уйлыйм, чөнки анда тарихка, әдәбиятка һәм сәнгатькә караган мәгълүматлар гаять күп. Журналны бастыру, тарату чыгымнарын Алманиядә корылган «Мерседес-Бенц» фирмасының Төркиядәге хуҗасы Әхмәтвәли Меңгәр үз өстенә алды. Ул анда үзе дә татарлар тарихы турындагы кызыклы мәкаләләре белән катнаша иде...

Белүемчә, хәзерге вакытта Төркиянең берничә шәһәрендә татарлар тарафыннан корылган эреле-ваклы мәдәни җәмгыятьләр бар. Искешәһәрдә ул «Идел-Урал төрекләренең мәдәни вә ярдәмләшү җәмгыяте» дип атала.

Аларның эшчәнлегендә төп урынны бергәләп дини бәйрәмнәр үткәрү, җәй башында Сабантуй бәйрәмен тәртипләү, шунда укучы татар-башкорт студентлары белән сирәк булса да җыелып милли кичәләр уздыру кебек эшләр алып тора. Ул җәмгыятьләрнең матди мөмкинлекләре бик аз, шул сәбәпле мәдәни тормышка бәйле күп кенә хыялларын тормышка ашыра алмыйлар. Шунысы да кызганыч, «Казан» журналы чыкмый башлагач, Төркиядәге татарларның иҗтимагый тормышы, бүгенге хәлләре һәм ихтыяҗлары турында хәбәрләр бирердәй матбугатыбыз тернәкләнеп китә алмады...

Өченче очрашуыбыздан файдаланып *(Истанбул, 2002, гыйнвар, «Йолдыз» кунакханәсе)*, мин Фәрит Бичуридан аның 1990 еллардан соң Казанга килүләре белән бәйле хатирәләрен сөйләвен үтендем. Ул истәлекләр шактый озын вә тәфсилле килеп чыкты. Мин аларның кызыклы һәм үзенчәлекле булып тоелганнарын бирегә күчердем.

—Читтәге татарларның туган якларына кайта алмыйча, туганнарын күрә алмыйча яшәүләре бигрәк тә озакка сузылды шул. Советлар иле белән башка илләр арасына корылган тимер диварлар җимерелүен көтә-көтә меңләгән җаннар сагыштан саргаеп, тилмереп күзләрен йомды. Инде, иншалла, безгә-яшьрәкләргә ул диварлар җимерелүен күрү насыйп булды, сиксәненче еллар ахырында, туксанынчы еллар башында йөзләгән татар тарихи ватаннарына кайтып, ата-бабалары рухына зиярәт кылдылар, туган-тумачаларын күрделәр, Ватан дип аталган газиз җирнең йомшак туфрагы җылысын күңелләренә сеңдереп ләззәт кичерделәр. Мин дә шуларның берсе идем. Татарстан җиренә беренче кат аяк басуым 1992 елда булды. Ул вакыт Казанда дөньяга таралган татарлар белән бәйләнешләр оештыру өчен корылган «Ватан» җәмгыяте дәртләнеп эш алып бара иде. Мин Казанга шул җәмгыять чакыруы буенча килгән идем. Җәмгыять рәисе Дамир Гыйсметдин белән шунда таныштык. Ахырдан без аның белән дуслар булып киттек. Сез дә, Илбарис абый, шул җәмгыятькә булышып йөри идегез. Безнең танышуыбызга, димәк, быел ун ел тулачак икән. Ул көннәрдә «Ватан» бөтендөнья татарларының беренче Корылтаена хәзерлек эшләре белән шөгыльләнә иде. Чит илдә яшәүче бер татар буларак мин дә шул эшләрдә катнаштым. Шул вакытлардан башлап «Ватан» җәмгыяте мине үзенең идарә әгъзасы итеп сайлады. Берничә ел дәвамында мин җәмгыять эшчәнлегенә хәл кадәри ярдәм итәргә тырыштым...

—Төркиядән сайланган делегат сыйфатында Беренче бөтендөнья татар конгрессы корылтае эшендә катнашкан көннәрем әле дә хәтеремдә саклана. Гади сүзләр белән генә аңлата алмаслык олы, тарихи вакыйга булды ул Корылтай. Төркиядән 34 делегат килгән иде. Корылтайның төп утырышында аларның өчесе чыгыш ясады. Барыбыз да Татарстанның суверен дәүләт булуына, татар халкының милләт буларак якты өметләр белән яшәвенә чын күңелдән куандык. Ул Корылтай безнең халыкның җегәрле, көчле булуына, дөньяга әйтер сүзе, күрсәтер эшләре булуына ышаныч уятты дияр идем. Корылтай тәмамланып Төркиягә кайткач, Татарстанны, татарны дөньяга танытыр өчен нинди-дер эшләр эшлисе килү дәрте күңелне биләде. Төркиядә һәм Аурупа илләрендә Татарстанны, татар халкын бик аз белүләренә элек-электән күңелем сызлана иде. Шул вакытларда теләгемне аз булса да тормышка ашырырдай форсатлар да килеп чыкты.

Сиксәненче еллар башында Төркиядә халыкара балалар фестивале үткәрелә башлады. Һәр елны апрель аенда дөньяның төрле илләреннән килгән балалар күңелле концертлар биреп, кызыклы тамашалар күрсәтеп китәләр иде. Мин Казанда чакта «Ватан» җәмгыятендә бу фестивальгә Татарстаннан да бер ансамбль җибәрергә булдык. Әмма 1992 елда бу теләгебез барып чыкмады. Мәскәү чиновниклары «Татарстан мөстәкыйль дәүләт түгел» дип, рөхсәт бирмәделәр. Алай да без бирешмәскә карар кылдык. Төркиянең премьер-министры Сөләйман Демирельгә махсус мөрәҗәгать иттек. Бу кыен мәсьәләне ул Татарстан файдасына хәл итүдә булышты. 1993 ел язында Чаллы шәһәренең «Чулман» балалар ансамбле Төркиягә барып зур уңыш казанып кайтты.

Бу урында мин Фәрит Бичури хикәясенә өстәп ул искә алган вакыйга

турында «Шәһри Казан» газитәсендә *(1993, 4 май)* «Татарстан әләмен балалар күтәрде» дигән исем астында басылган бер хәбәрдән өзекләр китерү дөрес булыр дип уйлыйм: «Истанбул аэропортында безне Төркиядә яшәүче татарларның «Ватан» җәмгыяте вәкиле Фәрит Бичури әфәнде һәм Назлы Имре ханым каршы алды... Икенче көнне алар биргән автобус белән Анкара шәһәренә килдек... 23 апрель көнне алты мең кеше сыя торган спорт залында гала-концерт башланып китте. Аны Төркия радио-телевидение берләшмәсенең балалар ансамбле ачып җибәрде. Аннары зал уртасында фестивальдә катнашучы 39 илдән беренче булып, Татарстан әләмен югары күтәреп, безнең «Чулман» ансамбле чыгып басты. «Әссәламегаләйкем» дигән җырыбыз Татарстан халкының бөтен дөнья халкын үз телендә сәламләве, дуслык, иминлек теләү авазы булып яңгырады. «Сабантуй» дигән җырлы-биюле тамаша да җыелган халыкка бик охшады... Бу концертны Төркия телевидениесе турыдан-туры күп илләргә тапшыруны оештырган иде...»

Фәрит Бичуриның бүленгән сүзен дәвам итик.

—1993 елның җәендә миңа Казаннан хәбәр килде. Татарстаннан Алмаз Алиев исемле бер яхтачы егет үзенең иптәшләре белән Төркиягә киләчәк икән. Алар Мәрмәрә диңгезендә үткәреләчәк халыкара ярышларда катнашачак икән. Казан егетләрен каршылау, аларга булышу вазыйфасын миңа йөкләделәр. Яхтаны яхшы итеп әзерләргә тырыштык, аңа күренеп торырлык итеп Татарстан әләмен элдек. Алмаз яхтасы ярышларда алдынгы урынны алды.

Яхтага бәйле янә бер истәлекне искә төшерәсем килә. 1997 елда Русиядә яхталарда дөнья тирәли сәяхәт кылу ярышлары уздырылды. Бу ярышларда Татарстаннан Казан шәһәре командасы да катнашты. Шәһәр хакимияте «Локомотив» спорт җәмгыятенең бер яхтасын хәзерләргә карар кыла. Аның җитәкчесе Олег дигән бер егет иде. «Тимер Казык йолдызы» исемле ул яхтаны Истанбулга җибәрделәр. Әзерлек эшләрендә миңа да катнашырга тәкъдим булды. Яхтаны озын юлга дүрт ай чамасы әзерләдек. Татарстан әләме эленгән яхтадагы егетләр дөнья тирәли елдан артык сәяхәттә йөреп, Татарстанны танытып, исән-сау Истанбулга кайттылар. Аларның кайтуы хөрмәтенә без Истанбулда тантана оештырдык. 1993 елда да, бу юлы да Татарстан яхтачылары турында Төркиянең яхтачылар журналында, газиталәрдә яздылар, телевизион тапшырулар күрсәтелде. Сурәтләрдә һәрчак Татарстан әләме җилферди иде. Боларны күрү күңелне күтәрүен, Татарстан өчен горурлык хисләре уятуын әйтсәм, моны арттырып әйтү дип уйламасалар.

Әңгәмәбез ахырында күбрәк соңгы еллар турында сөйләштек. Шул уңайдан Фәрит Бичури мөһим генә фикерләр әйтте. Аның карашынча, хәзерге Татарстан халыкара мәйданга чыккан бер ил, чөнки ул байтак кына илләр белән икътисади өлкәдә килешүләр төзегән, аны танйылар, аны беләләр. Төркия белән Татарстан арасында икътисади өлкәдән тыш мәдәни өлкәдә дә килешүләр төзелгән. Шуның нәтиҗәсендә рухи-мәдәни бәйләнешләр елдан-ел киңәя, тирәнәя бара. Моңа мисал итеп Фәрит Бичури соңгы елларда Төркиягә Г. Камал, К. Тинчурин исемендәге танылган театрларның, Дәүләт Курчак театрының, Татар җыр-бию ансамбленең, атаклы җырчыларның килүләрен искә төшерде. Аннары ул Татарстаннан килгән театр тамашаларын, концертларны карау өчен Төркиядәге татарларның яратып йөрүләре хакында сөйләде һәм:

—Ни генә димә, милли телнең, милли моңның, милли тамашаның сүз белән аңлата алмаслык сере, сихере бардыр, алар хәтта төрекләшкән татарлар күңеленә дә мәңге онытылмаслык булып уелгандыр,—дип сүзен тәмамлады. Әйе, аның бу фикерләренә кушылмый мөмкин түгел.

Бу урында мин дә, сүзгә катнашып, моннан берничә ел элек Казанда Төркиянең дөньяга мәгълүм «Тумата» ансамбле концертларын каравыбызны, бигрәк тә мөлаем татар кызы Гөлтән Ураллы җырларын яратып тыңлавыбызны, төрки халыкларының Казанда үткәрелгән театрлар фестивалендә төрек театрының зур уңыш казануын искә төшердем.

Дөрестән дә, төрек-татар арасындагы мәдәни бәйләнешләр хакында сәгатьләр буе сөйләргә була...

Без Фәрит Бичури белән быел җәен Казанда очрашырга булып саубуллаштык.

## Мәхмүт Әлүкәй

Безнен тәүге күрешү 1992 елның жәендә Бөтендөнья татарлары конгрессы корылтаенда булды. Мәхмүт Әлүкәй Төркиядән килгән делегатларның берсе иде. «Татар эмиграциясенен тарихы һәм бүгенге хәле» дигән секциядә бергә утырдык. Ул анда Төркиядәге татарлар тарихы һәм бу Корылтайның милләтебез тормышында мәртәбәле вакыйга булуы турында сөйләгән иде. Корылтайга багышланган китапта аның рәсеме дә бар. Кучкыл йөзле, житди карашлы, тапкыр сүзле бу милләттәшем белән мина ахырдан күп тапкыр Истанбулда һәм янә бер кабат Казанда очрашырга насыйп булды. Фикер күгенен киңлеге, хәтеренен әйбәтлеге, укымышлы булуы һәм юмор хисенә байлыгы белән сокландырды ул мине.

Мәхмүт Әлүкәй истәлекләренен төп өлешен мин 1996 елның мартында Истанбулда язып алдым. Анкарада булган халыкара «Нәүрүз» конференциясеннән кайтып барганда, Мәхмүт мине үзләренә алып китте һәм без тәүлектән артык аларда дусларча аралашып яшәдек. Монда шуны әйтү зарурдыр, Әлүкәй һәм анын хәләле Зөһрә ханым гадәттән тыш ачык чырайлы, кунакчыл кешеләр. Моны мин генә түгел, бу гаиләдә булып киткән кайбер казанлылар да ихластан танийлар дип әйтә алам. Аларнын иркен фатирында татар, төрек, рус, инглиз телләрендәге бай китапханә һәм төрле илләрнең музыкаль классикасын эченә алган дискетлар тупланмасы бар. Мәхмүт Әлүкәй гомере буена әдәбиятка, музыкага табынып яшәгән кешеләрнең берсе. Ул Тукай, Пушкин, Омар Хайямнарның байтак шигырьләрен яттан сөйли, ә мәгълүм рус тәнкыйтьчесе Дмитрий Писарев әсәрләреннән өзекләрне күнелдән белә. Бу унайдан мин анын Писаревка булган кайнар мәхәббәтенең серен сорадым. «Писарев—XIX гасырның атаклы публицисты, нибары 28 ел яшәгән трагик шәхес»—диде ул.—Анын әсәрләре вулкан кебек, ялкын белән сулый. Ул нигилист, дөньяны ачы тәнкыйть аша кабул иткән. Анын менә шушы сыйфаты ошый миңа»... Музыкага килгәндә, Мәхмүт Әлүкәйнең ин яраткан композиторлары Чайковский, Шопен һәм Сәйдәшев икән. Жырчылардан ул Илһам Шакировны һәм Американын дөньяга танылган жырчысы Нал Кинг Колны тынларга ярата.



*Сулдан уңга: Зөһрә ханым Әлүкәй, Мәхмүт Әлүкәй, Фәрит Бичури, Рәшидә ханым Бичури. Истанбул, 1998 ел.*

Мәхмүт Әлүкәйнең тәржемәи хәле кызыклы да, кызганыч та, мажаралы да дияр идем. Тормыш юллары турында мина ул менә нәрсәләр сөйләде.

—Кытайның төньягында эчке Монголия дип аталучы бер төбәк бар. Менә шунда—Русия чик буена диярлек урнашкан Хайлар шәһәрендә 1930 елда туганмын мин. Әтием белән әнием дә XX гасыр башында Кытайда—Харбин шәһәрендә туганнар, ә бабам бу илгә XIX гасыр ахырында ук килгән. Чыгышы белән ул Сарытау губернасының Яңа Кулаткы авылыннан, әбием исә Пенза тирәсендәге Юнә авылыннан... Хайлар нигезен XX гасыр башында кытайлар салган. Бу шәһәр мөһажирләр күплеге белән аерылып торган. Төгәл хәтерлим әле, 1940 елда анда 30 мең кеше бар дип исәпләнә иде. Шуның 25 меңен кытайлар, 2 меңен япон хәрбиләре, 2 меңгә якынын руслар, 600 дән артыгын татарлар, калган кечкенә өлешен башка халыклар алып тора дигәннәре истә калган. Шәһәрдә берничә урамнан торган руслар бистәсе, бер урам хасил иткән татарлар бистәсе бар иде. Бу бистәдәге халыкның төп кәсебе һөнәрчелек һәм сәүдә белән эш итүдән гыйбарәт иде. Татар бистәсендә иң бай гаиләләр булып Тарпищевлар, Акчуриннар, Агеевлар, Кудяковлар, Тенишевлар санала иде.

Белүемчә, 1914 ел башында Хайларда татар җәмгыяте корыла, ә 1919 елда бу җәмгыять хисабына мәчет һәм мәктәп салына. Шул ук елда Казаннан Хатип Халиди исемле бер мөгаллим чакыртып, аны мәктәп директоры итәләр. Мәктәп акрынлап 6 сыйныфлыга әйләнә. Укытучылар да арта. Хәтерлим әле, тора-бара ул мәктәп Хайларның милли-мәдәни бер учагы булып китте. Мөгаллимнәр һәм укытучылар төрле елларда «Галиябану», «Сүнгән йолдызлар», «Таһир-Зөһрә», «Җан Баевич» пьесаларын уйнап халык күңелен күрәләр иде. Мәктәптә яшьләрнең күңел ачу кичәләре дә еш була иде. Пьесалар кую, күңел ачуларның төп максаты татарлык тойгысын саклау, телне, гореф-гадәтләрне онытмауга юнәлгән булуын, боларның өлкәннәр уе белән эшләнүен мин үсә төшкәч ныграк аңладым.

Хайларда VI еллык татар мәктәбендә укыганнан соң, шул ук шәһәрдә ун еллык рус мәктәбенә йөри башладым. 1949 елда аны бик яхшы билгеләренә тәмамладым. Шул елларда рус әдәбиятын, дөнья әдәбиятын күп укый идем. Сәләтле, үткен булганмын күрәсең, 10 да укыганда мине сыйныф җитәкчесе итеп сайладылар, укучылар исә миңа «Князь Алюкей» дип, хөрмәтләп дәшәләр иде. Урта белемгә ия булгач, Харбинга юл тоттым, анда медицина институтына кереп, аны уңышлы тәмамлаганнан соң табиб булып Хайларга кайттым...

Мәхмүт Әлүкәй сөйләвенчә, ул елларда Хайлардагы иҗтимагый-сәяси вәзгыять шактый буталчык була. СССР чикләренә якын торганга күрә, шәһәрдә советлар йогынтысы нык сизелә. 1946 елда Хайларда совет паспорты кабул ителә, бераз соңрак «Совет яшьләре берлеге» дигән фирка оештырыла, сталинизм тәгълиматы киң колач җәя. Әлүкәйне дә көчләп яшьләр берлегенә кертәләр һәм Казакъстанга чирәм җирләр күтәрешергә җибәрмәкче булалар. Әмма Мәхмүт Әлүкәй бу эшнең асылында кара мәкер ятканын сизеп, анда китүдән баш тарта. Моның өчен аны берлектән куалар, ул җәбергә дучар ителүчеләр исемлегенә эләгә.

Хайларда егерменче-утызынчы елларда күркәм генә булып оешкан милли татар хәяты илленче еллар уртасында туза, җимерелә башлый. СССРдагы яшерен «иминлек» оешмалары монда да тамыр җибәреп, татарларны Русиягә кайтырга өндиләр, ялган вәгъдәләр бирәләр, куркыталар, яныйлар. «Безне кеше ирегеп буа торган каһәрле сәясәт болытлары каплап алды. Хайларда тыныч кына яшәү мөмкинлеге калмагач, без Төркиягә китәр өчен яңа паспортлар артыннан йөри башладык, ләкин безгә совет органнары белән килешеп эш итүче кытайлылар адым саен аяк чалдылар, төрле тозаклар корып җанга тиделәр. Мине табиб булып эшләгән хастанәдән кудырдылар, ике ел буена эшсез йөрттеләр»,—дип искә ала ул карангы елларны Мәхмүт Әлүкәй.

1956—1958 елларда Хайлардагы татар җәмгыяте тәмам таркала. Андагы татарлар кабат мөһаҗиргә әйләнеп күп өлеше Төркиягә, бер өлеше Америкага күчеп китәләр. Бүгенге көндә Хайларда бер генә татар да яшәми. Менә ул СССРда һәм Кытайда урнашкан ике тоталитар режимның азсанлы татарларга карата алып барган мәкерле сәясәт нәтиҗәсе.

Мәхмүт Әлүкәйгә Төркиягә китү рөхсәте иң соңыннан—1958 елда гына бирелә. Шыксыз көзге көннәрнең берендә ул әнисе Шәмсинур апа, хатыны Зөһрә ханым, уллары Шамил белән башта Пекинга, аннары Гонконг һәм Италия аша диңгез юлы белән Төркиягә килә. Илгизәрлек сәяхәте озакка сузыла, юл михнәтләре күп була, ләкин киләчәккә баглы өметләр газапларны җиңәргә көч бирә.

Мәхмүт Әлүкәй истәлекләренең дәвамын мин 1997 елның апрелендә, Әхмәтвәли Мәңгәр вакыфы эшләре унаеннан чакыру килеп, Истанбулга баргач «Таксим-Уста» кунакханәсендә очрашканда язып алдым.

—Менә кырык елга якын инде Төркиядә яшибез,—дип башлады ул сүзен.—Монда безне бераү дә кочак җәеп каршы алмады. Беренче елда бигрәк тә авыр булды. Ярый әле Кытайдан элегрәк күченеп килгән якташлар бар иде. Шуларның киңәш-табышы, ярдәме белән тормышны җайлап җибәрә алдык. Тагы шунысы да әйбәт булды, мондагы кануннар буенча безгә мөһаҗир буларак биш ел буе налог түләтмәделәр. Тик эш табуы кыенга әйләнде. Табиб булып эшләр өчен яңадан имтиханнар бирергә, яңа диплом алырга кирәк иде. Елга якын вакыт эчендә бу мәшәкатьләрдән дә котылдым.

Шул елларга бәйле бер хатирә сөйлим әле. Көннәрнең берендә мине

Истанбул университетының тюркология факультетына чакырдылар. Профессор Зәки Вәлиди янына. Килдем, таныштык. Ул әлеге факультет башлыгы иде. Минем рус телен белүем белән кызыксынды. Ахырдан шул факультет студентларына рус теленнән өстәмә лекцияләр укырга чакырды. Сәгатьләп кенә. Риза булдым. Берничә ел шунда лекцияләр укып йөрдем.

Төрек телен яхшылап өйрәнгәч, медицина фәннәре докторы дигән гыйльми дәрәҗә алыр өчен диссертация якларга ниятләдем. Бу авыр эш алты елга сузылды. 1970 елда теләгемә ирештем. Шуннан соң озак еллар дәвамында Истанбулның зур бер хастаханәсендә терапия бүлеге мөдире булып эшләдем. Шулай итеп, Кытайдагы шаян «Князь Алюкей» Төркиядә җитди «Доктор Әлүкәй»гә әйләнде. Мондагы кануннар буенча 1985 елда пенсиягә чыктым. Әмма әле бүген дә «Мерседес-Бенц» ширкәтендә табиблык хезмәтен дәвам итәм.

Мәхмүт Әлүкәйнен Төркиядәге татарлар турындагы фикерләре аерым игътибарга лаек. Ул бу илдәге татарларның миллилеге хәзер күбрәк гаилә мохите белән чикләнгәнлеген таный. «Илленче-алтмышынчы елларда хәл үзгәрәк иде»,— ди ул. Кытайдан күчеп килгән мөһаҗирләр гайрәте белән Тукай клубы оешуын, төрле шәһәрләрдә милли-мәдәни җәмгыятьләрнең матур гына эш алып баруын, «Казан» журналы чыгуын искә төшерә. «Тик заман агышы үзгәртә хәлләрне, киләчәктә мондагы татарларның төрекләшүен туктатырдай көчләр әлегә күренми, милли телне, гореф-гадәтләрне саклый торган учаклар сүнеп бетте диярлек»— дип, күнелсез сөземтә ясый ул.

Мәхмүт Әлүкәй Россиядә барган үзгәрешләрне тулаем хупласа да, ул үзгәрешләрнең байтагы тиреннән уйламыйча эшләнүенә пошыну белдерә. Рус шовинистларының латинга каршы киртәләр коруына борешмәскә кирәген искәртә, чөнки латин татарны руслашудан аерып Европага якынайтачак, ди.

Монда шуны искә төшерәсе килә. Безнең бу очрашудан соң ике ай үткәч, 1997 елның июнендә Төркиядән Казанга өч кеше килде: Әхмәтвәли Мәңгәр вакыфы президенты Сафия ханым Имре, аның ире доктор Иззәт Имре һәм вакыф президентының урынбасары доктор Мәхмүт Әлүкәй. Сәяхәтләре вакытында алар Әтнә районының Олы Мәңгәр авылында Сабан туе карадылар, Казан белән таныштылар, галимнәр белән очраштылар. Көннәрнең берендә кунакларны Татарстан президенты Минтимер Шәймиев кабул итте. Шунда Сафия Имре республикабыз җитәкчесенә татар әдәбияты классигы Гаяз Исхакыйның Төркиядә сакланучы архивының бер өлешен һәдия кылды. Минтимер Шәймиев бу бүләк өчен вакыф җитәкчеләренә зур рәхмәт белдереп, аларга уңышлы эшләр теләде. Бу урында Әхмәтвәли Мәңгәр вакыфы эшчәнлеген оештыруда Мәхмүт Әлүкәйнен күп һәм төрле файдалы хезмәт күрсәтүен әйтүне кирәк саныйм. Бу вакыфны кору тарихы турында сүз чыккач, ул шулай дигән иде:

—Мин бит Әхмәтвәли абзый Мәңгәрне Кытайдан ук беләм. Ул әле анда чакта ук үзен милли җитәкчебез итеп таныткан иде. Монда Төркиядә күрешеп тордык. 1985 елда мине үзенең «Мерседес-Бенц» ширкәтенә табиб итеп чакырды... Әхмәтвәли абзый тумыштан талантлы кеше иде. Ул бит сәүдә эшенә әле нәни малай чагында ук тотынган. Садри Максуди аны юкка гына «Сәүдә даһие» дип атамаган. Меценат буларак аның дистәләгән татарга булышканын беләм, «Казан» журналы ун ел буе аның матди ярдәме белән чыгып барды. Миңа ул тәрҗемәи хәлен тәфсилләп сөйли иде. Маҗаралы романнан ким түгел аның гомер юлы. Язар идем, андый кабилият бирмәгән миңа Раббым. Сафия Имре әтисе исемендәге вакыф корып Әхмәтвәли Мәңгәр рухына изгелек эшләде дип әйтер идем. Бүген бу вакыфның телгә алып сөйләрдәй эшләре аз түгел.

... Һай, гомерләр... Әхмәтвәли Мәңгәр вакыфын җитәкләгән Сафия ханым Имре дә, аның төп ярдәмчесе булган Мәхмүт әфәнде Әлүкәй дә бу дөньядан бер-бер артлы китеп бардылар. Урыннары җәннәттә булсын. Әмма алар башлаган эшләр дәвам итә. Вакыфның хәзерге җитәкчесе Эргин Имре Сафия ханым һәм Иззәт Имренең улы Төркия—Татарстан арасындагы мәдәни бәйләнешләрне баету һәм төрләндерү өлкәсендә яна юллар эзли...

**Илбарис НАДИРОВ**

## Фатих Урманче

# МЕҢ ЯРЫМ ЕЛ ЭЛЕК

## ЕВРОПА ХАЛЫКЛАРЫ ЭПОСЫНДА ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫНДА АТИЛЛА ОБРАЗЫ

### Бөек исемгә ябышып...

Евразия халыкларының матди һәм мәдәни тарихында Атилланың шөһрәтле урын биләгәнен хәзер инде күпләр белә. Югыйсә, аның исеме мең ярым ел буена күнелләрдә сакланмаган булыр иде. Әнә шул хакыйкатьне яхшы аңлаган немец язучысы Феликс Дан шушы исемдә—«Атилла» дигән роман яза. Китапка бирелгән аннотациядә әйтелгәнчә, автор халыкларның бөек күчеше чорындагы конкрет тарих вакыйгаларын яхшы белеп яза. Әсәрдә сүз барыннан да элек һуннарның Европаны яулап алуы һәм шул яулап алучыларга каршы көчле көрәш турында бара. Беренче карашка, романның хронологик рамкалары шактый тар: анда сүз нигездә Атилла гомеренең соңгы елы хакында гына бара. Шулай да әсәрдә һуннар тарихына, аларның Көнбатыш Европа халыклары тормышында уйнаган роленә, гот һәм һун кабиләләренең мифологиясенә һәм көндәлек тормышына, хуҗалык эшләренә хас үзенчәлекләр ярыйсы ук киң чагылыш таба. Тик әсәргә гомуми бәя биргәндә, мәсьәләгә бик сак килергә һәм ифрат та мөһим ике факторны истә тотарга кирәк. Беренчедән, һуннар һәм готлар арасындагы житди каршылыкларны һәм шулар белән бәйле кайбер конкрет фактларны автор яхшы гына белсә дә, аның төп концепциясе, роман сюжетының нигезендә яткан идеясе үтә дә каршылыклы. Язучының төп максаты—гот-герман вәкилләрен күкләргә чөеп мактау, ә һуннарны, аларның юлбашчысы Атилланы мөмкин кадәр хурлау, фаш итү, юкка чыгару. Ф. Дан—мәгълүм европоцентризмның ортодоксаль вәкиле. Аның субъектив карашы романының беренче битләреннән үк күзгә ташлана. Тарихи дөреслеккә каршы торган идея баштан ук әсәрнең абруен төшерә, авторның обьективлыгында тирән шик уята. Романда киң чагылыш тапкан тупас бер фактик хатага да игътибар итмичә мөмкин түгел. Автор үзенең кемнәр турында язарга тиешлеген рәтләп белми: һуннарны ул монгол кабиләләре дип атый. Күрәсең, ул XIII гасырның беренче яртысында ярты Европаны айкап чыккан монгол-татар халыклары да, V гасырның урталарына таба Европа һун державасын төзегән һуннар да бер үк халыклар булган дип уйлый. Батый хан гаскәрләренең дә, Атилла урдасының да төп өлешен төрки-татар кабиләләре тәшкил иткәнлеге шиксез, әлбәттә. Әмма шуның белән бергә һуннарның монгол булмавы да күптән ачыкланган факт бит. Икенчедән, бер кабиләне мактап, икенчесен мөмкин кадәр хурлау шулай ук язучыны дөреслектән нык кына ераклаштыра. Хәлбуки, язучы, телиме ул моны юкмы, һуннарның римлеләрдән

---

Ахыры. Башы 7 санда.

өстен торуын адым саен конкрет фактлар белән раслап бара. Романның төп вакыйгалары нигездә берничә тарихи шәхес: король Визигаст, аның кызы Ильдихо, соңгысының яраткан егете, скирлар ханзадәсе (королевич) Даггар һәм Атилла тирәсенә тупланган. Вакыйгалар барышында шулай ук Атилланың әтисе Мундцук, уллары Дзенгизиц, Эрлак, Эллак, аксакал-кинәшчесе Хелхал, абыйсы Бледа һ. б. катнаша. Романның барлык вакыйгаларын бер тирәгә туплаган төп сюжет сызыгы—Ильдихо һәм Даггар мәхәббәте. Алар бер-берсен өзелеп яраталар. Әмма төрле тарихи вакыйгалар, язучы фикеренчә, һуннарның юлбашчысы Атилланың баскынчылык сәясәте, һуннар алып барган туктаусыз сугышлар әлеге саф мәхәббәткә киртә булып торалар. Даггар, бигрәк тә Ильдихо образларын сурәтләгәндә автор еш кына гот-скандинав риваять-легендаларына да, мифология мәгълүматларына да мөрәҗәгать итә. Мәсәлән, анда герман кабиләләренең иң югары дәрәҗәле алласы, Җиһан белән идарә итүче Вотан, аның улы, сугыш алласы Циу, Вотанның хатыны, югары дәрәҗәле алиһә Фригга, мәхәббәт һәм никах алиһәсе Фрейа, Күк күкрәү һәм җир эшкәртү алласы Донар, аның әнисе—Җир, тынычлык һәм килешү алласы Форзете һ. б. турында үзенчәлекле мәгълүматлар китерелә. Гот-герман кабиләләре вәкилләре, аеруча Ильдихо һәм Даггар әлеге алла-алиһәләргә ихлас күңелдән ышаналар, аларга төрле үтенечләр белән мөрәҗәгать итәләр. Күрсәтелгән алла-алиһәләр, әлбәттә инде, гот-германнарга һәрвакыт ярдәмгә килеп торалар.

Шулай да биредә безнең төп максат—романда һуннарны һәм аларның юлбашчысы Атилла образын ничек сурәтләүне ачыклау. Объектив тарихтан нык кына ераклашып, язучы һуннарга һәм Атиллага тирән нәфрәт белән карый. Һәм моны ул яшерми генә түгел, бәлки, киресенчә, кат-кат һәм ассызыклап әйтеп бара. Һуннарга һәм Атиллага карата кулланылган бер үк яманлау, хурлау сүзләрен романның башыннан ахырына кадәр туктаусыз кабатлау укучыда ризасызлык хисе, язучының объективлыгына карата тирән шик уята. Бу җәһәттән җырчы-ханзадә Даггарның зур күләмле ярыммифологик рухтагы җыры аерым бер игътибарга лаек. Анда әйтелгәнчә, герман, дат, сакс, норвег, франк һ. б. кабиләләрнең барысы да Вотан алладан яки аның якын туганнарыннан «үрчеп киткәннәр». Романда әлеге арий кабиләләренең барысы да—Җиһандагы иң югары дәрәҗәле затлар, расалар дигән фикер ярылып ята. Әсәрдә ул кат-кат тәкърарлана. Шуннан соң инде Даггар «рәхәтләнеп» һуннарның шәҗәрәсен бәян итәргә керешә, башта ук «һуннарның килеп чыгышы турында коточкыч риваятьләр йөри» дип әйтеп үтә. Кайчандыр готлар белән танылган король идарә иткән. Ул финн кабиләләреннән бик күп хатыннарны әсирлеккә алган. Бу хатыннар, көндәлек тормышта бик тә уңган булып, шул ук вакытта төрле ырым-сихерләргә дә оста булганнар: алар мал-туар харап итү, иген кырларын яндыру, бозлы яңгыр «чакыру», кыю сугышчыларны акылдан шаштыру кебек гамәлләр кылганнар. Нәтиҗәдә, гот җирләрендә коточкыч фаҗигаләр башланган. Гот ир-егетләре әлеге финн хатыннарын үз җирләреннән ерак төньякка, кеше яшәми торган җирләргә куганнар. Әмма әлеге төньякта бик килбәтсез, явыз рухлар гомер кичерә икән. Алар үзләренең иксез-чиксез далаларыннан, төпсез баткак-сазлыкларыннан, тау-таш араларыннан чыгып, әлеге сихерче финн хатыннары белән кавышканнар. Әнә шундый йөзләрчә-меңнәрчә никахлардан һун кабиләләре барлыкка килгән, имеш. Тора-бара аларның саны берничә йөз меңгә житкән. Тышкы кыяфәтләре белән һуннар бик ямьсез булсалар да, алар искиткеч кыю, батыр, куркусыз һәм оста яугирләр булганнар. Европа халыкларының бәхетсезлеге, фаҗигасе әнә шул һуннардан килә дә инде,—дип тәмамлый үзенең җыруын Даггар. Бу риваятьнең беренче версиясе Иорданның мәгълүм китабында китерелә. Риваятьтәге «Җиһанда Европа халыкларыннан да мәдәниятлерәк халыклар юк», дигән фикер европа-центризм галимнәре күңеленә бик тә хуш килә. Һуннарның килеп чыгышы явыз көчләр, җен-шайтаннар белән бәйләнгән дигән әлеге риваять нык кына популярлашып китә.

Ф. Дан романы баштан ахырга кадәр һун халкына һәм Атиллага тирән нәфрәт белән сугарылган, дидек. Нәкъ әнә шуңа күрә романны укуы шактый авыр. Чөнки анда бит саен нәфрәт, ялган, яла ягу, явызлык мотивлары. Ә бит конкрет тарих вакыйгаларыннан, скандинав сагаларыннан һәм герман эпосы

әсәрләреннән билгеле булганча, Европа халыклары Атилланы тик тискәре яктан гына бәяләгән дип булмый. Хәтта һич тә теләмәсә дә, моны Ф. Дан да танырга мәҗбүр. Романның кайбер эпизодлары нәкъ әнә шул хакта сөйли. Әйтик, язучы Атилланың гомер буена бер тамчы аракы, хәтта шәраб та капмыйча, һәрвакыт агач савыттан тик салкын чишмә суын гына эчеп торуы турында кат-кат әйтеп үтә. Аның хәрби таланты, шәхси ихтыяр көче, галеллеге хакында да әсәрдә махсус искәртелә. Автор Максимин исеменнән Атилла турында түбәндәге сүзләрне әйттерә: «Тарихтан билгеле тулганча, әлегә кадәр бер генә зат та, хәтта Александр Македонский белән бөек Юлий Цезарь да, шулкадәр кыска вакыт эчендә мондый зур нәтиҗәләргә ирешә алмаган иде». Димәк, язучы Атилланың хәрби һәм оештыру талантын Искәндәр Зөлкарнәйн белән Юлий Цезарьдән өстен куя. Һәм бу хәл Атилланың хәрби талантында гына түгел, хан урдасының көндәлек тормышында да ачыктан-ачык күренеп тора. Бу җәһәттән романның түбәндәге күренешләре игътибарга лаек. Һуннарга әсирлеккә төшеп, Атилла кулына эләккән грек сәүдәгәре Гелиос үзенең һуннар урдасындагы тормышы турында Прискка—Византиянең Атиллага илчелеге әгъзасына тәфсилләп сөйли. Һуннар кулына тоткынлыкка эләккән кеше аларның яуларында катнаша алган. Ана шул сугыш вакытында кулына төшергән байлыкның бер өлешен түләп, тулы азатлыкка ирешү мөмкинлеге дә бирелгән. Бер сугыштан соң әлеге грек, яуда алынган алтын хисабына азатлыкка ирешә. Ягъни ул хәзер ни теләсә, шуны эшли ала: теләсә, һун илендә кала; теләми икән, үзенең туган иленә кайтып китә. Талантлы кеше буларак, ул Атилла алдында зур дәрәҗә яулап ала: хан хәтта аны үз өенә кунакка да чакырып тора икән. Гелиос үз иленә кайтудан баш тартып, һуннар илендә яшәп кала һәм мона һич тә үкенми. «Һуннар күп сугышлар алып баралар дисән, Византия дә бу яктан һич тә ким түгел бит,—ди ул.—Аерма тик шунда гына: Византиянең ялкау, талантсыз яу башлыклары бик күп очракларда җиңеләләр, меңнәрчә гаскәр бер дә юкка яу кырында ятып кала. Ә инде Атилла яуларына килсәк, ул һәрбер сугышта җиңеп чыга». Димәк, һәрбер гади гаскәри кулына да һәр орыштан соң шактый байлык эләгә. Әйтелгәннәр хәрби сугыш вакытларына гына түгел, тыныч тормыш чорына да карый. Анда, Византиядә ясак җыючы дәүләт чиновниклары бертуктаусыз гади халыкны кыерсытып, җәберләп, талап торалар; гади кешеләр Византиядә тәмам хәерче хәлендә калган. Византия белән чагыштырганда, биредәге, һун урдасындагы тормыш—оҗмах. Византиядә гади кеше беркайчан да үзенең язмышына кагылган мәсьәләләр буенча гадел хөкем чыгартуга ирешә алмаячак. Анда вөҗдан, хакыйкать, гаделлек кебек төшенчәләр гомумән онытылган, күптән юкка чыккан. Берәр гадел карар кабул итүгә ирешү өчен, шул суд биналарындагы привратниктан башлап, иң югары дәрәҗәдәге судьяга кадәр—уннарча, йөзләрчә чиновникларга күп итеп ришвәт бирергә кирәк. Әле алай иткәндә дә кешенең гадел карарга ирешүе икеле. Ә бирегә, һун илендә барысы да бик җиңел хәл ителә. Беренчедән, һуннарда, Византиядән аермалы буларак, иң бай кешедә дә йөгерек ат белән сугыш коралыннан башка берни дә юк. Дөресрәге—һуннарның иң бай кешесенә дә башка бернәрсәнең дә кирәге юк. Ә инде сүз Византия чиновниклары турында барса, андыйлар бирегә—һун илендә гомумән була алмый. Бу җәһәттән Гелиос мондый бер хәл турында да сөйләп үтә: күптән түгел сармат кенәзләреннән берәү ярлы гына бер һунның таен урлап китә. Бер сәгатьтән соң инде ул—әлеге кенәз җәзага тартыла, аны аяк-кулларыннан агач тәрәгә кадаклап куялар. Бирегә, һун илендә исә тик бер генә кешенең минем мал-байлыгымны, хәтта хатынымны да тартып алырга кодрәтеннән килә. Әмма ул зат үзенә тугрылыклы кешеләргә бармагы белән дә кагылмаячак. Башкаларга да моны рөхсәт итмәячәк. Минемчә, мең чиновникның даими җәзасына дучар булып торганчы, бер гадел хөкемдарга тугрылыклы булып калу мең тапкыр артыграк. «Шуна күрә мин Афины шәһәрендә сәүдәгәр булганчы, Атилла кул астында яшәү хәерлерәк дигән карарга килдем»,—дип бетерә үзенең сүзен грек Гелиос. Китерелгән өзек шул яктан аерым бер мәгънәгә ия. Әлеге сүзләрне язучы үз илен яраткан һун авызыннан түгел, ә бәлки элеккеге әсир, грек сәүдәгәре Гелиос исеменнән әйттерә. Һәм бу хакта кем электе шул түгел, ә тарихта мәгълүм объектив галим һәм язучы Приск сөйли.

Романның идея эчтәлеген һәм Атилланың эшчәнлегенә хас үзенчәлекләрне

ачыклау өчен, тагын берничә күренешкә тукталып үтәргә кирәк. Бу җәһәттән Атилланың могҗизалы төше зур әһәмияткә ия. Төшендә ул һун пантеонының баш алласы, сугышлар һәм үч алу алласы Пуруны күрә. Әнә шул төш ханның киләчәген билгели. Атилланың төшендә Пуру-алла Европаның төрле халыклары турында мөһим мәгълүматлар китерә. Бигрәк тә Византия, Рим һәм римлеләр хакында. Биредә шул Пуру-алла сүзләреннән аерым өзекләр китерү кызыклы булыр: «Әгәр син минем сүземне тыңлар булсаң, уян, Атилла!—ди ул.—Римнең мең еллар буена җыелып килгән коточкыч әхлаксызлыгы үч алуны таләп итә. Мин—үч алу алласы. Телисеңме минем кылычым булырга? Ризамы? Әгәр риза булсаң, үзеннең йомшаклыгыңнан, мәрхәмәтлелегеннән ваз кич! Барлык хисләреннән арын! Минем кулымдагы кылыч кебек бул! Минем ихтыярыма гына буйсын!..» Атилланың бераз куркып калуын күреп, Пуру-алла аңа үзенең җинелү белмәс кылычының кайда икәнлеген әйтә. Әнә шул легенда-төштә әйтелгәнчә, Атилла Европа халыклары мифологиясендә һәм эпосында Алла кылычына ия була һәм үзе «Алла камчысы» дигән исем ала. Китерелгән өзекләр нигезендә шундый бер нәтиҗә ясарга мөмкин: Рим империясе мең елдан артык колбиләүчелектә гомер кичерә, яу кырларында әсир булганнарның барысын да колларга әверелдереп, рәхимсез рәвештә аларның хезмәтеннән бушлай файдалана, аларны арзан бәягә башка илләрдән сатып алып, коллар белән даими сәүдә итә. Римдә ачлыктан, ялангачлыктан, даими авыр хезмәттән интеккән колларның байтагы—Җаек, Түбән Идел, Тын (Дон) буйларыннан башлап, Кара диңгез, Дунай буйларына кадәр җәелеп яткан дала-кырларда, урман-тау итәкләрендә гомер итүче күчмә кабиләләрдән була. Пуру-алладан алынган тылсымлы кылыч ярдәмендә Атилла Европада колбиләүчелеккә чик куярга, шул явызлыкның мең еллык үзәге булган Рим империясен тар-мар итәргә тиеш була. Атиллага нинди генә мөнәсәбәттә булса да, язучы Ф. Дан аның төп миссиясен танырга мәҗбүр: Атилла бу дөньяга Европа илләрен колбиләүчелектән азат итү өчен җибәрелгән! Пуру-алла кылычы ярдәмендә ул бу бурычны нигездә башкарып чыга. Дөрес, изге Рим империясенең акрынлап таркалуын һәм тора-бара тәмам юкка чыгуын тик Атилла эшчәнлеге, аның яулары белән генә бәйләп карау тарихи объективлыкка бөтенләй үк туры килеп бетмәс иде. Атилла чорында—V гасырның урталарына таба адәм балалары өчен коточкыч тормыш шартлары тудырган колбиләүчелек Кешелек тарихының инде узган чоры иде. Изге Рим империясенең үзендә дә моны бик күптән аңлаганнар иде. Рим империясенең эчтән череп таркала башлавы инде безнең эраның I—II гасырларында ук ачык сизелә. Атилла һәм аның яулары, ул төзегән Европа һун державасы әнә шул тарихи процессны тизләтүдә, ахыр чиктә аңа нокта куюда хәлиткеч роль уйный.

Атилла тормышын һәм аның хәрби эшчәнлеген яктырткан һәрбер фольклор әсәренең яки әдәби романның һәркайсы төп игътибарны хан тормышындагы аеруча мөһим мизгелләргә яки вакыйгаларга юнәлтә. Шундыйларның берсе—ханның үлеме. Тарихтан билгеле булганча, Атилла чыннан да нииндидер серле шартларда үлә. Бу фаҗиганең чын сәбәбе әлегә кадәр тәгәл ачыкланмаган. Бәлки, нәкъ әнә шуңа күрәдер, әлеге фаҗига белән бәйле вакыйгаларны төрлечә, дөресен әйткәндә—ничек теләсәң шулай яктыртырга мөмкин. Ф. Дан бу «мөмкинлектән» бик киң һәм, әйтергә кирәк, шактый оста файдалана. Башта язучы Атилланың үлеме нидән буласын берничә тапкыр сүз унаеннан гына искәртеп үтә. Юраучылар, мәсәлән, ханны түбәндәгечә кисәтәләр: «Сине, Атилла, бернәрсә дә: металл да, таш та, агач та, пычак та, кыска сөңге дә, ук та, айбалта да, чукмар да яралый алмый. Син үзеңнең йокы бүлмәңдә, искиткеч гүзәл хатынның назлы кочагында үләчәксең»,—диләр. Бу юраугa хан әллә ни борчылмый. Әлеге фаҗигане алдан кисәткән икенче хәл: хан гомере буена сары чәчле сылу кыз—гот-герман кызы турында хыяллана. Роман вакыйгалары дәвамында ул кыз—шаһзадә-королевич Даггарның сөйгәне, король Визигастның кызы Ильдихо булып чыга. Королевич Даггар да король Визигаст та Ильдихоны Атиллага кияүгә бирүгә каршы чыгалар. (Язучы әйтүенчә, әлеге кыз—хан Атилланың ике йөз дә беренче хатыны булырга тиеш икән!) Ильдихо үзе дә һич тә беркатлы кыз түгел, ул—кыю, үзсүзле, искиткеч чибәр, ярыйсы ук көчле; романда ул—халык эпосында еш очрый торган пәһлеван кыз сыйфатында сурәтләнә. Моны Атилла

кызны беренче күрүдә үк сизә һәм гомере буена беркайчан да, беркем алдында да куркуга төшмәгән хан каушап кала. Чынлыкта мондый хәлләр булганмы-юкмы, моны хәзер беркем дә әйтә алмый. Тик язучы Ф. Данга Атилланы әнә шулай сурәтләү кирәк: анын төп максаты—Атилланың эпик образын мөмкин кадәр түбәнәйтү. Табигый, романда да хикәяләү нәкъ әнә шул рухта алып барыла. Атилла үзенең иң якын киңәшчесе Хелхал картка болай әйтә: «Син беләсең, менә мин инде кырык алты ел дәвамында судан башка берни эчкәнем юк... Бүген йокы бүлмәсенә Аквилейдән алынган зур алтын кувшинга иң көчле шәраб коеп куй!»—ди. Ильдихо Атилладан ничек булса да котылып калу турында уйлый. Әмма корал тапмый. Тик ана ярдәмгә хан үзе килә. Йокы бүлмәсенә кергәч тә ул әлеге алтын кувшиндагы шәрабны төбенәчә эчеп бетерә. Кырык алты ел буена бер тамчы шәраб капмаган хан, әлбәттә, исерә. Биредә романга тагы бер мәгълүм эпик мотив килеп керә: эпик каһарманнарның кайберсе, эчеп-исереп, зур бәлагә дучар була (мәсәлән: Алпамыш)... Форсаттан файдаланып, Ильдихо Атилланы үзенең озын чәче белән буып үтерә. Ә инде хатын-кыз кулыннан һәлак булу һәр җәмгыятьтә, бигрәк тә борынгы һуннарда, әйтеп бетергесез зур хурлык дип саналган. Шул рәвешчә, тарихтан билгеле күренешләрне төрлечә үзгәртеп, еш кына—фальсификацияләп, Ф. Дан үзенең шикле максатына ирешә: ул бөек яугир-полководец Атилладан «үч ала». Тик бер нәрсәне һич тә онытырга ярамый; Атилла—Европа тарихында, анда яшәүче халыкларның мифологиясендә һәм эпосында атаклы каһарман. Немец халкының алдарак күзәтелгән «Нибелунглар турында жыр»ында бу аеруча ачык күренә. Ничек кенә тырышсаң да, бөек хан Атиллага нисбәтле карашларны төптән үзгәртеп булмый. Чөнки аның образы Ф. Данга кадәр «Вельсунглар турында сага», «Өлкән Эдда», «Нибелунглар турында җыр» кебек классик әсәрләрдә төрле яклап, кирәк дәрәҗәдә киң һәм тирән яктыртылган иде инде. Европа халыклары аны шулай дип кабул итә дә! Аны берничек тә шул югарылыктан төшереп булмый. Бәлки нәкъ әнә шуңа күрәдер ул, язучының ничек сурәтләвенә карамастан, әлеге романда да гаять югары дәрәҗәдә торган, чын мәгънәсендәге эпик-мифологик каһарман булып кала бирә.

## Атилла турында соңгы сүз

Күп санлы тарихи романнар авторы Мөсәгыйт Хәбибуллинның ике китаптан торган, беренче тапкыр 1998—1999 елларда «Мирас» журналында басылып чыккан тарихи романы шулай ук «Атилла» дип кенә атала. Атиллага багышланган башка күп кенә әсәрләрдән аермалы буларак, әлеге романда Атилланың тормышы, аның ата-бабаларыннан башлап үлеменә кадәр шактый тәфсилле сурәтләнә. Романда үзәк урынны, әлбәттә, Атилла образы алып тора. Әсәрнең беренче бүлекләреннән үк авторның төп игътибары Европа халыклары күңеленә гаять тә үзенчәлекле, катлаулы, каршылыклы һәм кырыс шәхес буларак кереп калган Атилланың холкына, әхлакый сыйфатларына, үз-үзен тотышына юнәлтелә. Шушы унайдан язучы Приск Панияле язмаларында, Ф. Дан романында һ. б. кайбер китапларда чагылыш тапкан Тәңре кылычына да туктала. Бу җәһәттән М. Хәбибуллин Угыз ханнан калган һәм Евразиядә киң таралган Тәңре кылычы турындагы мәгълүмат легенданы китерә: «Көннәрдән бер көнне Угыз ханның көтүчесе сазлыкта утлаган таналары арасында аягы яраланган хайванны күрә. Күрә дә кан эзе буйлап сазлыкка юнәлә. Бакты исә, сазлыкта угы күккә карап торган кылычны күрә. Күрә дә аны көч-хәл белән тартып чыгара һәм Угыз ханга кайтарып бирә. Угыз хан кылычны кулга алуы була, күктән Тәңре тавышы килә: «Угыз хан, бу кылычны сина Тәңрең җибәрә. Бу кылыч синең кулыңда булганда сине беркайчан да, беркем дә җинә алмас. Ошбу кылыч кем кулына керсә дә, кылыч иясе хан булыр». Шул рәвешчә, төрки-татар дөньясында Тәңре кылычы атадан—балага, баладан—оныкка тапшырылып, көч, куәт, батырлык, гадел хакимият символына әверелә. Һәм бу хәл һун-кыпчак далаларында мең ярым ел буена дәвам итә. Тәңре кылычын беренче тапкыр атасы Мәнгүк тәхеткә күтәрелгәндә күргән сабый Атилла, үзалдына сөйләнгәндәй: «Килер бер көн,

мин дә Тәнре кылычын тагып яу чыгармын һәм Рим легионерлары сатып вә урлап алып киткән канкардәшләремне мәнгегә азат итәрмен»,—дип кинәнә. Романны укучы «сабый Атилла күңелендә шундый тирән сәяси мәгънәгә ия фикерләр тугандыр» дип раслауга ышанмаячак, билгеле. Биредә язучы үзенең төп идеясе белән мавыгыбрак киткән. Әмма шуна да карамастан, аның нияте изге. Ни өчен дигәндә, Атилла шәхесенә һәм аның яуларына карата Европа халыклары иҗатында да, тарих фәнендә дә (бигрәк тә совет историографиясендә) капма-каршы карашлар яшәп килә. Хәтта борынгы төркиләр тарихы буенча күпсанлы житди хезмәтләр язган Л. Н. Гумилев та һун яуларын тик тискәре күренеш дип кенә бәяли. М. Хәбибуллин исә моңа капма-каршы фикер уздыра һәм романның башыннан ахырына кадәр һун державаларының хәрәкәтен, Атилланың колбиләүчелеккә, төрле халык вәкилләрен коточкыч фажигаләргә дучар иткән Рим империяләренә каршы көрәшен тарихи унай күренеш дип бәяли һәм моны күпсанлы конкрет мисаллар белән раслап бара. Колбиләүчелек белән генә череп баеган Рим империяләрен юкка чыгаруның зарурлыгы Европа галимнәренең кайберсе тарафыннан да таныла... Әнә шундый мөһим идеягә нигезләнгән романында татар язучысы Евразиянең шул чорлардагы киң тарихи панорамасын күз алдына китерергә омтыла. Романның беренче китабында Иделнең түбәнге агымы, Жаек, Тын (Дон), Кара дингез буйларында урнашкан Көнчыгыш һун дәүләтенең Урта Азия, Иран-фарсы илләре белән бәйләнешләре турында шактый киң мәгълүмат бирелсә, икенче китапта сүз күбрәк Европа һун дәүләтенең шул яктагы илләр, бигрәк тә Көнбатыш Рим һәм Көнчыгыш Рим-Византия империяләре белән багланышлары турында бара. Тик шуны әйтеп үтәргә кирәк: киң тарихи панораманы күз алдына китерү идеясе белән мавыгып, автор аратирә гади тарих сөйләүгә күчә. Бигрәк тә ерак Иранда һәм Византиядә булган вакыйгалар хакында язганда. Мондый очракларда (ә алар әсәрдә—байтак!) роман художество әсәре булудан бигрәк, тарихи трактат формасын ала башлый.

Ерак чорларда яшәгән халыкларның көндәлек тормышын күз алдына китерү өчен, аларның ышануларын, йолаларын, гореф-гадәтләрен яхшы белергә кирәк. Язучы бу мәсьәләгә бик житди якын килә һәм борынгы һуннарның тормыш-көнкүрешенә нисбәтле мөһим мәгълүматлар китерә: иртән торгач ук, тирмәдән чыгып, Кояшны сәламләү; вафат булган хан-хөкемдарларны жирләү, тәхет варисы кулына Тәнре кылычын биреп, аны хан дәрәжәсенә күтәрү һ. б. Биредә без бер генә житди йолага тукталып үтик. Сүз ике яшьнең өйләнеп, гаилә коруы турында бара. М. Хәбибуллин язуынча, берәр кызга гашыйк булган егет елның билгеле бер вакытында уздырыла торган махсус бәйрәм-тантанада атка атланып качкан кызны куа китә. Әгәр ул кызны аткан ук очар жирдә куып житсә, аңа өйләнү хокукы ала. Ягъни, үзенең булачак хәләл жефетен, чынлыкта егет түгел, кыз сайлый: әлеге егеткә кияүгә чыгу дәрте булган кыз «әлләни ашыкмый»; ә инде ул никахка каршы булса, ничек тә качып котылу ягын карый. Әнә шундый күренешләрнең берсен сурәтләгәннән соң, язучы түбәндәгечә дәвам итә: «Ул арада кызлар егетләрне сайладылар да елга буена төшеп, бер-берсенең күзләренә карашып, битләрен-биткә куеп менделәр. Һәм китте атларга йөгән кигерү. Һәр кыз үзе сайлаган егет атына йөгән кигерде һәм тезгенне уң кулына бирде. Аннары кардәшләре кызга ат китерделәр һәм ике яшь Сафура бикә янына узды. Сафура бикә гадәттәгечә аларның чәчләрен чәчкә бәйләде, димәк үз фатихасын бирде». Язучы китергән мәгълүматларга караганда, әлеге фатиханы алганнан соң, сарматларда егет белән кыз икесе ике атта далага чыгып китәләр һәм шунда, үз жайларын үзләре табып, бер атна яшиләр. «Бер атнадан соң, хәзер инде ир-хатын йөзендә өйләнешкәннәр ыстанга кайталар һәм ил башы Сафура бикәдән фатиха алып, яшьләрне гаилә алласы (алиһәсе булырга тиеш!—Ф. У.) Инәйгә тапшыра». Сүз V гасырда (ә бәлки аннан да элегрәк) булган хәлләр турында бара. Димәк, бу чорда сарматларда (уйларга кирәк, аларга тугандаш халык һуннарда да—Ф. У.) матриархаль гореф-гадәтләр дә билгеле бер урын алып торган. Мәгълүм ки, Шәрекъта хатын-кызлар культы элек-электән зур роль уйнаган. Һәм бу—романнан әле генә китерелгән күренешләрдә генә чагылып калмый. Бу жәһәттән романның беренче китабында житди урын алып торган Сафура бикә образы аерым бер игътибарга лаек. Әсәрдә әйтелгәнчә, Сармат-

ханның ир баласы булмый. Икенче төрле әйткәндә, әсәргә Борынгы Мисыр ташъязма истәлекләрендә, изге китаплардан Тәүратта һәм Коръәндә, борынгы һәм урта гасырлар төрки-татар эпосында киң таралган баласызлык бәласе мотивы килеп керә. Үзенең ир баласы булмагач, Сармат-хан яраткан кызы Сафураны фарсы шаһиншаһыннан килгән Бәһрамга кияүгә бирә. Шулай итеп, романда Иран мифологиясенең мәгълүм персонажы Бәһрам Гур билгеле бер урын ала... Әмма Сафура яшьтән үк Атилланың әтисе Мәнгүк-ханны ярата. Һәм алар, шактый сонарып булса да, кавышалар. Ягъни, Сафура бикә—кыю, үзсүзле, беркемнән дә курыкмый торган асыл зат. Бәһрамда кияүдә булганда, ил, тәхет мәсьәләләрен Сафура бикә үзенчә һәм бик гадел хөкем итеп утыра. Биредә дә Борынгы Шәрекътән килгән уңай традиция дәвам итә: халык һәм ил алдында ир хөкемдар белән аның хатыны бер үк дәрәҗәдә торалар, ил белән ир һәм хатын бергәләп идарә итәләр. Романда бу хакта конкрет сүз дә бар: Мәңгүк ханга «янә шунысы ошады—түр якка ике тәхет куелган иде, кайтышында хатыны утыра—Сафура ханбикә». Әлеге сүзләр Борынгы Хетт илендәге сарай тормышын хәтерләтә. Шундый ук гадәт башка илләрдә дә булган. Моның ачык мисаллары итеп Борынгы Мисыр патшабикәләре, мәшһүр Эхнатонның хатыны Нефертитине (б.э.к. XIV гасыр), Юлий Цезарьның һәм Антонийның хатыны, шәҗәрә башы Искәндәр Зөлкарнәйннән килгән Птолемейлар нәселеннән соңгы патшабикә Клеопатраны (б.э.к. I гасыр), урта гасырлар тарихына тукталсак, Казанның соңгы ханбикәсе Сөембикәне (1520—1557) күрсәтергә мөмкин. М. Хәбибуллин романындагы Сафура бикә дә әнә шундый асыл затлардан. Тик бу бикә хакында укыганда, бер шик тә туа. Мәгълүм ки, Сафура—гарәп теленнән кергән исем. Аның бер мәгънәсе—һәр кешенең игелекле эшләрен язып баручы фәрештә. V гасырда Көньяктагы дала-кырларда гомер иткән сармат-һуннарда гарәп теленнән алынган исемнәр булдымы икән?!

Билгеле булганча, борынгы чорларда, шулай ук «дөнья буталган» II—V гасырларда (халыкларның бөек күчеше) төрле илләр тарихында аерым диннәр житди роль уйный. Әйтик, III гасырда Якын Көнчыгышта манихейлык дине барлыкка килеп, тора-бара ул Рим империясеннән Кытайга кадәр тарала. Шул ук вакытта элегрәк барлыкка килгән диннәрдән тәңречелек тә (б.э.к. IV—III меңъеллыклар), зәрдөштлек тә (зороастризм, б.э.к. X—VI гасырлар), христианлык та (эралар чиге яки б.э.к. I гасыр) төрле халыкларның көндәлек тормышында әһәмиятле роль уйнавын дәвам итә. Кайдадыр бу диннәр арасында кискен каршылыклар барлыкка килсә, икенче бер очракларда алар аралашып, укмашып, бер-берсенә ярдәм итеп «яшиләр».Шул чор тарихын гади халыкның көндәлек тормышына турыдан-туры «катнашкан» әлеге катлаулы идеологик процесслардан тыш күз алдына китереп булмый. Моны роман авторы да бик яхшы аңлый: төрле халыкларда таралган диннәр, аларның төп үзенчәлекләре турында ул кинәеп, тәфсилләп сөйли. Моны тискәре күренеш дип булмый, әлбәттә. Тик бер нәрсәне генә онытырга ярамый: дин, аңа хас үзенчәлекләр, аның тарихы—ифрат та катлаулы һәм каршылыклы фәлсәфи-мифологик категорияләр. Аларны яктыртуга бик тә сак килү таләп ителә. Кайвакыт язучы бу хакта онытып жибәрә: романның беренче китабында ул утка табынучылар, Мәңгелек ут храмнары турында сөйли. Бу күренешләрне манихейлык дине белән бәйләп, язучы болай ди: «Манилар *(Мани динен тотучылар дип уйларга кирәк—Ф. У.)* империя куәтенә мәдхия укырга, аның нигезен ныгытырга, тәхеттә утырган сасанидлар династиясен мактарга тиеш булалар. Нәкъ шул чорда храмнарда мәңге сүнмәс утлар яна башлый, утка табынучылар исә руханилар йөзендә дәүләт белән идарә итәргә керешәләр». Авторның бу сүзләре белән килешеп булмый, әлбәттә. Манихейлык динен тотучыларны автор утка табынучылар дип игълан итә. Билгеле бер дәрәҗәдә утка табыну байтак диннәрдә бар. Тик шунысы да төгәл мәгълүм: утка табынучылар дип манихейлык тотучыларны түгел, ә бәлки зәрдөштлекне кабул итүчеләрне атыйлар. XIX йөз һәм XX йөз башы дин белгечләре зәрдөштлектә торучыларны утка табынучылар дип кенә атаганнар. Манихейлыкның барлыкка килү вакыты III гасырга карап, ярым-мифологик рухани Мани (216—277 еллар) исеме белән генә бәйләнгән булса, утка табынучыларның һәм беренче Мәңгелек ут храмнарының пәйда булуы

б.э.к. X—VI гасырларга карый һәм Зәрдөшт-пәйгамбәр (Зороастр, Заратуштра) исеме белән бәйләнгән.

Тик шулай да язучы һуннарның асыл максатын беркайчан да онытмый: Атилланың һәм һун гаскәренең төп бурычы—нигездә «варвар»лардан җыелган колларны, шул ук далаларда яшәүче ярым күчмә халыкларның бәхетсез улларын ничек кенә булса да әнә шул коточкыч язмыштан коткару. Бу хакта әсәрдә кат-кат әйтелә; еш кына конкрет күренешләр, канлы орыш-сугышлар да шул фикерне раслый. Мисал рәвешендә түбәндәге сүзләрне китерергә мөмкин: «Соңгы елларда тоташ коллар базарына әйләнгән Ольвия каласы Атилла яубаш юлында аркылы ята иде». Әнә шул шәһәрдәге колларны азат итүне һәм рим легионнары белән сугышны язучы киеренке, кырыс күренешләр ярдәмендә сурәтли. Шушы унайдан һун дәүләте хөкемдарларының, шул исәптән Атилланың да, колбиләүчелеккә мөнәсәбәте турында да әйтеп үтәргә кирәк. Ольвия шәһәрен яулап алгач, Атилла кулына бик күп әсирләр эләгә. Хан алдында «аларның язмышын ничек хәл итәргә?»—дигән сорау калкып чыга. Хилхәй атакай: «Син аларны иреккә җибәр»,—ди. Тик бу киңәш аңа башта ошамый. «Ләкин бераздан соңгы улына атакайдан исем куштырганда анардан балага әйткән сүзләрне үзенә алып: «Кеше явызлык кылыр өчен дөньяга килми, олан»,—дип балага дәшүен ишеткәч, уйга калды. Һәм инде хәзер әсирләргә чынлап та ирек бирергә дигән фикергә килде. Тик менә белми иде: ышанырлармы мона варварлардан үлем көткән легионерлар. Чөнки алар үзләре хуҗасыннан качкан һәр колны җәзага тарткан кешеләр иде». Язучының бу сүзләре тарихи чынбарлыкка никадәр туры килә? Чыннан да булганмы шундый хәлләр? Бу сорауга төгәл җавап бирүе җинел түгел. Кайбер фаразлаулар белән чикләнергә туры килә. Алдарак күзәтелгән, тулысынча европоцентризм рухында язылган Ф. Дан романында да шуңа якын фикерләр бар. Һәм аларны, инде әйткәнебезчә, һуннарда тоткынлыкта булган грек Гелиос әйтә. Һун дәүләте һәм шул дәүләтнең башында торган Атилла хакында шактый бай мәгълүмат тупланган «Нибелунглар турында җыр»да һуннардагы колбиләүчелек яки коллар белән сәүдә итү турында шулай ук бер сүз дә юк. Димәк, М. Хәбибуллин романыннан әле генә китерелгән сүзләр дә тарихи чынбарлыктан ерак булмаса кирәк.

Тарихи чыганакларда һәм төрле әдәби әсәрләрдә Атилланың абыйсы Биләү *(тарихи чыганакларның кайберсендә—Бледа; «Нибелунглар турында җыр»да—Бледель; Ә. Мөхәммәди хезмәтләрендә—Белит)* белән мөнәсәбәтләре төрлечә сурәтләнә. М. Хәбибуллин романында бу хакта түбәндәге мәгълүматлар китерелә, «Һун аксакаллары һәммәсе дә Атилланың башкаласына җыелалар һәм һуннар ханы итеп агалы-энеле Атилла белән Биләүне сайлыйлар. Тик Тәнре кылычы Биләү угланга тапшырыла, гәрчә ике туганга да хан титулы бирелсә дә». Әлеге хәл кыю, кырыс, үзсүзле Атилланың ачуын китерә. Һәм бу аңлашыла да: яубаш буларак кылган эшләре ягыннан, киңрәк алганда, гомумән шәхес буларак Атилла үзенең абыйсы Биләүдән күп өстен тора. Димәк, Тәнре кылычы да аның кулында булырга тиеш. Тик Атилла абыйсын әлеге кылычны үзенә алу өчен генә үтерми. Ул Биләү ханның хыянәт юлына басуын, колбиләүче римлеләр белән төрле килешүләр төзеп, «ант эчүен» ачыклый. Атилла хан шул дәрәҗәгә житкән хыянәтне кичерә алмый: Тәнре кылычы да, бернәрсә белән чикләнмәгән хакимият тә хәзер тулысынча аның кулына күчә. Табигый, роман вакыйгаларының барышы да хәзер тик Атилла ихтыярында гына кала.

Романның искиткеч бай, үзенчәлекле, катлаулы һәм шактый каршылыклы эчтәлеген һәм сәнгатьчә үзенчәлекләрен зур булмаган бер күзәтүдә тулысынча инләп булмый, әлбәттә. Шулай да аның иң әһәмиятле сыйфатлары турында махсус әйтеп үтәргә кирәк. Барыннан да элек, язучы М. Хәбибуллин үзалдына бик тә катлаулы бурыч куйган: бу—моннан мең ярым ел элек яшәп, Кешелек тарихында ифрат зур роль уйнаган атаклы шәхеснең гаилә тормышын, кылган җитди тарихи гамәлләрен хәзерге заман укучысына житкерү. Тик сүз бер тарихи шәхес турында гына түгел, ә бәлки безнең борынгы ата-бабаларыбыз булган һун-сарматларның гомуми тарихта тоткан урынын, аларның хәрби яуларын, бер яктан икенче якларга күченеп йөрүләрен, хуҗалык-икътисадларына, көндәлек тормыш-көнкүрешләренә, дини-мифологик карашларына, гореф-гадәтләренә,

аларның этнографиясенә (өй-тирмә, кием-салым, савыт-саба, аш-су һ. б.) хас үзенчәлекләрен ачыклау һәм алар хакында да һәркемгә аңлаешлы телдә сөйләп бирү турында бара. Бу яктан әсәрдә аеруча уңышлы сурәтләнгән түбәндәге моментларны билгеләп үтәргә мөмкин: көндәлек тормышта һәм төрле орыш-сугышларда хатын-кызларның роле; һун-сарматларның бик тә үзенчәлекле никах туе йолалары; мәет, бигрәк тә ил башын, хан-хөкемдарны җирләү һ. б. Күрсәтелгән һәм башка шундый мәсьәләләрне ачыклау өчен, язучы бихисап тарихи чыганакларны өйрәнеп чыккан. Аларның барысы белән дә ул изге ният белән танышкан. Әнә шул чыганакларга таянып, ул әлегә кадәр үтә дә каршылыклы күрсәтелеп килгән Атилланы тулысынча уңай герой буларак сурәтләүгә ирешкән. Язучының һун-сарматларны сурәтләвенә карата да шул ук фикерне әйтергә мөмкин. Гомумән алганда, язучы М. Хәбибуллин изге эшкә алынган һәм аны, һичшиксез, уңышлы башкарып чыккан.

Тик романның яңа басмасын әзерләгәндә, аның кайбер моментларына аерым бер игътибар белән якын килү таләп ителә. Әйтик, төрле диннәр һәм дини мәзһәбләр турында язганда, автор кайвакыт роман сюжетына катнашы булмаган идеологик көрәш мәсьәләләре белән кергәннән артык мавыгып китә. Әсәрнең ахырына якынайгач, ул башлангыч христианлык (первоначальное христианство) турында тәфсилләп сөйли. Авторның Атилла тарихыннан шактый ерак торган бу мәсьәлә белән кергәннән артык мавыгуын гафу итеп тә булыр иде. Тик шунда ук әлеге катлаулы проблеманың икенче—гаять тә катлаулы ягы калкып чыга: автор тәнречелекне христианлыкка каршы куеп, соңгысының кайбер кимчелекләре турында кинәеп, әйтергә мөмкин, хәтта рәхәтләнеп сөйли. Әлеге каршылыклы мәсьәләгә болай якын килү, бәлки, кемгәдер ошар да, кемнеңдер күңеленә хуш та килер. Тик мәсьәләнең икенче, житдирәк ягын да истән чыгарып булмый. Фәндә күптән ачыкланганча, һәрбер дин, иудаизм, христианлык һәм ислам кебек дөньякүләм диннәрне дә кушып, халыкның бик борынгы мифологик карашлары нигезендә барлыкка килә һәм тегәл бер идеологик система булып оеша. Төрле халыкларның мифларын һәм мифологик системаларын тәнкыйть итеп булмаган кебек, аерым диннәрне дә «фаш итеп» булмый. Һәм моның, бигрәк тә XX гасыр ахыры—XXI гасыр башында һич тә кирәге юк. Аерым диннәрнең хосусый үзенчәлекләрен, тарихын, халыкның көндәлек тормышында тоткан урынын махсус өйрәнү—күп тапкыр әһәмиятлерәк, житдирәк, нәтиҗәлерәк бурыч.

Романда сүз моннан мең ярым ел элек булган зур тарихи вакыйгалар турында бара, дидек. Алар укучыларга аңлаешлырак булсын өчен, автор романның башыннан ахырына кадәр бик күп тарихи хезмәтләрдән, тикшеренүләрдән, монографияләрдән алынган өзекләр китереп бара. Аларның әдәби-сәнгати хикәяләүгә катнашы булмаса да, роман эчтәлеге өчен алар, тулаем алганда, артык түгел. Тик бу үзенчәлекле алымга мөрәҗәгать иткәндә, мәсьәләгә бик сак килү таләп ителә. Беренчедән, әлеге саф фәнни өзекләрнең байтагы хронологик яки вакыйгалар барышы ягыннан роман эчтәлегенә туры килми һәм әсәрнең сюжетын «бутый», бөтенләй икенче якка яисә башка тарихи дәвергә алып китә. Икенчедән, сайлап алынган өзекләрнең кайберсе теоретик яки фактик яктан дөрес түгел. Романның XV бүлегендә автор Л. Н. Гумилевның «Хунны в Китае» (М., 1974) хезмәтеннән түбәндәге өзекне китерә, «Һун этногенезы бары тик кешелек тарихындагы этник чыгыш кына ул. Этногенезда башка халләрдәге кебек берлек, күплек белән шул чиккә җиткерелеп буталган ки, кисәк кенә берсеннән икенчесен аеру мөмкин түгел. Бишенче гасырда һун этносы Җир шарының дүрт җирендә юкка чыга, көнчыгышта, көнбатышта, көньякта һәм төньякта». Нинди дә булса этносның тулысынча юкка чыгуы гомумән мөмкин түгел. Ул ниндидер күбрәк санлы һәм көчле, «перспективалы» кабиләләр һәм халыклар арасында «эреп», яңа бер этносның яки этносларның барлыкка килеп, оешуында билгеле, ә кайвакыт хәлиткеч роль уйнарга мөмкин. Шуның белән бергә скиф-һун-сармат кабиләләре дә күпсанлы төрки халыкларның оешуында бик зур роль уйныйлар.

Тулаем алганда, М. Хәбибуллинның «Атилла» романы—бүгенге татар тарихи әдәбиятының зур казанышы. Күрсәтеп үтелгән аерым кимчелекләрдән арындырганда, ул тагын да камилләшә төшәчәк.

* * *

Күзәтелгән материаллардан күренүенчә, Атилла—Европа дәүләтләре һәм халыклары тарихында, һичшиксез, зур роль уйнаган тарихи шәхес. Аның исеме белән бәйле риваять-легендаларның беренче үрнәкләре әле ул исән чакта ук ижат ителеп, төрле халыклар күнеленә тирән үтеп керә һәм шактый киң тарала. Җиңелү дигән нәрсәне белмәгән легендар яугир тормышның иң киеренке мизгелләрен чагылдырган әлеге әсәрләр Европа халыклары күнелендә-теленә чарлана бара һәм берничә гасыр буена яши. Атилла бу дөньядан китеп 5—6 гасыр узгач, әлеге әсәрләр нигезендә Европа, бигрәк тә Скандинавия, Ирландия халыкларында чагыштырмача зур күләмле сагалар, дастан-жырулар барлыкка килә. Аларның барысында да диярлек Атилла нигездә уңай герой, ә инде немец халкының «Нибелунглар турында жыр» дастанында талантлы, игелекле, гадел, бер сүз белән әйткәндә—идеаль хөкемдар буларак сурәтләнә... Тагын 7—8 гасырдан соң Атилла образы язма әдәбият әсәрләренә килеп керә һәм анда шактый каршылыклы чагылыш таба. Индоевропеистика, европоцентризм идеяләренә нигезләнгән Феликс Дан әсәрендә Атилла кире, тискәре герой буларак сурәтләнсә, татар язучысы М. Хәбибуллин романында ул уңай герой буларак гәүдәләнә.

Татар халкының тарихи үткәнен өйрәнү яна бер югарылыкка күтәрелгән безнең көннәрдә ата-бабаларыбыз арасында булган, төрле халыклар язмышында тирән эз калдырган зур шәхесләр тормышы белән кызыксыну да тирәнәя һәм киңәя бара. Әнә шундый шәхесләр арасында беренче урында Атилла тора булса кирәк.

---

## Авторлар игътибарына

Кульязма җибәргәндә түбәндәге мәгълүматлар булу мәҗбүри:

1. Фамилиягез, исемегез, әтиегезнең исеме
2. Яшәү урыныгыз
3. Туган ел, ай, көнегез
4. Паспорт мәгълүматларыгыз
5. Дәүләт пенсия страховкасының страховка таныклыгы номеры
6. Вертикаль портрет рәвешендәге яхшы сыйфатлы фотосурәтегез
7. Телефоныгыз *(шәһәр кодын да күрсәтеп)*

# 28—КАСАС (КЫЙССАЛАР) СҮРӘСЕ

**Касас сүрәсе 88 аятьтән тора. Мәккәдә иңгән, берничәсе Мәдинәдә иңгән. Касас—кыйсса, хикәя, вакыйга сүзләренең күпчелеген аңлата.**

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим.

**1.** Та. Син. Мим. **(2)** Болар *(хәләлне харамнан, хакыйкатьне ялганнан)* ачык *(аерып бирә торган)* Китапның *(Корьәннең)* аятьләредер.

**3.** Иман китергән кавемнәр өчен Муса белән Фиргәвен турындагы хикәяләрнең берничәсен дөресе илә сиңа сөйләп бирербез. **(4)** Дөресе шул, Фиргәвен ул жирдә *(Мысырда)* хаким буларак артыгын кылана башлады: халкын фиркаларга аерып бетерде. Аларның бер өлешен изеп, зәгыйфьләндерде, аларның *(яһүдләрнең)* угылларын суеп, кыз балаларын гына калдыра башлады. Ул, чыннан да, бозыклык кылучы, рәхимсез хаким иде.

*(«Аятьтә сөйләнә торган кимсетелгән халык яһүдләр, ягъни, Исраил угыллары булыр. Берәүсе Фиргавенгә: «Исраил угыллары арасыннан бер ир бала дөньяга килер һәм шул ир бала үскәчтен синең солтанатыңның астын өскә китерер, тәхетеңне тартып алыр»,—дип сөйли. Һәм Фиргавен исраил угылларының яңа туган һәр ир баласын суйдырта бара».*

Хәсән Чантай тәфсиреннән.)

**5.** Без шул кыерсытылганнарга ярдәм итәргә теләдек. Алардан *(хәерле эшләргә)* өндәүче имамнар чыгарып, аларны *(Фиргавен халкының)* милкенә *(Мысырга)* варис итәргә теләдек. **(6)** Аларга *(изелгәннәргә)* ул жирдә *(Мысырда)* кодрәт биреп, Фиргавенгә, Фиргавеннең баш вәзире) Һамәнгә вә аларның гаскәрләренә дә аларның курыккан нәрсәләрен башларына китереп күрсәтергә ихтыяр иттек.

**7.** Муса анасының күңеленә Без:

—Аны имез. Аңа куркыныч килеп, син чарасыз калсаң, аны диңгезгә ташла, *(батып үләр дип, баласыз калырмын, дип)* курыкма. Без аны янә сиңа кире кайтарырбыз. Һәм аны пәйгамбәрләрнең берсе итәрбез,—дип боерык иңдердек.

**8.** Ниһаять, Фиргавеннең гаиләсе *(хатыны)* табылдык баланы елгадан алды. Соңыннан бу бала үзләренә дошман һәм афәт чыганагы булачагын алар белми иде. Чөнки Фиргавен белән Һамән вә аларның гаскәрләрендәгеләр азгын юлда иде.

**9.** Фиргавеннең хатыны әйтте:

—Минем өчен дә, синең өчен дә күз карасы кебек *(бер куаныч булыр)*.

---

Журнал өчен **Рабит БАТУЛЛА** әзерләде

Аны үтертмә, зинһар. Киләчәктә, бәлки, файдасы да тияр. Яки аны угыллыкка алырбыз,—диде. Ләкин алар эшнең асылын белеп бетерми иде әле.

**10.** *(Баласының рәхимсез Фиргавен сараена эләккәнен белгәч)* Муса анасының күнеленә борчу инде *(ул йокысыз калды)*. Әгәр дә аны иманлы итеп, *(сабырлык бирмәгән булсак)* ул дөреслекне *(серне)* ачып салган булыр иде.

**11.** Анасы Мусаның апасына әйтте:

—Муса артыннан калма,—диде. Ул, Фиргавен гаиләсе сизенмәсен, дип, сиздерми генә, ерактан күзәтте.

**12.** Без әүвәл имезүче сөт аналарының сөтен харам иттек *(Муса чит имчәкләрне авызына алмады)*. Шулчак апасы әйтте:

—Аны сезнең өчен бик яхшы тәрбия итәчәк, үзегез дә аннан канәгать калырлык бер гаилә табып биримме сезгә?—диде.

**13.** Шулай итеп, аны анасына кайтардык. Күзе-йөзе яктырсын дип, кайгыдан бетерешмәсен, дип. Аллаһның вәгъдәсенә шик белдермәсен, хак икәнен белсен, дип. Ләкин аларның күбесе Хакны белми.

**14.** Егетлек чагына килеп житкәндә, Без Мусага хикмәт (акыл) вә гыйлем бирдек. Менә, Без игелек кылганнарны шулай бүләклибез.

*(«Хөкм» сүзеннән килеп чыккан «хикмәт» сүзе тәфсирләрдә еш кына «пәйгамбәрлек кылу» мәгънәсендә кулланыла».*

Ибраһим Дөнмәз тәфсиреннән.)

**15.** Бервакыт *(Муса)* беркемгә дә хәбәр бирмичә бер шәһәргә килеп керде. Бу шәһәрнең халкы ваемсыз гына ял итеп *(яшәп)* ята иде. Һәм ул ике кешенең сугышканын күрде. Аларның берсе үзенең *(яһүд)* токымыннан, икенчесе исә дошман *(Фиргәвеннең кыптый)* кавеменнән иде. Милләттәше аннан ярдәм сорап кычкырды. *(Муса)* йодрыгы белән *(кыптыйга)* китереп орды да, үтерде дә. *(Бу кылмышына аптырап, Муса):*

—Бу—шайтан эше булып чыкты. Ул, чыннан да, адзыручы, котыртучы ап-ачык бер дошман,—диде.

*(«Бу вакытта Муса гаделлекне яклаучы булып житешкән иде инде. Кыптыйлар Исраил угылларын кыерсыта башлый, аларны талыйлар, өйләрен туздыралар. Менә Муса шул гаделсезлеккә шаһит була һәм түзеп торалмыйча мескенне якларга алына һәм белештерми кеше үтерә. «Бу—шайтан эше булып чыкты», дигән сүзен ике мәгънәдә шәрехләргә була. Рәхимсез кыптыйның бичара яһүдине җәберләве турында әйтелгән сүз дип тә, артык кызып, адәм үтергәнен гөнаһ санап, үзенә карата әйткәндер, дип тә аңларга була».*

Ибраһим Дөнмәз тәфсиреннән.)

**16.** Муса:

—Йа, Раббым, чыннан да, мин язык кылдым. Ярлыка мине,—дип ялварды. Һәм Аллаһ аны ярлыкады. Ярлыкаучы һәм чиксез миһербанлы бары тик бер Аллаһ кына.

**17.** Муса әйтте:

—Раббым, мина биргән нигъмәт *(һәм гафу)* хакы өчен жинаятьчеләргә беркайчан да ярдәмче булмам, иншаэаллаһ,—диде.

**18.** *(Икенче көнне иртәнчәк ул)* курка-курка гына, алак-ялак карана-карана шәһәргә чыкты. Ни күзләре белән күрсен, кичә үзеннән ярдәм сорап кычкырган кешене тагын очратты. *(Ул тагын бер кыптый белән сугышып ята иде)* тагын ярдәм сорап кычкырды. Шунда Муса әйтте:

—Син үзең гаугачы икән,—диде.

**19.** Муса икесенең дә дошманы булган кыптыйны сугыштан тыярга теләгән иде дә, тегесе әйтте:

—Әй, Муса, син кичә бер жанны кыйган идең инде, мине дә үтерергә телисеңме?—диде.—Димәк ки, син монда тәртип урнаштырырга *(игелек кылырга)* түгел, *(кеше үтереп)* залим бер хаким булырга килгәнсең, ахрысы.

**20.** Шәһәрнең икенче башыннан килеп, берәүсе ашыгып әйтте:

—Әй, Муса, сарайдагылар сине үтерергә тели. Тиз бул, син чыгып кач. Бу минем сиңа булган игелекле киңәшем,—диде. **(21)** Муса курка-курка, алак-йолак карана-карана шәһәрдән чыгып китте.

—Раббым, мине залимнәр өереннән коткар,—дип ялварды.

**22.** Мәдьянгә туп-туры барганда ул:

—Раббым мине тугры юлга күндерер дип ышанамын,—диде.

**23.** Муса Мәдьян шәһәре тирәсендәге су улаклары янына килгәндә хайваннарына су эчерүче бик күп кешеләрне күреп алды. Алардан бераз читтәрәк хайваннарын суга якын җибәрмәскә тырышучы ике кызны да күрде. Аларга:

—Сез нигә малларыгызга су эчермисез?—диде. Шушы җавапны алды:

—Чабаннар үз малларын эчереп бетермичә, без малларыбызны эчертә алмыйбыз. Атабыз исә бик олы яшьтә *(малларга су эчерерлек хәлдә түгел).*

**24.** Шуннан соң Муса аларның малларын эчерде. Соңыннан күләгәгә керде һәм:

—Йа, Раббым, хактыр ки, иңдерeләчәк һәр ниг ъмәтеңә мохтаҗмын, —дип дога кылды.

**25.** Шуннан соң теге ике кызның берсе тарсынып кына аның янына килде:

—Атам хайваннарыбызны эчергәнеңә күрә, рәхмәт йөзеннән, бүләкләр өчен сине үз янына чакыра,—диде. Карт *(хәзрәти Шөгаеб)* янына килеп, Муса башыннан кичкәннәрне бәян итте. Карт әйтте:

—Курыкма, син инде шул гаделсез халыктан котылдың,—диде.

**26.** Кызларның берсе әйтте:

—Атакаем, син аны эшләгәнеңә хак биреп, чабан итеп ал. Түләп эшләтәчәк бу игелекле егет—көчле һәм ышанычлы кеше,—диде.

**27.** *(Шөгаеб)* әйтте:

—Сигез ел миңа хезмәт иткәннән соң, мин сиңа шушы ике кызымның берсен никахлармын. Ун ел эшләргә теләсәң—ихтыярың. Мин сине ирексезләмимен. Иншаэаллаһ, син мине һәрчак игелекле кеше буларак белерсең,—диде.

**28.** Муса болай диде:

—Бу синең белән минем арадагы *(килешү)* булыр. Бу ике шартның кайсысын гына үтәсәм дә, миңа каршы үпкә-ризасызлык *(ирексезләү)* булмаска тиеш. Сөйләшкәнебезгә Аллаһ—шаһиттер.

**29.** Килешенгән хезмәт вакытын тутырып, гаиләсе белән юлга чыккач, Муса Тур тарафында бер ут күреп, гаиләсенә:

—Сез шушында торып торыгыз: мин еракта бер ут күрдем, бәлки, аннан берәр хәбәр яки җылыныр өчен утлы кисәү алып килермен,—диде.

**30.** Анда баргач, шул мөбарәк үзәннең уң тарафыннан, куаклыклар эченнән бер өн ишетелде:

—Әй, Муса, син белеп тор, бөтен галәмнәрнең Раббысы ул—Мин буламын—Аллаһ Тәгалән!

**31.**—Карышкыныңны ыргыт,—дигән тавыш ишетелде. Муса таягын җиргә ташлады, таяк еланга әверелде, Муса артына да борылып карарга куркып, кача башлады. Тагын әйтелде:

—Әй, Муса, кире борыл. Курыкма. Син иминлеккә ирешкәннәрдәнсең.

**32.**—Кулыңны куеныңа тык, ул зыян күрмичә, ап-ак булып чыгачак. Куркудан җәелгән кулларыңны кушыр. Менә бу ике галәмәт *(еланга әверелгән таяк белән ялтыравыклы кул)* Фиргавен һәм аның адәмнәре алдында Раббың тарафыннан җибәрелгән һәм инкарь ителмәстәй ике дәлилдер. Алар юлдан язган бозык халык булып чыкты.

**33.** Муса әйтте:

—Раббым, мин аларның бер кешесен үтергән идем, мине үтермәгәйләре, дип куркамын,—диде. **(34)**—Кардәшем Һарун миннән матуррак сөйли. Хаклы икәнемне раслаучы ярдәмчем итеп аны да минем белән бергә юлла. Алар миңа *(ялганчы кушаматы тагарлар дип),* дип куркамын.

**35.** Аллаһ боерды:

—Энең сиңа ышанычлы терәк булыр. Һәм мин сезгә шундый бер кодрәт бирәчәкмен ки, аятьләребез *(могҗизаларыбыз)* мәсьәләсендә алар сезне җиңәлмәс. Сез һәм сезгә ияргән иманлылар өстен чыгачаксыз,—диде.

**36.** Муса аларга ап-ачык аятьләребезне китергәч, алар:

—Бу—күз буу сихередер. Ата-бабадан бу турыда ишеткәнебез булмады,—диделәр. **(37)** Муса әйтте:

—Тугры юлга өндәүче итеп кемне күндергәнен һәм ахырда кемнең Сәгадәткә ирешәчәген иң яхшы белүче—Раббым Үзедер. Хактыр ки, залимнәргә котылу *(җәннәт)* булмас.

**38.** Фиргавен әйтте:

—Әй, яраннарым, сезнең өчен миннән башка илаһ барлыгын мин белмимен. Әй, Һамән, син учак як, кирпеч яндыр. Миңа биек манара житкез. Мин Мусаның Тәңресе янына менмәк буламын. Әмма ул чеп-чи ялган сөйли, дип уйлыйм мин,—диде.

**39.** Фиргавен һәм аның буйсынарлары *(яраннары)* урынсызга горурландылар һәм Безнең хозурымызга кайтарылачакларын инкарь иттеләр. **(40)** Без аны һәм гаскәрләрен тотып алдык та, диңгезгә ташладык. Бакчы, залимнәрнең язмышы ничек булып бетте.

**41.** Без аларны утка *(тамугка)* чакыручы житәкчеләр иттек. Кыямәт көнендә алар ярдәм күрмәячәк. **(42)** Бу дөньяда Без аларга ләгънәт ордык. Кыямәт көнендә дә алар ләгънәтләнгән һәм мескен хәлдә булыр.

**43.** Хактыр ки, әүвәлге *(Нух, Һуд, Салих, Лут)* халыкларын Без һәлак иттек. *(Һәлак булганнарның фаҗигасе турында уйлый-уйлый үгет-нәсихәт алсыннар дип, кешеләргә ап-ачык дәлилләр, тугры юлга юнәлтүче вә рәхмәтебез буларак)* ул Китапны *(Тәүратны)* Мусага бирдек.

**44.** *(Ий, Мөхәммәд)* Мусага әмеребезне күндергәндә, син тауның Көнбатыш ягында түгел идең, ул вакыйганы күреп тормадың. **(45)** Әмма Без *(Мусадан)* соң бик күп халыкларны яралттык, алары озын гомерле булды. Син Мәдьян халкы арасына кереп, аларга аятьләребезне укымадың, ләкин Без *(булып узганнарның хәбәрен—Коръәнне)* сиңа күндердек. **(46)** Муса белән *(вәхий аша)* сөйләшкәнебез вакытында син Тур тавы янында түгел идең. Ләкин синнән алда үзләренә кисәтүче *(пәйгамбәр)* килмәгән бер кавемне кисәтер өчен Раббыңнан бер рәхмәт буларак, *(алдагы вакыйгаларны сиңа белгерттек)* сине сайладык. Бәлки, алар уйлап, үгет алыр!

**47.** Әгәр дә үзләре кылган *(гөнаһлары)* аркасында башларына бәла төшсә, алар:

—Раббыбыз, әгәр дә син безгә пәйгамбәр җибәргән булсаң, без аятьләреңә ияргән булыр идек тә, иман китергән булыр идек,—дип әйтәчәкләрен белмәсәк, сине күндермәгән булыр идек.

**48.** Безнең тарафтан аларга Хакыйкать *(белән Пәйгамбәр)* килгәч, әйттеләр:

—Мусага бирелгән кеби аңа да могҗизалар бирелергә тиеш түгел идемени?—диделәр. Ярый, аннан байтак элек Мусага бирелгәнне инкарь итмәделәрмени?

—Бер-берсен тулыландыручы ике сихер(че),—диделәр.—Һәм шунысы хактыр ки: без аларга ышанмыйбыз.

49. *(Ий, Мөхәммәд)* әйт:

—Әгәр дә сез хаклы икәнсез, Аллаһ яныннан бу ике Китаптан да *(Тәүрат белән Коръәннән дә)* яхшырак-дөресрәк бер китап китерегез һәм мин ана иярермен,—диген. **(50)** Әгәр дә алар сиңа иярмәсә, белеп тор, димәк, алар нәфесләренә *(кирелекләренә)* күрә генә эш йөртәләр. Аллаһтан тугры юл күрсәтелмәгән килеш, бары тик үз нәфесенчә генә эш йөртүчедән дә азгынрак башка берәү буламы икән? Әлбәттә, Аллаһ азгыннарны тугры юлга күндермәс.

**51.** Хактыр ки, уйлап үгет алсыннар дип, сүзебезне *(Коръәннән аятьләрен)* берсе артыннан икенчесен өзлексез төшерә тордык. **(52)** Аннан *(Коръәннән)* элек китаплы булганнар (яһүдләр, христианнар) да иман китерде. **(53)** *(Коръән)* укыганда, алар:

—Ана иман китердек. Чөнки ул Раббыбыздан килгән Хакыйкать. Чынлыкта без инде әллә кайчан Аллаһны бер дип танучылар идек,—диделәр.

**54.** Сабыр иткәннәре һәм итагатьләре өчен аларга ике тапкыр әҗер бирелер *(ике китапка да ышанганнары өчен)*. Болар яхшылык эшләп, яманлыкны куучылар. Алар үзләренә без күндергән ризыктан хәер бирүчеләр. **(55)** Алар буш сүз *(гайбәт)* сөйләүчеләр янында тормас:

—Безнең эшебез бар, сезнең дә үз эшегез. Сезгә сәламнәр булсын. Без җаһилләр арасында булуны эстәмибез,—дип китеп барырлар.

**56.** Хактыр ки, *(ий, Мөхәммәд)* син үзең сөйгән кешеләрне тугры юлга күндерә алмассың. Үзе ихтыяр иткәннәрне фәкать Аллаһ тугры юлга күндерер. Кем тугры юлга керәчәкне Ул бик яхшы белеп тора.

**57.** Алар *(Кураеш мөшрикләре)* әйтте:

—Сиңа ияреп, иман китергән булсак, без йортсыз-җирсез, ватансыз калган булыр идек *(безне имансызлар куган булыр иде)*,—диделәр.

Без аларны үз тарафыбыздан күндерелгән һәр төрле җимешләре мул булган хөрмәтле вә имин урынга *(Мәккәгә)* урнаштырмадыкмыни? Ләкин аларның күбесе моны белми.

**58.** Без *(муллык эчендә)* яшәүләре белән мактанучы ничә кавемнәрне һәлак иттек. Әнә, алардан соң калган ул буш урыннарга бик азлар килеп урнашты. Аларның малларына Без варис булып калдык. **(59)** Халык күп яши торган шәһәрләргә аятьләрне укып бирә торган пәйгамбәрләрен алдан җибәрмичә торып, Раббың ул шәһәр халыкларын һәлак итмәде. Без халыклары залим булган шәһәрләрдән башкаларны һәлак итүче булмадык.

**60.** Сезгә бирелгән һәр нәрсә *(мал, байлык, ләззәт)* фани дөньяда алдавыч бизәк һәм тиз үтеп китүчедер. Аллаһ хозурындагылар исә *(җәннәт)* тагын да хәерлерәк һәм тагын да гомерлерәк. Моннан соң да акылыгызга килмәссезмени?

**61.** Гүзәл сүзләр илә *(Аллаһтан)* вәгъдә алган һәм Аның белән *(Аллаһ вә җәннәт илә)* кавышкан кешеләр *(бар)*; фани дөньяда вакытлыча гына бирелгән байлык һәм рәхәтеннән файдаланып та, Кыямәт көнендә *(җәза өчен)* хозурыбызга китереләчәк кешеләр бар. Шулар икесе бертигез булырмы?

**62.** Ул Көнне аларны чакырып әйтер:

—Нәҗес теләкләрегез белән уйлап чыгарган һәм Аллаһка тиң саналган уртакларыгыз кайда? *(Күрсәтегез!)*

**63.** Алар*(ның җәһәннәмгә керәчәкләре)* турында әйтелгән сүз гамәлгә ашканнан соң:

—Йа, Раббыбыз, менә боларны без income аздырдык. Үзебез ничек азган булсак, аларны да шулай аздырдык. *(Хактан)* ераклаштык. Сиңа баш ордык. Алар безгә табынмадылар *(үз нәфесләренә, җенси ихтыяҗларына табындылар)*,—дип әйтерләр.

**64.** Аларга әйтерләр:

—*(Аллаһка)* тиндәшләрне чакырыгыз,—диярләр. Чакырырлар. Ләкин алардан

*(сыннардан, ташлардан, бозаудан)* җавап булмас. Менә шунда алар җәзасын алыр. Их, алар иман китергән булса *(бу газапларны күрмәс иде).*

**65.** Ул Көнне *(Хак Тәгалә)* аларны дәшеп:—Пәйгамбәрләремә сез ничек җавап биргән идегез?—дип сорар. **(66)** Ул Көнне аларга барлык хәбәрләр дә шомлы булыр. Үзара хәл сораштырырга да чамалары булмас. **(67)** Әмма тәүбә итеп, иман китереп, игелек кылганнар морадларына *(Сәгадәткә)* ирешкәннәр арасында булыр.

**68.** Раббың теләгәнен эшли, ни теләсә, шуны сайлап ала. Аларның *(мөшрикләрнең)* сайлау хокукы юк. Аллаһ *(алар Аллаһка тиң, дип инанган уйдырма тәңреләреннән)* пакь һәм өстен. **(69)** Күнелләренә ни яшергән булсалар, нәрсәне ачык эшләсәләр—барысын да Раббың белеп тора. **(70)** Аллаһ ул шундый: аннан башка *(Илаһи кодрәткә ия һәм)* Тәнре булырдай һичберкем юк. Дөньяда да, Ахирәттә дә бөтен мактау Аңа гына. Хөкем дә Анда гына. Барыгыз да Аңа кайтарылачаксыз.

**71.** Әйт:

—Әгәр Аллаһ Кыямәт көненә чаклы өстегездә төн караңгылыгын тота калса, Аллаһтан тыш сезгә яктылык китерәчәк башка тәнре булырмы? *(Булса, күрсәтегез.)* Әле шуннан соң да сез колак салмыйсызмы?—диген. **(72)** Әйт:

—Әгәр Аллаһ Кыямәткә кадәр өстегездә яктылык тота калса, истирахәт *(ял, йокы)* өчен төнне Аллаһтан гайре кем китерәчәк? *(Булса, күрсәтегез.)* Әле шуннан сон да *(Хакыйкатьне)* күрмәссезме?—диген. **(73)** Рәхмәте илә Ул сез тынычлап ял итсен өчен, истирахәт кылыр өчен төнне, нигъмәтләр казаныр өчен көнне яралтты. Шаять, шөкер итәрсез!

**74.** Ул Көнне *(Аллаһ)* аларга эндәшер:

—Нәҗес теләкләрегез белән уйлап чыгарган, Миңа тиң санаган уртакларыгыз кайда?—дип сорар. **(75)** Һәр халыктан берәр шаһит *(үз пәйгамбәрен)* чакырырбыз да:

—Дәлилләрегезне китерегез,—диярбез. Алар шунда белер, Хакыйкать Аллаһ янында. Табынган нәстәләре дә аларны ташлап, юк булыр.

**76.** Карун—Муса кавеменнән иде. Ләкин ул *(халкына)* каршы гаделсезлек кылды. Без аңа шундый байлык бирдек ки, *(аның хәзинә саклана торган амбарларының)* ачкычларын хәтта куәтле баһадирлар да көчкә күтәреп йөрер иде. Шул вакыт кавемдәшләре аңа әйтте:

—Масайма (байлыгың белән)! Аллаһ мактанчыкларны сөймәс,—диде.

*(«Карун хәзрәти Мусаның туганнан туган энесе иде. Башта ул Мусага ияреп иман китерде. Ләкин хирыслыгы, саранлыгы, көнчелеге аркасында монафикъ булды. Исраил угылларының башында Фиргавен хаким булып торганда, Карун аның ярдәмчеләреннән берсе булды, ягъни залимлек ягына күчте. Байлыгы, дәрәҗәсе белән мактана башлады. Имеш, Тәүратны иң яхшы укый белүче Карун гына. Химия һәм сәүдә эшләрендә галим булган кеше. Ләкин ахырда галимлеге дә, байлыгы да аңа ярдәм итми, Карун һәлак була. Бөтен байлыгы белән аны Җир йота».*

Ибраһим Дөнмәз тәфсиреннән.)

**77.**—Аллаһның сиңа биргән мөлкәтеннән *(хәер, садака, зәкят)* биреп, Ахирәт көненә әзерлән. Дөньядагы өлешенне дә онытма. Аллаһ сиңа бәрәкәт биргәне кеби, син дә *(кешеләргә садака биреп)* юмарт бул. Җир йөзенә бозыклык таратма. Аллаһ бозыкларны сөймәс.

**78.** *(Карун)* әйтте:

—Бу байлык миңа бары тик гыйлемем аркасында гына *(үз тырышлыгыма күрә)* килде,—диде. Үзеннән әүвәл килгән, аннан да куәтле-бай өстен булганнарны Аллаһ һәлак иткәнен белмимени ул? Андый гөнаһлылардан сорау алып торылмас *(алар туп-туры җәһәннәмгә ябылыр).*

**79.** Шулай киенеп, ясанып *(Карун)* халык каршысына чыкты. Дөнья артыннан куучылар әйтте:

—Их, Карун кебек бай булсаң иде. Ул чыннан да, дөньядагы иң насыйп *(бәхетле)* кеше,—диделәр.

**80.** *(Дөньяны аңлаган)* белемле кешеләр әйтте:
—Йазыклар, йазыклар булыр сезгә. Аллаһның савабын туплау, иман китерү—игелек кылучылар өчен *(ул байлыклардан)* чиксез хәерле. Ләкин сабыр иткәннәр, *(Аллаһ юлында)* чыдам булганнардан башкасы *(Сәгадәткә)* ирешмәс,—диделәр.

**81.** Ниһаять, Без аны, зиннәтле сарайлары белән бергә, җиргә уптырдык. Аллаһ каршысында якларлык аның беркеме дә юк иде. Ул үзен-үзе якларлык хәлдә дә түгел иде.

**82.** Кичә аның урынында булырга теләгән көнчеләр иртәнчәк әйттеләр:
—Ай-һай ла, Аллаһ колларының берсенә ризыкны мул итеп бирә, икенчесенә исә тар итә. Аллаһ безгә мәрхәмәтле булмаса, безне дә йоттырыр иде. Димәк, Хакыйкать шулдыр ки: *(комсызлар, гаделсезләр)* кяферләр Сәгадәткә ирешмәс,—диделәр.

**83.** Ахирәт йорты шул булыр. Без аны Җир йөзендә тәкәбберләнмәгән, байлык артыннан кумаган, азгынлык таратмаган кешеләргә бирербез. Иң яхшы нәтиҗә саф мөселманнарныкы булыр.

**84.** Кем игелек кылган, аның өчен шуннан да *(кылган игелекләреннән дә)* мул хәер алачак; кем яманлык кылган, кылганнарыннан артык җәзаланмас.

**85.** *(Ий, Мөхәммәд)* Коръәнне *(уку, аңлату, аңа ияртүне)* сиңа фарыз кылган Аллаһ, әлбәттә, сине кайтарылырга тиеш җиргә кайтарачак. Әйт:
—Кем тугры юлдан бара, кем тугры юлдан яза—барысын да Аллаһ бик яхшы белеп тора,—диген.

**86.** Син бу Китапны үзеңә төшерелүен көтмәгән идең. Ул бары тик Раббыңның рәхмәте илә иңдерелде. Бәс, аң бул, кяферләргә аркадаш булма. **(87)** Аллаһның аятьләре сиңа иңдерелгәч, сак бул, алар сине аятьләрдән биздерергә тырышыр. Кешеләрне Аллаһ юлына чакыр. *(Ярдәм кирәк булса)* Аллаһка ялвар. Ләкин мөшрик була күрмә *(ярдәмгә башка уйдырма илаһларны чакырма).* **(88)** Аллаһка тинләп, башка бер ялган илаһка табына күрмә. Аллаһтан башка *(Илаһи кодрәткә ия һәм)* Тәңре булырдай һичберкем юк. Аннан башкалар барысы да һәлак булачак. Хөкем Аның хозурында вә сез бары тик Аның хозурына кайтарылачаксыз.

صدق الله العظيم

## ШАГЫЙРЬ АРХИВЫННАН

*Зәет ага Мәҗитов—соңгы елларда бик актив язды, гамьле, чәмле, хәтта усал, заманча шигырьләр бастырды. Яңа китаплары да дөнья күрде. Беребез дә көтмәгәндә дөньядан киткән өлкән каләмдәшебез, озак еллар университет доценты, фольклор һәм поэзия, аерым алганда Фатих Кәрим иҗаты буенча белгеч булган шагыйрьгә быелның августында 75 яшь тулачак иде... Үлгәннән соң аңа Бәләбәй шәһәре (Башкортстан Язучылар берлеге) бүләге—үзе гомере буе иҗатын, тормышын өйрәнгән, әсәрләрен чыгарган Ф. Кәрим исемендәге премия дә бирелде. Исеме яд ителә, шигырьләре дә басыла тора. Без бу санда тәкъдим иткән шигырьләре шагыйрьнең архивыннан алынды: аларторле елларда язылганнар.*

## Зәет Мәҗитов

### Рәнҗемәгез!

Рәнҗемәгез миңа, чәчәкләр,
Сирәк мактыйм сезне шигырьдә.
Килгәнем юк күптән күрергә,
Хозурланып карап йөрергә,
Рәнҗемәгез миңа, чәчәкләр.

Рәнҗемәгез миңа, былбыллар,
Җырыгызны язмый башладым,
Язганын да ертып ташладым,
Тыңлаучыны чөнки тапмадым,
Рәнҗемәгез миңа, былбыллар.

Рәнҗемәгез миңа, чишмәләр,
Хәлегезне күптән белгән юк,
Йөзек салып сәлам биргән юк,
Суыгызга башым игән юк,
Рәнҗемәгез миңа, чишмәләр.

Рәнҗемәгез, урман-кырларым,
Чыкканым юк сезгә күптәннән,
Дөнья баскан мине, күмгән гамь,
Әйтерсең мин җансыз бер адәм,
Рәнҗемәгез, урман-кырларым.

Рәнҗемәгез, зәңгәр күкләрем,
Айлы төннәр, гафу итегез,
Шигыремнән күптән киттегез,
Шаян түгел хәзер, җитди без,
Рәнҗемәгез, зәңгәр күкләрем.

Рәнҗемәгез, гашыйк чибәрләр,
Зурласам да тиң, саф сөюне,
Югалттым мин гыйшык көемне,
Җырлы түгел җаным, көюле,
Рәнҗемәгез, гашыйк чибәрләр.

Рәнҗемәгез, илдәш-кардәшләр,
Онытып барам сезнең кадерне,
Үз җаена борып тәкъдирне,
Талый заман җанны, бәгырьне,
Рәнҗемәгез, илдәш-кардәшләр.

Рәнҗемә син миңа, Гүзәллек,
Матур хисләр бизә күңелдән,
Тәмле сүзләр китә телемнән,
Ямь тапмыйча йөрим илемнән,
Рәнҗемә син миңа, Гүзәллек.

Рәнҗемә син миңа, Каләмем,
Язмыйм бүген шат җыр, тантана,
Имансызлык аза, мактана,
Йөрәгемнән сызлап кан тама,
Рәнҗемә син миңа, Каләмем.

## *Төрле еллардан*

### Шаяру

Уема да кермисең дип,
Син юри кыйланасың,
Хәзер машина да уйлый,
Ник кеше уйламасын?!

❦

Бөртекләп җыела бөртекләр,
Бөртекләрдән туа көшелләр,
Күптән белгән моны кешеләр,
Белмәгән тик минем ишеләр.

❦

Болытлар артында болыт бар,
Офыклар артында офык бар,
Карама караңгы болытка,
Җит үз таңың аткан офыкка

## Кайчагында

Ник бу шулай: тел әйләнми тора
Әйтәсе сүз бик күп булганда?
Ник кайвакыт күңел ялгыз була
Кеше кайнап торган урамда?

## Кеше

Эше белән кеше булып яши кеше,
Нидер төзү, нидер көйләү—кеше эше.
Кеше түгел, яшәсә тик үзен уйлап,
Кешеләрне уйлап кына кеше—Кеше.

❦

Мәхәббәтнең тонык чишмәсенә
Син шаярып балчык ташладың.
Офтанасың хәзер үзең менә,
Инде үзең сусый башладың!

❦

Телсез йөрде гомергә.
Хәзер баеган сергә,—
Бик тели сөйләшергә.
Тик шунсы гына яман—
Бер якыны калмаган,
Сөйләшә алмый агаң.

❦

Бер хакыйкать әйтәм—аңла аны—
Заман үзе кат-кат раслаганы:
«Әгәр өскә менсә ашказаны,
Аска төшә, шиксез, баш казаны».

## Яшәдем

Яшәдем мин намус саклап, сабыр итеп,
Аз-маз гына үземә дә өлеш көтеп.
Төшендем мин беткән чакта гомер үтеп:
Өлешемә тигән көмеш—тишек, китек.

❦

Бер уңмаган сәфәр кабат уңмас,
Уты сүнгән учак кабынмас.
Яшәлгәнне кабат яшәп булмас,
Бер югалткан бәхет табылмас.

## Беләм, язмыш

Беләм, язмыш, сине: шук нәрсә син,
Күп шаярдың инде минем белән.
Тик барыбер мине—җиңәлмәссең,
Һич югында җиңәм... үлем белән.

## Бәйрәм көткәндә

И бизәнә соң Казан, и бизәнә,
«Мин—мөстәкыйль» дип бәйрәмгә кинәнә.
Ике башлы бөркет исә кизәнә:
«Җырла, тик бел: син әле дә биләмә».

✿

Язмасаң каләм дә тутыга,
Карасы кипшенә аның да,
Янмасаң йөрәк тә сулыга,
Ут бетә, дәрт сүнә канында.

## Учак

Кабыздым да учак, көтәм карап
Ялкын теле үрләп киткәнен.
Искә төшә, язмыш уты ялап,
Көеп беткән өтек үткәнем.

## Тавыш купкан

Ир белән хатын арасында тавыш купкан,
Эчмәдем, дип аклана ир—каһәр суккан.
Ир генәме, бүген бездә ил исерек,
Юк, акылга кертәлмәссең хет ат туптан.

## Каян әле?

Урамнарга чыктык сыймый базарга без,
Каян әле баедык соң товарга без?
Гаделләрне калдырдык та хаерчегә,
Ертлачларга юлны ачтык азарга без.

## Ак юл сезгә

Күбәләктәй уйнап ява эре карлар,
«Бәхеткә ул» дип сөенеп йөри парлар.
Гашыйкларга карың ни дә, бураның ни?—
Наз бит яз ул. Ак юл сезгә, язы барлар!

## Янды офык

Чирәмнәргә сибә-сибә көмеш чыкны
Янды офык, бишегеннән кояш чыкты.
Әрсезләнеп тутырдым да йөрәгемә
Шигырь итеп чәчәм шушы Хозурлыкны.

## Инде сип су

Бер генә кат карадың ич нурлы итеп,
Нинди утың бу җанымны алды өтеп.
Көне-төне янам инде—ялкында мин,
Утын тёрттең, инде сип су салкын итеп.

❦

Мин еш кына шундый хәл кичерәм:
Мең уй килә башка берьюлы,
Шатлык катнаш була кайгым белән,
Дәртем—әсир кебек тыюлы.

❦

Булмады Рәсәй илендә
Хөр яшәүнең яктысы.
Сызланды ил читлегендә
Тукайның да җан кошы.

*1968—1999.*

## *Юмор -сатира*

# Әнәс Хәсәнов

ШАЯН ХИКӘЯЛӘР

### Яңабаштан

Гатаулла абзыйның сөйләшеп торганда, әллә каян гына, «яңабаштан» дип китереп кыстыра торган гадәте бар. Аптырады инде үзе дә шул кирәкмәгән чүп сүз аркасында. Бөтенләй кәтелмәгән урынга шул «яңабаштан» килеп кысылгач, тыңлаучылар кычкырып көлеп җибәрә.

—Еллар уза, без картаябыз, энем, яшьләр үсә, яңабаштан. Менә күрше Гыйльметдин кызы әле кайчан гына яланаяк тәпили иде, хәзер, күрәсең, үзенең дә баласы туган, яңабаштан. Бәхете белән үссен инде, яңабаштан.

Моны ишеткәч яшьләр көлми ничек түзсен...

Теге сүзне кыстыруын үзе дә сизеп алгач, Гатаулла абзый кинәт туктап кала, аның чал кашлары бергә килеп кушыла. Аннан ул, көрсенеп, тамырлары бүртеп торган кулын селтәп, сүзен дәвам итә.

Тора-бара Гатаулла абзыйның теленә авыл халкы ияләшеп тә бетте. Ә менә чит кеше...

Бер мәртәбә болай булды. Гатаулла абзый күптән инде йортын яңартырга йөри иде. Күмәк хуҗалык аңа менә дигән юан-юан нарат бүрәнәләр дә, түбә ябарга өр-яңа шифер табаклары да кайтартты, ә менә балта осталарын китерә алмады. Инде барысы да әзер, эш башларга кирәк, дигәндә генә балта осталары ашыгыч төстә амбар сала башладылар. Хуҗалык рәисе Сәлимов: «Бераз көт, Гатаулла абзый, амбардан соң синең йортыңа тотынырбыз», дисә дә, Гатаулла абзый риза булмады. Җәйнең матур көннәре санаулы гына калып килә дип, күрше авылга балта осталары эзләргә китте.

Берничә көннән иске йортның тузанын җил тузгытып ташлады, нарат бүрәнәләр чутланып, яшел чирәм өстенә сузылып яттылар. Эш шулай уңай гына барганда беркөнне Гатаулла абзыйлар янына Сәлимов машинасы килеп туктады.

—Оят булса да сиңе борчырга туры килә инде, Гатаулла абзый,—диде ул.—Ындыр табагында эшләүче Нәфикъ авырып китте бит. Алыштырырга кеше юк. Ул терелгәнче генә булышып тормассыңмы?

Шундый үтенеп сорагач, олы кешенең сүзен ничек кире кагасың инде. Сәлимов үзе бит! Аның авылдашларына эшләгән яхшылыгын әйтеп бетерерлек түгел. Гатаулла абзый риза булды. Осталар да каршы килмәде:

—Бар, кирәк икән, үзебез генә дә булдырырбыз,—диделәр.

Гатаулла абзый, салына башлаган йорт эшләрен ташлап, ындыр табагына йөри башлады. Аннан ул төш житкәч, капкалап алырга гына кайта иде. Кайткан арада осталар янына килеп, аларның хәлләре белән кызыксына. Тегеләр аңа эшләгән эшләрен күрсәтеп йөргәндә, Гатаулла абзый:

—Тәрәзә төпләрегез яхшы булган, яңакларын да шулай матур эшләсәгез, яңабаштан,—дип кысытырып куя.

---

Әнәс ХӘСӘНОВ *(1935)—күпсанлы тәрҗемә китаплары һәм телевизион спектакльләр авторы. Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. Казанда яши.*

Мондый сүзләрдән соң осталарның йөзе карангыланып китә.

Элек-электән сәер бу халык, дип уйлый хуҗа кеше әчтән генә, син аларны мактыйсың, ә аларга бу нигәдер ошамый. Үзләре сүзгә дә саран, житмәсә.

Иртәгесен осталар тәрәзә яңакларын көзгедәй шомартып бетергән. Гатаулла абзый аларның эшеннән бик канәгать кала.

—Менә булган. Түшәм такталарын да шулай тигез, матур итеп шомартсагыз, яңабаштан...

Кичкә кадәр осталарның бөтен вакыты түшәм такталарын шомартып үтә.

Тора-бара алар Гатаулла абзый белән бөтенләй сөйләшмәс булдылар. Мона кадәр осталарның һәр нәрсәне жентекләп, кат-кат эшләгәннәренә шатланып йөргән Гатаулла абзый, тәмам аптырашта калды.

Бер кичне келәттә йокларга яткач хатыны Галимәгә бәйләнде бу:

—Әллә син аш-суыңны кысан тотасыңмы, яңабаштан, кеше тиктомалдан шулай итенмәс иде?!

—Ату син мине белмисең! Бүген генә саранланып торырга... Теге утлы савытларыңны азсыналармы икән әллә? Әйттем мин сиңа, алларына ящиге белән куй, дип. Бөтен районда мәсхәрәгә каласың килде, күрәсең. Авылларына кайткач, Кырмыска Гатаулласыннан да карун кеше юк икән, дип сөйләп йөрүләре бар әле.

Таякның юан башы үзенә төшүен күргәч, Гатаулла абзый ярсып китте:

—Юкны лыгырдап ятмале, яңабаштан! Ничек келәделәр, шулай куям. Мине районда белмиләрдер шул! Тукта әле, мин бүген өйләнгән кияү түгел, ләбаса, тел яшереп торырга,—диде ул. һәм, дәфгатән торып, эчке күлмәк-ыштаннан гына күршеләренә керуп китте. Балта осталарына урын-жирне алар күрше Сәгыйтьләрнең өйалдына түшиләр иде.

Галимә түти:

—Башта киен, ичмаса,—дип, артыннан кычкырып калса да ишетмәде.

Ул арада Гатаулла абзый әйләнеп тә кайтты. Аның аптыраган йөзенә күз салгач, Галимә түти бөтенләй шомлана калды.

—Иртән өлгермәс иденме? Арып йокыга киткән кешеләрне бимазалап йөрмәсән? Нәрсә булды?

Гатаулла абзый актан-карадан берни дәшмичә акрын гына урынына барып ятты.

—Ник эндәшмисен? Әллә теленне йоттыңмы?

Гатаулла абзый бик озак дәшми яткач, хатынының аптыратуыннан туйды, ахрысы:

—Киткәннәр алар, яңабаштан,—дип, юрганын аяк астына тартып китерде. Аннан кинәт сикереп торып, мендәрләрдән нидер эзли башлады. Ниһаять, мендәр тышына кадалган кечкенә генә, нечкә генә бер йомычка табып, аны бөтен көченә селтәнеп, ачу белән читкә ыргыткач, борылып ятты да күзен йомып, уйга талды. Осталарның: «Мондый бәйләнчек кешене беренче очратабыз. бөтен эшне кат-кат эшләтә», дип күрше Сәгыйтькә зарланганын ул хатынына әйтмәде.

... Иртәгесен кояш чыгып килгәндә ул күрше авылда иде инде.

... Балта осталары шаркылдап көлә-көлә аның йортын бик тиз өлгерттеләр.

Гатаулла абзый яна йорт болдырында аларны:

—Кулыгыз алтын икән. Рәхмәт яусын сезгә, яңабаштан!—дип озатып калды.

## Туган көн

Ул бүлмәгә килеп кергәндә ике кулы белән дә биленә таянган иде. Кунаклар белән кул биреп күрешкәндә дә аның сул кулы билендә калды.

Күрешеп бетергәч, сәгатенә күз төшереп алды да:

—Зар-интизар булып көтеп утырабыз, дисез инде! Көтегез, сүнекләнеп,

көтегез,—диде ул, шырык-шырык көлеп.—Шәхсән үзем эшне сузарга яратмыйм, гаепләмәссез. Шуңа да реаль карашлы Раил диләр мине—һәм ул өстәлдәге ризыклар өстенә ябылган зур тастымалны ачып җибәрде.

—Oho-ho-ho! Бар монда хәлләр!

Егет, кыска бармаклы кулларын угалап, өстәлдәге ниг ъмәтләргә тагын бер кат күз йөртеп чыкты. Аннан турап куйган кызыл балыкның зур бер кисәген алып авызына капты. Кунакларның күбесе моны уенга санадылар бугай, көлешеп алдылар. Авызындагы балыкны чап-чоп чәйнәп йоткач, ул сүзен дәвам итте:

—Ә сез көтеп утырасыз...

Аннары, ул әллә кайчангы таныш сыман миңа күз кысты да бик җитди кыяфәт белән аңлатырга кереште:

—Банкетларга, реаль күзлектән караганда, гел соң җыелалар. Эш көнендә бигрәк тә. Мин үзем көтеп утырмас өчен алтыга чакырсалар, җидегә барам. Как разга туры килә. Соңга калган булсаң, шәпләп «штрафнойны» әйләндерәсең дә тиз генә бүтәннәрне куып җитәсең. Вакытны бушка әрәм итү безнең заманда булдыксызлар фигыле, картларча әйтсәк.

—Раил кемне гаепли шулай?

Моны кухнядан килеп чыккан хуҗабикә Гөлнара әйтте. Ә Раил туктамастан сүзне аңа борды:

—Менә синең Инсафыңны ачуланып торам әле. тапкан туар вакыт, понимаешь. Атна уртасында, эш көнендә тумаса, шимбә, якшәмбе ярамаганмыни?

Кунаклар елмаешып, Инсафка текәлделәр. Уңайсызланудан, йөзе кызарган ирне Гөлнара яклады:

—Әй, туар алдыннан синең белән киңәш иткән булса соң...

—Беләм инде, беләм, син Инсафыңа тел-теш тидертмисең. Синең өчен ул күз өстендәге каш булды, понимаешь. Ә беләсеңме, Инсафың бит башта минем булачак хатыным артыннан йөрде.

—Минме? Булмаганны!.. Син әллә моны төшеңдә күрдеңме?!—Инсаф кунаклар каршында каушап калды.

—Йә инде, шаяртам гына ич. Уен күтәрмисең син. Һаман элеккечә калдың,—дип киеренкелекне йомшарткан булды Раил.

... Ниһаять, мәҗлес башланып китте.

Туган көне белән котлап, Инсафка матур-матур теләкләр әйтелде. Раил һәр кеше сүзенә үзенекен—«иң кирәген» өстәп, мәҗлеснең күрке булырга тырышты. Кыстатмады, рюмкасын да бик оста тотты. Иреннәре янына гына китерә дә, башын артка ташлап, каплый да куя. Еллар буе өйрәнсәң дә ул хәтлек булдыра алмассың.

Юбилярны күптәннән белгәннәр Инсаф дусны котлап, бик күп теләкләр әйтергә теләгән иде дә, ләкин эшем кешесенең тагын бер тормышчан тәкъдиме туып өлгерде.

—Ашап-эчеп кенә утырмыйк әле, ял итеп алырга кирәктер!

Минем дә сүз өзелде. Кунакларга ияреп Инсаф белән һавага чыгып киттем. Башкаларга нидер сөйләп торган Раил безнең янга килеп басты.

—Шулай да егетләр, туган көн уздыру мәшәкатьле эш. Бүгенге кыйммәтле заманда бигрәк тә. Ә хатын-кызга хезмәте күпме тагын.

Мин моңа каршы төштем:

—Яраткан кешесе өчен кем мәшәкать дип тора инде.

Болай да кысык күзен тагын да кыса төшеп, Раил башын янтайтыбрак миңа төбәлде:

—Димәк, синең бәйрәм уздырганың юк әле дус кеше. Менә шушындый мәҗлестән соң савыт-саба юып кара. Юк, егетләр, юк. Рәтең булып, туган көн уздырам дисәң, аны ресторанда эшләргә кирәк. Мәшәкате аз. Чын оркестры янында. Магнитофон акырту, йә гармунчыга ялыну түгел инде. Заказ ясa да тыпырдый бир. Аннан соң—иркенлеге, парин, биергә, дип әйтүем. Инсаф, син ачуланма, үзең беләсең, мин тормышка реаль карыйм.

Инсаф ияк кагып ризалашып торса да мин аның кәефе шактый кырылганын сиздем.

—Соңгы вакытта, төрле йорт кирәк-ярагы бүләк итү модага әйләнде,—дип ләчтит сатуын дәвам итте Раил.—Әнә, сиңа да кемдер кофе чәйнеге алып килгән. Реаль караганда, сиңа аның ни пычагыма кирәге бар, шулай бит, парин?

Бу сүздән аптырап киттем, чөнки ул чәйнекне мин үзем алып килгән идем.

Безнең тирәгә җыелган кунакларның берсе «Ник?»—дип сүз кушарга ниятләгән иде, Раил аның авызын тиз томалады:

—Соң, егетләр, кибетләрдә хәзер ирләргә яраклы әйбер беткәнмени? Менә шушы арзанлы люстра урынына, йә булмаса, кыек-мыек агачтан ясалган картина урынына Инсафка импортный күлмәк бүләк итсә, бу аның эчен тишәр идеме, ә? Ярар, Инсаф, ул күлмәк миннән булыр, яме. Минем бүген вакытым булмады. Иртәгә кертеп чыгармын мин аны. Сүземне җилгә очырганым юк әле. Киләсе бәйрәмеңдә өстәл башында мондый гади күлмәктән утырмассың.

Инсаф, сүзне уенга борырга теләп, нидер әйтергә омтылса да уңайсызлануын яшерә алмады. Ул арада Раил кинәт икенче борылыш ясады.

—Убщым, парин, тагын бер айдан, белеп торыгыз, якшәмбе көнне сәгать алтыда, «Нәүрүз» ресторанына рәхим итегез. Мондый кысанда түгел, минем день рождениены шунда, иркендә уздырыйк әле. Барыгызны да чакырам, егетләр. Анда урын киң. Инсаф, син Илдарларны да калдырма. Ризамы, Илдар?

Тәкъдим капылт кына ясалганга, мин:

—Әлбәттә, барырбыз,—дип әйтми булдыра алмадым.

... Билгеләнгән көн тиз килеп җитте. Тик һич кенә дә аяк тартмый, барасы килми. Җиде ят ич инде ул безгә, дип хатыным Разия да шактый киреләнде. Бармасаң да ярамый, теге чакта ашыгычлык белән ризалык биреп ташладым. Бүләгеннән куркып килми калды, дип уйлавы бар. Сыртны җиргә тидерәсе килми. Нинди бүләк алырга дип борчылып йөрүләремне әйтеп тормыйм, ничек булса булды хатыным белән без Раилнең туган көненә киттек.

«Нәүрүз» рестораны түбәндә безне чыраена сукыр лампа кабызып элгән Раил үзе каршылады.

—Ну, парин, болай килешми, көтә-көтә көтек булам бит инде, бигрәк авыр җыеласыз,—диде ул, сәламебезгә дә җавап бирмичә.

Мин кулымдагы «Харьков» электр бритвасын Раилгә тоттырдым. Ул аны әйләндереп-әйләндереп карады да:

—Рәхмәт. Вообще-то зря алгансыз, минем мондые бар иде инде. Беләсезме, хәзер иң яхшы электробритва «Юбилейный» санала икән,—дип куйды.

Мин тагын юньсез эш эшләвемне абайлап, үз-үземне тиргәргә тотындым. Сатучыдан: «Хәзер кайсы бритва үтемлерәк?», дип сорыйсы калган.

Кунаклар җыелып беткәндә сәгать сигез тулды. Раил безне кат-кат санап йөрде дә әллә кая китеп югалды. Ә бераздан мин аларның хатыны белән ике зур хуҗалык сумкасы күтәреп баскычтан менеп килгәннәрен күрдем. Өстәл артына утыргач, ул тирә-ягына каранып кына, сумкалардан зур кәстрүл һәм эчемлек шешәләре алып аяк астына идәнгә тезде. Аннары Инсафка дәшеп:

—Әйдә, парин, эшләп аша әле!—дип өстәл өстендәге тәлинкәләрне бер тирәгәрәк җыярга кушты. Раил аларга кашык белән кәстрүлдән салат бүләргә кереште.

Кунакларының гаҗәпләнүен күргәч, аңлатырга кирәк тапты, бугай:

—Швейцар белән тарткалашып алдым әле. Үзең белән берни дә алып керергә ярамый, ди, парин. Ни кабымлыгын, ни аракысын. Аларның бөтенесе дә бар, янәсе. Бар, кәнишне—биш бәясенә. Помидор-кыярның килосы базарда егерме сум торганда, монда бер-ике кашык әйберләре өчен утыз сум каерып яталар. Чуртан койрыгыннан акмый бит ул акча.

Зур, озын өстәлнең буш тәлинкәләре янында ике-өч кенә шешә

эчемлек күргәч, мин башта ук гажәпләнгән идем. Аның җае бар икән...

—Йә, дуслар, беренче сүзне кемгә бирик?—дип кунакларга мөрәҗәгать итте Раил. Тик кунаклар, башларын аска иеп, бер-берсенә карарга уңайсызланып утыралар иде.—Ашыйсыгыз киләдер инде, озак көттердек шул. Болай итик, иптәшләр...—дип, Раил янадан сүзен башлауга, яныбызда гына утырган оркестр дөбер-дөбер музыка уйнап җибәрде. Раилнең бер генә сүзе дә ишетелмәс булды. Ул аптырагач, рюмкасын өстәлгә куеп, музыка беткәнне көтә башлады. Тик кая ул!

Безнең өстәлләр тирәсендә битен-күзен җитмеш җиде төскә буяган кызлар, майлы чәчләре җилкәләренә салынып төшкән аксыл йөзле малайлар боргалана. Моның очы-кырые күренмәгәч, Раил торып басты, кулы белән ияк астына чиертеп, сүзсез-нисез генә тост күтәрергә ишарә ясады.

Шундый бер-ике «тост»тан соң безнең өстәл артындагы кунаклар берәм-берәм торып, биючеләргә кушылдылар. Гел тик утырмассың ич инде. Мин дә Разиямны ияртеп биергә чыктым. Бераздан өстәлебез күземә чалынган иде, аптыравымнан туктап ук калдым. теге зур кәстрүл өстәл өстенә менеп утырган һәм аның бер як токкасыннан Раил, икенче ягыннан официант йолкып тарткалашалар иде.

Раилнең бер яңагы тавык йомыркасы кадәр бүлтәеп чыккан—ул буш кулы белән авызына ашык-пошык салат тутыра, ә хатыны битен куллары белән каплап, урындыкка сыгылып төшкән иде.

## Кызлар озатырга өйрәтимме?

Бик күптәнге хәл инде бу, шулай да сөйлим әле, егетләр. Минем тәҗрибәм, бәлки, сезгә дә ярап куяр.

Ул чакта сугыш беткәнгә әле өч-дүрт кенә ел иде. Безнең җиденче класста гына укып йөргән чаклар. Ач булсак та яшебезгә күрә гыйшкыбыз җитәрлек. Классыбыздагы кызларның берсенә минем күнелдә җылы бер нәрсә шытып килә. Күрмичә түзә алмыйм үзен. Хәтта дәрес вакытында да башкаларга сиздермәскә тырышып, гел аңа карап утырам.

Әй, үзен генә аулак җирдә очратып, рәхәтләнеп карап утырасы иде дә туйганчы сөйләшәсе иде. Нәрсә турында дисезме? Каян белим инде мин аны?!

Кызның исемен әйтмәдем бит әле. Әминә ул. Куе кара кашлы, кара чәчле. Йөзе ап-ак. Ә күзләре! Җәйге аяз көннең җиде катлы күгемени, валлаһи. Минә шул күзләре белән миңа караса, йөрәгем әллә нишли шунда, кылт итә дә, минем тәннән электр тогы йөгереп уза, буыннар йомшарып китә.

Дустым Рафикъ минем хәлне белә, җае чыкканда ярдәм итәргә тырыша. Без аның белән Әминәне ялгызын гына кайда очратып була икән, дип, бик озак баш ваттык.

Ниһаять, караңгы төшкәч очратырга кирәк дигән уйга килеп, авылыбыз клубында кино булганны көтеп йөрибез.

Син теләгәндә авылга киносы да озак кайтмый тора бит әле аның. Безгә шактый озак хыялланырга туры килде. Һәм менә, ул көн килеп җитте! Рафикъның киңәшен тотып, мин үзем кинога кереп тормадым. Әминәнең алданрак чыгып китеп күренми калуы бар ич. Рафикъка рәхмәт, кино беткәч, ул иң алдан чыгып, Әминәне күздән югалтмаска тиеш иде.

Менә берзаман клуб ишеге ачылып китте. Кешеләр тарала башлады. Бер мәлне мин качып утырган куаклар янына Рафикъ йөгереп килмәсенме!

—Әйдә тизрәк, чыктылар!—диде ул, миннән дә аруырак сөенеп. Тагын тыным кысылгандай булды. Алай да сер бирмәскә тырышып, Рафикъ артыннан элдерттем.

Әминәгә Тәскирә ияргән. Биш-алты адым артта калып аларны озата кайтабыз. Тик ничек яннарына барырга, ничек сүз кушарга? Рафикъ кыюрак, һушлырак та, мине өйрәтеп тора:

—Таң алдыннан салкынайтты, туңмыйсызмы, дип сора. Әминә чәч толымнарын сырма якасы өстеннән йөртә. Чәчең озын синең, диген. Үзең генә калгач, толымын тот. Тасмасы иске инде искесен. Ә син шулай да чәч тасман матур икән, дигән бул. Шуннан сүзгә сүз ялганып китәр.

Әйтергә онытып торам икән. Безнең авыл уртасында сай гына инеш бар. Аның аша тар күпер салынган. Менә шул күпер янына житкәч, кызлар туктап калды. Курыктылар бугай. Мин үзем алай курыкмыйм куркуын. Тик ялгыз гына булганда шул күпер астыннан гел бүре килеп чыгар төсле тоела. Анысы бар, яшермим.

Кызлар таптанып басып тора. Без бөтен батырлыкны жыеп якын килдек. Тегеләр, таныгач, көлешеп алдылар. Ничек сүз башларга белмим. Рафикъ миңа төртә дә төртә. Ниһаять, үзе сүз кушты тагын:

—Кызлар, туңмыйсызмы? Һава суына төшкән!

—Безнең өстә сырма гына шул. Кайберәүләрнеке кебек пәлтә түгел.— Тәскирәнең мине чеметтерүе инде бу.

—Алай да зәп-зәңгәр булган әле!

Менә сиңа мә, Әминә дә кимен куймады. Минем өстәге «пәлтә» дигәннәре әтинең егерме еллап аунап ятып, сыекланып беткән иске чикмәненнән генә әмәлләгән бер нәрсә иде. Искегә тимә, исең китәр, диләр бит әле. Бу «пәлтә» дә шундыйлардан инде. Кызларның сүзенә хәтерем калды. Көләләр бит болар миннән. Болай булгач, озатмыйм. Үзләре генә кайтсыннар. Күперне чыккач, мин әкрен генә артта калдым. Моны сизгәч, Рафикъ кызулый башлады:

—Әйдә инде тизрәк, озатсак озатыйк, өйләренә кайтып житәрләр бит,—ди.

—Озатмыйм,—минәйтәм,—кешедән көләләр. Әнә Әминә мине зәп-зәңгәр булгансың, диде.

Рафикъ:

—Һи, жүләр, Тәскирәгә кушылып кына әйтте ич ул аны. Бу дөм караңгыда синең зәңгәрләнгәненне каян күрсен инде ул,—дип, каршы төште.

Тагын киттек. Рафикъ Әминәләрдән бер-ике йорт аша гына торган Тәскирәгә иярде. Мине инде үзегез беләсез.

Менә, Әминәләр өе янына килеп життек. Әле дә гажәпләнәм, ул капка келәсенә үрелгәч, каян килгәндер миңа бу кыюлык, кинәт кенә:

—Кирәсеңдәмени, Әминә? Синең чәчүргеч тасмаларың ай-һай матур! Ал икән!—дип әйтеп өлгердем.

Әминә борылып:

—Бу караңгыда ничек күрәсең соң син аны?—дип кайтарып сорады.

Мин тагын телсез калдым. Каян сүз табарга инде?! Ник аны баштарак уйлап куймадым соң! Шулай шактый гына дәшми торгач, Әминә:

—Ярар, шәһәрнекеләр әйтмешли, сиңа тыныч йокы. Хуш!—дип өйләренә кереп китте.

—Сиңа да, Әминә...

Мин уйга калдым. Һе, «каян күрәсең... караңгыда», имеш. Ә үзе баягынак зәп-зәңгәр булгансың, дигән иде. Ул да караңгыда төсне аермый бит. Алай... Әллә ул да миңа ничек сүз кушарга белми йөрде микән? Карале, әллә ул да мине...

Шатлыгымнан нишләргә белмичә, Рафикъ янына йөгердем. Ул нәрсә әйтер икән?

—Рафикъ, Рафикъ, син кайда?

Артык кычкырмадым бугай инде. Тик шушы саксызлык эшне харап итте. Якында гына, күк күкрәгәндәй, карлыккан эт тавышы яңгырады:

—Вах-вах!

Мин ни уйларга да өлгерә алмый калдым, янымнан жан фәрманга йөгереп, сулуы капкан Рафикъ узып китте.

Тәскирәләрнең Муйнак исемле бик усал этләре бар икәнен әйттемме әле, юкмы! Бозау хәтле дисәм, көләрсез микән. Ул этнең күрше урамдагы Баһау абыйлар баз өстеннән ярты сарык түшкәсе ашап чыкканлыгын әйтсәм,

безнең халне үзегез аңларсыз, бәлкем. Шул гыйфрит сизмәсен дип, бу урамнан шым да чыгармыйча узарга теләсәм дә аяклар үзләреннән-үзләре йөгерергә ниятләп тора, котын ботка төшә.

Эшнең мөшкеллегенә тиз төшендем, баскан урынымнан, яшь тай кебек, алга ыргылдым. Ул арада Рафикъ кемнеңдер читәнен шатырдатып бәрәңге бакчасына очты. Үзем ике куллап казыкларга барып ябыштым. Сикерим дигәндә генә Муйнак минем пәлтәмнең чабуын «Вах» итте.

Шулай итеп, мәхәббәт мәсьәләсе һич уйланмаган борылыш алды. Эт тә бу кадәрен көтмәгән иде, күрәсең. Авызына кереп тулган пәлтә кисәгенә тыгылып, чиный ук башлады, аннары, шыншый-шыңшый кирегә элдертте.

Йөрәкнең гөрс-гөрс тибүе басыла төшкәч, мин аякларымның туңа башлаганын сиздем. Капшап карасам, йон оекбашлардан гына калган килеш, эреп бетмәгән кар өеме өстендә басып торганымны шәйләдем. Менә сиңа мә! Мин, үзебезнең заман өчен мактаулы кызыл эчле галошлар кигән идем ич, алар кайда соң? Лыжырдаган бакча аларны аяктан суырып алып калды микәнни?

Ул арада тыны кысылган Рафикъ әйләнеп килде.

—Әйдә инде.. нәрсә терәлеп каттың?! Тагын килмәсен!—ди.

Ә минем үз кайгым кайгы:

—Галошларны югалттым бит әле, малай. Оекчан гына калдым. Инде нишләргә? Кайда гына төшеп калган соң ул нәгъләтләр!

Рафикъ дустым да аптырады:

—Аяк атлаганда пычрак «былт-былт» итеп тора шул. Каян эзлибез инде,—ди.

Аның үзенең эше начар түгел—аягында резин итекләр. Минем генә менә...

—Читән аркылы сикергәндә бар иде әле алар,—дим.

—Эзеңнән кире барып эзләп карыйк әле,—дип Рафикъ пычрак бакча буйлап китте. Туңы куера башлаган ләпектән итекләрен ул да көчкә-көчкә тартып ала иде.

Әллә курку һаман бетеп житмәгәнгә, әллә тунганга, минем тешләр шык-шык килә башлады.

—Рафикъ, син аны читән кырыеннан ук карап кил әле.

—Берни күренми, караңгы бит.

Рафикъ бик озак эзләп таба алмагач, үзем дә яңадан пычрак эченә кереп киттем. Бакчаның салкын туфрагына кул тыгып икәүләп күпме эзләгәнбездер, әйтә алмыйм. Ниһаять, таптык. Бакча боламыгы аларны мин читән өстеннән сикереп төшкән хуттан ук суырып алып калган икән. Бу бакча Мәрфуга әбинеке иде. Сукыр лампа уты дерелдәп торган тәрәзә яныннан узганда Рафикъны күргәч, мин эчемне уа-уа көлә башладым. Дустым кара савытыннан үрмәләп чыккан тараканга охшаган иде.

—Моннан соң Әминәнне үзең генә озат, яме! Көлеп тора тагын!—дип ачуланмакчы булган иде ул, минем дә баштанаяк пычракка батуымны, чабусыз калган пәлтәмне күргәч, көлүдән хәле китеп, үзе дә жил капка колгасы өстенә ауды.

Ә иртә белән Мәрфуга әбинең күрше-күләнгә зарланып торганын ишеткәннәр: кемнәрдер ярты бакчамны саз иткән. Нәрсә генә эзләделәр икән? Хәерлегә булсын инде...

... Менә шулай. Тормышның рәте киткәндә, йә минем кәеф булмаган чакларда Әминә жиңгәгез чоландагы сандыктан теге кызыл эчле галошларны алып кереп урындыкка куя да, йомышка ярардай оныкларымның берәрсен Рафикъ белән Тәскирәне кич утырырга чакырырга жибәрә. Дөнья тагын түгәрәкләнеп китә.

# Сөләйман

## ҮРТӘМЕШЛӘР

*Уралымнан урап кайтамын да*
*Улакларга ятып су эчәм...*

Гамил Афзал

**Улаклардан**
**ятып су эчкәндер абзый,**
**Әллә чынлап, улакларга ятып микән?**
**Барыбер бит дияр идем аны,**
**Әнә берсе—**
**тәки ятып эчкән—**
**улакларны ватып киткән.**

*Чибәр сатучының товары тизрәк үтә.*

Шәүкәт Галиев

**Чибәр сатучының товары тизрәк үтә—**
**...Ә кибет товары**
**киштәдә тора бирә.**

*Мин дә үстем Казансуга карап,*
*Бөдрәләрем чайкап суында...*

Фәйрүзә Мөслимова.

**Казансуга карап алсам—**
**Үсә гайрәт—өчләтә.**
**Бөдрәләр чайкап аккан су**
**Менә бит ул нишләтә!**

*Безне дә атлы булыр дип*
*Ышанган бабам,*
*Түзгән.*
*...Кемнәрдер ил туендырмак...*
*Ботка пешерел сүздән.*

Газинур Морат

**Извини, брат,**
**Дустым Морат!**
**Бабаң ышанычын аклап**
**Булырсыңмы**
**Гомерлек ат?**
**Бабаң хаклы,**
**Булыйк атлы,**

**Тик компьютер абзарыннан**
**Сайлыйк аргамакны.**

**Җир сөрү—эш, нефть алу—эш,**
**Эш тә эш дия-дия,**
**Күрше корсагы тук әнә,**
**Безгә—информация!**

## Морад Дусай

# АЛАЙ ТҮГЕЛ, БОЛАЙ УЛ...

### Сере бә-әк гади...

—Ню! Алып китәм! Ике елдан артык ята ич инде хикәям, ә чыкмады!— дип, Әхәт Гаффар «Шәһри Казан» гәзитенең әдәбият-сәнгать бүлеге мөдире Нәсим Акмалга дулый икән.

—Соң, Әхәт абый, ике ел элек минем урында үзең эшләдең ләбаса. Нигә хикәянне шул чагында чыгармадың?—дигән ана тегесе.

—Ню!—дигән Әхәт Гаффар.—Аның сере бә-әк гади: Әхәт Гаффар Әхәт Гаффарны сыйлый алмый ич инде!

### Телевизор бәласе

Ркаил Зәйдулла дусты Ләбиб Леронга яңа китабын бүләк итә.

Бер ай үтә.

—Укыдыңмы?—ди Ркаил.

—Юк әле...—ди Ләбиб.

Ике ай үтә.

—Жә, укып чыктыңмы инде?—ди Ркаил.

—Юк әле...—ди Ләбиб.

Көннәрдән бер көнне, инде өч ай булды дигәндә, Ркаилнең эш бүлмәсенә сулуы капкан Ләбиб йөгереп керә. Йөгереп тә керә, сүз дә башлый бу:

—Ну, бу хатынны! Ну, бу хатынны!

«Укыдыңмы соң?» дип әйтергә авыз ачкан Ркаил аптырап кала:

—Ни булды?—ди ул ниһаять.

—Хатын телевизор алып кайткан! Укытучылар конкурсында беренче урынны алган...

—Соң... Әйбәт булган диген, тиле!—ди ана Ркаил.—Менә минеке алып кайтсын иде әле!

—Болай да бүлмә саен телевизор,—ди Ләбиб, уфтанып.—Ижат кичәсен үткәреп йөргәндә Мөслимнән—бер, Актаныштан —бер, Кукмарадан ике телевизор бүләк иттеләр. Инде синең китапны укырга дип кенә...

—Укыдың што-ли, ниһаять?!—ди Ркаил, түземсезләнеп.

—Әле кичә генә синең китапны укырга дип туалетка кереп утырган идем—анда да телевизор тора минсиңайтим!—дип, Ләбиб жинел сулап куя...

### Авыз эченнән әйтелгән сүз

Язучыларның бер жыелышында Газинур Морат, уң ягында утыручы Марсель Галиевкә, сул ягында утыручы Мансур Вәлиевкә карап ала да, авыз эченнән генә үзалдына әйтеп куя:

—Безнең халык Фатыйх Кәрими белән Фатих Кәримне бутый. Жиде Галиев белән сигез Вәлиевне каян килеп кенә аера алсын соң инде ул, йә?!

## Акыллы нәтиҗә

Язучылар берлеге ишегалдындагы «Сарман» кафесы төбендә бер төркем әдип тәмәке көйрәтә. Гәп әлеге дә баягы хәмер тирәсендә куера.

—Зоопаркларда, мәсәлән, филгә аракы эчерәләр, ә маймылга—сыра!—ди Газинур Морат.

—Нигә?

—Иң акыллы хайваннар коллыкны бик авыр кичерәләр икән,—ди Газинур.

—Коллыкта яшәгән халыкның да иң акыллы затлары хәмер эчәргә мәҗбүр,—дип акыллы нәтиҗә ясап куя Ләис Зөлкарнәй.

—Димәк, үлгәнче коллыкта яшәячәкләр!—ди болар яныннан ашыгып кына үтеп баручы Рәфикъ Юныс.

## Әйбәт кеше

—Рөстәм абый, Камил Кәримовның «Ком сәгате» романын укыдыгызмы?—дип сораганнар яшь язучылар Рөстәм Мингалимнән.

—Юк!—дип җавап биргән өлкән әдип.—Әмма ул кешене мин беләм. Бик әйбәт кеше ул. Шәп кеше! Гаҗәеп кеше. Яратам мин аны хәтта. Тик аның белән мөнәсәбәтләремне бер дә бозасым килми. Шуңа күрә дә ул язганнарны беркайчан да укымаячакмын.

## Борчылу

Равил Фәйзуллин туган ягына әтисе янына кунакка кайткан. Кайтып керүгә үк, беренче сүзе итеп ул 85 яшьлек әтисе Габдрахман агадан сорый икән:

—Әти, «Казан утлары»на язылдыңмы?

—Юк, улым, өлгермәдем әле,—дигән аңа әтисе.

—Их, әти, әти, син язылмасаң, бүтәннәр язылмаса, инде болай да битараф татар халкы кая барып чыгар?!—дигән Равил Фәйзуллин һәм шуннан соң гына әтисе белән: «Нихәл, әти?!»—дип кул биреп күрешкән.

## Лимит

Шагыйрь Зиннур Мансуров—аз сөйләп, күп эш башкаручы шәхес.

Бервакыт аңа язучылар җыенында рәислек итәргә туры килә. Теләсә дә, теләмәсә дә, рәис байтак кына тел тибрәтергә мәҗбүр була.

Бу җыеннан соң Зиннур әфәнде өендә бер атна чамасы сөйләшмичә йөри.

—Ни булды сиңа, әтисе?—дип сорый икән аннан хәләл җефете Роза ханым.

—Бер көндә бер айлык сүз сарыф итеп карале башта! —дигән аңа шагыйрь.

## «Мә, гариф министрлыгы»

Инде моннан ун еллар чамасы элек, Гариф Ахунов Ленин урамы буйлап Кремльгә таба бара икән. Артыннан моны Җәвад Тәрҗеманов куып җиткән. Куып җиткән дә бу, язучыга бәйләнә дә башлаган:

—Гарифҗан, әйт әле син миңа, ничек иттереп бу кадәр югары дәрәҗәләргә ирештең—язучылар башлыгы да, депутат та булдың, китапларың да ел саен кырык телдә чыга тора... Сере нидә?

—Тургай бит мин, туганкаем, тургай...

—Ничек инде—тургай?

—Иртә торам мин, туганкай!

—Ә шулай да...

—Шулае—шул! Үзең миңа, туганкаем, бүген йокыңнан ничәдә тордың?

–Сигезләр тирәсендә...
–Менә сиңа вәйт! Ә мин иртәнге дүрттә тордым.
–Хәзер инде кая юл тотышың?
–«Мә, Гариф министрлыгы» дип язганда өтерен төшереп калдырганнар. Менә шуны төзәтергә килүем иде әле,–дип, Гариф Ахунов бәйләнчек юлдашыннан котылу өчен, кырт борылып, Мәгариф министрлыгына кереп киткән имеш.

## Бабил буталышы

Мөдәррис Әгъләм белән Равил Фәйзуллин Аккош күленә юл тотканнар. Кара «Волга»да «Вавилон» супермаркетын узып киткәндә Мөдәррис әйтә куя:
–Карале, Равил, «Вавилон»–«Равилон»!–Бер генә хәрефен үзгәртәсе бит, әй! Дәрт итсәң, үзгәртәсең дә әле син аны!
–Бер дә бүтән кайгым юк иде...–ди Равил Фәйзуллин, көрсенеп,–эшкә барсаң–журналның 80 еллыгы, дип, ремонт дип мәш киләләр, өйгә кайтсаң–бәләкәй Газиз жылый, ә башта–Бабил буталышы...

## Җаен тапкан

Язучы Марсель Галиев Татарстан Дәүләт Советы рәисе урынбасары Роберт Миңнуллиннан:
–Сезнең эштә гел урысча гына сөйләшәләр бит, ничек аралашасың син алар белән? Читен түгелме?–дип сорый икән.
–Сөйләгәннәрен тыңлап-тыңлап торам да, «Да-а...»–дип куям, тагын ун минут тыңлагач: «Неужели?»–дим, бераздан: «А как же...», аннары «Конечно!», ә иң соңыннан: «Не может быть!»–дигәч, тегеләр яңа баштан сөйли башлый,–дигән Роберт Миңнуллин.

## Тәңкәле витамин

Аккош күлендә су коенганда Ркаил Зәйдулла Равил Фәйзуллинның читкара күзеннән яшереп сала торган авына юлыккан. Сөкә төбендә сикерешкән бармак башы кадәрле алтынсу кәрәкәләрне тиз-тиз генә чүпләштергәләгән дә бу, алай-болай Равил абый үзе очрый күрмәсен тагын дип, кача-поса гына, дөбер-шатыр килеп, алачыгына ашыккан.
Аннары исә, кар беткәннән бирле гөмбә, каен бөресе, бака үләне, усак кайрысы, мүк, какы-кузгалак, әрекмән тамыры һәм кычыткан белән генә тукланып яшәүче күршесе Әкә кушаматлы Мөдәррис Әгъләмне балык кыздырырга дәшкән дә, кытыршы нарат сайгагыннан корыштырган саллы сәкесенә кырын ятып, «Казан утлары»ның яңа санын укырга керешкән,
Өч минуттан Әкә әйләнеп тә кергән.
–Тор! Пеште!
–Шул арадамы?–дип гаҗәпләнгән Ркаил.
–Кәрәкәне ике минут ярымнан артык утта тотсаң, тәме китә, көя башлый ул,–дигән аңа тегесе.
–Бәр-рәч, соң, син моның тәңкәсен дә чистартмагансың лабаса!?
–Белмәсәң–бел! Кәрәкә дип аталган балыкның тәңкәсен генә ашыйлар аның. Бөтен витамины–тәңкәсендә!–дигән белдекле Әкә.
Ә табада кәрәкәләрнең тәңкәләре генә калган икән...

# CƏLİLÇE RƏXİM SATTAR

ŞAĞİRNEŅ TUUINA 90 YIL

*Rəxim Sattar (tulı iseme—Ğabdelrəxim Sələyman ulı Ğabdelsattarov) bik keçkenədən uqıŋğa-yazarğa əyrənə, inde dürtençe sıynıfta uqığanda uq üze də qələm tibrətə—berençe tezmələren yaza başlıy. Ul bik tiz məstəqil tormış yulına ayaq basa: cideyılıq məktəptə uqıp çıqqaç uq tərle eşlər başqara, kəndəlek matbuğatta berençe ədəbi parçaları dənya kürə. Ozaqlamıy ul Qazanda çığa torğan «Qızıl yəşlər» gazetasında—ədəbi xezmətkər, annarı cawaplı məxərrir urınbasarı bula. Tərle gazet-jurnallarda şiğerlərə, oçerk-məqələlərə, ədəbi tərcemələre basıla kilə.*



*Əmma sələtle şağirgə tulısınça açılıp kitərgə məmkinlek bulmıy—Watan suğışı başlanuğa uq ul üze teləp, irekle bulıp frontqa kitə. Desantçı Rəxim Sattar doşman tılında baytaq suğışçan operatsiələrdə qatnaşa həm 1942 yılınıŋ may ayında, çolğanışta qalıp, əsir təşə. Berniçə ay tərle lager'larda ğazap çikkənnən soŋ anı, başqa tatar həm başqort əsirlərə belən berlektə, Berlin tirəsendəge Vustrau lager'ına iltep tığalar—anda «İdel-Ural» legionı təzelep kilə ikən. Şunda Rəxim Sattar Qazannan uq üzenə yaxşı tanış Musa Cəlil həm Abdulla Aliş belən oçraşa, alar oyıştırğan yəşeren oyışmanıŋ ışanıçlı keşese bulıp tanıla. Ul «İdel-Ural» legionına aldap-kəçləp kertelgən əsirlər arasında listovkalar yazıp taratuda aktiv qatnaşa. Cəlilçelərne qulğa ala başlağaç, Rəxim Sattar 1943 yılınıŋ cəyındə qaçıp kitə həm bilgesez yuğala. Anıŋ şunnan soŋğı yazmışı bilgesez, açıqlanmağan kileş qala.*

*Rəxim Sattarnıŋ suğışqa qədərle ber kitabı da çığa almıy qalğan. Barı tik 1966 yılda ğına anıŋ ulı, filosofiə fənnəre kandidatı İl Sattar, ətiseneŋ şiğerləren cıyıp, «Cır dəwam itə» isemle kitabın bastırıp çığara. Annarı rus telendə «Tri poeta-voina» digən kitap (1979) dənya kürə. Anısında Abdulla Aliş, Xəyretdin Məcəy həm Rəxim Sattar şiğerlərə tuplanğan bula.*

*Jurnalıbıznıŋ bu sanında bez uquçılarıbızğa şağir Rəxim Sattarnıŋ ulı İl Sattar nəseren həm cəlilçe şağirneŋ berniçə şiğeren təqdim itəbez.*

# İl Sattar

## WASİƏT

NƏSER

Bəyek Watan suğış qırlarında ilebeznen distə millionnarça keşese başın saldı. Alar üz ğəmerlərе belən beznen kiləçəqne saqlap qaldılar. Minem ətiem Rəxim Sattar da şul həlak bulğannar arasında.

1943 yıl. Tatar şağire Rəxim Sattar alman xalqı başqalasında—Berlinda üzenen şiğerlərеn küçerep utıra. Berlinnın qaysı poçmağında bulğandır bu xəl, əytə almıym, ləkin beləm—bu waqıyğa bulğan. Çənki minem østələmdə əti qulı belən yazılğan qulyazma kitapçıq yata.




Bu kitapçıqnın qıymməten bəyəli torğan baylıq yuq minem øçen. Anın bəyəse—keşe ğəmere. Tatar şağire Rəxim Sattar, yegerme dürt şiğeren küçerep beterə də, menə mondıy sonğı yulların yazıp qaldıra:

Küçerep beterə almadım.
Min xıyənətsez.
Sin də şulay bul.
Ber yul. Başqa yul yuq.
Əni, İl, Alsu, tuğannar...

Bu yullar minem künelemə uyılıp quyılğan. Tik bu ber mizğeldə genə yazılğan yazmanın məğnəsen anlap-açıqlap beterer øçen minem zihenem citməster şikelle. Bolar—yazmış süzlərе. Rəxim Sattarnın ulına həm başqa tuğannarına əytkən sonğı süzlərе—wasiət süzlərе. Bu süzlərnen tirənten məğnəsenə təşener øçen beznen ətilərebez kiçergənnərne üz başıbızdan kiçerü kirəkter.

Min xıyənətsez.
Sin də şulay bul...

Əlbəttə, bu süzlərnen məğnəsen bez barıbız da beləbez. Alarda bernindi də yanalıq yuq kebek. Əmma bu süzlər ətiemnen xuşlaşu mizgelen sıydırıp qalğan. Əti keşe keçkenə ulı belən xuşlaşa. Ətisenen bu süzlərеn ul berniçə distə yıl ütkəç kenə uqıyaçaq. Əti keşe bu süzlərеnen ilenə həm ulına barıp citəçəkme, əllə yuqmı ikənen belməgən.

Qulyazmalar yanmıy, dilər. Musa Cəlilnen qulyazmaları yanmadı. Əti qulı qələm yərtkən qulyazma da, əllə niçə men çaqrım yulnı uzıp, əllə niçə distəgə suzılğan yıllarnı kiçep, tatar ilenə qaytıp citte.

Bəyek Watan suğışı keşelərnen nindi bulırğa tieşlegen açıqlağan. Awır, kisken kəraş üze sınıy, üze tikşerə. Keşenen ruxi sıyfatlarının qıymməten bilgeli. Şuna kürə əti keşe ulına in məhimen əytep qaldırırğa tırışqan:

Min xıyənətsez.
Sin də şulay bul...

Başqa bernindi süz də kirəkmi. Xıyənət itmi torğan keşe bulsan, keşelər arasında tormış qora alırsın. Keşelər arasında... Monısı bik tə məhim. Xıyənətsez keşenen keşelegе tulayım cəmğiət yəşəyeşe belən bilgelənə. Üz künelendə-qalbendə keşelek yazmışın kütərep bara ala torğan keşe genə xıyənətsez bula ala. Xalıq yazmışı qayğısı künelenə sengən çaqta ğına. Anı külmək almaştırğan kebek almaştırıp ta kiə almıysın. Monı künelen tabiğıy rəweştə xalıq yazmışı belən totaşqan çaqta ğına toyıp bula.

«Min xıyənətsez»,—dip, Rəxim Sattar ulına ğına mərəcəğət itmi. Ul xalqı aldında ğına ulına şulay əytə ala. Çənki bəten keşelek dənyasına xas

bulğan məğnəwi eçtəlekne xalıq qına kütərep bara, ber üzen yalğız utrauda yəşəp «min xıyənətsez» dip əytü məmkin tügel.

«Sin də şulay bul»,—dip əytkəndə də Rəxim Sattar ulının künelenə ictimağıy eçtəlek salırğa tırışa. İn qurqınıçı—bu süzlərnen tirənten məğnəwi eçtəlegen xalıq üze sizmi başlasa, xalıqnın ruxi mirası sayığayıp barğan çaq bula-nitə qalsa. Bu sıyfatnı xalıq yuğaltsa—bu inde xalıq, millət üze betə digən süz bulır ide.

Məngelek aldında «min xıyənətsez» dip əyt əle. Anın da bit üzenen çaması bardır. Sin iptəşen aldında tuğrı bulıp qala alasın, balan aldında, ğəylən, xatının, əti-ənilərən aldında da tuğrı bulıp qalırğa məmkin. Ləkin İlen-Watanın aldında xıyənətsez bulıp qala alğan çaqta ğına sin çın-çınlap, tulı məğnədə «xıyənət itmədem» dip əytə alasın. Rəxim Sattarnın wasiəte nəq ənə şul məğnədə yazılğan da. Əye, nəq şul məğnədə.

Min bu süzlərdə ətiemnen, açınulı bulsa da, ğorurlıq xislərən də toyam. Başın yuğarı totıp tormış yulınnan atlıy ala torğan keşe genə bu süzlərne wasiət itep əytep qaldıra ala, minemçə. İlebez eçen iskitkeç faciğəle, iskitkeç awır afət belən suğarılğan çorda əytelgən wasiət ul. Bu wasiətnen sallı buluı şiqsez.

İn yaqın keşenə, ulına sonğı süzenne əytkəndə küp səyləp tornp bulmıydır şul. İn mohimen əytep qalırğa kirək.

Min barısın da anlıym kebek. Keşe canı tirən məğnəle süzgə moxtac bulıp yəşi. Süz—keşe künelenen icatı. Keşe künele süzsez yəşi almıy. Süz—anın rızığı. Süz ul künelne yuata da, açındıra da, künelne təşerə də, kütərə də. Süz keşe künelen keşe künele itə.

Ətinen wasiət süzləre anın künelennən ağıp təşkən. Zaman, çor anın künelenə ələge wasiət süzlərən üze yazğandır şikelle. Ə min, anın ulı, olığayıp betkəç tə, şul ğədi genə süzlərnen tirənten məğnəsen haman da açıqlap beterə almıym kebek əle. Xəzer xalıq bolgenlekkə təşep bara, ilnen xəle yamannan da yamanraq... Sonğı un yılda Rəsəy xalqı un millionğa kimegən. Təxettə kemnər utıruına qaramastan, gorləp torğan il yuqqa çığıp bara. Bu wəzğiət xakimiət başındağı türələrnen il xalqına xıyənət itüennən barlıqqa kilmədeme son?

1943 yılnın cəyendə tatar şağire Rəxim Sattar Berlinnan Pol'şağa—Edlino digən urınğa kilə. Biredə nemeslar oyıştırğan tatar legionının berniçə batal'onı urnaşqan bula. Rəxim Sattar belən biş keşe ozaqlamıy Edlinodan qaça...

Boyek Cinü kone kilde. Kemnər bu Cinü konen—iskitkeç Boyek şatlıqnı buldırğan? Kemnər alar—millionlağan isemsez batırlar?

Ətiemnen şəcərəsen barlıym. Ətinen ətise Sələyman babam Ofe gubernası Çişmə oyəzenen Tübən Xacət digən awılında mulla bulğan. Sovet xakimiəte yıllarında az qıyınlıqlar aşamağandır ul...

Minem üz ğomerem bəxetsez də buldı, bəxetle də. Bəxetsez buldı, çonki ətiem suğıştan əylənep qayta almadı, yazmışı bilgesez bulıp qala kilde... Anın küləgəse mina da qağılmıy qalmadı... İnde menə bəxetle buldım: çonki ostələmdə ətiem qulı belən yazılğan kitapçıq yata. Bu kitapçıq—ətiemnen berdənber istələge. Anı Berlinnan 1945 yılda uq Rawilə Ageeva isemle xatın alıp qaytqan həm Donetsk olkəsendə kompartiə oyışmasına tapşırğan bula.

Mina bu qulyazma kitapçıq turında barı tik 1964 yılnın cəyendə genə (!) yazuçı Ğabdraxman ağa Minskiy əytte. Ul şul çorda Tatarstan Yazuçılar berlegenen partiə oyışması sərkətibe ide. «Partiə olkə komitetına bar, seznen seyfığızda əti qulı belən yazılğan şiğerlər yata, mina kürsətegez anı, dip sora»,—dide. Bardım, soradım. Ləkin qulyazmanı mina kürsətmədelər də. «Əye,—didelər,—menə şuşı seyfta yata sinen ətiennen Germaniə əsirlegendə yazğan şiğerləre. Əmma xəzergə bez anı sezgə kürsətə almıybız əle...»—didelər...

Şul yılnın caendə, nihayət, ətinen ul şiğerlərə «Sotsialistik Tatarstan» gazetasında berençe tapqır basılıp çıqtı!

Niçəmə yıl inde min ətiemnen şul şiğerləren küçerep utırğanın küz aldıma kiterergə tırışam.

Küçergən qədəresen ber dustına tapşırıp, əti totqarlanmıyça yulğa çığa. Nemeslar oyıştırğan tatar legionının yəşeren oyışması qararı buyınça alar—biş keşe—Edlinodan Sovetlar yağına qaçıp kitərgə tiyeş bula. Alarnı Edlinoda kətələr. Şiğerlərne küçerer əçen səbəp şul bulğandır. Yulda ni bulıp betəsen kem belə? Anın şiğerləren legiondağı tatarlar belgən. Tik kem yazğanın ğına belməgənnər. Həm ətiem berençe tapqır şiğerlərə astına üzenen isemen yazıp quya. Yuq, üz isemen məngeləşterü əçen tügelder, dip uylıym. Anısı başqa nərsə. Xalıq üz ullarının kərəşen belergə tieş. Alarnın kərəşe də xalıq tarixına yazılır. Qayçandır cinü kəne kiler. Cinü niçek yawlap alınğanın tatar xalqı da, Sovetlar ile də belergə tieş. Tormışta xəter digənen də bar. Cinü yulında bu şiğerlər də üz eşləren başqarğannar. Alar bu faşist totqınlığında yaqtaşlarnın, kərəştəşlərnen kü̇nelləren il yulında saqlap qalğan. Rəxim Sattar da xalqı aldındağı burıçın ütəgən. Tatar xalqının milli xəterenə alar da kerer, saqlanır dip ışanğan.

...Waqıt tar. Küçerep beterə alğannarı qalır. Berlinnan tizrək kitep ıçqınırğa kirək. Yəşeren oyışma keşelərə xəbər kitergən. Şəfi Almaz Rəxim Sattar əstennən gestapoğa ələk yazğan. «İdel-Ural» isemle gazetnın baş məxərrire ul, bulaçaq İdel-Ural ştatı xəkümətenen prezidentı, yənəse! Rəxim Sattar da şul gazetta eşləgən bula.

Şəfi Almaz Rəxim Sattar əstennən yazğan ələgendə: «1. Rəxim Sattar gazet xezmətkərləren «nemeslarğa qarşı suğışqan tatarlarnı nemeslarğa əsirlekkə təşsennər» dip əndəp listovka yazu eşennən baş tartırğa çaqırğan həm alar çınnan da bu listovkalarnı yazmağannar; 2. «Lenin Tatarlarğa dəwlətçelekne qaytarıp birgən» digən məqələ yazğan həm gazetqa təqdim itkən; 3. Tuqaynın «Kitmibez!» isemle şiğeren Şəfi Almaz bulmağanda gazetqa bastırtqan, bu şiğerdə Tuqay «bez ruslar belən niçəmə yöz yıl bergə yəşədek həm bez bar məs'ələlərebezne də bergə çişə alabız» dip yazğan; 4. gazet xezmətkərləren nemes komandovaniesenə qarşı eşlərgə əndi; 5. ğomumən, Rəxim Sattar: «Sovet komandovaniəse mine seznen belən eşlərgə cibərde»,—dip tezep kitkən»,—dip yaza.

Rəxim Sattar üzenen kiləçək yazmışın belmi. Niçə kənnən, niçə səğəttən ni bulasın, isən qalamı, əllə yuqmı, inde anı da faciğəle yazmış kətəme?.. Tik əytəse süzen əytep qalırğa tieş ul. Bu izge wasiəten məngelekkə yullap qaldırırğa tieş.

Bu wasiət, bu süzlər Berlindağı qaysı yortta, qaysı ayda yazılğanın da belmim min. Ber şiğer axırına ber-berenə ərqılı yatqan ike qılıç yasap quyılğan, ikençesennən son qoş surəte... Ətinen yazuı matur. Ul yegermençe yıllarnı uqığanda latin şriftı belən yazğannar. Əti də latin belən küçergən üzenen şiğerləren.

Anın wasiəte, anın şiğerlərə distələgən yıllarnı kiçep, suğış faciğələrenə qaramastan, niçəmə menn çaqırımnarnı ütep ilenə qaytıp citte. Ulı İlgə də kilep ireşte...

Rəxmət, Ətiem!

REDAKSİƏDƏN:

**Ni qızğanıç, İl Sattarnın ətisenə bağışlap yazılğan bu nəseren avtor üze basılıp çıqqan xələndə kürə almadı. Rəxim Sattarnın ulı İl Sattar 2001 yının 21 aprelendə wafat buldı.**

# Rəxim Sattar

## Ber süzen

Hər kən sayın işek açasın da:
—Kildem inde, Rəxim, yanına!—
Disen. Üzen berni bulmağanday
Boz salasın inrəü qanıma.

Qotqı salıp tınıç uylarıma
Hər kiç sayın işek qağasın.
Utlı qaraş mina salasın da,
Üzen salqın ğına qalasın.

Tawışın sinen sixri tən çişməse:
—Kildem inde,—disen,—min üzem!
Üzen nigə yalğız? Kirəq mina
Çın küneldən əytkən ber süzen!
—Səyəm!—digen.

## Bülengən cır

Tabiğət tın ide, ul bay ide,
Yata ide tınlap al tanını.
İşetə idem cırlap üz tawışımnın
Kin urmannı urap qaytqanın.

Yəşəü tügel ide, cır ide ul,
Şat künelle duslar yanında.
Əzelep qaldı ul cır, bülenep qaldı
Tawışı kütərelgən çağında.

## Xalqım əçen

Kənçığışta alsulanıp
ata al tan,
Kükkə qalqıp tawlar kürenə—
güyə qalqan.

Alğa qarıym. Anda yata
toman haman.
Yıraq tuğan ildə yəşi
Ğaziz anam.

Qoraldaşlar yaw qırında!
Qayda son min?
Kem min sina, yətimmeni?
Əyt, tuğan il!

Bar xəsrəten, bar mixnəten
Mina urtaq.
Sin genə suq, sin irkələ,
sin mine qaq.

Ləkin sin bel, hər sulışım,
barlıq keçem,
Sinen өçen, tuğan ilem,
Sinen өçen!

## Ənkəmə xat

Şatlıqlarnı bergə kiçerdek bez,
Xəsrət kilde, tik sin yıraqta.
Kem belən son anı urtaqlaşıym?—
Awır xəsrət yalğız yөrəktə.

Külməgemə tamğan küz yəşlərən
Küptən inde kibep bettelər.
Tik süzlərən haman qolağımda
Kөrəşüne taləp ittelər.

Beləm, əni, bar analar kebek,
Mine çiqsez өzelep səyden sin.
Həm şuşındıy tirən səygən өçen:
—«Kөrəşep ül, ulım»,—diden sin.

Ul waqıtta əytten mina qarap:
—İlgə kertsən doşman etlərən,
Xəram bulsın, ulım, men qat xəram
Sina birgən izge sөtlərem.

Doşmannarğa arqan kürsətep sin
Qart kөnemdə xurlıq kitersən,
Ğөmrem buyı ləğnət uqırmın min,
Songı sulışta da kiçerməm!

.........................................

Uylıysındır: «Ulım qaytqan kөnne
Peşerermen qoymaq, belennər.
Өstələmdə tonr kükrəgemə
Quyıp kiskən qalın telemnər...»

Kөtmə əle, kөtmə—erep betər
Mina diep cıyğan maylarıŋ.
Kөrəş ozın, kөrəş qorban sorıy,
Belep bulmıy dөnya xəlləren.

Tik xəzergə mine qarğamıy tor,
Oyat kitermәs ulın yөzenə.
Xalqı səygən ulın yuldan yazmas,
Ülər, ləkin tonr süzendə.

# ҮЗИ АВЫЛЫНЫҢ ГАЗИЗҖАНЫ

## ГАЗИЗ КАШАПОВ-ҮЗИЛЕНЕҢ ТУУЫНА 60 ЕЛ

Прозаик, шагыйрь, журналист Газиз Кашапов турында истәлекләр язар алдыннан шәхси архивымны барларга булдым. Саргая төшкән бер хат игътибарымны җәлеп итте. Аны мөхтәрәм язучыбыз Барлас абый Камалов 1992 елның август кичендә Газизҗанның ярты гасырлык юбилеена багышланган радиотапшыруны тынлагач язган булган икән.

*«Тәлгат энем!*

*Газиз Кашапов турында тапшыру тәмамланыр-тәмамланмаста язам бу юлларны. Нәбирә Гыйматдинова чыгышын да, син сөйләгәннәрне дә бик әсәрләнеп тыңладым. Ихластан булгандыр, синең чыгышың аерата дулкынландыра. Бик рәхмәт.*

*Дуслык ул берең фани дөньядан киткәч тә дәвам итсә генә олы дуслык санала аладыр да. Әлеге җәһәттән син күпләргә матур үрнәк бирәсең. Монысы өчен дә рәхмәт.*

*Газиз хакында хатирәләр язарга бурычлы син. Бүген радиодан сөйләгәннәреңне киңәйтеп, детальләп һәм тирәнәйтебрәк тә язу хәерле булыр. Әдипнең 60 еллыгы да җитәр. Ул чагында синең хатирәләрең үтә тансыкка әйләнер. Эшең күп, вакытың тар, мәгәр җан дустың Газизҗан хакына моны эшләргә җай табарсың дип ышанасы килә.*

*Сәлам, ихтирам, гозер вә өмет белән: Барлас».*

Әйе, безне чал тарихлы Казан университеты ахирәт дусларга әйләндерде. 1973 елда татар теле һәм әдәбияты бүлегенә читтән торып укырга керү өчен имтиханнар тапшырдык. Бу көннәрдә булачак курсташлар белән артык аралашмадык, чөнки һәркем үзенчә сынауга әзерләнде. Безнең арада өлкәнрәк яшьтәге бер ир-ат күзгә ташлана иде.

Менә студент булуның «татлы мизгелләрен» кичердек һәм тәүге сессиягә киллек. Аны русча «установочная», диләр. Янәсе, бу иң җиңел сессия: зачетлар, имтиханнар тапшырасы юк. Әмма рус теле укытучысы Луиза Бәйрәмова беренче көнне үк өй эше бирде. Лекциядән соң Газиз белән (туу турында таныклыкта Газизҗан Салихҗан улы) сөйләшеп киттек, ул минем кая урнашуымны сорашты. Ул үзе туганнары Риза абыйларда тора икән. Мин «Совет» кунакханәсендә идем. Икенче көнне килеп тә керде бу. Бирелгән заданиене эшләдек. Сөйләшеп киттек. Җитмәсә тагын бер нәрсә ачылды. Ул мин Армиядә хезмәт иткән Амур өлкәсенең Благовещенск шәһәрендә хәрби училище тәмамлаган булып чыкты. Без шушы сессиядән соң аерылмас дусларга әйләндек. Алты ел буе төрле кунакханәләрдә бер бүлмәдә яшәдек. Кышкы сессияләр гадәттә 1 гыйнвардан башлана иде. Урыннар «дефицит» булганлыктан, без чиратлап, Яңа ел каршыламыйча, алданрак, 31 декабрьдә килеп урнашып кала идек. Ул көнне бар да диярлек кайтып бетә, кыскасы, номер эләктереп була. Газизҗанның гаиләсе ул елларда Чиләбедә яшәде, аннан алар башта Әлмәткә кайттылар, соңыннан Чаллыга күчтеләр. Безнең җәмәгатьләребез дә уртак тел тапты, гаиләләребез белән бик еш аралаша башладык. Алар—безгә, без аларга бардык. Фәһимә апа белән Газизнең көмеш туйларында да катнашырга насыйп булды әле. Туганлаштык шулай итеп...

Соңгы тапкыр Сабага Газизҗан вафатына 43 көн кала килде. Редакция коллективы белән очрашу үткәрдек. Ике кич кунды. Мунча бик ярата иде, һәр көнне чабындык. Аннан соң «Жигули»енда Казанга бардык. Эшләр беткәч, ул шуннан Чаллыга китәргә тиеш иде.

—Газизҗан,—дидем,—әйдә кире кайтыйк Сабага, тагын бер тапкыр мунча чабынырбыз.

Ул бик теләп риза булды. Казаннан кайтып, тагын бер кич кунды. Күңеле сизде микән: аның Сабага соңгы килүе, капка төбендә минем ахыргы мәртәбә озатуым булган иң...

Бу урында Татар халык язучысы, Мөхәммәт абый Мәһдиевнең истәлекләреннән *(«Татарстан яшьләре», 11 август, 1992 ел)* өзек китерү зыян итмәс.

«... Үз гомеремдә байтак юбилей мәкаләсе, үземнән өлкәннәр, замандашлар һәм яшьләрнең туган көннәренә багышланган, яңа чыккан китапларын мактаган мәкаләләр, авторларының үзләре үтенүе буенча китапларына сүз башлары яздым, дистәләгән кешене Язучылар Союзына тәкъдим итеп рекомендацияләр биргәнмен (архивымны актарганда гаҗәпкә калып утырдым—кайберләре Союзга керүгә язудан туктаганнар, бу гөнаһлар минем өстә), нәшрияттагы кульязмаларына уңай әчке рецензия юллаганмын.

Әсәрләренә мин фатиха биргән, Язучылар Союзына керергә рекомендация язган һәм китабына сүз башы юллаган Газиз Кашапов шулар арасыннан, миңа карата чиста күңелле бердәнбер егет булып калды. Мәрхүм белән 1991 елның июль ахырларында Кама буеның Боровец урманында ял базасында очраштык: ул минем үтенечем буенча Чаллы кибетләреннән кайбер китаплар алгалый һәм кеше аркылы җибәрә иде. Мин шунда аның белән акча исәбен өздем. Ул ике якка ыргылган куе мыекларын сыпырып:

—Ашыгыч түгел бит, сез—юлдагы кеше, акча кирәк булыр,—дип икеләнеп торды.

—Юк, дөньяныкы дөньялыкта өзелә торсын,—дидем мин, үз гомерем турында уйлап.

Дүрт атналап узгач, төнгә таба, миңа Чаллыдан телефон шылтыравы булды:

—Газиз үлде, иртәгә Аксубайга алып китәбез,—диде хатыны Фәһимә ханым. Мин тынып калдым, аңладым: тиз генә җыенып чыгып чаба торган ара түгел иде. Бердәнбер гамәлем шул булды: Саба район газетасы редакторы, Газизнең университет буенча ахирәт дусты Тәлгат Нәҗмиевкә чылтыраттым. Тәлгат ерак юлга чыгарга машинасын әзерләп йөри икән инде.

Кама буендагы очрашу шулай безнең иң соңгы күрешүебез, якты да, авыр да хатирә булып йөрәктә уелып калды...

... 1972 елның июлендә мин гаиләм белән Күктүбә (Кырым) иҗат йортында ял итә идем. Шунда Чиләбедән килгән тыйнак егет Рөстәм Вәлиев белән дуслаштык. Ул—язучы, татар тормышын рус телендә тасвирлаучы прозаик. Дуслаштык, ахырдан языша, бер-беребезгә китаплар җибәрә башладык. Бервакыт Рөстәм үтенеч белән хат яза: «Капитан Газиз Кашапов дигән егет авариягә очраган, «комиссовать» иткәннәр. Аның укырга керәсе килә. Казан университетының татар бүлегенә. Син шунда эшлисең бит, ярдәм ит, ди. Шундук яшь офицерга ярдәм итәсем килү хисе биләп алды. Ләкин бу җәйдә мин кабул итү имтиханнарында эшләмим бит. Тиздән ялга китәм, капитан Кашаповка кем күз-колак булыр? Андый кешегә ярдәм итү һич тә начарлык түгел, имтиханнар вакытында нинди генә хәлләр, нинди генә гаделсезлекләр булып бетми! Нишләргә? Рөстәмнең үтенече—минем өчен закон. Һәм мин кабул итү комиссиясендә бүлектән кемнәр эшләвен ачыкладым. Арадан берсе—кешеләргә байтак игелек эшләп тә, шулардан ук шактый зыян күреп яшәп яткан доцент Флера Сафиуллина икән. Кыйссаны шуңа аңлатып бирдем. Газиз Кашаповның имтиханнарда ничек баруын ул контрольгә алган. Ахырдан миңа әйтте:

—Бу мишәр егете бик уңган кешегә охшый, безнең ярдәмнән башка да узган булыр иде ул,—диде.

Университетта Газиз үзен шәп тотты: группаның «костягы» иде алар Тәлгат Нәҗмиев белән (анысы—староста). Группадагы кызлар, ханымнар авыр мәсьәлә килеп чыкканда (имтихан срогын күчерү, лекцияләрне берәр көнгә авыштырып Сабантуйга кайтып килү, берәр имтиханны «досрочно» бирү, фәлән кызның политэкономиядән яки КПСС тарихыннан алган «неуд»ын бетерү һ. б., һ. б.) һәрвакыт Газиз белән Тәлгаткә мөрәҗәгать итәләр иде. Аларның бу дуслыгы Газизнең соңгы көннәренә кадәр барды. Тәлгат Нәҗмиев миңа сөйләде: тормышының иң кыен минутларында Газиз һич тә хәбәр

итмәстән. Сабага килеп чыккалаган, дустыннан киңәш сораган.

Газиз бик чиста күңелле егет иде. Чиста күңеллелек—язучы өчен иң кирәкле сыйфат. «Вөҗдан» дигән төшенчәне Газиз бик зурдан бәяли иде һәм ул үзенең кыска гомерен вөҗданын бик нык саклаган көе узды. Шуңадыр инде, үзе исән чакта дөнья күргән китабына исемне дә ул «Вөҗдан хәтере» дип куйды».

Язмыштан узмыш юк, диләр. Шулай булса да, үлем үкенечсез булмый: талант иясе йөрәгенең 49 яшендә тибүдән мәңгегә туктавына ышанасы килмәде башта. Аның оптимистик рухта язылган, яшәүгә, тормышка мәдхия җырлаган шигырьләре, хикәя, повесть һәм романнары дөнья күрмичә калды. Үзеннән соң шигырьләренә көйләр язылды. Мәсәлән, Башкортстанның танылган артисты Радик Динәхмәтов башкаруындагы «Бүген ярат мине» (Дүртөйле егете Азамат Гыйльманов музыкасы) дигән җыры аеруча популярлашты. Әмма үлем—котылгысыз, табигый шул. Аның шулай икәнен Газизҗан да аңлый иде. Шулай да тәкъдир сәгате кайчан сугасын белмәде, болары инде, өлкәннәр әйтмешли, бер Алланың үзенә генә мәгълүм булгандыр. Бу көннең киләчәген Газизҗан бөтенләй сизмәде түгел. Чөнки 1969 елда хәрби хезмәт вазифасын үтәгән чакта авыр җәрәхәтләнеп, төрле госпитальләрдә бик озак дәваланулар аңа әҗәл барлыгын искәртеп торгандыр. Баш авыртуы белән бик җәфалана иде ул (үзе егерме елдан артык зәм-зәм суын бөтенләй капмады, тәмәке тартмады). «Баш түбәсеннән шул кадәр каты басалар, авыртуына чыдый алмыйча, җирне тишеп керердәй булам»,—дигән сүзләре хәтердә калган. Шуңадыр, бер хатында мондый юллар язган иде. «...Хәтерлисеңме, дустым, М. Җәлил иҗатын Гази Кашафка васыять иткән. Авыр эш бу. Булган барлык әйберләрне чыгару, кабатлап чыгару. Минем иҗатны кайгырту синең өстә булыр. Моның өчен сиңа күп вакыт әрәм итәргә туры килер. Дуслык хакына тырышырсың инде. Алай-болай булсам, 1987 гә—«Язмышыңа ышан», 1989 га—«Вөҗдан хәтере» дигән китаплар әзер диярлек, иң соңгы «Аваз» повестын гына бастырып аласы... «Аваз»—87 гә—«Казан утлары»на Ренат Харис вәгъдәсе (бу әсәрләр Г. Кашапов үзе исән вакытта дөнья күрде—Т. Н.). Аннарыга: 92 дә илле яшькә зуррак китап, аннары алтмышкамы бөтенесен җыеп—ике, бәлки, хатлар, рецензияләр, очерклар белән өч том булыр дип уйлыйм. Бу эшләр белән шөгыльләнүне дә сиңа ышандырам. Андый-мондый җай чыкса... Әлбәттә, болар барысы да минем теләгем генә. Син теләмәгән очракта, моның кадәр эшне йөкләве кыен.

Сау-сәламәт йөреп кайтсам, барып чыгармын шәт. Хөрмәт белән, тугрылыклы дус булганың өчен рәхмәт хисләре җыеп, Газизҗан.

20 июнь, 1986 ел.

Чаллыяр.

P. S. Бу хатны сакларга туры килер инде».

Әйе, хат сакланган, әмма ярты гасырлык юбилеена китабын чыгарып булмады. Чөнки еллар болганды, система үзгәрде, базар икътисады нәшрият тирәсенә дә китереп сукты... Ярый әле исән вакытта «Сәмум җиле» (бу повесть «Казан утлары» журналында басылгач, Фәнис Яруллин бик җылы рецензия язган иде) дип исемләнгән автобиографик повесть, «Солдат иртә ир була», «Җир җылысы», «Убырут», «Гомернең утлы өлеше», «Лачын кошка күкләр калерле», «Язмышыңа ышан», «Гыйфрит», «Дисбат» (икенче исеме «Тилчә тамыры». Тилчә—ракны аңлата) кебек әсәрләр иҗат итеп, биш китап чыгарырга өлгергән иде. Ә менә басылмаган күп кенә шигырьләре, хикәяләре һәм поэмалары калуы йөрәкне әрнетә (быел шигырьләр җыентыгы чыгар дип көтелә).

1991 ел башында ул Ташкент якларында булып, элек үзләренең туган төбәкләрендә яшәгән Сиражетдин мулланың көндәлеген табып алып кайткач, тагын бер романлык материал бар, дип шатланып сөйләгән иде. Газизҗан туган якларын, балалык елларын бик сагынып искә алырга ярата. Ул ятимлектә үсә. Әтисенең сугышта һәлак булуы турында хәбәр килгәч, әнисе аны Мәһруй әбисенә калдырып китеп бара. Алар башка очрашмыйлар...

Газиз Кашапов көчле публицист та иде. Ул Әлмәт шәһәрендә чыга

торган «Хезмәт байрагы» газетасы һәм КамАЗ радиотапшырулар редакцияләрендә әдәби хезмәткәр, «Социалистик Татарстан» газетасының Түбән Кама, Алабуга, Мамадыш, Тукай районнарындагы үз хәбәрчесе булды. Аннары Язучыларның Чаллы оешмасын житәкләде. Гомумән, Газиз журналистиканы чын күнелләрн яратты. Ул Татарстан Язучылары съездында татар публицистикасы турында ялкынлы доклад ясады һәм мөнбәрдән төшүгә аңа көчле инфаркт булды. Шуннан соң да әле бер роман, ике повесть бастырып чыгарды, ижат эшчәнлеген дәвам итте. Бигрәк тә якташы, танылган шагыйребез Хәсән Туфанга багышланган «Киек каз юлы» дигән романы өчен бик күп фактик материал туплады. Күренекле драматург Туфан Миңнуллин белән бергә олы шагыйрь эшләгән Пермь өлкәсендәге Лысьва шәһәрендә мемориаль такта куюны һәм аны тантаналы төстә ачтыруны оештырды. Туфан утырган төрмәгә барып, Газизжан аның «шәхси дело»сын тапты, «халык дошманы»ның сирәк очрый торган рәсемен алып кайтты. Хәсән ага сөргендә булган Новосибирск өлкәсендәге авылны эзләп, аны белгән кешеләр белән очрашты, шагыйрь яшәгән землянка урынында төн кунды... Әмма Г. Кашапов бу романның беренче кисәген генә тәмамлый алды. «Киек каз юлы» дип исемләнгән әлеге китап вафатыннан соң дөнья күрде.

Романга кереш сүзне тагын бер могикан язучыбыз Аяз ага Гыйләжев язып, фикерен болай дип тәмамлаган иде. **«Белүемчә, Газиз Кашапов-Үзиле гомеренең соңгы сулышына кадәр якташы Хәсән Туфанның гыйбрәтле язмышын роман битләрендә күрергә тырышып ижат итте. Сез кулга алган әлеге китап Хәсән Туфанга һәйкәл буласы иде... Бу әсәре аның үзенә дә һәйкәл булыр дип кем уйлаган?»**

Әйе, әйткәнемчә, Хәсән Туфан ижатына кагылышлы бик күп материал туплаган иде Газизжан. Менә тагын ул язган бер хаттан өзек: **«Тәлгат дус! Әле синең белән сөйләшеп киткәннән соң Казанга барып кайттым. «Язмышыңа ышан» акрынлап эшләнә башлаган. Булыр инде. Ренат Харис белән бүлмәсендә бер сәгать сөйләшеп утырдык. 1.07 очам, 12 дә кайтам, аннан Покровка, Чыпчык авылы—Прометей атлы үгез белән, татарның бөек шагыйре яшәгән жирләргә сәфәр кылмакчымын... Исән булсам...»**

Мин, бу юлларның авторы буларак, Газиз Кашаповка исән вакытта Хәсән ага Туфан белән очраштырган өчен дә мең-мең рәхмәтлемен. Татар поэзиясе аксакалының фатирына ике тапкыр бергә бардык. Бу очрашулар миңа, районда яшәүче журналистка, Хәсән Туфан һәм Газизжан турында истәлекләр (урыннары оҗмахта булсын) язарга жирлек булды.

Үз-үзенә бик таләпчән, нык характерлы, куелган максатына ирешә торган үҗәт кеше иде Гази Кашапов. Бөек Ватан сугышында ук һәлак булган, үзен бер тапкыр да күрмәгән офицер әтисенең каберен ул «Кызыл Хач» җәмгыяте аша Польша жирләреннән эзләп тапты. Икенче атадан туган Үзбәкстандагы энеләрен эзләп (Газиз хәрби хезмәттә вакытта анасы гүр иясе була) якын туган итте, яннарына барып кайтты. Аннары үзләре килделәр.

Газизнең 1990 елның 15 сентябрендә Мәскәү янындагы Переделкино ижат йортыннан язылган тагын бер хатыннан өзек китерәм. **«Сәламәтлекне ныгытуны онытмыйм. Иртәнге биштә торам, бер сәгать гимнастика, чәй эчәм... ике сәгать эшләп утырам. Тугызда—иртәнге аш, унда йөрергә чыгам, 15 км.ны әйләнеп кайтам. Көн дә. Газеталар укыйм. Аннары тагын бераз эшлим. 14 тә төшке аш. Тозсыз, майсыз пешертәм бит тәки... 16 да—1,25 минут гимнастика, урында йөгерү иртән 8 мин., 19 да кичке аш. 1,5 сәгать язу. 21 дә «Вакыт». 10 сәг. 30 минутта йокларга яту. Железный порядок. Менә бүген, һәр шимбәдәгечә—кырык ике сәгатьлек ачлык. Бары су гына эчәм—биш стакан...»**

Әмма Газизжанга болар гына ярдәм итә алмады...

Ул, алдан язылган васыяте нигезендә, үзе теләгән урынга—Яна Үзигә алып кайтып жирләнде.

Газиз Кашаповны районлашлары, авылдашлары тирән хөрмәт иткән икән. Мәрхүмне жирләгән вакытта бу бигрәк тә ачык күренде. Яна Үзи авылы кешеләре матәм митингысы вакытында язучының музеен кору һәм колхозда аның исемендәге премия булдыру, бюст кую турында карар кабул




иттеләр. Бу тәкъдимнәр Аксубай район хакимияте (ул чоргы башлык Марс Халитов) тарафыннан хупланды һәм бер ел эчендә тормышка ашырылды. Бюстны эшләтү һәм кую, музей ачу, экспозицияләр туплау өчен эшмәкәр Рәшит Гафуров, мәктәп директоры Альбина Зартдинова, язучының кайнагасы, ветеран-укытучы Рәхимҗан ага Мәхмүтов, туганнан туган абыйсы Исламетдин Кашапов һәм башка бик күпләр җан атып йөрделәр.

Шәхси әйберләрен һәм архивын хатыны Фәһимә ханым, балалары Илусә, Резеда, Гамил, Дамир хәстәрләп бирде. Халык искит-кеч күп булган тантаналы мизгелләргә кунаклар бөтен республикадан җыйналган иде.

Мин үзем, чакырулы булуга карамастан, якын дустыма бюст һәм музей ачу тантанасына бара алмадым. Бераз соңрак, Казанда кабер ташы ясатып илттем. Аны җәмәгатьчелек катнашында җиренә җиткереп урнаштырдык.

Әйе, изге күңелле, поэтик җанлы иде шул дустым. Шулай булмаса, шифаханәгә керер алдыннан—туган көненә бер көн калгач, үз-үзенә шигырь язып, эш өстәлендә калдырыр идеме?!

## Туган көнемә—21 августка

Алтынланган агач яфраклары,
Тынып калган урман.
Миләшләргә сары сагыш сауган,
Алма пешеп тулган.
Язлар быел иртә килде диеп,
Әй шатланган идек.
Августның да егермесе җитте.—
Китеп бара киек.
Һәр фасылның үз вакыты вакыт.
Артыгы юк аның.
Кырык тугыз тапкыр дүртәр фасыл
Тумышымнан алып...
Юк,
Туктатып булмыйдыр ул, бәлки,
Гомер агышларын.
Минем әле яна үрләр яулап
Алга барышларым.
Тормыш үзе катлаулы да болай,
Ачы да соң язмыш.
Тик барыбер каршы алам әле
Тагын илле язны.
Әйтсеннәр соң көнче җирдәшләрем
Туксан тугызлы дип.
Әрнүләре, рәнҗүләре белән
Бу дөнья кызык бит...
Миләшләргә сары сагыш сауган,
Алма пешеп тулган.
Алтынланган агач яфраклары
Тынып калган урман.

Тәлгат **НӘҖМИЕВ**

*Котлыйбыз!*

## Рифат Сверигинга – 70 яшь



Хәзерге әдәби тәнкыйтьнең алгы сафында баручыларны ачыкларга телибез икән, беренчеләрдән булып тәнкыйтьче һәм галим Рифат Сверигин исемен атыйбыз. Ул кырык еллап фәнни һәм әдәби иҗат юлында ару-талу белмичә хезмәт итеп килә. Аның татар прозасының үсеш тенденцияләрен ачыклауга багышланган күпсанлы хезмәтләре, язучылардан Ә. Еники, Ф. Хөсни, А. Расих, Р. Төхфәтуллин һ. б. ларның иҗади үзенчәлекләренә, психологик һәм рәссамлык осталыкларына караган саллы-саллы мәкаләләре республика матбугатында, аерым китапларда һәм төрле фәнни җыентыкларда даими басыла.

Татарстан Язучылар берлегенә кабул ителгәч аның иҗади активлыгы тагын да артты, Рифат ага язучылар алдында кызыклы, тыңлаучыга күп мәгълүмат бирә торган докладлар белән дә еш чыгышлар ясый, прозаның иң актуаль проблемаларын иҗатчылар алдына калку итеп куя, аларны яңа уйлануларга, тагын да нәтиҗәлерәк эзләнүләргә чакыра. Тәнкыйтьче повесть жанрының торышы белән бигрәк тә якыннан кызыксына, системалы рәвештә шөгыльләнә.

Рифат Сверигин үзенең актив иҗатын Казан дәүләт педагогия университетындагы укыту эшчәнлеге белән бергә алып бара. Ул озак еллар укыту дәверендә бу коллективның тырыш, намуслы һәм якты күңелле, олы җанлы шәхесе буларак зур абруй казанды.

Татарстан Язучылар берлегенең әдәби тәнкыйть буенча бирелә торган Җамал Вәлиди исемендәге премиясенә дә 2001 елдагы актив иҗаты һәм эшчәнлеге өчен Рифат Сверигин лаек булды.

Талантлы әдәбият галимен, журналыбызның актив авторын олы юбилее белән кайнар котлыйбыз, саулык-сәламәтлек һәм яңадан-яңа иҗат уңышлары телибез!

# ЖУРНАЛГА ЯЗЫЛУ БАШЛАНА

Хөрмәтле укучыларыбыз!

Быелның 1 сентябреннән 2003 елның беренче яртыеллыгы өчен вакытлы матбугатка язылу башлана. **"Казан утлары"ның индексы— 73210.**

Журналга язылуны җиңеләйтү максатыннан абонемент үрнәген тәкъдим итәбез. Әлеге квитанцияне кисеп алып, анда тулы адресыгыз, исем-фамилиягез һәм язылырга теләгән айларны күрсәтеп, элемтә бүлегенә тапшырырга кирәк.

Казанлылар исә безнең журналга "Горпечать" киоскларында языла алалар. Бу очракта журналны ай саен шуннан барып аласы була.

80 еллык бай тарихы булган мәдәниятебез елъязмасы "Казан утлары"на язылырга онытмагыз!

Ф.СП-1

Управление почтовой связи "Татарстан Почтасы"

**АБОНЕМЕНТ на** ~~газету~~ журнал — 73210 (индекс издания)

***Казан утлары*** (наименование издания)

Количество комплектов:

на 2003 год по месяцам:

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | |

Куда ____ (почтовый индекс) ____ (адрес)

Кому ____ (фамилия, имя, отчество)

**ДОСТАВОЧНАЯ КАРТОЧКА**

ПВ | место | ли-тер

на ~~газету~~ журнал — 73210 (индекс издания)

***Казан утлары*** (наименование издания)

| Стои-мость | подписки | ____ руб. ____ коп. | Количество комплек-тов |
|---|---|---|---|
| | пере-адресовки | ____ руб. ____ коп. | |

на 2003 год по месяцам:

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | |

Куда ____ (почтовый индекс) ____ (адрес)

Кому ____ (фамилия, имя, отчество)

## Ictimağı-mədəni tormışıbızdan
## Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан

### ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫНЫҢ XIV КОРЫЛТАЕ ДЕЛЕГАТЛАРЫНЫҢ ТАТАР ХАЛКЫНА МӨРӘҖӘГАТЕ

Газиз халкыбыз!

Мәгълүм булганча, 2002 елның октябрендә Россия Федерациясендә халык санын алу кампаниясе узачак. Бу тарихи вакыйганың әһәмиятен статистика яки гражданлык проблемалары белән генә чикләү дөрес булмас иде. Әлеге эш тирән сәяси төс ала бара. Татар милләтен берничә «кавем»гә бүлеп карарга тырышу—шуның бер дәлиле. Бу хәл татар әдипләрен дә бик борчуга салды. Чөнки татарны ваклау, милләтне таркату—ул мең еллык тарихы булган әдәбиятны ваклау һәм таркату да... Татарны төрле якка тарткалау—хәл итеп булмаслык авыр тел, мәдәният, йола, дин проблемаларына китерәчәк, милләтнең болай да шактый какшаган хәлсез рухын тәмам юкка чыгарачак.

Мәшһүр Тукаебызның шигырьләрен тагын биш-алты стильгә төрләндереп укыйкмы? Г. Исхакый әсәрләрен төзәтеп утырыйкмы? Һ. Такташның бунтарь поэзиясенә, Х. Туфанның ягымлы лирикасына ревизия ясыйкмы? Бүген әдәби иҗатта беренче адымнарын гына ясаучы яшьләрнең кыйблаларын буташтырыйкмы? Аларның тернәкләнеп кенә килгән ышанычларын югалтыйкмы? «Кайсы матбугат органын кайсы кавемгә кертәбез?» дип бәхәсләр кузгатыйкмы? Ниһаять, ярсый-ярсый татар әдипләрен бүләргә керешикме? Бу хәлләрне күз алдына китерү дә кыен.

Татар әдәбияты бер генә ул! Татар теле дә бер генә! Йоласы да, рухы да, язмышы да бер генә аның! Шушы берлекне саклый алсак кына бөеклегебезне, милли үзенчәлегебезне һәм киләчәгебезне тәэмин итә алачакбыз.

Сүзебез бер булсын: без—татарлар. Аннары гына—мишәрләр, әстерхан, себер татарлары, нугайлар, керәшеннәр, типтәрләр... Болары инде—татарның милли аерымлыгы түгел, ә бәлки, күңел байлыгы, рух байлыгы, тел байлыгы... Менә шушы күңел, рух байлыгын югалтмыйча, бердәм, нык һәм өметле татар милләте булып яшәргә дә яшәргә безгә!

Газиз халкыбыз! Дәрдемәнд тә: «Татарлыгым өчен җан атармын»,—дигән. Без дә бу хакта онытмыйк, халык санын алу кебек җаваплы, мөһим вакыйганы бер милләт булып, «татар» булып башкарып чыгыйк.

Безнең бердәмлеккә омтылышыбыз һич тә милләтебезнең башка халыклардан өстенлеккә ирешергә теләвен аңлатмый. Без, татарлар, һәр халыкны ихтирам итәбез. Шул ук вакытта алардан үзебезне дә ихтирам итүне таләп итәбез.

### ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕНДӘ

Татарстан язучыларының XIV корылтаенда (31 май) иҗат берлегенең рәисе һәм 22 кешедән торган идарәсе сайланган иде. Июнь башында яна идарәнең беренче утырышы үткәрелде. Анда үткән корылтай йомгаклары буенча эшлекле-җитди сөйләшү булды. Берлек рәисе **Фоат Галимуллин** һәм идарә әгъзалары корылтай кабул иткән резолюцияне тормышка ашыру буенча эш юнәлешләрен билгеләделәр.

Идарә утырышында берлек рәисе урынбасарлары итеп яңадан **Галимҗан Гыйльманов** һәм **Шаһинур Мостафин** сайланды. Журналны гамәлгә куючылар белән килештерелеп, «Казан утлары» журналының баш мөхәррире итеп **Равил Фәйзуллин** расланды. «Идел», «Салават күпере», «Мәйдан» журналларының баш мөхәррирләре **Рашат Низамиев, Зиннур Хөснияр, Факил Сафин** шулай ук үз урыннарында калдылар—идарә әгъзалары аларга да бертавыштан ышаныч күрсәтте. Язучылар берлегенә кабул итү коллегиясенең рәисе итеп яңадан **Равил Фәйзуллин**, Аксакаллар шурасы рәисе итеп **Мөсәгыйт Хәбибуллин** сайланды.

Остаханә җитәкчеләре итеп **Зиннур Мансуров** (шигърият), **Солтан Шәмси** (проза), **Кыям Миңлебаев** (әдәби тәрҗемә), **Җәүдәт Дәрзаман** (балалар әдәбияты), **Мансур Вәлиев** (әдәби тәнкыйть), **Владимир Корчагин** (рус әдәбияты) расланды.

Татарстан Язучылар берлегенең һәм Лаеш районы хакимиятенең Г. Державин исемендәге премиясен 2002 ел өчен рус телендә иҗат итүче прозаик **Әхәт Мушинскийга** бирү турында да карар кабул ителде.

### САБАНТУЙЛАР ДӨНЬЯ ИҢЛИ

Татар халкының иң күркәм милли бәйрәме Сабантуй соңгы елларда дөньяның

төрле кыйтгаларында даими үткәрелә башлады. Быелгы Сабантуйлар Россия регионнарында аеруча оешкан төстә үтте һәм безнең язучылар бу бәйрәмнәрдә актив катнаштылар. Июнь-июль айларында **Мәдинә Маликова**—Саратов, **Ренат Харис**—Пермь һәм Пенза, **Фоат Галимуллин**—Санкт-Петербург, **Равил Фәйзуллин**—Түбән Новгород, **Айдар Хәлим, Фәүзия Бәйрәмова, Факил Әмәк, Вахит Имамовлар**—Чиләбе, **Рашат Низамиев**—Төмән, **Шаһинур Мостафин**—Йошкар-Ола, **Радиф Сәгъди**—Сургут Сабантуйларында булдылар, милләттәшләребезгә язучы-әдип сүзен ирештерделәр.

### МАТБУГАТ БЕРЛӘШТЕРСЕН

27 июньдә «Ливадия» санаториенда Россия Федерациясе төбәкләрендә яшәүче татарлар өчен бастырып чыгарыла торган массакүләм матбугат чаралары баш редакторларының беренче семинары булды.

Семинар ТР Министрлар Кабинетының иҗтимагый оешмалар һәм массакүләм матбугат чаралары белән эшләү бүлеге инициативасы буенча оештырылды. Аның эшендә Россиянең 15 төбәгеннән 23 кеше катнашты. Бүлек вәкиле **Равил Хәсәншин** әйтүенчә, семинар массакүләм мәгълүмат чаралары аша Россия төбәкләрендә яшәүче татарларны берләштерүдә беренче омтылыш булып тора һәм аны август аенда чакырылачак Бөтендөнья Татар конгрессы алдыннан үткәрү бик тә актуаль. Семинар эшендә ТР Дәүләт Советы Рәисе урынбасары **Роберт Миңнуллин,** Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты рәисе **Индус Таһиров**, Дәүләт Советының фән, мәгариф, мәдәният һәм милли мәсьәләләр комиссиясе рәисе **Разил Вәлиев**, тарих фәннәре докторы **Дамир Исхаков**, Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты рәисе урынбасары **Римзил Вәлиев** катнашты һәм докладлар белән чыгыш ясады.

Семинар кысаларында «Татарстан яшьләре» газетасы, «Татарстан» журналы, «Татарстан—яңа гасыр» телекомпаниясе оештырган «түгәрәк өстәл» утырышлары булды.

Семинар эше тәмамлангач, анда катнашучылар белән Татарстан Премьер-министры урынбасары **Зилә Вәлиева** очрашты. Әңгәмә барышында Россия төбәкләрендә массакүләм матбугат чараларының хәле, татарлар өчен чыгарыла торган массакүләм матбугат чаралары алдында тора торган проблемалар турында сөйләнде.

### «ИДЕЛ»ДӘ ТАТАР ЯШЬЛӘРЕ

6—13 июль көннәрендә «Идел» халыкара туристлык лагерында **«Татар яшьләре көннәре» фестивале** үтте. Инде 13 нче тапкыр уздырыла торган бу очрашуларда 23 регионнан 100дән артык егет һәм кыз катнашты. Килгән кунаклар атна дәвамында татар халкының культурасы, милли мохите белән якынрак таныштылар, төрле иҗтимагый оешма, иҗат берлекләре вәкилләре белән очрашып, яшьләр мәсьәләләре буенча фикер алыштылар.

Фестиваль көннәрендә яшьләр Бөтендөнья Татар конгрессы башкарма комитеты җитәкчеләре белән очраштылар. БТК рәисе **Индус Таһиров** «Яшь буын үзенә йөкләнгән миссиясенең ни дәрәҗәдә җитди икәнлеген аңласын иде. Туган телебезне, милли мәдәниятебезне, гореф-гадәтләребезне саклау һәм үстерү яшьләр кулында. Казан шәһәре бөтен татарларны берләштерүче рухи һәм мәдәни үзәк ролен үти»,—диде ул. Кунаклар, үз чиратында, конгрессның эше белән кызыксынды. Алар үзләренең эшчәнлекләре турында да сөйләделәр.

Фестиваль кунаклары шулай ук ТР Мәгариф министрлыгында, ТР Диния нәзарәтендә, Республика балалар китапханәсендә булды. Анда ТР мәдәният министры **Илдус Тарханов** яшьләргә Татарстанның мәдәни куәте, мөмкинлекләре һәм монда үткәрелгән республика һәм халыкара акцияләр хакында сөйләп үтте.

Кунакларның исендә калырлык вакыйгаларның берсе изге Болгар җиренә сәяхәт булды. Фестивальгә килгән яшьләрнең күбесе иҗат кешеләре. Алар биредән яңа көч, дәртилһам алып киттеләр.

### КЫРЫМНАН КАРДӘШЛӘР КИЛДЕ

Июнь аенда—21еннән 24енә кадәр республикабызда **Кырым Республикасы көннәре** булып үтте.

Кырымнан зур делегация килде. Аның составында кырымтатарларының Украина Президенты каршында вәкилләре советы секретаре, Мәдәният министрлыгы вәкилләре, сәнгать оешмалары, фольклор ансамбльләре җитәкчеләре, язучылар, журналистлар бар иде.

Татарстанда Кырым мәдәнияте көннәрен 1941 елда ук уздырырга планлаштырылган булган. Бу планнарны сугыш җимереп ташлый һәм әлеге чара Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы белән Украина дәүләте арасында кул куелган килешү кысаларында алтмыш елдан артык вакыт узганнан соң гына тормышка ашты. Очрашуда мәдәният, әдәбият һәм башка өлкәләрдәге хезмәттәшлекне дәвам итәргә дип килешенде.

### ЮБИЛЕЙ ЭМБЛЕМАСЫ БУЛЫР

Татарстан башкаласы хакимияте Казанның 1000 еллыгына **иң яхшы эмблема-символга конкурс** игълан итте.

Конкурста безнең республикада һәм Россиядә яшәүчеләрдән тыш, башка ил вәкилләре дә катнаша ала. Катнашучылар Казанның тарихи, милли, мәдәни традицияләре идеяләренә таянырга, үз уйларының төпле, аңлаешлы һәм үзенчәлекле чагылышына омтылырга тиеш.

Беренче урын алган проект Казанның 1000 еллыгын бәйрәм итүгә рәсми эмблема-символ дип игълан ителәчәк. **Иң яхшы эшкә бүләк—25 мең сум.** Конкурс эшләрен тапшыруның соңгы срогы—бу елның 15 октябре.

### БЕРЕНЧЕ ЧЫГАРЫЛЫШ

28 июнь көнне республикабыз башкаласындагы **Россия Ислам университетында (РИУ) беренче чыгарылыш** шәкертләрен олы тормыш юлына озату вакыйгасы булды.

Ислам университеты ачу бик күп дин әһелләренең хыялы иде.

1998 елның мартында Тукай урамындагы Гали мәчете бинасында, Казан мәдрәсәләрендәге ин сәләтле шәкертләрне җыеп, РИУнын әзерлек бүлеге эшли башлаган иде (шул вакытта кабул ителгән 18 шәкертнең 14е укып бетерде.) Анда ике ел ярым яшәгәннән соң, 2000 елның сентябрендә университет заманча җиһазландырылган яна бинага (Газовый, 19) күченде. Хәзер атна саен диярлек бирегә РФнын төрле төбәкләреннән генә түгел, чит илләрдән дә кунаклар килә.

Чыгарылыш тантанасында Татарстан мөфтие, РИУ ректоры **Госман хәзрәт Исхакый**, ТР Президентының тышкы эшләр департаменты директоры **Тимур Акулов**, Татарстан буенча федераль инспектор **Денис Әхмәдуллин**, ТР Министрлар Кабинеты каршындагы Дин эшләре шурасы рәисе **Ринат Нәбиев**, ТФАнын баш гыйльми сәркатибе **Илдус Хәйбуллин**, БТК рәисе, академик **Индус Таһиров**, академик **Мирза Мәхмүтов**, политология фәннәре докторы **Рәфыйк Мөхәммәтшин**, Ульяновск өлкәсе мөфтие **Фатыйх хәзрәт**ләр чыгыш ясадылар, яшь дин хадимнәренә уңышлар теләделәр.

### ГЫЙЛЬМИ ДӘРӘҖӘ АЛДЫЛАР

Казан дәүләт университетынын филология фәннәре буенча диссертацияләр яклау советынын 6 майдагы утырышында **Зөфәр Рәмиев** «XX гасыр башында татар әдәбияты: авторлык, төп текст, хронология проблемасы» дигән темага филология фәннәре докторы дәрәҗәсенә, **Илсөяр Рәмиева** «Әдәбиятта Сөембикә образы» (чор һәм әдәби герой) дигән темага филология фәннәре кандидаты дәрәҗәсенә диссертацияләр яклады лар.

Ә 13 майдагы утырышта **Гүзәл Насыйрова** «Каюм Насыйринын татар тел гыйлеме өлкәсендә эшчәнлеге» темасына, **Нурфия Гафиатуллина** «XX гасыр татар шигъриятендә Тукай образы» дигән темага, **Рифә Харрасова** «Гаяз Исхакыйнын башлангыч прозасы әдәби багланышлар контекстында (1895—1905)» дигән темага филология фәннәре кандидаты дәрәҗәсенә диссертацияләр якладылар.

### ТУГАННАРНЫҢ САГЫНГАН ЧАГЫ

Башкортстан Республикасынын «Рамазан» төрки милли-агарту үзәге татар халкын үз тарихына якынайту һәм Татарстанның тарихи урыннары белән таныштыру максатында шушы елнын 5-12 июлендә Уфа-Сергеевка-Түбән Кама-Болгар-Казан-Чаллы-Уфа маршруты буенча «В. Зайцев» теплоходында уңынчы юбилей круизын оештырды. Анда Башкортстан һәм Татарстаннын сәнгать йолдызлары, күренекле язучылары, Башкортстаннын Дәүләт Җыены депутатлары, җәмәгатьчелек вәкилләре катнаша.

9 июльдә Казаннын елга портында «Бөек Болгарга сәяхәт» программасы кысаларында узучы шушы круизда катнашучыларны тантаналы каршылау булды. Кунаклар башкалабыз Казаннын тарихи урыннары белән таныштылар, шәһәр җәмәгатьчелеге, Бөтендөнья татар конгрессы һәм татар милли-мәдәни оешмалары вәкилләре белән очраштылар.

### ҮЛГӘННӘРНЕҢ КАБЕРЕН БЕЛ

28 июнь көнне Казаннын Иске Бистәсендәге татар зиратында күренекле әдип, Татарстаннын халык язучысы **Гомәр Бәшировның каберенә таш куелды.**

Гомәр Бәширов, моннан 3 ел элек, 98 яшендә вафат булган иде. Яшел төстәге, гади дә, шул ук вакытта затлы һәм милли бизәкле бу мәрмәр таш Татарстан Мәдәният министрлыгы, Арча районы хакимияте һәм Татарстан Язучылар берлеге инициативасы һәм ярдәме белән ясатылган.

Быел, шулай ук, әдип яшәгән йортка (Маяковский ур. 23 а йорт) истәлек тактасы да куелган иде.

### ИГЪТИБАР: КОНКУРС

«Татарстан республикасы халыклары телләре» һәм **«Татар алфавитын латин графикасы нигезендә торгызу»** турындагы Татарстан законнарын гамәлгә ашыру йөзеннән, Республикабызнын Элемтә министрлыгы иң яхшы язмаларга конкурс игълан итә. Мәкаләләрдә күпмилләтле республикаларда ике дәүләт теле һәм башка телләрнең яшәү үзенчәлекләре, латин әлифбасына күчү проблемалары яктыртылырга тиеш. Оештыру-хокукый формасы ягыннан нинди ведомствоныкы булу-булмавына карамастан, әлеге конкурста барлык газета-журналлар катнаша ала. Грант алу өчен министрлыкнын массакүләм мәгълүмат чараларына булышлык итү бүлегенә II яртыеллыкка эшләнгән план-проект җибәрергә кирәк. Анда басылып чыгачак язмаларнын эчтәлеге, вакыты, автор турында мәгълүмат бирелә. Шулай ук фаразланган нәтиҗә, чыгымнарнын сметасы һәм мөмкин булган финанс чыганаклары күрсәтелергә тиеш.

Хәбәрләшү өчен телефон: 92-72-00, 36-75-25. Телефакс: (8432) 64-51-42.

**«ТАТАРСТАН—НОВЫЙ ВЕК»—«ТАТАРСТАН—ЯҢА ГАСЫР» РЕСПУБЛИКА ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ХӘРӘКӘТЕНЕҢ СӘЯСИ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ МӨРӘҖӘГАТЕ**

2002 елның 5 июнендә Россия Федерациясе Федераль Җыены Дәүләт Думасы беренче укылышта «Россия Федерациясе халыклары телләре турында» законга төзәтмәләр кабул итте. Алар күпмилләтле Россиянең барлык халыклары язуында кириллица графикасын гына файдалануны беркетә. Ә бу карар Россия Конституциясенең «Республикалар үзләренең дәүләт телләрен урнаштырырга хокуклы» һәм «Россия Федерациясе үзенең барлык халкына туган телләрен саклау хокукын, телне өйрәнү һәм үстерүгә шартлар тудыруны гарантияли»,—дигән 68 нче маддәсен кире кага. Шул ук вакытта әлеге төзәтмәләр Россия кул куйган кайбер халыкара документларга да каршы килә.

Дәүләт Думасы кабул иткән карар унаеннан, үзенең сафларында төрле милләттәге һәм диндәге, төрле социаль катлаудагы һәм сәяси караштагы йөз меңләп республика кешесен берләштергән «Татарстан—новый век»—«Татарстан—яңа гасыр» иҗтимагый-сәяси хәрәкәте җыенының игътибарын үзвакытында Россия Федерациясе Конституциясенең күпмилләтле халык исеменнән кабул ителүенә, «халыкларның тигезлегенә һәм үзбилгеләнүенә» нигезләнгән булуына юнәлтә. Безнең илебез тарихи яктан күпмилләтле дәүләт буларак формалашканга күрә, халыкларның урнашуы, аларның хәләхвәле, киләчәк үсеше дәүләт сәясәтендә үзәк мәсьәләләрнең берсе булды.

Россия Федерациясендә һәрбер халыкның үзенчәлекле милли тормышын саклау беренче чиратта телне, мәдәниятне, гореф-гадәтләрне үстерүгә шартлар тудырудан башланырга тиеш. Татар халкы X гасырда ук рун язуыннан гарәпнекенә күчкән. 1929 елда латин графикасы кертелгән һәм ул 1939 елга кадәр сакланган. Аннан соң СССРда яшәүче күпчелек халыкның, шул исәптән татарларның да язуы административ рәвештә кириллицага күчерелгән. Төрле алфавитлардан файдалану тәҗрибәсе, татар теле өчен иң туры килгәне—дөньяви үсешнең заман таләпләренә җавап бирә торган латин графикасы булуын күрсәтте. II Бөтендөнья татар конгрессының Татарстан Республикасы җитәкчелегенә татар язуын латин графикасына күчерүнең максатчан чара һәм кирәкле гамәл булуы турында махсус мөрәҗәгать кабул итүе дә тикмәгә генә түгел. Әлеге мөрәҗәгать 1999 елның сентябрендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советының «Татар алфавитын латин графикасы нигезендә торгызу» турында закон кабул итүенә этәргеч ясады.

«Татарстан—новый век»—«Татарстан—яңа гасыр» хәрәкәтенең сәяси советы президиумы Дәүләт Думасының «Россия Федерациясе халыкларының телләре турында»гы законга керткән төзәтмәләрен татар халкының мөстәкыйль рәвештә үз телен үстерүгә булган хокукын боза һәм аны үз карамагындагы мәсьәләләргә һәм Татарстан Республикасы гамәлләренә тыкшыну дип бәяли.

«Татарстан—новый век»—«Татарстан—яңа гасыр» хәрәкәтенең сәяси советы президиумы сан ягыннан Россиядә иң зур милләтләрнең берсе булган халыкның фикерен, тарихи тамырларын, социаль-мәдәни үсеш үзенчәлекләрен исәпкә алып Дәүләт Думасы депутатларын әлеге мәсьәлә турында тагын бер тапкыр фикер алышырга чакыра.

Федерация субъектлары хокуклары, татар халкының рухи үсеше мәнфәгатьләре турындагы мәсьәләләр урындагы хәлләрнең барысын да исәпкә алып, төгәл хәл ителергә тиеш. Бүгенге көндә Дәүләт Думасы депутатлары алдында латин хәрефенә күчү яисә кириллицаны саклап калу түгел, ә федерализм белән унитаризм арасында Россиядәге этник-милли хәлләрне демократик һәм авторитар ысуллар белән чишү мәсьәләсе тора.


---

*Тышлыктагы сурәтләр*

**Тышлыкның беренче битендә:** Башкалабызда—Республика көне.

**Тышлыкның дүртенче битендә:** Г. Меркаторның «Тартария» картасы (1630) һәм Б. Урманченың «Татарстан» триптихының (1977) композициясе.

# ЯҢА КИТАПЛАР





Татар сынлы сәнгать тарихында истәлекле вакыйга: Татарстанның халык рәссаме Әхсән Фәтхетдинов әсәрләреннән торган уникаль альбом-китап дөнья күрде. Бу хезмәтне «Рухият» нәшрияты әзерләгән, Финляндиянең «Otava Printers» полиграфия ширкәте басып чыгарган. Милли эчтәлеге ягыннан булсын, зәвыклы бизәлеш ягыннан булсын, татар сәнгате казанышы итеп, дөньяның теләсә кайсы ил-халыклар күзенә күрсәтерлек бу альбом. Әлбәттә, бу олуг хезмәтне чыгаруда Татарстан Президентыннан башлап корректорларга кадәр бик күпләрнең хезмәте кергән. Түбән Кама хакимиятенең һәм промышленность предприятиеләре житәкчеләренең тырышлыгын һәм матди ярдәм итүләрен аеруча әйтеп үтү кирәк. Рәссам ижаты турында кереш сүз—эссе-хикәятне сәнгать белгече Розалина Шаһиева язган. Анда мондый сүзләр бар:

«Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, нәкышче, сынчы, агач уймалар остасы Әхсән Фәтхетдинновның ижаты — жилләр, һәлакәтләр, традиция ташкыннары, халык фажигаләре, кешеләрнең сыкранулары белән тоташудан туган сәнгать; аның табигать язмышы, гомумцивилизация, милләт, дәүләт, этнос хакындагы хәсрәтле уйларының чагылышы. Нәкъ шушы сыйфатлар аны аң тарлыгыннан, чикләнүләр, заман кысалары, базар исәп-хисапларыннан өстен булган фидакарь фикер иясенә әйләндерде. Безнең сәнгатьтә моңарчы күрелмәгән, мәгънәсе тапталмаган чор проблемалары хакында нәбиләрчә күрәзәлек иткән хикмәт-гыйбрәт тулы әсәрләр ижат итүгә китерде; чын мәгънәсендә халык мәнфәгатен кайгыртучы, хөр күнелле, тирән сәяси акыллы халык рәссамы итеп танытты».

Бу күркәм альбом турында жәмәгатьчелектә фикерләр күп булыр әле. Шунысы бәхәссез: талантлы шәхесләрнең әсәрләрен зур дөньяга чыгару юнәлешендә «менә ничек итеп эшләргә кирәк!» дигән мәгънәдә матур үрнәк бу.

Альбом-китапның редакторы—Татарстанның халык шагыйре **Равил Фәйзуллин.**

Индекс 73210




КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)